ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1996



# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

*Редакциябез хәзинәсендә сезнең өчен кызыклы булган байтак кына әсәрләр, язмалар бар. Менә аларның кайберләре:*

Гомәр Бәширов. «Гыйбрәт». *Роман.* Октябрь инкыйлабы нәтиҗәсендә капма-каршы рухи дөньяның бәрелеше, татар язмышы, иман югалтуның фаҗигасе хакында.

Ринат Мөхәммәдиев. «Утлы таба өстендә». ГКЧП вакыйгалары, 1993 елның 3—5 октябрь көннәре, Россия парламентын туп һәм танклар ярдәмендә куып тарату — шушы хәлләр шаһитенең документаль-публицистик язмасы.

Зәки Зәйнуллин. Повесть. Теге заман мафиозлары — ат каракları турында яңа әсәр. «Геройларның эш масштабы киң — казах җәйләүләре, Оренбур далалары, Эстәрле баш тугайлары.

Сафуан Поварисов. «Пәйгамбәр таңы». *Роман.* Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның яшьлек еллары турында.

Фәрит Яхин. «Ахырзаман пәйгамбәре». Кыйссаның II нче кисәге. Әсәрдә Мөхәммәт пәйгамбәрнең дин юлында күргән михнәтләре, көрәше, җиңү һәм җиңелүләре сурәтләнә.

Хәсән Туфан. Классик шагыйребезнең моннан 30 ел элек язылып та моңарчы басылмаган хезмәте. Мәкаләдә сүз 60 нчы еллардагы яшь шагыйрьләр иҗаты турында бара. «Нюанслар иле» дигән шигырьләр циклы анализлана. Шигърияттә «аталар һәм балалар» проблемасының үзенчә бер чагылышы.

Шәриф Хөсәенов. «Газап диңгезен эчеп...» Күренекле драматургның бөек композитор Рөстәм Яхин турында истәлек язмасы. Автор үзара иҗади хезмәттәшлек һәм Маэстро халкының кайбер сәер яклары турында яза.

Шамил Акчурин. «Урыс тегермәне дә тарта алмаган»... *Публицистик язма.* Тарихларда мәгълүм «Слово о полку Игореве» язмасының кириллица хәрефләре белән язылган төрки әсәр икәнлеге хакында тагын бер гипотеза.

Беренче төрки дәүләтнең (каханлыкның) төзелүенә 1450 (!) ел тулу уңаеннан күренекле тарихчыларыбызның гыйльми язмалары.

Тәлгать Галиуллин. «Элмәк». *Роман.* Бүгенге болгавыр заманның җинаятьчел төркемнәре арасындагы низаглар, йогынты өчен көрәшләр хакында. Бу әсәр — сезгә таныш «Тәүбә» романының дәвамы.

Шулай ук, исемнәре халыкка киң мәгълүм шагыйрьләребезнең — Г. Афзал, И. Юзиев, Р. Фәйзуллин, Роб. Әхмәтҗанов, Р. Харис, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт һ. б. әсәрләре дә журналны бизәячәкләр.

Журналның индексы — 73210.
1996 елның икенче яртыеллыгына язылу бәясе — 13 мең 200 сум.

УКЫГЫЗ, ЯЗЫЛЫГЫЗ!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**5**

**(883)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Утлы таба өстендә. *Роман* ..... 3
Ф. ГАБДРӘХИМ. Ватандар хис. *Шигырьләр* ..... 65
Ә. ГАЛИЕВ. Җимерелгән хыяллар. *Роман* 71
К. ЛАТЫЙП. Сурәтле сүзләр. *Шигырьләр* 120
Н. МӘДИЯРОВ. Тынды җилләр. *Шигырьләр* ..... 123
Җ. РӘХИМОВ. Әҗәл вагонында. *Хикәя* .. 126

ГАМИЛ АФЗАЛГА 75 ЯШЬ

Г. АФЗАЛ. Ян, йолдызым, ян... *Шигырьләр* ..... 57

ПУБЛИЦИСТИКА

И. САЛАХОВ. Хәсрәт төенчекләре ..... 140

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ШАБАЕВ. Сандугач язмышлы шагыйрь ..... 150

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Б. СОЛТАНБӘК. Тапталмас исем ..... 159
С. МАЛЫШЕВА. Фуад Туктаров ..... 165

ФАТИХ УРМАНЧЕГА 60 ЯШЬ

Ф. УРМАНЧЕ. Чыңгыз хан һәм аның эпик биографиясе ..... 171

ӨЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК

Т. НӘҖМИЕВ. Мәзәк хәлләр ..... 182

Укучы сүзе ..... 186
«Казан утлары» архивыннан ..... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары —
49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

**«Проза и поэзия»**: начало романа Р. МУХАМАДИЕВА **«Горячие дни октября 1993 года»**; продолжение романа А. ГАЛИЕВА **«Разрушенные мечты»**; рассказ Дж. РАХИМОВА **«В вагоне смерти»**; стихи Г. АФЗАЛА, Ф. ГАБДРАХИМА, К. ЛАТЫЙПА, Н. МАДЪЯРОВА.
**«Публицистика»**: статья И. САЛАХОВА **«Горемыки»**.
**«Литературная критика»**: статья М. ШАБАЕВА посвящена творчеству поэта Зульфата.
**«Выдающиеся личности»**: статьи Б. СУЛТАНБЕКОВА **«Незапятнанное имя»** и С. МАЛЫШЕВОЙ **«Фуад Туктаров»**.
**«К 60-летию Фатих Урманче**: «статья Ф. УРМАНЧЕ **«Чингиз хан и его эпическая биография»**.
**Забавные истории** Т. НАЗМИЕВА.
**Дневник общественно-культурной жизни.**
**На наших обложках**: «Казан. Середина XVI века» — **фоторепродукция из картины художника Р. Загидуллина; известный поэт Шамил Маннапов.**

## IN OUR ISSUE

**«Prose and Poetry»**: the beginning of R. Mukhamadiev's novel **«Hot October Days of 1993»**, the sequel of A. Galiev's novel **«Destroied Dreams»**; J. Rakhimov's story **«In Death Carriage»**; the verses of G. Aphzal, Ph. Gabdrakhim, K. Latyip, N. Nadyarov.
**«Publicism»**; I. Salakhov's article **«Poor Greatures»**.
**«Literary Critique»**: M. Shabaev's article devoted to the creative-work of Zulphat.
**«Eminent Persons»**: B. Sultanbekov's article **«Stainless Name»**; S. Malysheva's article **«Phuat Tuktarov»**.
**«Commemorating to the 60th Anniversary of Phatykh Urmanche»**: Ph. Urmanche's article **«Chingiz Khan and His Epic Biography»**.
T. Nazmiev's funny stories.
**The diary of social and cultural life.**
**In our covers**: R. Zagidullin's picture reproduction **«Panorama of Kazan»**; well-known poet Gamil Aphzal.

● **Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.**

● **Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**

● **Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 6.04.96 ел. Басарга кул куелды 6.05.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учети.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 349. Заказ Е-187.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.



**Ринат Мөхәммәдиев**

# УТЛЫ ТАБА ӨСТЕНДӘ

(БАШТАН КИЧКӘН ФАҖИГА)[1]

## I

Беренче съезд барган көннәрдән бер хатирә күңелгә уелып калган. Көннәрнең берендә мине Түбән Камадан сайланган Наил Махиянов эзләп тапты. Иң яшь депутатларның берсе иде ул, өйләнмәгән егет. Әмма әзерлеге, кыю, үз фикере булган мөстәкыйль кеше. Кызганыч, Татарстан Дәүләт Советына сайлауларда «кистеләр» үзен, ирек бирмәделәр. Сәләтле һәм мөстәкыйль егетләргә ихтыяҗ юк бездә ни өчендер...

— Ринат абый,— ди бу миңа, саф татарчалатып.— Сезнең ярдәм кирәк бит. Спасс капкасы янында мөфти Тәлгать Таҗетдинов тора. Үзе генә түгел, ярдәмчеләре белән. Кремльгә кертмиләр аларны. Ә аның Борис Николаевич белән очрашып сөйләшәсе килә. Бик тә мөһим мәсьәлә, ди...

Кремль комендантыннан рөхсәт кәгазьләре алдык. Мөфти һәм аның ярдәмчеләре өстендә Диния назариятенең махсус эмблемалары төшерелгән яшел чапан, башларында затлы чалма-бүрекләр. Капкадан тикшереп үткәрүчеләр булсын, Кремльнең Зур сараена кергәндә булсын, аларга шактый гаҗәпләнеп һәм, күрәсең, шикләнеп тә карадылар. Яшерен-батырын түгел, үземнең дә Тәлгать Таҗетдинны әлеге киемдә тәү кабат күрүем. Алар үтеп киткәндә һәркемнең гаҗәпсенеп күзәтеп калуы күңелдә яшерен бер горурлык хисе дә уятты әле хәтта... Күрсеннәр, танысыннар — безнекеләр уза ич. Затлы төсләр, зәвыклы киемнәр. Ул буй, төс-кыяфәт дисеңме. Бирсә-бирә бит ул Аллаһы Тәгалә...

Киң мәрмәр баскычлар буйлап икенче катка күтәрелдек, патшалар тантана иткән алтын сарай заллары аша уздык. Әллә ничәшәр Георгий тәреләре тагылган җансыз сыннар торып калды. Ә без бер ташкын, яшел җил сыман дип әйтимме, әллә яшел дулкынны хәтерләтәпме, алга узабыз. Уңга-сулга карау юк. Кая инде ул, ияклар югары, сакал үрә тора, борыннар төз, карашлар алга, бары тик алга төбәлгән. Ян-якка сибелеп юл ачалар безгә. Мөфтинең кодрәте чиксез.

[1] Әсәр кыскартып басыла. *(Автор)*.

Үтеп барышлый, борын астыннан гына мөфти Тәлгать Таҗетдиннан сорап куям:

— Йомыш бик җитди идемени соң? Ельцинны тотып булырмы икән, дим. Бик тә ыгы-зыгылы көннәре бит.

— Йомыш җитди. Ельцин үзе кирәк. Һәм кичекмәстән,— диде мөфти.

Без тоташ бәллүр һәм көзгеләрдән генә гыйбарәт, Кремль сараеның да йөзек кашы булып торган, Екатерина исемен йөрткән залга килеп кердек. Залның нәкъ уртасында торган яшел өстәлнең түрендәге затлы кәнәфигә килеп утырды мөфти.

— Көтәм,— диде һәм сәгатькә карап куйды.

Аның үз-үзен шул дәрәҗәдә горур, иркен тотуы таң калдырды мине. Шушы сарай һәм заллар буенча инде ун-унбиш көн йөрибез югыйсә, ә тартыну һәм мокытлыктан котыла алган юк. Күпме генә үзләштем дисәң дә, юк-юк та баш иелә, гел уйламаган бер җирдә тез чүгеп куя.

Съездда тәнәфес вакыты иде. Дөресрәге, ул инде тәмамланып килә. Ельцинны Президиум бүлмәсенә узган, диделәр.

Кердем. Әмма янына якын килерлек түгел. Яраннары һәм ярарга тырышып йөрүчеләр урап алган үзен. Югыйсә, теләсә кемне уздырмыйлар монда, журналистларга да юл ябык.

Ельцинның якыннарыннан Виктор Илюшин янына килдем. Йомышымны сөйләдем. Башын гына чайкады.

— Үзең уйлап кара. Ике-өч минуттан съезд дәвам итәчәк. Хәл итәсе мәсьәләләр муеннан. Ул аерыла алмый хәзер.

Үзем дә шулайрак уйлыйм уйлавын. Өмет юк. Әмма мөфти бик тә кызу тота бит анда. Аңарга ничек аңлатырмын. Башымны калкытып, Ельцинга таба текәлдем шунда.

Сөйләшеп торган җиреннән, үзен уратып алган кешеләрнең башлары өстеннән ул да, ничектер, мин басып торган тарафка карап куйды. Очраклы рәвештә карашларыбыз кисеште. Һәм, мине сәламләп, кулын күтәрде ул. Мин аңарга таба тартылып куйдым. Үзен уратып торган кешеләрне аралап, күрешергә кулын сузып, миңа таба килде Россия Югары Советы Рәисе.

— Нигә алай бер читтә басып торасың? Кәефеңне төшермә, нык бул,— диде, кулым кысып. Бу, әлеге дә баягы, сайлаулар һәм сайламау көннәре иде бит. Шуңарга киная ясавы. Ул борылып китеп барганчы дидем дә:

— Юк, Борис Николаевич, минем сезгә йомышым бар иде бит,— дип, тәвәккәлләп әйтеп салдым.

— Ни бар анда? Сөйлә,— диде ул.

— Европа һәм Себердә яшәүче бөтен мөселманнарның баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин күрешергә тели иде сезнең белән. Ул анда... Сезне көтә,— дидем, яшел залга таба ымлап.

Сәгатенә карап алды Ельцин. Вакыт юк икән бит, дигәнне аңлатып иреннәрен җыерып алды.

— Бик ашыгычмыни?..

— Ашыгыч.

«Борис Николаевич... Борис Николаевич...» дип, үзен төрле яктан тарткан, йолыккан тавышларга колак салмады ул.

— Кайда ул? Әйдә алып бар,— диде. Һәм артымнан ияреп тә китте.

Мөфти аягүрә басып сәлам бирде Ельцинга. Кара-каршы утырдылар, хәл-әхвәл белештеләр.

— Мин Сезне Россия Югары Советы Рәисе булып сайлануыгыз белән һәммә мөселманнар исеменнән тәбрик итәм,— диде Тәлгать Таҗетдин иң элек. Һәм шундук үгезне мөгезеннән алды:— Сезгә үтә мөһим үтенеч белән килдем, Борис Николаевич. СССР министрлары, ягъни бюрократлары безне гаять кыен хәлдә калдырырга җыена.

— Ни булды? Нинди ярдәм кирәк? Сөйләгез, галиҗәнап.

— Изге Кәгъбәгә хаҗ кылу нияте белән Россиянең төрле төбәкләреннән Мәскәүгә өч йөздән артык мөэмин-мөселман җыелды. Без бүген үк юлга чыгарга тиешле. Бу соңгы җитмеш елда беренче изге сәяхәтебез булачак безнең. Барысы да сөйләшенелгән, вәгъдәләр бирелгән иде. Әмма бүген «Сезгә самолет юк» диләр.

Ельцин башын күтәрде. Ярдәмчеләренә дәште.

— Гражданнар авиациясе министры Бугаевка җиткерегез. Самолетлар хәзер булсын, бер сәгатькә дә кичекмәсен.— Мөфтигә мөрәҗәгать итте ул шунда:— Ничә самолет кирәк булыр?

— Ике самолет «Ту-154»ләр.

— Ишеттегезме? Ике «Ту-154». Боерыкның үтәлүе хакында миңа бер сәгатьтән министр үзе хәбәр итсен,— мөфтигә карады Ельцин.— Бу мәсьәлә хәл ителде дип санагыз, галиҗәнап.

— Рәхмәт,— диде, үзен тыныч һәм җитди иркен хис итүендә дәвам иткән Тәлгать Таҗетдин хәзрәтләре.

— Безнең икенче мәсьәлә дә бар бит әле.

— Анысы ни?

— Безгә, олы юлга чыккан һәр мөселман башына берәр мең доллар күләмендә акча алмаштыру зарур,— диде мөфти.— Безгә «Доллар юк» дип җавап кайтаралар. Әлбәттә, без ул акчасыз да китә алабыз. Сәгуд Гарәбстаны Короле кунак итәргә әзер һәммәбезне. Бушлай кабул итәргә әзер. Әмма без ким-хур булырга теләмибез, Бөек илнең горур гражданнары буларак, үз хисабыбызга йөреп кайтуны өстен күрәбез.

— Россиянең Финанс министрын чакыртыгыз,— диде Ельцин.

Министр минут эчендә йөгерә-чаба килеп җитте. Ельцин аңарга сөйләп бирде.

— Ул кадәр доллар юк бездә,— диде Россиянең Финанс министры.— Һәм һичкайчан булганы да юк. Андый күләмдә акча алыштыру кануннар белән дә тыела.

— Мин таләп иткәнне үтәргә киңәш итәм, иптәш министр,— дип, тавышын күтәрә төште Ельцин.

— Үти алмыйм, Борис Николаевич, валюта эшләре белән СССР министры гына идарә итә.

— Соң, алай булгач, бар, кит. Нигә монда министр исәбендә торасың? Нефть Россиянеке, Татарстанныкы, Башкортстанныкы... Ә доллар юк, имеш... Бу министрның урынбасары бармы? Булса, килсен,— диде Ельцин, сөзәргә җыенган үгез сыман гайрәтләнеп.

Финанс министрының урынбасарын эзләп йөгерделәр.

Ә министр янәшәдә тора. Уйлана...

— Борис Николаевич, бәлки мин сезнең исемнән сөйләшеп карармын. Иптәш Павловка мөрәҗәгать итәрмен,— дип, юлын ук эзләргә керешә ул.

— Сез кем?— диде аңар Ельцин, тыңларга, сөйләшергә җыенмавын аңлатып.— Сез — министр түгел! Мин сезне белмим. Бар, китегез...

Коелып төште һәм китеп барды теге. Әле генә министр иде. Инде эшсез бер шәүләгә әверелеп калды. Һичкем иярмәде үзенә, кызганмадылар да, юатырга тырышучы да булмады.

Кемгә кирәк ул министр булмагач. Ул арада тирләп-пешеп министр урынбасары йөгереп килеп керде. Боерык аңарга бирелде. Сорауны аңладымы-юкмы, «Әйе», һәм «Ярар»дан башканы әйтмәде.

— «Ярар, Борис Николаевич...» «Әйе, Борис Николаевич...»

Бусы инде, һичшиксез, министр булачак. Бу — министр булу өчен туган... һәм озак көттермәде — министр итеп билгеләделәр үзен.

Мәсьәлә шулай итеп хәл дә ителде.

Мөфти Тәлгать Таҗетдин җитәкчелегендә ике «Ту-154» самолеты, билгеләнгән вакытта Гарәбстан тарафларына «Шереметьево-2» һава аланыннан күтәрелеп юл тотты. Доллар да табылган иде... Ул заманнар өчен кеше башына мең долларның ни булуын хәзер аңлату да җиңел түгел. Бик зур акча иде ул.

Ә Россия халык депутатлары съездында игълан ителгән тәнәфес ул чакта төгәл унбиш минутка озынгарак сузылды. Моны күпләр абайламый да калды бугай. Дөнья кадәр эш эшләнде.

* * *

1990 ел дәвам итте. Июнь башлары иде булса кирәк. Көннәрнең берендә Борис Ельцинның ярдәмчесе Виктор Илюшин мине янына чакырып алды.

— Ринат Сафиевич, Борис Николаевич якын араларда Татарстанга барырга җыена. Шул сәяхәтнең маршруты һәм очрашулар графигын хәстәрләшсәң иде,— диде.

— Ярар, уйланырмын. Күпме вакыт бирәсез соң?

— Хәзер үк утырабыз да эшкә керешәбез,— диде Илюшин, үзенә хас сабыр итагатьлек белән.

— Соң, бераз уйланырга, фикер йөртергә кирәктер бит,— дидем.

— Сәяхәт ике көн, күп дигәндә өч көн дәвам итәчәк. Казаннан соң Уфага, Башкортстанга бару күздә тотыла.

Шунда «Нигә әле мин төзергә тиеш икән ул маршрутны» дигән уй килде күңелгә. «Татарстан өлкә комитеты бар ич. Аның җитәкчеләре һәм зур аппараты». Табигый ки, сорау бирдем.

— Өлкә комитеты белән сөйләшкәнсездер ич? Аларның тәҗрибә зур инде...

Илюшин маңгай астыннан текәлеп карап куйды үземә. Акыллы һәм хәйләкәр караш иде бу.

— Өлкә комитеты Кремльгә карап фикер йөртә... Горбачевка карап. Ә без артык шау-шу кузгатып тормый гына килеп төшәргә уйлыйбыз... Хәбәр итәрбез, әлбәттә. Иптәш Горбачев белән дә, принципта, килешенелгән.

— Республика җитәкчелеге белгәч, миңа эш калмаган инде...

— Әйдә әле, утыр,— диде, вакытның заяга узуына эче пошкан Илюшин.— Өстәлдә Татарстан картасы. Күрсәт...

Утырдым. Һәм иренеп кенә фикер йөртергә керештем.

— Татарстаннан соң Башкортстанга китәсе булгач, минемчә, Казан-Чаллы-Әлмәт маршруты белән хәрәкәтләнергә туры киләчәк. Әлмәт Башкортстанга терәлеп үк диярлек тора. Ике көндә бөтен Татарстанны аркылы үтәчәксез.

— Юк,— диде Илюшин.— Син гадәткә кергәнчә фикер йөртәсең. Киресенчә итсәк, иң элек, нефтьчеләр, автомобиль төзүчеләр һәм игенчеләр белән очрашып, шуннан соң гына Казанга килеп керсәк ничек булыр?

— Алай итсәгез дә дөрес булыр... Болай итсәгез дә...

— Ниндидер оригиналь очрашулар кирәк иде. Киңәш ит әле,— дип, ирен читен тешләп көтәргә керeште Илюшин.

— Әйтик, гап-гади бер татар авылына кереп, гади генә бер өйдә көндезге ашка тукталсагыз...

— Тәк-тәк-тәк,— дип, такмаклап алды һәм кәгазьгә төртеп куйды Илюшин.— Тагы... тагы дәвам итик әле. Кайсы тирәләрдә булыр икән ул татар авылы?

— Мисал өчен, Мамадыш районында.

— Ул район нәрсәсе белән игътибарга лаек?..

— Барыннан да элек, ул минем туган ягым.

— Монысы әйбәт!— дип кеткелдәп алды әңгәмәдәшем.— Тагы ни әйтерсең?

— Гади бер авыл районы. Мәскәүдән түрәләр килгән район түгел. Халкы әйбәт, бозылмаган. Беренче җитәкчесе дә яшь кеше. Борис Николаевич кебегрәк озын, таза...

— Монысы булды,— диде Илюшин кулын сыпырып. Күрәмсең, ул шул рәвешле кешене фикерләү дәртенә тартып кертә.— Казанданиләр майтарырбыз?

— Партия өлкә комитетында очрашырсыз инде... Югары Советта...

— Юк, юк, Аллам сакласын. Оригиналь очрашулар кирәк.

— Иҗат интеллигенциясе һәм язучылар белән очрашырга була. Язучыларга хөрмәт аеруча зур ул бездә...

— Кайда?

— Бер зур театрда очрашу мөмкин... Ә инде Ельцин Язучылар берлегенең үзенә килеп очраша алса, бусы мәңге онытылмаслык бер вакыйга булыр иде. 160 урынлык клубыбыз да бар.

— Монысы да әйбәт булыр,— дип, уч төпләрен янә бер-берсенә уып куйды Илюшин.

— Казан дәүләт университетында булып, студентлар һәм гыйльми интеллигенция белән очрашу матур тәэсир калдырырга мөмкин.

— Монысы да әйбәт булыр.

— Гомумән, Казан университетында булмый торып, бер рус кешесенең дә бөеклеккә ирешкәне юк, диләр,— дип, шаярткан булдым.— Ленинны алыйкмы, Толстойны...

— Син дә шунда укыдыңмы әллә?— дип, шаяруны күтәреп алды Илюшин. Миңа университетта укыган даһиларны эзләп азапланыр урын калдырмады.

* * *

...Борис Ельцин һәм Минтимер Шәймиев утырган вертолет Мамадыш шәһәреннән җиде-сигез чакрым ераклыктагы клевер басуына шактый кичегеп килеп төште. Әлмәт һәм Чаллы якларындагы сәяхәтне мин күрмәдем. Озатып йөрүчеләр һәм каршы алучылар артык күп түгел, санаулы гына иде.

Мамадыш районының беренче секретаре Фатыйх Сибагатуллин белән янәшә басып каршы алдык кунакларны. Һәм, озак тоткарланмыйча, Берсут җәнлек совхозының «Тойота» микроавтобусына утырып, район буйлап сәяхәткә чыктык.

Машинаның кемнеке булуын тәфсилләвем шуңа, ул заманда районда берданбер чит ил маркалы машина иде әле ул. Хәзер генә ул түрәләрнең эшендә дә, бакчасында да «иномаркалар» тезелешеп тора. Хезмәт хакы түләргә һәм шифаханәләргә аспирин, анальгин кайтарырга акча юк дип тормыйлар. Түрәләрнең арты йомшакны ярата торган була ул...

Ельцинның егет чаклары иде әле. Алдан-арттан ияреп йөри торган ГАИ машиналарын да ияртмәделәр кебек. Һәрхәлдә, мин хәтерләмим. Юл хәрәкәтен дә япмадылар.

Үз гомерендә район җитәкчесен түгел, совхоз директорын да йөртмәгән шофер Шәмсетдин Нәҗмиевкә ишелеп төште бүген бәхет. Ельцин һәм Шәймиевне утыртып бара бит әнә. Ул гынамы, бер-ике мәртәбә, үз итеп, Ельцин аның җилкәсенә үзенең кирәк кадәр кулын да салып куйды хәтта.

— Хәлләр ничек?— дип, сорады башта.

— Хорошо,— диде Шәмсетдин.

— Исемең ничек?

— Хорошо,— диде Шәмсетдин. Сорауны ишетеп бетермәде. Күзләре һәм бөтен игътибары юлда иң. Без көлешеп алгач кына, сорауның асылын аңлап, Шәмсетдин,— дип, төзәтмә кертте.

— Яшәүләр ничек? Хезмәт хаклары...

Анысы да «хорошо» икән Шәмсетдиннең.

Юл читендә машинаны туктатып, бодай суктырган комбайннар янына да кереп чыкты кунак. Бер-ике комбайнчы егетнең аркасыннан какты һәм янәшә басып фотога төштеләр.

Түбән Сон авылында төшке ашка тукталды Борис Ельцин. Олы юлдан бер чакрымнар гына читтә утырган гади бер татар авылы ул. Кешеләре дә тыйнак һәм гадиләр. Ельцинны күрергә дип бөтен авыл чыккан иде урамга. Программада каралмаса да, машинадан чыгып юл читләп ике яктан тезелешкән апаларга, агайларга һәм борыннарын шырык-шырык тарткан малайларга кул биреп барды ул. Кыска җиңле ак күлмәктән, изүләрен өч сәдәпкә ачкан Ельцинны җылы кабул итте авыл халкы. Илдә гаять популяр чагы, егет чагы иде әле бу аның.

Олы урамнан сулга кереп киткәч, ямь-яшел бәбкә үләннәре үскән тыкрыктан бардык бераз. Гади бер ишегалдына алып керделәр. Торбасыннан төтен чыга, мунча ягылган. Сарай капкасы ачык, анда кетәклектән әле генә йомырка салып төшкән чуар тавык тантана итә. Алтын йомырка салган диярсең, Россия Югары Советы Рәисе килгән чакта бераз тыйнаклык күрсәткәндә дә ярар иде бит. Абау, әтәчләре дә бик сабырсыз икән, кунак дип тормый, кеше дип тормый, шундук тып-тып басып теге тавык янына килеп җитте. Хәер, болары махсус оештырылмагандыр инде...

Ишегалды уртасында яңа чабылган клевер чәчәкләре түшәлгән ат арбасы тора. Шул арбаның үрәчәсенә ат бәйләп куелган. Гомер күрмәгәндәй, йотлыгып клевер ашый ат. Ельцин булып, ул да беркавым арба өстендәге чәчәкләрнең хуш исенә хәйран калып басып торды. Ә Минтимер Шәймиев ат янына барып, аның яңакларыннан, муен һәм ялларыннан сыйпап сөйде.

Фатыйх Сибагатуллин өйгә, өстәл янына чакырды кунакларны. Аш өстәле ике җирдә хәстәрләнгән иде. Түр яктагы өстәлгә Ельцин, Шәймиев, район хуҗасы Сибагатуллин һәм, якташ буларак, мин чакырылдым. Токмачлы аш китерделәр иң элек. Аннан бәлеш чыкты. Колхоз рәисе Госман Бәдретдинов аягүрә йөреп кыстап торды. Телгә кеше кесәсенә керә торган түгел, җор егет. Булганлыгы җитеп ашкан. Кукмарада гына туып-үсә диләр андый егетләрне...

Ашап-эчкәч тә Минтимер агай сәгатенә карап куйды: «Казанга кайтасы бар, соңга калабыз»,— дип әйтүе иде. Без дәррәү торырга керештек. Фатыйх Сибагатуллин торып чыгып китте. Минтимер Шәймиев... Һәм Госман Бәдретдинов та кыстаудан туктап, ишегалдына юнәлде.

Мин дә сикереп торган идем, әлбәттә. Кузгалып китәргә өлгерә алмый калдым. Кырык бишле ботинка белән өстәл астыннан аякка китереп бастылар. Ә өстәл артында Ельцин белән мин генә утырып калган идек.

— Ә син утыр,— диде ул, дустанә дорфалык белән, шаярган атлы булып. Һәм як-ягына борылып эзләнергә кереште. Госманны эзләве икән.

— Кая ул, теге кара чәчле «шустрый татарин?» Ул да качтымы әллә?..

— Китәргә кирәк диләр бит, Борис Николаевич. Миңа да үземә генә калып утыру уңайсыз...

— Ә мин кем?!. Синең җитәкчең түгелмени. Утыр әйдә, кыбырсынма. Тагы кайчан шулай утырырбыз әле.

Ул арада, Ельцин башын бора-бора хуҗалардан бер-бер кеше күренмәсме дип эзләнгәндә, йортның хуҗасы күренде аралыктан. Җыйнак кына гәүдәле, тыйнак кеше.

— Син бу өйнең хуҗасы бит?— дип, дәшеп алды аны Ельцин.

— Әйе, хуҗасы.

— Ә нигә соң аны мин сизмим?.. Саранлыктан түгелдер бит. Кая, китереп утырт берне. Һәм үзең дә утыр. Дөньяны өч борынга көйләп алыйк бераз.

Хуҗа кеше җәт кенә аралыкка барып килде. Өстәлгә өч чирекле «Мамадыш егете» — «Золотое кольцо» китереп утыртты. Мәҗбүр итеп диярлек, үзе янына хуҗаны да утыртты Ельцин. Һәм шул мәлдә бер-бер

нәрсә кирәк түгелме икән дип йөгереп килеп җиткән хуҗабикәгә мөрәҗәгать итте.

— Апа,— диде, авызын тутырып. Һәм кулы белән ишарәләп күрсәтте.— Теге зур, түгәрәк әйбер тагы юкмы?.. Бигрәк тәмле булган.

Тиз аңлады хуҗабикә. Һәм җәт кенә йөгереп кереп китте дә, ялт итеп килеп тә чыкты. Пар бөркеп торган яңа бәлеш өстәл өстенә килеп утырды. Кыстый-кыстый алдыбызга кисеп салды бәлешне. Бер читтә эшсез торган өч кырлы стаканга олы кунак тум-тутырып салды. Күпме карышып та каршы тора алмагач, буйсынырга мәҗбүр булдык.

— Нәрсә анда, бармак башы кадәр рюмкалар белән эчеп утыру,— дип сукраныш алды ул, моңа кадәр булган рәсмилекне ошатмыйча.— Әйдә, әйдә, үзебезчә, мужикларча булсын. Тамчысы да калмасын.

Үзе дә егет икән, кыстатып тормады. Калганын тигезләп бүлергә кереште. Хәйран калдым, төгәл тигез чыкты.

Дөнья түгәрәкләнде. Шулай бер утыруга ни җиткән. Тартыну, уңайсызлану тойгысы да юкка чыкты. Урыным ишегалдына чыккан тәрәзәгә каршы булуы гына алама иде. Биш минуттан биш минутка ашыктырып кул изиләр, чакыралар. Фатыйх Сибагатуллин ике потлы гер кадәрле йодрыкларын да болгый-болгый аңлатып карады инде.

Мин аңлыйм да бит. Олы кунакка аңлатып кара син. Яисә йодрыкларыңны да аңарга күрсәт...

— Калмасын, әйдә... Бу бәлеш астына тагы берәү сыя әле, шулай бит,— дип, хуҗаның иңбашларын кагып-кагып алды Ельцин.

«Ходаем», дип уйлыйм эчтән генә. Дөрес сөйлиме бу, юкмы — тәмам хур итә, башны бетерә икән бит... Алла рәхмәте, кыстамады башка... Өйне яңгыратып бер көлде дә урыныннан торды олы кунак.

— Бик зур рәхмәт сезгә,— диде. Хуҗабикәгә дәште аннан:— Апа, миңа бик охшады бу «балиш». Тагын бер килә калсам, пешерерсезме?..

— Пешерермен, пешерермен, Бурис Никулаевич,— диде хуҗабикә һәм яулык читен тарта төшеп, кече якка чыгып китте.

Урам тагы да матурайган кебек иде. Күпме генә ашыктырмасыннар, бер-ике урында машинаны туктатып Түбән Сонлыларны тагы бер мәртәбә сәламләргә төште Ельцин. Көләч иде ул, үзенә булган игътибардан гаять бәхетле дә иде. Әмма егет тә булып калды, сынатмады. Чайкалмады...

* * *

Язучылар берлеге урнашкан бина каршысына халык диңгез кебек җыелган иде. Комлев урамы шыплап тулган. Урам аша үтеп йөрү кая, аркылы чыгарлык түгел. Ельцин белән күрешергә килгәннәр. Иске заманны сүгеп, киләчәккә таулар вәгъдә иткән, бик популяр чагы...

Язучыларның Тукай исемендәге клубы да шыгрым тулы инде күптән. Тәрәзәләре киереп ачылган. Идәндә генә түгел, тәрәзә төпләрендә дә юк буш урын. Кинокамера аскан журналистлар гына да уннан артык иде, ачуым бер килмәгәе.

Зал зур түгел, шуңа анда язучылар һәм беркадәр журналистлар, галимнәр генә кертелде. Сәхнә исә тагы да кечкенәрәк. Анда Ельцин, Шәймиев, Сабиров һәм ул вакытта Казан шәһәр комитетының беренче секретаре булып эшләгән Зерцалов утырды. Ельцинның уң тарафында оештыручы һәм алып баручы буларак мин утырдым. Ә арка тарафта Виктор Илюшин урын алды.

Ил җитәкчесе, Россиянең булачак Президенты белән тагы кайчан шулай күзгә-күз очраша, ачыктан-ачык әңгәмә кора, сөйләшә алган булыр иде икән татар язучысы.

Сорау артыннан сорау яуды залдан. Әмирхан Еники, Роберт Батулла, Ризван Хәмид, Рашат Низамиев һәм Фәүзия Бәйрәмовалар аеруча активлык күрсәтте булса кирәк.

Ельцин да сүзгә аптырап тора торганнардан түгел. Өздереп җавап биреп барды, турыдан ярды. Аның «Суверенлыкны теләгәнегез кадәр, күпме йота аласыз, шулай алыгыз» дигән, соңрак телгә кергән тарихи сүзләре беренче мәртәбә нәкъ шул очрашуда әйтелде дә инде. Юкка гына, Ельцин киткәчтен дә ун-унбиш көннән Татарстанның суверенлыгы мәсьәләсен беренче булып күтәреп чыккан оешма Татарстан Язучылар берлеге булмагандыр.

Шаярта да белә иде Ельцин. Залдан Роберт Батулла янып, кызарып-бүртенеп сөйләгәндә аның минем колакка иелеп:

— Бу кем, Чыңгызхан түгелдер бит?— дип, сорап куюы хәтердә калган.

Батулланың чәчен кырдырып алган, биленә хәнҗәр тагып йөргән чагы. Чын-чынлап күңеленә шик кергән булып чыкты ахры.

— Бумы? Бу — Батуллахан! Бату ханның оныгы,— дип җавап бирдем мин, шаяруга шаяру белән.

Авызын колакка кадәр ерып көлде кунак.

Нәкъ шул көнне инде, татарның бөтен зыялылары каршысында Ельцинның үз башына да татарның милли түбәтәен кидердек. Шул чакта әйтелгән төче сүзләремне әле дә хәтерлим һәм уңайсызлык хисе белән хәтергә төшерәм. «Татарның бу изге түбәтәе Сезнең тәвәккәл һәм акыллы башыгызны сакласын һәм озак яшәтсен»,— дигән идем, Ельцинның башына 60 нчы үлчәүле чигүле Арча түбәтәен кидереп кулын кысканда. Минем теләк юш килә шул. Дөрес, соңыннан тар күңелле татар матбугатында килде-китте сәясәтчеләр бу түбәтәйне чүбеккә әйләндергәнче чәйнәделәр әле. «Бир безнең түбәтәйне... Түбәтәйне кайтарып бир, Ельцин»,— ди-ди әтәчләнделәр. Мәкаләләр яздылар, мәйданнарда сөйләделәр. Хәтта үзенә дә язып салганнар, диделәр... Мәгънәсезлектә чама җебен ычкындыручылар.

Бүләкне кире алмыйлар. Һәм сорамыйлар да. Бүләкне биргән кеше әйтмәде бу сүзне.

Түбәтәй чын-чынлап рух күтәренкелеге һәм тәвәккәллек өстәде кебек Борис Ельцинга. Очрашу тәмамлангач та Язучылар берлегенең коридоры буйлап чыгу юлына киттек без. Түбәтәй башта, ул аны салырга ашыкмады. Уңнан да, сулдан да тарткалыйлар, кул бирәләр, автограф сорыйлар. Әрсезрәкләр юлына аркылы ук төшеп баса. Ельцинның кәеф күтәренке, авыз колакта... Шуңадыр, ул да барына да ярарга тырыша, итагатьле итеп җавап бирә. Кем генә яратмый икән үзенә булган игътибарны.

Залда вакытта ук «авыз кибә» ди-ди утырган иде олы кунак. Ә тәкъдим ителгән «Нарзан»ны эчмәде. «Зал тулы кеше утырганда, алдыңа су китерделәр дип, эчәргә ашыкма. Анда да кибеккән, эчәсе килгән кешеләр була. Алар сиңа карап утыра. Түз, эчмә! Юкса, үзеңне залга каршы куячаксың...»— дип, гыйбрәт бирде ул миңа. Һәм президиум өстәленә чыгарылган су, стаканнарны кире алдырды.

Коридор буйлап барганда колакка пышылдап өлгерде ул:

— Кабинетта, суыткычыңда ни бар? Шампан шәрабы бармы?

— Бар. Алар зарыгып безне көтә...

Авызын киң җәеп канәгать елмайды, үз итеп күзләрен сирпеп алды олы кунак. Мин аны кулыннан ук җитәкләп бара идем инде.

Икенче катка, минем эш кабинетыма илтүче баскыч читендә тоткарландык тагы бераз. Мин бит әле республика җитәкчеләрен дә күздән ычкындырмаска тиеш. Кунак китәр, алар кала. Алга таба да яшисе бар. Юл биреп, аларны югары уздырдым...

— Мансур абый, зинһар озата бар,— дип, урынбасарым Мансур Шиһаповны да дәшеп алдым.

Ниһаять, кулын сузган җиде-сигез кешедән аерып, Ельцинны хәрәкәткә китердем. Юлның өчтән берен күтәрелдек дигәндә, Борис Ельцинның түбәтәйле башы тагы артка каерылып карамасынмы...

Киереп ачылган зур ишекләрдән урам һәм ишегалды күренеп тора. Анда алма төшәр җир юк, халык...

— Ул халык нигә җыелган?—дип, сабыйларча эчкерсезлек белән сорап куйды Ельцин.

— Сезне күрергә... Сезне каршы алырга һәм озатып калырга,— дидем.

Шул сүзләрне ишеткәч тә, әллә ни булды Ельцин белән, гүя алмаштырдылар үзен. Күзләре ялтырап китте аның, ике утлы күмер диярсең. Кош сыман урамга таба талпынып куйды.

— Ничек алай?! Димәк, алар мине көтә,—диде ул, чарасыз калган сабый сыман. Һәм мине түбәнгә тартырга кереште. Әле булса җитәкләшеп тора идек бит.—Көттермик аларны. Бер минутка гына чыгып сәламләп керик үзләрен. Алар киткәчтен, без дә иркенләп шампан эчәрбез.

Кире борылырга ярамаганлыгын белә идем. Әмма каршы тора алмадым. Ельцин, гайрәте ташып ашкан үгез кебек, мине урамга өстерәде. Баскыч төбенә чыккач та, түбәтәен кулына алып күрешергә килүчеләрне сәламләде. Берәүләр «Урра!» кычкырды, берәүләр сызгырды. Безне уратып алдылар. Һәм халык ташкыны, арттан этә башлап, иң әүвәл урам уртасына, аннан Бутлеров урамына таба этеп алып китте.

Ельцинның тән сакчылары һәм милиция дә әзер түгел иде вакыйгаларның болай китүенә. Ул үзе дә шөлли калды булса кирәк. Ташкын булып өскә килә, этә иде халык. Туктый, янсә абынып егыла калсаң, билләһи дим, таптап-сытып китәчәкләр. Бер кулына түбәтәен кысып тоткан Ельцин, икенче кулы миндә, һәлакәттән качып тиз-тиз атлап йөгерә үк башладык. Ул арада милиция хезмәткәрләре һәм нинди дер егетләр юл арчырга керештеләр, ярдәмгә өлгерделәр.

Бутлеров урамына, ягъни 2 нче трамвай тукталышына кадәр дәвам итте бу хәл. Тукталышта трамвай тора иде. Трамвайга утыру минем уйга да килмәде. Ә Ельцин, көтмәгәндә, кисәтми-нитми кузгалып китәм дигән трамвай ишегенә сикерде. Һәм кул болгарга да онытып китеп барды. Мин тукталышта калдым. Аерылдык...

## II

Ельцинның «Суверенитетны күпме теләсәгез, шулкадәр алыгыз», дигән сүзләре бәрәкәтле туфракка төште. Татарстанда, бигрәк тә татар язучылары, татар интеллигенциясе даирәсендә шундук күтәреп алдылар аның бу сүзләрен. Һәм, 1990 елның август урталарында булса кирәк, Язучылар берлеге идарәсе инициативасы белән Иҗат берлекләренең берләшкән Пленумын җыйдык. Оештыру, ул зур киңәшмәне алып бару минем җилкәгә төште. Йомгак документлар һәм резолюцияне Язучылар берлеге идарәсе әгъзаларыннан төзелгән махсус комиссия хәстәрләде.

Республика җитәкчелеге бу киңәшмәне уздыруга хәер-фатихада түгел иде. Шулай да Пленум башланып киткәч, арткы рәтләрнең берсенә тавыш-тынсыз гына ике кеше кереп утырды. Аларның берсе Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов булса, икенчесе, ялгышмасам, Өлкә комитеты секретаре Рево Идиатуллин иде кебек. Әмма алар җыелышның барышына катнашмады, ничек тавышсыз-тынсыз гына килеп кергән булсалар, кулларындагы блокнотларганиләрдер сызгалап утырдылар да, шул рәвешле үк китеп тә бардылар.

Гаять кайнар чыгышлар булды ул Пленумда. Язучылар, театр әһелләре, композиторлар, рәссамнар—һәммәсе бер дулкында сөйләделәр. Татар иҗат интеллигенциясенең шул дәрәҗәдә булдем, тәвәккәл һәм бары тик халык, ил мәнфәгатьләрен генә кайгырткан мизгелен мин башка хәтерләмим. Бу безнең, шагыйрь әйтмешли, «уянгач, беренче

көнебез» иде булса кирәк, романтик дәверебез. Тора-бара республика халкы да иярә язды бит шул дулкынга. Һәм бәйсезлек дулкынында бер-ике ел дип әйтерлек шашынып яшәдек, гүя иңнәребезгә канат үскән иде, очып йөрдек, аякларыбыз җиргә тимәде.

Пленум тәмамлангач та, без — иҗат берлеге рәисләре — Татарстан партия өлкә комитеты бинасына киттек. Һәм үзебезне Югары Совет Рәисе Минтимер Шәймиевнең кабул итүен таләп иттек.

Шәймиев очрашудан баш тартмады, безне кабул итте. Үзара сөйләшү ике сәгать ярымнан артыкка сузылды. Башлап сүз әйтү, Пленумның карарларын җиткерү һәм әңгәмәне әйдәп бару, яшерен-батырын түгел, минем өскә төште. Әмма башка рәисләрне дә кул кушырып кына утырды дип әйтү дөрес булмас. Аеруча Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллинның кайнарлыгы һәм кыюлыгы хәтергә уелып калган. Бер карагында аз сүзле, үтә сабыр булса да, республиканың беренче җитәкчесе каршында җебеп төшмәде, аяк терәп бәхәсләште Рәшит. Мин шул көннән аны фикердәш дустым итеп күрә башладым.

Театр эшлеклеләре берлеге рәисе Ринат Таҗетдинов та иң кирәкле мизгелләрдә аркадаш була белде. Кыскасы, без бер фикердә идек. Хәтта Эдуард Гущин булып, ул да безне җөпләп утырды.

Пленумда кабул ителгән төп фикер — Татарстан икенче сортлы республика булуыннан туктап, үзенең дәрәҗәсен союздаш республикалар югарылыгына күтәрергә тиеш, дигән таләп иде. Авырлык белән булса да, шактый каршылыклар аша булса да, Минтимер әфәнде Шәймиев белән без дошман булып аерылмадык кебек. Һәрхәлдә, уй-фикерләребез шул вакыт аралыгы эчендә шактый якыная төште.

30 август көнне Татарстан үзенең Дәүләт бәйсезлеге хакындагы тарихи Декларация кабул итте. Бу көнне эчендә җаны булган һәр татар, ягъни ярты Казан урамда, Ирек мәйданында иде. Хөкүмәт йортын уратып алган митингның башында иҗат интеллигенциясе. Алар — Роберт Батулла, Рәшит Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшитов һәм Вафирә Гыйззәтуллинага кушылып, «Азатлык» дип тәкърарлады берөзлексез.

Югары Совет утырышында да депутат әдипләр әйтте төп сүзне. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Разил Вәлиев, Фәүзия Бәйрәмова һәм Роберт Миңнуллиннарның кайнар чыгышлары уртак фикер белән өртелгән иде: Татарстан суверенлы дәүләт булырга тиеш! Гәрчә Татарстан халык депутаты булмасам да, миңа да сүз бирделәр. Иш өстенә куш булсын дигәннәрдер.

Сүз чыккан икән, рәислек иткән Минтимер Шәймиевнең каршылыклы чыгышларны бер-берсенә искиткеч осталык белән үреп бару сәләтен дә бәяләргә кирәк. Фикер алышуларның йомгаклау өлешендә ул язучылар һәм суверенлыкны таләп иткән милләтпәрварлар Фәндәс Сафиуллин, Рүзәл Йосыпов, Азат Зиятдинов, Дамир Сираҗиев, Марат Мөлековларның чыгышларын шулкадәр сәяси зирәклек илә чиратлаштырды ки, каршы торучыларның тавышы гел йомылып, югалып калды. Бу — югары бәягә лаек хезмәтне күпләр абайламый да калган булуы ихтимал.

Казанда бәйрәм. Татарстан тантана итә иде әле. Икенче көнне үк таң белән Мәскәүгә очтым мин. Россия Югары Советының гадәттән тыш утырышында көн тәртибенә «Татарстан мәсьәләсен» өстерәп керттеләр. Тетмәсен тетәләр республиканың. Казанда калып бәйрәм итеп кенә ятасы калган да бит...

— Татарстан җитәкчеләрен — Шәймиев һәм Сабировны хәзер үк монда чакыртырга кирәк,— дигән тәкъдим кертте берәү. Ялгышмыйм кебек, бу тәкъдимне мордва егете, Саранск шәһәреннән сайланган депутат Николай Медведев күтәрде иң элек.

— Ә килмәсәләр, нишләрсез. Алар бәйсез бит хәзер,— дип кычкырды икенчесе.

— Килмәсәләр, китерербез. Мәҗбүр итәрбез,— дип әтәчләнде өченче бер депутат, урыныннан сикереп торып. Бусы да үзебезнең күрше —

чуваш егете, Валерий Шуйков иде. Әнә шундый ул безнең кардәш милләтләрнең дан-дәрәҗәгә омтылган вәкилләре. Шактый тирәнгә кереп башлады болар. Китте, кузгалды... Туктатам димә.

Урынымнан сикереп торып микрофонга барып ябыштым:

— Туктатыгыз, җәмәгать. Мин әле бүген генә Казаннан килдем. Анда иминлек. Бәйрәм рухы. Россиянең суверенлыгын игълан иткәндә, мин сезне яклап тавыш бирдем. Һәммәгез белән бергә куандым, аягүрә торып кул чаптым. «Русларны куарга, русларны суярга җыеналар...»— дигән уйдырмалар сөйләүчеләрнең теле корысын. Татарстанда бүген, Аллага шөкер, иминлек. Киләчәктә дә шулай булыр.

— Әнә, ишеттегезме, ни сөйли,— дип, микрофонга Виктор Скрынник чәчрәп чыкты. Ул Татарстаннан, Чаллыдан, шул исәптән, минем туган як — Мамадыш тарафларыннан сайланган депутат.— Кичә, Татарстан Югары Советында, сепаратизмны яклап аеруча кайнар чыгыш ясаган кешеләрнең берсе әнә шул Мөхәммәдиев инде. Милли хәрәкәтнең яшертен идеологларыннан берсе ул. Ә ул монда комитет җитәкчесе һәм Югары Совет Президиумы әгъзасы. Мин Мөхәммәдиевне бүген үк бу эшләреннән азат итәргә кирәк дигән тәкъдим кертәм.

«Их, Виктор,— дип уйлап куйдым күңелемнән.— Шул эшне эшләсәгез, мин иртәгәсен үк Казанга күкрәк киереп кайтып төшәр идем. Анда да теңкәмә тиделәр бит инде. «Син, Рәсәй депутаты, нигә анда ятасың, кайт»,— дип тинтерәтеп бетерә яздылар. Алар дигәнчә, сез дигәнчә генә булсын иде дә бит ул. Түгел шул...»

Скрынник хакында сүз чыккан икән, тагы бер нәрсәгә игътибар юнәлтми булдыра алмыйм. Хатыны — татар аның. Берсеннән-берсе матур ике кыз үстерәләр. Ә менә шул кеше «Татарстан» һәм «татар» дигән сүз ишетсә, күркә сыман кабарынып чыга. Яратмый татарны.

Аңламыйм, нигә шулай?! Татар үзе кемгә чыкса, кемгә өйләнсә, дөньясын оныта, хөрмәт итә. Әмма үзенекен хөрмәт иттерә, яраттыра белми. Нигә бу шулай?

Казанда «Без — багымсыз. Без — мөстәкыйль. Россия — чит бер дәүләт» дип сөйләшү модага кереп китте тора-бара. Хәтта кайбер газеталар «Иностранная Российская Федерация» дип үк язып җибәрәләр. Мәскәүдә исә ачыктан-ачык Татарстан һәм татарлардан дошман образы ясау гадәткә кереп бара. Мин ике ут арасында торып калдым.

Казандагы вакыйгалардан да читтә каласым килми. Мәскәүдә дә даими рәвештә булырга мәҗбүрмен.

1991 елның башлары иде булса кирәк. Россия Югары Советы һәм Министрлар Кабинеты Президиумының берләштерелгән ябык утырышы булды. Аны Руслан Хасбулатов ачып җибәрде. Әмма төп сүзне әйтүче Бурбулис иде. «Татарстанда һәм Чечен Республикасында гадәттән тыш хәл кертү зарурлыгын» таләп итте ул. Яклаучылары да байтак иде. Сөйләргә, «сепаратистлар»ның тетмәсен тетәргә әзер торучылар берсе артыннан икенчесе сикереп чыкты.

Ни хикмәт, кулымның күтәрелүе булды, Хасбулатов миңа шундук сүз дә бирде. Әлбәттә, каршы чыктым. «Милли республикаларга каршы көч куллану демократик Россия тарихында иң ямьсез һәм кара сәхифә булачак»,— дип тә искәрттем булса кирәк. Миннән соң ук якут-саха кызы Зоя Корнилова чираттагы мәртәбә үзенең чын егет икәнлеген исбат итте. Бу җыелышта күтәрелгән мәсьәләне «куркыныч һәм кара авантюра» дип бәяләде. Коми егете Николай Ген, мәскәүле Сергей Ковалев һәм тагы берничә кеше нярде үзебезгә. Нәтиҗәдә, милли сәясәтне бутау-чуалту буенча төп белгечләр саналган Абдулатыйпов һәм Шахрай да бераз сагая төштеләр. «Гадәттән тыш хәл кертү» турындагы мәсьәлә узмады. Бу — беренче һәм зур җиңүебез иде. Шулай итеп, Татарстанга һәм Чечен Республикасына танк колонналары кертелми, кан түгелми калды.

Ә Казанда исә бу хакта, гүя, белмәделәр, ишетмәделәр дә. Митинг артыннан митинг үтә торды. Гадәттән тыш Президиумның икенче

көнендә үк, чираттагы мәртәбә, Казанга кайтып төштем. Ирек мәйданына чыктым. Консерваториянең концертлар залы каршысында милли хәрәкәт, ягъни Бәйрәмова, Мөлеков һәм Зәйнуллиннар митинг уздыра. Мәскәүдә мине әнә шуларның фикердәше, идеологлары дип санаучылар күбәйде. Гәрчә, һич кенә дә алай түгел. Һичкемгә һичбервакыт үз фикеремне көчләп тākканым, кемнендер оскыртучысы, идеологы булганым юк. Ә бу кешеләрне исә, Аллам сакласын, мин һичкайчан татар халкының лидерлары буларак кабул итә алмадым.

Минем мәйданга килеп керүем булды, Зәки Зәйнуллин сүз алды. Үз вакытында беренче әсәрләрен «Казан утлары»на соратып алучы һәм редакцияләп бирүче идем мин. Ерактан ук күреп алды ул мине һәм «сәламләргә» кирәк тапты. «Милләтнең һәр заман үз ялагайлары, Мәскәү алдында куштаннары булган. Әнә, Рәсәй депутаты Ринат Мөхәммәдиев шундый түгелмени?! Ни калган аңарга Мәскәүдә?!» Китте бу, китте... Аның шул беренче сүзләрен ишетүгә үк бугазыма төер килеп тыгылды. Колак ишетмәс, күзләрем күрмәс булды. Зәки сөйли, Зәки дәвам итә. Мәйдан аны тыңлый, дәррәү кул чаба. «Позор!... Позор!»— дип кычкыра мәйдан. Кемнәрдер бармак төртеп-төртеп күрсәтә үземә. Икенче берәүләре кул биреп исәнләшә, түземле булырга киңәш итә. Әмма карашлары сынаулы, «бу ни рәвешле кичерә» дип сынаучылары да булгандыр арада. Ә мин аларның берсен дә күрмим һәм танымыйм инде. Бөтен көчем бугазга килеп тыгылган, күзләремә тулып мөлдерәгән кайнар ташкынга каршы тору, ирек бирмәү, сынатмау...

Ул да түгел, бөтен мәйдан «Азатлык!.. Азатлык!..» дип кычкырырга кереште. Мин дә кушылмак иттем аларга, әмма тавышым чыкмады. Гарьлектәнме, әллә бәхеттәнме — күзләремнән кайнар тамчы бәреп чыкты. Бер читкә борылып борыным сөрткән булдым.

Кай арада тагы үземне өч-дүрт татар хатын-кызы — апалар һәм әбиләр уратып алган. «Оятсыз син, оятсыз... Җирбит. Язучы башың белән үз милләтеңне сатып йөрергә...»— дип, сукранды, сүгәргә кереште болар. Берсен-берсе уздырышып тетмәне тетәләр. Һәм берәве лачкылдатып йөземә үк төкереп куймасынмы.

Җавап биреп булмый. «Апалар,— дип өзгәләнеп, аңлатмакчы да булып карадым.— Мин бит Мәскәүдә дә татар язучысы, үзебезнең мөстәкыйльлек тарафдары булып калам. Чын мөстәкыйльлеккә ирешәбез икән, кайтачакмын. Анда минем бернинди эшем юк. Ашыкмагыз, түзегез бераз, кабаланмагыз...»

Юк, тыңларга теләмиләр. Ишетергә теләмиләр. Тәмам чаманы оныттылар болар.

— Ул чит илдә сиңа ни калган?

— Россия чит ил түгел бит әле, бераз сабыр булыйк,— дип чираттагы мәртәбә аңлатып карамак булам.— Татарстанның бәйсезлеге Казанда игълан ителсә дә, Мәскәү аны танымады. Дөнья танымады. Хәтта кардәшләребез, күршеләребездән дә танырга җыенучы юк. Бәйсезлек өчен көрәш хәзер Парламент ысулы белән һәм, нигездә, Мәскәүдә дәвам иттерелергә тиеш...

— Их, оятсыз... Җирбит икәнсең, Мәскәү куштаны,— дип кул селтәде берсе.

— Милләтнең каргышы төшсен, Рәсәй депутаты... Рәсәй депутаты,— дип, бер кызып алгач, тагы ике мәртәбә йөземә төкерергә итенде икенчесе.

Йөзем каплалдым. Борылып өлгердем, бу юлы инде йөземә төкертмәдем. Өченчесе, дүртенчесе йодрык белән аркамны төяргә кереште, хәтта тибенергә итенделәр. Тәмам котырына ук башлады болар. Ялгыш бер хәрәкәт ясасам, каравыл кычкырачаклар. Җавап биреп булмый шул, апалар үзебезнеке. Ак шәл ябынганнар өстәвенә... Үзләреннән котылып, икенче бер читкә китеп бару җаен таптым. Башка чарам юк иде чөнки...

Авыр булды, әлбәттә. Әмма, ни эшләмәк кирәк, чарасыз да идем мин. Көчсез дә... Һәм япа-ялгыз. Мәйдан «Азатлык» дәгъва итә әнә. Бәлки бу апалар, чыннан да, Татарстанның азатлыгы өчен Россия Федерациясе депутатларының үз эшләрен ташлап кайтуы кирәк дип уйлый торганнардыр. Ихластан шунарга ышанганнардыр. Ялгыша торганнардыр... Их, шулай булса икән ул. Шул минутта ук, артларыннан йөгереп барып, кочып алган булыр идем үзләрен. Үпкәләү кая ул, үзем гафу үтенгән булыр идем, берәм-берәм аркаларыннан сыйпап чыгар идем.

Алай түгел икән шул. Тагы биш-ун минутта әлеге «милләт апалары»ның мәйданның түрендә үзләре кебек үк ак шәлгә бөркәнгән, минем өчен бик тә таныш булган икенче бер зат янына барып, канәгать кыяфәт белән көлешә-көлешә торуларын күрмәгән булсам әгәр... Бәлки, ышанган да булыр идем...

* * *

1991 елның июль ахырында җәйге ялга җыенабыз. Тәкъдим ителгән урыннар байтак. Дәүләтнең Кавказда булсын, Кара диңгез ярында булсын санаторийлары тезелеп тора. Югары Совет Президиумы әгъзалары өчен тагы да кызыклырак вариантлар тәкъдим ителә.

Әмма минем сәясәттән, ул депутатлардан — «демократлар»дан ни дәрәҗәдә туйганлыгымны белсәгез икән. Унбиш-егерме көнгә булса да күрми торасым килә үзләрен. Озак уйлап тормадым, язучыларның Ялтадагы иҗат йортына тәвәккәлләп китеп бардым. Миндә бит әле ял кайгысы түгел, «Сират күпере» романын тәмамлыйсым бар. Ә иҗат йортларында эшләп тә, ял да итеп була иде әле ул чакларда.

Китәсе көнем килеп җиткәч, яныма Югары Совет Президиумының ул вакыттагы оештыру сәркатибе Сергей Александрович Филатов керде. Мөнәсәбәтләр дустанә, якын иде, протоколда каралмаган җылылык белән киңәш-табыш итеп утырдык. Минем дәүләт санаторийларының «люкс» номерларына тәкъдим ителгән юлламалардан баш тартуыма гаҗәпләнде ул, кире уйларга, ялгышымны төзәтергә киңәш итте.

Үз туксаным туксан иде. Эш папкасын ачты Филатов һәм үзенең сорауларына алынган җавапларны үтә мөһим бер төгәллек белән теркәп барды.

— Димәк, Ялтага китәм дисең инде, ә?

— Әйе, Ялтага.

— Кайда тукталасыз?

— Язучыларның иҗат йортында. 26 нчы бүлмәдә.

— Август урталарында анда буласызмы әле?

— Әйе, шунда булырга җыенам.

— Кемгә дә булса бер-ике көнгә кунакка китү ихтималын юкмы?

— Бик мөмкин.

— Кайда? Кайда? Миңа боларның һәммәсен белеп тору гаять мөһим.

— Әйтә алмыйм, Сергей Александрович. Бакчасарайга барып кайту уем бар. Севастопольны күргәнем юк...

— Бик күпкә китә бит бу, Ринат Сафиевич. Сезнең Югары Совет Президиумы әгъзаларының һәр көн, һәр сәгатьтә кайда булуларын белеп тору йөкләнгән миңа.

— Кем тарафыннан?

— Ельцин һәм Бурбулистан.

— Аларга мин нигә кирәк булырмын икән?

— Син генә түгел, менә кара, Президиум әгъзаларының һәммәсеннән җыйдык без андый мәгълүматларны.

— Моның кемгә кирәге булыр дип уйлыйсыз?

— Беләсең ич, Ринат, — диде Филатов, үз итеп. — Август урталарында Союз килешүенә кул кую күздә тотыла. Кем белә, төрле шартлар,

кетелмәгән вакыйгалар килеп туарга бик мөмкин. Ихтыяҗ туса, көнесәгате белән җыелырга туры киләчәк.

— Аңладым,— дидем.— Татарстанга «Союздашлык» та бирсәгез, чакырмый да кайтырмын.

Җылы гына кул кысыштык. Хушлаштык.

— Кара аны, эз югалта күрмә,— дип серле елмайды Сергей Филатов китеп барганда һәм, үз итеп, күз кысып куйды.

...Ялтада иҗат итәм. Эш муеннан. Көннәр матур, кояшлы. Көндезләрен иҗат йорты бушап кала, һәммәсе, шул исәптән, минем гаилә дә, диңгез ярына китә. Эшләп аргачтын, мин дә диңгезгә барып, бер-ике чумып кайтам.

10 август. Көндезге 2 ләрдә гаиләм белән диңгездән төшке ашка кайтып киләм. Каршыма очраган бер язучы хәбәр җиткерә:

— Сине эзлиләр...

Без урнашкан корпус каршысында түбәсенә зәңгәр ут куелган «Волга» көтеп тора иде.

— Әнә, әнә, Мөхәммәдиев кайтып килә,— дип, бармак төртеп-төртеп күрсәттеләр үземә. Уңайсыз булып китте.

Хәрби киемдәге лейтенант кулыма сургычланган дәү конверт тоттырды. Имза куеп алдым. Һәм ул китеп тә барды.

Шунысы гаҗәп, әллә никадәрле ыгы-зыгы сәбәп булган ул конвертта шаккатырлык яңалык юк иде. Союз килешүенең проекты салынган. Ә ул Мәскәүдә чагында ук мәгълүм иде миңа. Һәм тагы бер кәгазь. Анысына түбәндәге сүзләр язылган: «Августның 15 ләреннән соң һичкая китмәвегезне, әлеге адреста калуыгызны үтенәбез».

Августның 13 ендә китерделәр тагы шул ук хатны. Һәм 17 сендә.

Әмма аларга ул кадәр игътибар бирмәдем. Бетмәс анда... корыны бушка аударып яталар шунда. Инде ял тәмамланып килә. Әле минем Ялтадан бер адым да читкә тайпылганым юк. Севастопольны гизү дигән ниятем бар. Һәм, һичшиксез, Бакчасарайны күреп кайту кирәк иде. Анда Кырым татарларының каһарман улы Мостафа Җәмил көтә мине.

19 август. Таң белән юлга чыктык. Ялта газетасында эшләүче Гөндез атлы әзәрбәйҗан егете үз машинасында сәяхәт иттерергә булды.

Юлыбыз кыска түгел. Иң әүвәл Севастопольга юнәлдек. Әмма, гомер булмаган хәл, юлда, багана саен диярлек туктатып, документ тикшерергә керештеләр. ГАИ хезмәткәрләре генә түгел, хәрбиләр дә мыжгып тора иде. Форос тирәсеннән узып барганда хәтта машинадан төшереп тентеделәр үзебезне.

— Сезнең хакыгыз юк, мин халык депутаты, Россия Югары Советы Президиумы әгъзасы,— дип, әтәчләнеп тә караган идем, булмады.

Документ сорадылар.

Күрсәттем.

— Күрәсезме,— дидем.— Уналтынчы номерлы таныклык! Борис Ельцинның үз имзасы куелган!

— Кызык... Бик кызык бу,— дип, борын тартып куйды майор һәм минем таныклыгымны тоткан көе янәшәдә генә торган вагон эченә юнәлде.

— Әйдәгез әле, әйдә, керик әле,— диеп, үзе артыннан мине дә ияртте.

Эчтә утырган полковникка сузды ул минем таныклыкны.

— Иптәш полковник, игътибар итегез, Президиум әгъзасы,— диде, мәгънәле итеп.

Минем монда нинди максат белән килеп чыгуым, кайда тукталуым һәм кайда юл тотуым белән кызыксынды полковник.

Ничек бар, шулай җавап бирдем. Һәм берочтан үземне шулай озак тоткарлап торуларына канәгатьсезлегемне белдердем.

Машинада гаиләм булу гына коткарды. Ул миңа документымны кире бирде һәм киңәш итте:

— Бу кенәгәгезне, иптәш Мөхәммәдиев, еракларак яшереп куегыз. Аның Сезгә бүтән бервакытта да кирәге чыкмас, дип уйлыйм. Хәерле юл телим үзегезгә.

— Ни әйттегез? Кабатлагыз әле, аңламадым,— дидем, әле генә колагым ишеткәннәргә һич ышанмыйча.

— Хәерле юл теләдем. Юлыгызны дәвам итә аласыз,— диде полковник. Һич шаярганга охшамый иде үзе.

Берни аңламадым. Сорауларыма да җавап бирүче булмады.

— Горбачев ял итә бит монда, шуңарга күрәдер ул,— дип, тынычландырды юлдашым Гөндез.

Севастопольны иплә генә гиздек. Бакчасарайга да барып җиттек. Туктатмадылар башка. Бакчасарай, үзенең кәрван-сарайлары, тарихи истәлекләре белән барын да онытырды. Көне дә җылы һәм кояшлы иде.

Көндезге 2 ләр тирәсендә Мостафа Җәмилнең өенә барып чыктык. Хөрмәтләр күрсәтеп каршы алды безне. Җәйге бакчада, җимеш агачлары күләгәсендә аш өстәле хәстәрләнгән иде. Матур гына әңгәмә кылып утырабыз. Тик шулай да Мостафа әфәнденең күңеле кырылган, нигәдер эче пошкан кебек күренә миңа.

Түзмәдем, бер җайлы мизгелне тотып алдым да сорарга кирәк таптым.

— Ни булды, Мостафа әфәнде, сез теше сызлаган кешедәй утырасыз,— дидем.

— Әллә синең кәеф яхшымы?— дип сорауга сорау белән җавап кайтарды ул.

— Мин бик бәхетле, Мостафа әфәнде. Сезнең иректә булуыгызга бәхетле. Бакчасарайга килеп чыгуыма. Шулай синең белән күзгә-күз карап әңгәмә кылып утыруыма... Төрле-төрле язмышка дучар ителгән ике татар баласы бит без.

— Ә Мәскәүдәге хәлләр,— диде ул, тирән сулыш алып.— Алар эчеңне пошырмыйммы?

— Нинди хәлләр?— дип кабаланып сорадым мин. Күңелдә яшеренгән хәвеф киеренкелеге бәреп чыкты.— Анда нәрсә булган?!

— ГКЧП игълан иткәннәр. Мәскәүдә хәрби фетнә. Син нәрсә, ишетмәгән идеңме, белми идеңме әллә?

— Ипидер белми идем. Белми идем.

Йөрәгем жуылдап китте. Менә нәрсә аңлаткан икән ул Филатовның кабат-кабат төпченүләре. Ике көннең берендә килеп торган сургычлы хатлар. Бүген иртән булган тикшерүләр... Һәм теге полковникның сәер сүзләре...

Димәк, барысы да алдан уйланылган, планлаштырылган булган...

Очрашуыбыз тәмамлангач та, без иң кыска юл белән, таулар аша Ялтага ашыктык. Шул ук кичне мин Мәскәүгә очтым. Камалышта булган Югары Совет бинасына керә алырмын дип һич өметләнмәгән идем. Баксаң, хәлләр бүтәнчә икән. Аэропортта каршы алган машина белән һичбер тукталышсыз Югары Советның сигезенче номерлы ишеге төбенә илтеп җиткерделәр үземне. Ә урамнарда — ыгы-зыгы һәм танклар да бар иде кебек, югыйсә. Баксаң, ул көннәрдә Мәскәү урамнары театр сәхнәсен генә хәтерләткән икән. Ә танклар һәм теге ыгы-зыгы, күрәсең, бутафория өчен кирәк булган. Ул тамаша һәм аның геройлары хакында башка әйтер сүзем юк. Ә без — халык депутатлары — «массовка» өчен кирәк булганбыз...

* * *

— Синңа ни калган иде анда?— диләр миңа еш кына. Туганнарым әйтә. Якын дусларым.

— Гомер бер генә бирелә ич, аның белән мәгънәсезгә шаяралар димә?..

Икенче ел китте инде. Әмма 1993 елның сентябрь-октябрь айларында Мәскәүдә булып узган вакыйгалар хакында сүз чыктымы, кайтып-кайтып һаман да офтану, дусларча шелтә ишетергә туры килә миңа. Котырган үгез сыман, якага ябышыр дәрәҗәгә житеп: «Кемне якладың, урыс шовинистларынмы?!»—дип, канга тоз салучылар да аз булмады. «Татарстан—суверен дәүләт. Чит ил парламентын саклап ятмасаң, сиңа, татар язучысына, эш беткән идемени?»—дип, йөзгә төкерер дәрәҗәгә житеп гайрәтләнүчеләр күп булды. Бер өлкән каләмдәшем исә, минем исән-аман котылып Казанга кайтып төшкәнлегемне ишеткәч тә: «Милләт өчен гыйбрәт булыр иде, кызганыч, дөмекмәгән, качып котылган икән...»—дип сукранып та куйган, имеш...

Сорау, шелтә, хәтта янауларның булуы да гаҗәп түгел минем өчен, табигый күренеш. Киңәш һәм акыл бирүче күп була ул һәрчак. Әгәр дә мәгәр Мәскәүдәге сентябрь-октябрь вакыйгаларының нәтиҗәсе башкачарак килеп чыккан булса, беләм, шул ук кешеләрнең күбесе кулым кысар, тәбрикләгән булыр иде. Ишек тоткасы дуслардан бушап тормас иде. Нишлисең, без һәм безнең таныш-белеш, дуслар шундый инде. Кешенең табигатеннән киләдер бу. Мәхәббәт һәм нәфрәт гел янәшә булган кебек, хаклылык һәм хата, шатлык һәм хәсрәт, тәбрикләү һәм шелтәләр дә һәрчак янәшә йөри торгандыр.

Олы нәтиҗәләр ясау түгел максатым. Сәяси бәя һәм хөкемнәрдән дә булдыра алганча читләшергә тырышырмын. Гомумән, соңгы еллардагы вакыйгаларга ашыгычлык белән берьяклы нәтиҗәләр чыгару әлегә мөмкин түгелдер. Шулай да, 1990—1993 елларда Мәскәү шәһәрендә иң югары даирәләрдә хакимият өчен барган көрәш, сәяси ыгы-зыгы, тулаем, минем күз алдымда узды. Ул вакыйгаларда актив яисә пассив рәвештә катнашкан бердәнбер татар язучысы идем мин. Шуңа да дәшми кала алмыйм. Чөнки беләм, күпме генә «без мөстәкыйль» дип лаф орсак та, Мәскәүдәге вакыйгалар Татарстан һәм татар халкы язмышына турыдан-туры мөнәсәбәтле иде...

* * *

1993 елның 21 сентябрь кичендә мин Казанда идем. Россия Федерациясе Президенты Борис Ельцинның 1400 нче хисап номерлы Указын үз өемдә телевизор экраныннан ишеттем. Югары Совет әгъзасы һәм Югары Советның Президиумы әгъзасы буларак, Мәскәүдә булырга тиешле идем, әлбәттә. Чөнки ул елны хәтта җәйге айларда да ял бирелмәде халык депутатларына, сәяси хәл гадәттән тыш киеренке иде. Россия Президентының «августта артподготовка башлап, сентябрь аенда хәлиткеч һөҗүмгә хәзерләнүе» бөтен дөньяга игълан ителгән иде бит.

Ул да түгел, телефон шалтырады өйдә. Мәскәүдән Югары Совет Президиумы секретаре Виталий Сыроватко:

— Ринат, ишеттеңме?—дип башлады сүзен.—Ашыгыч рәвештә Мәскәүгә килеп җитәргә кирәк. Булдыра алсаң, Татарстаннан сайланган башка депутатларга да хәбәр итсәң иде.

«Бармыйсың!»—дигән киңәшне инде берничә тарафтан ишетеп өлгергән булсам да, бару-бармау мәсьәләсендә икеләнү юк иде башымда.

— Аңладым,—дидем.

Виталий Григорьевич белән бер-беребезне яхшы беләбез. Ул үзе дә башка җавап көтми иде миннән. Әмма, ни өчендер, телефон трубкасын куяр алдыннан:

— Үзеңә генә әйтәм, хәлләр соң дәрәҗәдә киеренке,—дип өстәп куярга кирәк тапты.

Минем өчен атна саен Мәскәү—Казан юлын таптау гадәти күренеш иде ул чакларда. Дипломатым әзер. Әмма бүген, инде вакытның төнге

уннар тирәсе булуын истә тотсаң, Мәскәүгә барып житү мөмкин түгел. Иң якын юл, иртәнге алтылар тирәсендәге самолет белән очу.

Сәгать биштә, ул вакытта Татарстанның Сәламәтлек саклау министры булып эшләгән Рамил Хәбриев мине үзенең машинасы белән кереп алырга вәгъдә бирде. Казанда булган югары житәкчеләребездән берсе белән киңәшеп, жан тынычлыгы өчен аның хәер-фатихасын алдым. Мәскәүдәге шоферыма шалтыратып, каршы алырга куштым.

Иртәнге самолетта жиде-сигез депутат булып чыктык. Берсе дә Конституцияне бозып Югары Совет һәм Халык депутатлары Съездын куып таратырга жыенучы Б. Ельцинны хупламый. Гомумән, ул көннәрдә Россия Президентын хуплаган кешене очратырга туры килмәде миңа. Хәтта үзләрен ачыктан-ачык аның тарафдарлары санаган сәясәтчеләр дә бераз югалып калган. «Ашыга төшкән, болай ук кирәкмәс иде...» диебрәк сөйләштеләр.

Мәскәүдәге Домодедово һава аланында каршы алучы булмады үзебезне. Кая карама, анда машина юклыктан зарланып арлы-бирле чабулап йөргән депутатлар. Самарадан, Уфадан, Пермьнән һәм тагы әллә кайсы шәһәрләрдән.

«Син монда даими эшләүче депутат, Президиум әгъзасы, тап бер чарасын»,— дип, әйтә иде сыман Казаннан бергә очып килгән юлдашларым.

Шунда гына мәсьәләнең шактый житди куелып, Б. Ельцинның ныклап тотынганлыгына төшенә башладым.

1991 елгы август вакыйгалары башланган көнне, әйтеп киткәнемчә, мин Ялтада идем. Симферополь һава аланына депутатларны самолетларга утыртмаска дигән телефонограмма жибәрелгән. Югарыда төшкән әмерләрнең азмы-күпме үтәлгән чаклары иде әле. Депутатларга чынлап та билет бирмәделәр. Зур бер төркем үз хокукларын дәгъвалау белән мәшгуль иде. Без — Чиләбедән сайланган депутат, хәзер дә югары даирәләрдә булган Починок белән — шәһәрдәге кассага төшеп сатып алган билетләр белән Мәскәүгә очып киттек. Шәһәрдә комендант сәгате тәртипләре булып, бөтен юллар ябык саналуга да карамастан, Внуковода мине даими шоферларымның берсе — Сергей Ионов каршы алган иде. Һәм чат саен диярлек юлга аркылы куелган танк патрульләрен узып, ишегаллары һәм кәжә тыкрыклары аша Югары Совет урнашкан йортка да илтеп житкергән иде. Дөресен генә әйткәндә, ул чактагы ГКЧП сабыйлар уены кебек кенә булган икән ул. Телевидение һәм радио аша килештереп сөйләүдән артык берни кылучы булмады ул заманда. СССРны юкка чыгару өчен алдан оештырылган тамаша иде нибарысы. Ә депутатлар, халык төркемнәре һәм бигрәк тә журналистлар тамашада үзләренә бүленгән рольне башкарды. Чын-чынлап хакимиятне кулга алырга жыенучы һәм Мәскәү шәһәрендә игълан ителгән гадәттән тыш тәртипләрне тормышка ашырырга омтылучы юк иде һәм булмады. Ак йорт янында һәм Калинин проспекты чатында жыелган яшь-жилкенчәк үзара ыгы-зыгы белән мәш килделәр, танкларда, БТРларда тыныч кына туңдырма ашап утырган солдат егетләрне төрле провокацияләр ясап конфликтка тартып кертергә омтылдылар.

Бу юлы да үземне каршы алырга тиешле шофер шул ук егет иде. Кичә соң гына өенә шалтыратып хәбәр иткән идем.

— Каршы алам, әлбәттә. Беләсез, Мәскәүдә мине тоткарларга сәләтле ГАИ хезмәткәрләре тумаган әле,— дип шаярткан иде.

Баксаң, Президент Указы укылгач та, Югары Совет эшен тәэмин итүче барлык оешмалар, шул исәптән махсус транспорт предприятиесе дә, хәрбиләр тарафыннан ныклы сак астына алынган икән.

Кем такси тота, кем сатулаша... Шәһәргә барып житү өчен бер айлык хезмәт хакың житмәс. Ул да түгел, тәгәрмәчләрен ачы сызгыртып, каршыма бер «Жигули» килеп туктады. Кинәт ишеге ачылып, шоферы атылып чыкты кабинадан.

«Күзеңә ни үскәнмени... Нишләп юл уртасында йөрисең»,— дип, атыюлы белән сүгенә башлый инде бу дип, башымны күтәрсәм, каршымда әлеге дә баягы Сергей Ионов басып тора. Авызы колагына җиткән.

«Бераз көттердем, ахры»,— ди. Гафу үтенә. Сүз арасында, үзләре дә тыныч кына яши белмәгән, башкаларга да яшәргә бирмәгән сәяси җитәкчеләрне сүгеп ала.

Мәскәүдә яшәгән бу гади рус егетенең намуслылыгы һәм вәгъдәлелегенә мин әле дә сокланып куям. Иртән торып эшкә барган. Кертмәгәннәр, халык депутатлары юк инде хәзер, сезгә ял бирелә, дигәннәр. Үз чарасын тапкан. Барыбер үзенең иске машинасына утырып, якын дустын, кардәшен каршы алгандай, килеп җиткән.

Мәскәү урамнары, Россия парламенты урнашкан бина тирәләре 1991 елның август көннәрен хәтерләтә иде. Ак йорт әйләнәсен халык чорнап алган, тимер-томыр, агач һәм таш кисәкләреннән баррикадалар кору белән мәш киләләр, бер карасаң, үтә наив халык инде үзләре, ул баррикадалар кемне тоткарларга сәләтле иде икән соң?!. Шул ук вакытта атналар буе Югары Совет урнашкан бина яныннан китмичә, көн дими, төн дими сакта торган ул кешеләргә хөрмәт белән карамау мөмкин түгел. Беркатлы булсалар да, фидакарьләр иде алар...

Югары Совет бинасы эчендә дә нәкъ ике ел әүвәл булып узган атмосфера. Умарталыкка килеп эләктем диярсең. Дөньясы ыгы-зыгы килә. Кем генә юк анда?! Сенсация юллап көтү-көтү булып бер почмактан икенче почмакка журналистлар йөгерешә. Кинокамералар күтәргәннәр, микрофоннар, тимер баскычлар... Төрле илчелек вәкилләре, дипломатлар күренгәләп китә. Сәяси партия лидерлары, хәрби чиннар, әдәбият-сәнгать әһелләре. Һәм мин танымаган, күрмәгән, белмәгән әллә кемнәр тагы... Һәркайсы каядыр ашыга-кабалана, кулларын болгый-болгый аңгәмә кыла, сукраналар, Б. Ельцинны һәм аның әйләнә-тирәсендәгеләрне битәрлиләр.

Чишенер өчен дип кабинетка керәм. Даими комиссиянең эшчәнлеген тәэмин итүче аппарат тулысынча эш урынында. Депутатларның исә кайсы килеп җиткән, кайсы юлда икән.

Кулыма төргәк-төргәк яңа документлар китереп тоттырдылар. Узган кичтә үк Югары Совет Президиумы булып узган. Төнге сәгать 12дә Югары Советның гадәттән тыш сессиясе ачылган. Анда Россия Федерациясе гамәлдәге Конституциясенең 121,6 маддәсе нигезендә Президент Ельцинның вәкаләтләре туктатылып, ил белән идарә итү вице-президент А. Руцкойга тапшырыла дигән карар кабул ителгән.

В. Зорькин җитәкләгән Конституцион суд та Ельцинны дәүләткүләм җинаятьтә гаепләп чыккан. Тагы күп кенә башка карар һәм документлар...

Йокысыз төннән соң таң белән самолетта очып килгән кеше хәлен аңлыйсыз булса кирәк. Аңгы-миңге башка сыймас дәрәҗәдә көтелмәгән һәм масштаблы хәбәрләр һәм вакыйгалар иде болар. Кәгазьләрне өстәл өстенә куйдым да, соңлап килүем өчен гаепле бер кыяфәттә, турыдан-туры элемтәдәге җитәкчем Милләтләр Советы Рәисе Рамазан Абдулатыйпов кабинетына юнәлдем. Ишек төбендә халык күп иде. Мин чиратсыз кердем.

— Эшләр менә шулайгарак китте, Ринат,— дип каршы алды ул. Йокысыз төн тәэсиреме, әллә бераз шүрли-икеләнә калган идеме, ул үз-үзенә охшамаган, агарынып калган.

Килешкәнлегемне белдереп, баш кактым.

— Мин яңа гына самолеттан төшкән кеше, Рамазан. Берни дә аңламыйм әлегә.

— Аңламавың белән бәхетле син,— диде ул, битараф кына. Күреп торам, уенда башка нәрсә аның. Каядыр китәсе бармы?.. Әллә берәрсенең килүен көтәме?

Авызымны ачып сүз башларга торганда, ул бармагын иреннәренә аркылы куеп ашыкмаска киңәш итте. Аннан өстәленең уң як почмагында тезелешеп утырган телефоннарга ым какты. «Монда сөйләшеп буламыни, тыңлыйлар...» дигән сүзе иде.

Хәер, ул кадәресен мин үзем дә яхшы беләм. «Колак» һәр җирдә, һәр кабинетта бар ул, телефонга гына бәйләнмәгән. Бу эшнең белгечләре белән сөйләшкәнем бар. Кирәксә, урын өстендә хатының белән пышылдашканны да яздырып алалар икән.

Уң кулын минем җилкәгә салды да түрдәге ял бүлмәсенә чакырды Рамазан.

Кара-каршы утырдык. Кофе ясады. Нәни генә рюмкаларга затлы Дагыстан коньягы тамызды. Безнең бергә-бергә тату эшләгән көннәребез хөрмәтенә тамак чылаттык.

Тостны Абдулатыйпов әйтте. Ә сорау минеке:

— Ә нигә «эшләгән көннәребез» дисең, без әле эшләячәк тә түгелмени?

Алай диде, болай диде, әмма туры җаваптан качты әңгәмәдәшем. Һәм мин моны күреп тордым. Ләкин, башымны юләргә салып, күргәнем, аңлаганлыгымны күрсәтми утырдым.

Ике ир-ат арасында узган әңгәмәне дөньяга чыгарып селкү егетлек түгел. Шулай да үзем башлаган бер-ике сорауны искә төшерү гаепкә алынмастыр.

— Рамазан, илдә барган ыгы-зыгыларның яхшы уйланылган һәм хәтта әллә кайчан һәм әллә кайларда (!) җентекле рәвештә планлаштырылган вакыйгалар икәнлеген, син дә беләсең, мин дә беләм. Качыш-гүрле уйнау кирәк түгел, шулай бит...

Килешкәнлеген белдереп ым какты ул. Әмма авызын тутырып сөйләшергә базмады.

— Дөрес әйтәсең, «процесс пошел» һәм аны синең белән без генә туктата да, үзгәртә дә алмыйбыз инде,— дип кенә куйды.

Миңа артык шәрехләү кирәк тә түгел. Күңелемдә әллә кайчан булып та башкалар белән уртаклашмаган фикерләремне барлыйм:

— Туксан беренче елгы тамаша СССР дигән держаованы (кемнәрдер аны «империя» дип атый) җимерү өчен кирәк булды. Ә бу юлы максат нинди?

— Югары Советны куып тарату... Парламентны...

— Ә моңардан ни максат?

— Күрербез...

Мин Абдулатыйповның соңгы бер ел эчендә Сергей Шахрай белән шактый нык якынлашып киткәнлеген белә идем. Элгәре елларда исә болар бер-берен күрә алмаган, сөймәгән кешеләр иде. Күп тапкырлар бер-берен кеше алдында кимсетү, битәрләүгә җиткән чаклары булды. Һәр икесе белән дустанә мөнәсәбәттә яшәгән кеше буларак, миңа бик кыенга килгән чаклар була иде... Заманалар башка инде хәзер. Дуслаштылар... һәм дуслыкларын чит күзләрдән тырышып-тырышып яшерергә омтылалар.

Боргаламый гына, туры сорау куярга җөрьәт иттем:

— Шахрай ничек уйлый?

Рамазан моны көтмәгән иде. «Аның ни уйлаганлыгын каян белим мин», дип тә котыла алмый. Чөнки Шахрай белән без иске танышлар, үзара якынаюлары күз алдымда булды.

— Актив хупламый,— дигән ярымпышылдау авазы тирән мәгънәгә ия иде.

Димәк, хуплый, әмма хуплаганлыгын күрсәтмәмешкә салыша. Россия Президенты тарафыннан кылынган һәр житди чарада, бер карашка үтә тыйнак һәм сабыйларча самими күренгән бу сәясәтченең хәлиткеч өлеше була. Дүрт ел дәвамында даими күзәтүләрем нәтиҗәсе шундый.

— Ә безгә ни эшләргә инде алай булгач, хөрмәтле Рамазан дус.

— Актив рәвештә каршы торырга. Парламентны якларга.

Җитди сөйләшүдән озак кына читләшеп torгандай булдык. Дустанә утырсак та, эчкерсезлек җитми иде. Һәм ул җитә дә алмый, әлбәттә. Зур сәясәттә, гомумән, иман юк, һәм ул була да алмый. Башка берәүгә һич ышанырга, мөкиббән китәргә ярамый сәясәттә. Үз сүзе, үз адымнары өчен һәр кеше бары тик үзе генә җаваплы. Бер карасаң, син гел таныш-белеш һәм дус-иш арасында йөрисеңдер кебек. Икенче карасаң, син япа-ялгызың һәм карурманда. Әйләнә-тирәңне бүре һәм шакал, хәйләкәр төлкеләр уратып алган.

— Актив рәвештә каршы торгач, уртак дустыбыз Шахрайга каршы көрәшү була түгелме?— дип, сораган булдым тагы.

— Түгел!

Җавап үтә серле булса да, катгый иде. Һәм ул эчкерсез дә булган икән. Бу сүзләрнең асыл мәгънәсенә мин күпкә соңлап, октябрь вакыйгаларына канлы нокта куелып беркадәр вакыт узгач кына төшендем.

Безнең матур әңгәмәне эчке элемтә радиоалгычыннан ишетелгән хәбәр бүлдерде. Бинада булган һәммә депутатларны зур залга чакырдылар.

Сессияләр залы. Дүрт елга якын Россия парламентында эшләү дәверендә монда нинди генә вакыйгаларга шаһит булынмагандыр. Шушы залда минем М. Горбачев, Б. Ельцин, Р. Хасбулатов, А. Руцкой кебек төрле масштабтагы дистәләгән сәясәтчеләр белән кул биреп исәнләшкәнем, фикерләшкәнем, бәхәсләшкәнем бар. Б. Ельцинның туган көнем белән котлаганы хәтердә. Россия халыкларының телләре хакындагы канун кабул ителгәч, Югары Совет дәррәү кул чабып мин җитәкләгән эш группасына рәхмәт белдергәне хәтердә. Милләтләрнең үзбилгеләнүгә хокукларын исбат итеп сөйләгәндә ничәмә-ничә мәртәбә Р. Хасбулатов тарафыннан микрофоннан куылган бар. Татарстанның суверенлыгын яклап ясаган чыгышларымнан соң залның салкын карашын, якын дусларымның аркасын тойган авыр сәгатьләр булды...

Багымсызлык хакында сүз чыкканда бу залның нинди нәфрәт ташкынына әверелгәнлеген заманында Татарстан Югары Советы Рәисе булып эшләгән Фәрит Мөхәммәтшин да яхшы белә. Ничә мәртәбә чын каһарманлык күрсәтте ул шушы залда, бер ялгызым калган сәгатьләрдә дә җиңелмәде.

КПСС юк ителгән зал бу. Горбачевны хакимиятсез калдырган зал. Һәм шул мизгелдә Б. Ельцинның М. Горбачев кулын кысып, җиңүче кыяфәтендә безгә карап вәкарь белән көлеп куйганы хәтергә уелып калган. Беловежск килешүе расланып, СССР рәсми рәвештә шушы залда таркатылды. Монда Ельцинның Хасбулатов белән кочаклашканы, А. Руцкойны күккә чөеп мактаган бар. Шушы залда сәгатьләр буе Д. Волкогонов белән серләшеп утырган, кайчандыр үзем өчен кул җитмәс ераклыкта торган космонавтлар Андриян Николаев, Виталий Севастьянов белән якын дус булып аралашкан бар. В. Шумейко янәшәмә утырып үзен безнең комиссиягә алуны үтенеп гариза язды монда. Сергей Филатов без сораткан документларны тарата, һәр көн яныбызга килеп баш иеп сәлам бирә, кулым кысып китә иде шушы залда. Монда — дөнья кайнады, дөньяны кайнаткан документлар кабул ителде. Дөньяны кайнаткан затларга канат иңдерелде. Бик күпләр күтәрелде, үсте һәм бик күпләр дөбердәп килеп төште монда. Үземә дә югары кресл олар тәкъдим итү аз булмады. Хасбулатов урынына сайламаган өчен — депутатларга рәхмәт. Башка тәкъдимнәрдән сабырлык һәм Алла үзе саклады. Менә шундый зал инде бу минем өчен.

Шул залда Россия Халык депутатларының гадәттән тыш X съезды җыелды. Һәм, цивилизацияле дөнья тарихында беренче мәртәбәдер бәлки, XX гасыр ахырында, Мәскәүнең кыл уртасында җыелган ул съезд шәм яктысында узды. Шәм яктысында узгангадыр инде, ул съездда кабул ителгән һәммә канун һәм карар, Россия Федерациясенең гамәлдәге Кон-

ституциясенә нигезләнгән булуларына да карамастан, кәгазьдә генә калды. Хәер, ул кәгазьләр озын гомерле булмады — янды, көлгә очты бугай инде...

Россия радиосы һәм телевидение, дәүләт даирәләренә якын торган һәммә газеталар сентябрь-октябрь көннәрендә тоташ ялган, караны — ак, акны — кара итеп сөйләделәр һәм яздылар. Газетчыларга, журналистларга якын кеше буларак, миңа бу хәлне күрү һәм аңлау гаять авыр иде. Ә ялган һәм фальцификацияләрнең чиге-чамасы булмады ул көннәрдә.

Дүрт ел Мәскәүдә узган гомеремнән чыгып үзалдыма уйланып куйдым әле. СССРны сәясәтчеләр түгел, журналистлар таркатты. Сәясәтчеләр үзләре генә бу эшкә сәләтле түгел иде. Бик күп чит ил агентлыкларының хәбәрчеләре, журналистлары кереп тулды Мәскәүгә. Аларга чикләнмәгән ирек һәм хокуклар бирелде. Сүз иреге һәм матбугат иреге дигән ялганга алданды безнең бабайлар. Ә чынлыкта, чикләнмәгән хокукка ия журналистлар, бер яктан кирәкле информация тупладылар, икенчедән, тиешле иҗтимагый-сәяси атмосфера тудырдылар. Күпләренең чит ил разведкаларына хезмәт иткәнлеге миндә һич кенә дә шик уятмый. Алар ачыктан-ачык акча яисә техника тәкъдим итеп, безнең хәерче журналистларны үзләренә хезмәткә ялладылар. Чит ил журналистлары аша хәтта сәясәтчеләрне, генералларны, яшел акча күргәчтен тәкатьсез кала торган кайбер депутатларны да кулга төшерделәр.

Россия халык депутатларының беренче съездын үткәргән көннәрдә үк инде вакыйгалар һәм кадрлар белән КПСС Үзәк Комитеты түгел, пассив күзәтүче хәлендә калган КГБ да түгел, журналист кыяфәтенә кергән чит ил разведкасы идарә итә иде. Вакыйгаларга билгеле беркадәр тәэсир итә алу ихтималы булган һәр депутатка ким дигәндә ике-өч «журналист», яисә дипломатик хезмәткәр беркетелгән иде. Менә алар эшли беләләр! Кем-кем, аларның үз эшләренә бирелгәнлекләре һәм профессиональ талантлары каршысында баш иярга мөмкин. Үз тирәмдә бөтерелгән ул талантлы һәм мөлаем егетләрнең кайберләрен, кем икәнлекләренә әле теге чакларда ук яхшы төшенсәм дә, мин хәзер дә бер хөрмәт һәм җылылык белән искә алам. Тышкы кыяфәтләре белән үк балкып торган, аек һәм йөгерек акыллы, югары интеллектка ия кеше, кем булуына карамастан, үзе артыннан якты нур сызып калдыра.

Россия журналистлары исә Мәскәүдәге вакыйгалар турында тоташ ялган сөйләделәр. Пычрак ялган. Аларның кайберләренә кул бирергә дә чирканырсың. Чөнки алар, мин хөрмәт белән искә алган егетләрдән аермалы буларак, үз халкы, үз Ватаны мәнфәгатьләренә хезмәт итмәде. Киресенчә, ялган, яла юлына басты, намусын сатты.

Мисал өчен, Россия телекомпаниясе рәисе Олег Попцовны гына алыйк. Сиксәненче еллар башыннан, әле Россия Федерациясе Язучылар берлегенең секретаре һәм партия оешмасы житәкчесе булып эшләгән заманнарыннан ук беләм аны. Чамасыз «кызыл» кеше иде. Инде чамасыз «демократ». 23 сентябрьдә иртәнге 10 да X съезд ачылганда янәшәмә килеп утырды. Ике кешелек урында өчәү — Р. Хәбриев, мин һәм ул утырдык. Башын боргалый-боргалый гел депутатлар белән шыплап тулган залны күзәтеп утырды.

— Карале, депутатлар бик күп җыелган икән бит, — дип пышылдаганы хәтердә.

Берәр сәгать утыргачтын, информация бирергә кирәклеген сылтау итеп чыгып китте. Күрде. Иң ким дигәндә залда 700—800 депутат утырганлыкны күрде. Ул китеп ярты сәгать узгандыр, тәнәфескә чыктык. Россия каналы информация тапшыра: «Әүвәлге депутатлардан бер төркем, ышанычлы мәгълүматларга караганда, аларның саны 125—135 тән артык түгел, Югары Совет бинасында җыелып съезд ачкан булып маташалар...»

Икенче көнне әлеге «ышанычлы мәгълүмат иясе» белән тагы очрашырга насыйп булды. Йомшак кына сорарга кирәк таптым:

— Нигә ул кадәрле ялган сөйлисез, Олег?—дидем...
Сискәнеп китте ул. Күзләрендә курку.
— Эшебез шундый,—диде. Башка сүз тапмады. Дөрес җавап. Эшләре шундый, әлбәттә. Башкача сөйләсә, шул сәгатьтә үк эшеннән, машинасыннан һәм тагы әллә никадәрле тормыш уңайлыкларыннан колак кагачак бит ул. Журналист ирексез, чын-чынлап ирексез шул әле безнең җәмгыятьтә. Ә менә ирексезлек шартларында да ирекле калып көрәшергә сәләтлеләре артык күп түгел. Әмма бар. Ак йорт әйләнәсендә журналистлардан да чын каһарманнар бар иде.
Телевидение, радио, газеталар ялган сөйләсә дә, съезд ачылды. Депутатларга юлланылган телеграммалар барып җитмәсә дә, самолетларга утыру һәм шәһәрләреннән чыгып китүдә төрле-төрле каршылыклар тудырылуга да карамастан, кворум артыгы белән бар иде. Кайбер өлкәләрдә хәтта Россия депутатларын съездга җибәрмәү өчен үзләрен төркем-төркем кулга алуга кадәр барып җиткәннәр. Татарстаннан сайланган депутатларга исә, ул көннәрдә булсын, соңрак булсын, җирле хакимият тарафыннан кырын караучы булмады кебек. Хәер, кырын карау булмаса да, күрмәмешкә салышу булды, бар һәм ул әле дә дәвам итә.
Гадәттән тыш шартларда җыелган һәм шундый ук гадәттән тыш шартларда эшләгән съезд, анда кабул ителгән документлар, яңгыраган кайнар чыгышлар хакында бәйнә-бәйнә сөйләү максатым түгел. Ул хакта инде җитәрлек язылды һәм Мәскәүдә байтак кына китаплар да чыгып өлгерде булса кирәк.
Мин бары тик үземнең шәхси күзәтүләрем белән уртаклашам. Чөнки ул күзәтүләр минем үзем өчен дә кызыклы хәтта. Мәскәүдә барган вакыйгаларга ачык кына бәя бирү җиңел эш түгел. Һәм ул бәяне, хөкемне чыгарырга тырышучылар, үзләре телиләрме-юкмы, билгеле бер сәясәт һәм хакимият өчен көрәш күзлегеннән чыгып шәрехлиләр. Объектив булу үтә кыен. Әмма бу җәһәттән минем хәл беркадәр җиңелрәк.
Мин—татар язучысы. «Коммуно-фашист»лыкта гаепләү мөмкин түгел безне. Әгәр дә мәгәр андый оешкан көч бар икән, аның корбаны булу ихтималыбыз гына бар. Парламент йортында «рус шовинистлары» җыелып ята диделәр. Ихтимал, андыйлар да булгандыр. Әмма якут-саха кызы, икътисадчы профессор Зоя Корнилованы, чуваш егете очучы-космонавт Андриян Николаевны, башкорт шагыйрәсе Гөлфия Юнысованы, Мари иленнән танылган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Геннадий Петуховны, ногай егете, дин әһеле Мурат Заргишеевны, азсанлы чукча халкының күренекле табибы Майя Эттырынтынаны, эвен (эвенк түгел) халкының ана телендә яза торган бердәнбер язучысы Андрей Кривошапкинны һәм тагы соң сәгатькәчә Югары Совет бинасын саклаган күп дистәләгән милләт вәкилләрен бөек державачыл шовинизмда гаепләп буламы икән?!
«Коммунистлар! Кулларыннан китә башлаган өстенлекләргә ябышып яталар...» диделәр тагы. «Каракның эшләпәсе яна» дигәннәре шул була торгандыр инде. Җаваплы партия органнарында эшләгән депутатлар инде әллә кайчан «демократик» дәүләт белән идарә итә. Беренче елны ук кайсы кайда җылы урын табып, качышып бетте инде алар.
Шәхси мәнфәгатьләрен онытып, парламентчылык рухын якларга җөрьәт иткән депутатларга, шул рәвешле, тагы әллә нинди ярлыклар тагылды.
Чынлап та, ә миңа, миңа ни калган иде икән соң ул Россия Югары Советында изаланып гомер кичергән «шовинист һәм коммунист» депутатлар арасында?!
Бу сорауга җавап бирү җиңел түгел. Чөнки мин һич кенә дә илдә 1985 елга кадәр хөкем сөргән атмосфера һәм тәртипләрнең кайтуын теләмәдем һәм теләмим. Ә бит яшерен-батырын түгел, парламент йортында һәм аның каршысындагы мәйданда көн-төн нотык тотучыларның бер өлешен нәкъ шундый максат биләп алган иде.

Сталин портретын күтәреп йөрүчеләр белән дә бер сафка баса алмыйм. Татар халкы, татар мәдәнияты һәм теле күпме җәбер-золым күрде шул тираннан. Икенче Сталинны күтәрер, кичерер көч калмады инде бездә.

Мәгълүм бер милләт вәкилләрен, ягъни яһүдиләрне, хакимияттән себереп түгүне максат итүчеләр байтак. Ил белән булсын, коллектив белән булсын, һәрчак акыллы, әзерлекле кешеләр идарә итәргә тиеш. Боларны да хуплап булмый. Хупладың исә, чират үзеңә җитәчәк.

Һәм соңгы еллардагы кыргый икътисади сәясәт, дөресрәге, җинаять нәтиҗәсендә эшсез, ашсыз һәм ялангач калучылар да күп монда. Бигрәк тә мәйданнарга, Мәскәү урамнарына чыгучыларга кагыла бусы. Ә мин, Алла рәхмәте, әлегә эшсез дә, ашсыз да, ялангач та түгел идем. Шулай икән, ни берләштерә соң мине бу кешеләр белән?! Нәрсә калган миңа бу үҗәт Россия депутатлары арасында?! Казандагы «киңәшче»ләрем әйткәнчә, «чит ил парламентында ни калган сиңа, татар язучысына?!»

Китә алмадым. Ташлап китү турындагы уй башыма да килеп карамады хәтта. Бер-бер хәйлә табып, кайберәүләр тапты ич сәбәбен, кайтып киткән булсам, гомер гафу итә алмаган булыр идем үземне. Һәм шул көннән кулыма каләм алмас хәлгә, иң зур җәзага дучар ителер идем.

— Ә нәрсәгә ирештең?— диярсез.

— Һичбер нәрсәгәирешмәдем. Бәлки, югалтканмындыр. Әмма җаным тыныч. Үз-үземне битәрләп, куркып яшәмим. «Әнә теге чакта Парламенттан качып киткән депутатлар арасында бер татар язучысы да бар иде» дип әйтмәячәкләр һичкайчан.

Аннан килеп, мине Татарстанның яртысын диярлек тәшкил иткән милли-территориаль округтан сайлаган сайлаучылар бар. 600 меңнән артык сайлаучылардан берәвенең дә: «Без сине чакыртып алабыз. Ташлап кит Мәскәүне. Россия депутатларына ихтыяҗ калмады»,— дип әйткәне булмады. Белүемчә, депутатны Кремль буфетында кара икра ашау өчен генә сайламыйлар. Кирәккәндә, үз мәнфәгатьләрен онытып, кыенлыкларны лаеклы кичерә белергә тиештер ул.

22—23 сентябрь көннәрендә Президент аппараты җитәкчесе урынбасары Сергей Красавченко берничә тапкыр мине сорап шалтыраткан. Әдәбият-сәнгать дөньясын якыннан белгән Мәскәү зыялысы. Парламенттан соңгы араларда гына китте. Элемтәгә керим дип телефонга үрелсәм, «Кремлевка» (АТС-1) өзелгән булып чыкты. АТС-2 дә сулыш алудан туктаган. «ВЧ» элемтәсе инде тагы да алданрак киселгән иде.

«Үзләре шалтыратуны үтенә, ә үзләре элемтә өзә» дип уйладым да, шәһәр элемтәсе аша секретарьларын юмалый-юмалый иза чикмәскә булдым. Сергей Николаевич белән ул көнне сөйләшү насыйп булмады.

Ләкин барыбер таптылар үземне. Җитди бер министрлыкка министрның беренче урынбасары булып эшкә күчәргә чакырдылар.

— Уйлап карармын,— дидем.

— Без синнән шушы тәүлек эчендә җавап көтәбез,— диде элемтәгә чыгучы. Ул шулай ук элеккеге депутат иде. Бүген Россия хакимиятендә гаять олы урын били.

Мондый тәкъдим бер миңа гына ясалмады, әлбәттә. Югары Совет әгъзаларыннан бик күпләренә чыгучылар булган. Һәм көтелмәгән тәкъдим алдында тәкатьсез калып китүчеләр дә байтак булды. Әлеге тәкъдимнәр, әлбәттә, без алыштыргысыз кадрлар булудан чыгып түгел, ә Югары Советны таркату максатыннан эшләнде. Депутатларга, «алга таба кайда эшләргә ният итәр идегез» дигән сорау белән анкеталар да тараттылар хәтта. Аларны тутыручыларның теләге, кагыйдә буларак, шундук канәгатьләндерелде. Кайбер министрлыкларга бер көн эчендә дүртәр-бишәр яңа урынбасар билгеләнде.

Кем-кемне алдады, кем-кемгә алданды, әйтү җиңел түгел. Һәркем үз язмышын үзе теләгәнчә яза. Әмма, шулай да, югары урынга алданып китүчеләр күп түгел, бармак бөгеп кенә санарлык иделәр.

Тагы бер көннән Татарстан депутатларының кайтып китүен таләп иткән ниндидер телеграмма да китергәннәр иде кебек. Әмма рәсми телеграмма түгел, аның кайдан һәм кемнән булуы да тәгаен хәтердә калмаган.

23 сентябрь кичендә Мәскәүдә кан түгелде. Һәм аны ялган информация чыганаклары (ул көннәрдә телевидение, радио һәм үзәк газеталар эшен башкача бәяләү мөмкин түгел иде) Югары Совет оештырган провокация итеп күрсәтергә омтылдылар.

Кичке тугызлар тирәсендә Ленинград проспектында урнашкан СНГ илләренең берләштерелгән хәрби көчләре штабына автоматлар белән коралланган билгесез бер төркем һөҗүм итә. Милиция капитаны үтерелә, икенче бер милиционер каты яралана. Һәм, ни хикмәт, бу бинага каршы яктагы йортның югары катларындагы үз фатиры тәрәзәсеннән әлеге ыгы-зыгыны карап торган пенсионер хатын да атып үтерелә. Очраклы пулядан түгел, төбәп атылган пулядан(!)..

Нәкъ шул сәгатьтә Ак йорт каршысында чираттагы митинг дәвам итә иде. Әле радио һәм телевидениегә дә ул хакта хәбәр җиткерелмәгән була. Ә мәйдандагы халык төркеме арасыннан берәү тавышкөчәйткеч аша оран салды: «СНГ хәрби көчләренең штабы Югары Советны яклаган офицерлар тарафыннан яулап алынды. Бу безнең беренче җиңү, җәмәгать!»

«Урра...» кычкырган авазлар ишетелде.

Ул да түгел, теге тавышкөчәйткеч тагы чакыру ташлады:

— Әйдәгез, җәмәгать, барыбыз да көрәшкә күтәрелик. Штабны яулап алучыларга ярдәмгә ашыгыйк...

— Әйдәгез... Көрәшкә... Урра...—дип, эләктереп алучылар булды.

Әмма, шундук, Югары Совет тарафыннан бер-бер артлы ике генерал—Макашов А. М. һәм Титов М. Г. чыгыш ясап, ярдәмгә ашыккан төркемне туктата алдылар. Бу чынлап та, беренче һәм җитди провокация иде.

Хәтерлисездер, нинди тавыш-гауга кузгатканнар иде радио-телевидение каналларында. Югары Совет оештырган фетнә диделәр моны, хәрби пенсионерларны берләштергән Офицерлар Союзына сылтадылар. Хәтта шул Союзның җитәкчесе Тереховны авырып яткан урыны өстеннән, өендә, кулга да алганнар иде бугай. Урам лидеры Анпиловны һәм генерал Макашовны да гаепләп маташтылар. Өч кеше җинаять урынында кулга алынды, дигән информация дә булды... Кыскасы, Югары Советтагы депутатларны җинаятькә мөнәсәбәтле итеп күрсәтергә тырыштылар...

Әмма ни өчендер әлеге җинаять фактына бүгенге көнгә кадәр җитди бәя бирелгәне юк. Кешеләре дә кулга алынгач, җитәкчеләре дә билгеле булгач, аларны хөкем итү авыр эш түгелдер ләбаса... Аз түгел ич, ике кеше гомере киселде.

Шулаен—шулай. Әмма чын җинаятьчеләрне эзләргә теләүче юк. Һәм булмады.

Шушы вакыйгадан соң ук генерал Кобец: «Атакага атака белән җавап бирергә кирәк. Югары Советка кичекмәстән һөҗүм итәргә...»,—дигән тәкъдим белән килә Министрлар Кабинетына.

— Эх, генерал, генерал! Син үзең дә безнең депутат идең ич. Телгә оста, җор һәм мөлаем кеше. Күрешкәндә, кочаклап алыр дәрәҗәгә җитеп балкый идең. Парламент йортын утка тоту дигән тәкъдимнең иң элек синең авыздан чыгуына («Комсомольская правда» шулай язды) ышанасы килми. Хәтерегездәме, халык депутатларының беренче съезды барган көннәрдә «Россия» кунакханәсеннән Кремльнең Зур сараена икәүдән-икәү генә әңгәмә кылып барган идек. Ул вакытта сөйләгәннәрегез минем колак очында. Ә сез оныткансыз... Гөнаһ шомлыгы, әллә минем кылларымны чиертеп каравыгыз гына булдымы ул?!

Тагы бер көннән Мәскәүнең Бакчалар боҗрасында хәрәкәтне ябу эше белән мәш килеп йөргән ГАИ офицеры машина астында кала, һәлак була.

Күз алдына китерүе кыен, ашыгыч ярдәм машинасы килеп җиткәндә, ул урынны инде журналистлар сырып алган була. Кай арада, ничек?! Бер Алла гына белә. Һәлакәтнең шаһиты булган ГАИ хезмәткәре сөйләгәнне колакларына да элми журналистлар. Телевидение, радио һәм газеталар бу бәхетсез очракны да Югары Советны яклаган төркемнәргә сылтау җаен тапты. Б. Ельцинны тәвәккәллек күрсәтергә, озакка сузып маташмаска чакырды алар. Кайчандыр үзен язучы санаган Юрий Черниченко исә, Югары Совет бинасындагы «хәшәрәтләрне таракан урынына сытарга» ашыктырды. Һәм шундый чакырулар тәүлек буенча дистәләгән каналлар аша бөтен Россия Федерациясенә, дөньяга таратылып торды.

Ә безнең халык, телиме-теләмиме, ышанучан. Телевидение яисә радиодан ишеткәнне, газетадан укыганын 70—80 процент кеше, анализлап тормый, хакыйкать дип кабул итә.

Бөгелмә шәһәрендә булган бер эпизод хәтеремә кереп калган. Бер төркем яшьләр, сайлаучылар белән очраша идем. Сөйләшү рус телендә бара. Усалдан-усал сораулар яудыралар. Алдын-артын уйламый җавап биреп барам. Көтмәгәндә, яшь кенә бер егет сорап куймасынмы:

— Сез язучы кеше. Турысын гына әйтегез әле, Юрий Черниченко яклымы сез, әллә Валентин Распутин яклымы?

— Черниченконы тыңлаганым бар, эзләп укыганым юк, ә Распутин минем иң яраткан язучыларымнан,— дип башладым сүземне.

Егет, кабалана төшеп, бүлдерде үземне:

— Юк, сез турыдан ярып әйтегез, шәхес буларак, сезгә аларның кайсы якынрак?

— Валентин Распутин.

— Егетләр, киттек. Минем бу депутат белән бүтән сөйләшер сүзем юк,— диде дә торып басты егет. Бүреген батырып киде. Ярты зал ук димәсәм дә, җиде-сигез егет һәм кыз иярде үзенә.

Көтелмәгән хәлдән каушап калдым.

— Әйтегез әле — дим,— исем-фамилиягез ничек сезнең?

Максатым бу егетнең милләтен ачыклау. Әллә бер-бер милли хәрәкәткә бәйле протестмы дим?..

— Минем фамилиянең сезгә кирәге чыкмас,— ди теге дорфа гына.

— Рус егетеме соң син?

— Авылдан чыккан. Чын рус.

— Ә Распутинны ник яратмыйсың, ул да синең кебегрәк рус авылында туып-үскән, рус авылының чын трагедиясе, моң-зарын ачып салган сүз остасы ич.

— Консерватор ул,— дип, ык-мык итте егетем.— Ничек дип әйтергә соң... Ну... Бер сүз белән әйткәндә, фашист инде. «Красно-коричневый...»

— Каян беләсең? Бу фикергә син ничек юлыктың, аның әсәрләрен укыдыңмы? Шул әсәрләрдә бармы фашизм?

— «Литературная газета» гына укыйм мин. Анда дөресен язалар,— диде дә, демонстратив төстә ташлап залдан чыгып ук китте егет.

Гыйбрәтле әңгәмә иде бу. Әнә ни дәрәҗәдә тәэсиргә ия ул көндәлек матбугат.

* * *

Парламент урнашкан бинада махсус элемтә беренче көнне үк өзелгән булса, иртәгесен шәһәрара һәм халыкара элемтә юк ителде. Эшли дә белә икән ул безнең элемтәчеләр! Югары Советтан шалтыратып булмый, ә анда шалтыраталар. Бер тәүлек дәвамында эшләде әлеге берьяклы элемтә. Байтак кына төбәкләрдән таныш-белеш шалтыратып торды.

Шулай кичкырын бер танышым белән хәл-әхвәл сорашабыз. Табигый инде, Казан кешесен Мәскәүдәге хәлләр кызыксындыра. Мин ипле генә сөйлим, аңлатам...

— Ишетәсеңме, колак сал әле, безнең сөйләшкәнне тәрҗемә итеп баралар түгелме?— дип, гаҗәпләнүен белдерде әңгәмәдәшем.

Телсез калдык. Ә трубкада өченче бер кеше тавышы: «Ты слышишь, прислушайся, по-моему, кто-то занимается переводом нашего разговора...»

Исең-акылың китәр! Чит кешенең телефоннан сөйләшүен тыңлау демократик җәмгыятьтә җинаять дип санала. Һәм бу эш өчен җәзага тарту да каралган. Әмма СССР заманында булсын, бүген булсын, безнең илдә кеше сөйләшкәнне тыңлау киң таралган. Кемне теләсәләр, рәхәтләнеп тыңлыйлар шуны. Депутатмы син, әллә җинаятьчеме, гади бер гражданинмы, әллә Президентмы — белегез, телефоныгыз тыңлана. Дәүләт куркынычсызлыгы максатында эшләнә икән, мин үзем дә моны мөмкин эш саныйм. Гомумән, телефон гайбәт яисә сер сөйләшү урыны түгел.

Ак йортны тыңлаулары да гаҗәп түгел. Тәрҗемәчеләр булуы да табигый. Ә менә син сөйләшкәннең сүзгә-сүз тәрҗемә кылынып баруы һәм шул тәрҗемәнең, очраклы рәвештә, ике тарафка да ишетелүе көтелмәгән һәм башка сыймаслык хәл иде. Тәрҗемәче шулкадәр мавыгып киткән, яисә гамьсез булган, күрәсең, әле ул үзенә мөрәҗәгать ителгән «йомшак» битәрләү сүзен дә яртылаш тәрҗемә итеп чыга язды...

Ә тагы бер көннән исә телефоннар, гомумән, үзелде, һәр ике тарафка да дәшмәс булдылар. Аннан халык депутатлары дөньядан изоляцияләнгән бинада ут киселде. Җылылык бирү туктатылды. Суны өзделәр. Канализация ябылды. Һәм, ниһаять, Югары Совет бинасына азык-төлек һәм су кертү катгый рәвештә туктатылды. Мәгълүм булганча, фашист төрмәләрендә бу шартларның кайсыберләреннән тоткыннар мәхрүм ителмәгән. Менә сиңа «демократия», менә сиңа кирәк булса «кеше хокуклары»...

Шулай да кайбер кабинетларда радиоалгычлар эшли иде әле. Алардан ялган тыңлап була. Хасбулатов һәм Руцкойда радиотелефоннар урнаштырылган. Тышкы дөнья хәбәрләре шуннан керә иде, нигездә.

23 сентябрь көненә Россия Федерациясенең 53 субъектында халык депутатлары сессиясе яисә кече совет утырышлары булып узган. Нигездә, барысы да Конституция һәм Парламентка каршы кылынган гамәлләрдән Президентның кичекмәстән баш тартуын таләп итә. Себер край һәм өлкәләре Президенттан, катгый рәвештә, Югары Совет йортыннан блокаданы алдыруын таләп итә. Новосибирск губернаторы Виталий Муха Россиянең башкаласын вакытлыча Новосибирскига күчерү турындагы тәкъдим белән чыга. Кемероводан Аман Тулеев үз-үзен аямыйча хаклык юлларын эзли, көрәшә. Һәм тагы дистәләгән-йөзләгән администрация башлыклары, житәкчеләр, сәясәтчеләр, хәрби командирлар яклап чыга Конституция сагында торган депутатларны.

Конституция һәм демократия сагында калган депутатлар даими игътибар үзәгендә булды ул көннәрдә. Россиянең төрле төбәкләреннән нык булырга киңәш иткән, теләктәшлек белдергән телеграммалар, хатлар күпләп килеп торды. Алда ни буласын күрәзәчелек иткән кебек якын тирәдәге өлкәләрдән үз депутатларына район һәм өлкә хакимияте башлыклары, вәкилләре җылы кием, урын-җир, төрле консервалар төяп китерделәр. Үз сайлаучыларының теләктәшлеген даими тойган хезмәттәшләремә көнләшеп караган вакытлар да булгандыр.

Әмма Татарстаннан мин моны күрмәдем һәм һичкемгә үпкәләргә җыенганым булмады. Хакым да юк. Ләкин, көннәрдән бер көнне сәер телеграмма алдык: «Хезмәт коллективлары үтенече нигезендә һәм элекке депутатларның исәнлеген кайгыртудан чыгып, В. Морокин, Р. Мөхәммәдиев, Н. Неласов һәм Н. Репинның Мәскәүне ташлап кайтуларын үтенәбез. Татарстан телевидение һәм радиотапшырулар комитеты».

Көнелдә байтак кына шик-шөбһә һәм сораулар уятты бу хәбәр. Һәм әле булса үзләренә җавап таба алганым юк. Ни өчен нәкъ шушы дүрт депутатка гына адресланган ул? Наил Махиянов, Хәсән Хәбибуллин, Вакиф Фәхретдинов һәм тагы берничә якташыбызны ни сәбәпле искә алмаганнар? Каян килеп әле безнең хезмәт коллективы телевидение хезмәткәрләренә мөрәҗәгать иткән? Телевидениедән кем җибәргән, һәм имза куйган?

Әлбәттә, бу сорауларга җавабы әзер булучылар бар. Ләкин алар дәшми. Хезмәтләре шундый.

Табигый ки, каршы як та йоклап ятмый. Ул да түгел, Югары Советны якларга әзер булуларын игълан иткән хәрби командирлар бер-бер артлы югала башлый. Берәүләре эштән алынган, икенчеләре, имеш, үз-үзләрен атып үтергәннәр. Югары Советны яклап чыгарга җөрьәт иткәннәре өчен Брянск губернаторы Юрий Лодкин һәм өлкә администрациясе вәкилләренең эш урынына автоматлар белән коралланган ОМОН бәреп керә. Үзләрен стенага терәп, аркаларына көпшә төбиләр. Губернатор Ю. Лодкинны вәхшиләрчә кыйнап, урамга ук чыгарып атканнар.

Вакыйгалар, күрәм, көне-сәгате белән кискенләшә бара. Мәскәү урамнарында чын мәхшәр башланды. Парламент урнашкан бина һәр тарафтан тимер-бетон каска һәм калканнар артына яшеренгән милиция, ОМОНчылар белән уратып алынды. Алар гына булса икән, урамнартыкрыклар су ташу өчен җайланган махсус машиналар белән уратылган. Кеше түгел, песи үтеп чыгарлык та түгел. Зәңгәр кузовлы, сары баклы ул машиналар һәммәсе өр-яңа, конвейердан чыккан. Исәп-хисабы юк машиналарның. Берсенә икенчесен терәп үк тезгәннәр. Су тутырылган үзләренә. Әби-бабайларны саллы кара таяклары белән дөмбәсләп туйгач, кызыл битле ОМОН егетләре аларның кабиналарына кереп җылынып, кәефләнеп чыгалар.

Урамга тулган халык төркемен Парламент урнашкан төбәктән изоляцияләү өчен әйтеп узылган киртәләр дә артыгы белән булгандыр, югыйсә. Юк, җитми икән! Ике кат тоташ чәнечкеле тимерчыбык сузарга да онытмаганнар. Бу теге, фашист төрмәләрен уратып торган чәнечкеле чыбыктыр инде дип уйласагыз, нык ялгышырсыз. Мин үзем дә шул без кинофильмнарда күреп үскән киртә сыманрак була торгандыр ул дип уйлаган идем. Ялгышканмын икән...

Тоткынлыктан шул тимерчыбыкларны келәшчә белән керт-керт кисеп котылган кыю әсирләр булган. Кинофильмнардан күреп сөйләвем. Һәм Нәби ага Дәүли романнарыннан укып. Ә монда, үзең күрә торып та аңлату мөмкин булмаган галәмәт. Радиусы бер метр чамасыдыр. Каткат үрелгән тоташ спираль. Чәнечкеләре исә, энә кеби үткер һәм очлы. Күзең төшкәч үк калтыранып куясың.

Әмма хикмәт ул спиральнең тышкы кыяфәтендә генә түгел икән әле. Бруно спирале дигән бу нәмәрсәне халыкара кануннар нигезендә, сугыш барган җирләрдә куллану тыела икән. Химия һәм бактерия кораллары кебек үк. Аның ни икәнлеген үз күзләрем белән күрдем. Кайнар башлы бер яшүсмер егет, ни рәвешледер, машиналар һәм милиция калканнары диварын узып, Иректе Россия мәйданына үтеп кермәк булган. Спиральне йөгереп килгән шәптән сикереп чыкмак булды, ахры. Әмма, аягы эләгеп, чәнечкеле еланның нәкъ уртасына килеп төште. Дөресрәге, спираль аны үзенә суырып кына алды. Һәм әллә ниткән сыйфатларга кереп тимер тешләр пычкы сыман кисәргә, бөтерелергә-чәбәләнергә керештеләр. Егет бер-ике талпынды да тынды. Әмма аны муенынннан, аякларыннан, биленнән кат-кат уратып алган канлы элмәкләр һаман кысыла бара, буыпмы-буалар. Гүя, мыжгып торган буар еланнар оясына эләккән. Һәр ике тарафтан ух-ах кычкырдылар... Милиционер егетләр булып, алар як-якка сөрлегеп куйды. Ул да түгел, «тамаша»ны күзәтергә, төшереп алырга дигән ният белән йөгерешкән

фотокорреспондентларны, кинооператорларны дөмбәсләргә керештеләр. Техникаларын алып асфальтка бәрделәр.

— Әнә тегесен, әнә тегесен ычкындырмагыз,— дип боерды ОМОН егетләре артына поскан милиция полковнигы.

Ара ерак түгел. Безгә эчке тарафтан беркадәр ачыграк күренә. Ике-өч егет, командирлары күрсәткән телеоператорны машина капоты өстеннән эчке якка өстерәп төшерделәр. Һәм типкәләргә керештеләр. Башына тибәләр, һәм куллары белән учына яшерергә тырышкан нечкә җиренә тибәләр. Вәхшилекнең чиге юк... Полковник та йөгереп барды тегеләр янына. Туктатырга ниятләдеме әллә дисәң, түгел икән. Тегенең корсагы астында калган кинокамераны суырып алды килә-килешкә һәм ике кулына күтәреп, кирәмәйләп асфальтка китереп бәрде.

— Но, но,— дигән авазы ишетелде канга баткан журналистның. «Үзе мә тиюгез җитмәгән, ул кыйммәтле техниканың ни гаебе бар?»— дип, әйтергә теләде бугай.

Чит ил журналисты икән. Швеция телевидениесеннән булган диделәр.

Мәскәү урамнарында ун-унбиш тәүлек дәвамына тоташ тантана иткән вәхшилекнең бер эпизоды гына иде бу.

Җиде кат чолганышта калган депутатлар, Парламент каршындагы мәйданда көн-төн аяк өстендә басып торган мәскәүлеләр һәм илнең төрле төбәкләреннән җыйналган фанатиклар да бар бит әле.

Искәртү урынлы булыр, чолганышта калган кешеләрне шәһәргә чыгаралар иде. Кат-кат тикшергәннән соң, аркаңа бер-ике таяк, күткә бер-ике солдат итеге аласың да дүрт ягың кыйбла. Әмма кире кертмиләр. Һәм кире керү мөмкин дә түгел. Чолганышта калучыларга җылы кием һәм азык-төлек кертү максаты белән йөргән Халыкара Кызыл хаҗ җәмгыяте вәкилләре каршында да киртәләр ачылмый.

— Ашыйсылары килсә, чыксыннар,— дип, җавап бирә икән министр Ерин.

Күрәсең, ашау һәм үз корсагын кайгыртудан да әһәмиятлерәк төшенчә юк аның өчен. Әле кайчан гына Югары Совет үзен министр итеп раслаганда, нинди итагатьле, тәрбияле кеше күренгән иде. Әфганстанда да булган. Өстәвенә якташ та икән әле, ди-ди хуплап, тавыш биргән идек. Менә сиңа мә...

Якташлар дигәннән, монда алар белән буа буарлык. Кем «нәчәлник», шул Татарстаннан диярсең.

Камалышта калган Югары Совет Әтнә районында туып-үскән генерал Ачаловны Хәрби көчләр министры итеп сайлады. Армиядә авторитет казанган, яшь, кыю, курку белмәс егет. Халык депутаты булып сайлануы да очраклы күренеш түгел.

Хәтерлисездер, 1990 елның яз башында узган сайлаулар СССР тарихында беренче һәм соңгы чын демократик сайлаулар булды. Югарыдан төшерелгән исемлекләр санга сугылмады ул чакта, халыкның сәяси активлыгы гаять югары иде. Татарстанны аркылыдан-буйга гизеп, сигез көндәшем белән һәр тавыш өчен көрәшкән сәгатьләремнән чыгып әйтәм.

Соңгы вакытларга кадәр Россиянең Дәүләт Куркынычсызлыгы министры булып эшләгән генерал Баранников та Татарстаннан. Алабуга районында рус авылында туып үскән. Ельцинның илне дөнья җиленә чыгарып селкү сәясәте белән килешмәгәнлеге өчен Баранниковны эшеннән китәргә мәҗбүр иттеләр. Югары Совет 22 сентябрьда аны яңадан үз урынына кайтару турында карар кабул иткән иде. Баранников үтә сабыр, тыйнак кеше, бер сүз белән әйткәндә, чын зыялы...

Урыны җәннәттә булсын, ул юк инде. Китте. Озаттылар булуы да бик ихтимал, бик күп белә иде ич. Күпне белгән — тиз картайган, диләр бит...

Хасбулатовның беренче урынбасары Ю. Воронин да Казаннан бит әле. Ул да сәяси ыгы-зыгыларның нәкъ уртасында кайнаган шәхес. Нәрсә-нәрсә, әмма Россия Федерациясенең финанс һәм икътисад өлкәсендәге мәсьәләләре берничә ел дәвамында турыдан-туры аның катнашында

хәл ителде, буталды, һәм, бәлки, тупикка китерелде. Һәрхәлдә, 1991 елдан алып Югары Совет куып таратылганга кадәр Ю. Воронин иң югары даирәләрдә аралашты, актив эшләде.

Шулай итеп, Воронин, Баранников, Ачалов һәм Ерин — олы чуалыш көннәрендә күзгә бәрелеп торган шәхесләр — һәммәсе Казан һәм Татарстан белән бәйле. Беренче өчесе — Парламент тарафында булса, соңгысы аларга аттыручы, аларны яклап урамнарга чыккан халык массаларын кыйнатучы.

Берсе дә очраклы кеше түгел, әлбәттә. Чөнки һәммәсе Совет дәверендә тырышып-тырмашып күтәрелгән. Гади авылдан чыгып кырык-кырык биш яшькә генерал дәрәҗәсенә күтәрелү өчен һәрхәлдә байтак кына акыл һәм физик җегәр түгәргә кирәклеге аңлашылса кирәк. Тик шулай да, шәхси симпатия һәм антипатияләрне читкә куеп уйлаганда, аларның берсе дә Россия язмышын хәл итүдә тарихка керерлек каһарманлык кылмады. Сентябрь-октябрь вакыйгаларында түгелгән кан һәм берничә меңнән артык өзелгән гомердә һәммәсенең теге яисә бу кадәрле өлеше бар. Берәвенә тәвәккәллек, икенчесенә кыюлык җитмәгәндер, бәлки, өченчесенә, аек акыл. Ә дүртенчесе, гомумән, кешелеклелек дигән төшенчәне оныткандыр...

Без — сугыштан соң туып-үскән буын. Әти-әниләребезнең сугыш башка һичкайчан булмас, дигән ышанычы, була күрмәсен, дигән өмет-теләкләрен ишетеп үстек. Безнең малай чакларда иң яраткан уен — сугышлы уен иде. Тактадан кисеп ясалган автомат кочаклап, кар астына тишеп кергән окопларда тәгәрәп үстек. Урысча беравыз сүз белмәсәк тә, «Хинде-хох» дип кычкыра-кычкыра, һөҗүмнәргә күтәрелдек. Караган кинофильмнарыбызның да уннан бере генә сугыш турында булмагандыр. Безнекеләр «урра» кычкырып атакага барган чакта, авыл клубында кино карап утырган малай-шалай дөньябызны онытып, бүрекләрне чөя-чөя «урра»га кушыла торган идек. Арабыздан берәү, шулкадәрле мавыгып киткән берзаман, киноэкран булып хезмәт иткән ак комачны башы белән тишеп чыккан иде хәтта.

Кыскасы, сугыш безнең өчен тамаша, уен гына булып тоела иде. Һәм шулай булып калыр да иде шикелле.

Россиянең башкаласы булган Мәскәүнең үзәгендә, сугышлы уйнап үскән яңа буын 20 нче гасыр ахырында, уеннан уймак чыгарыр дип, кем уйлаган бит!.. Һәм үземнең дә шул куркыныч «уен» үзәгендә калырмын дип һич башыма килмәгән иде.

Ак йорт камалышта. Азык-төлек паекка күчте. Ни теләсәң шуны түгел, ни эләксә, шуны ашарга туры килә. Һәм анысы да як-ягыңа карангалап: күршеңдәгеңә җиткәнме, аның ашарына бармы, иң элек шуны ачыклыйсың. Дуслык, туганлык хисе бермә-бер арта икән андый чакта...

Гомумән, азык-төлек кысынкылыгы алай ис китәрлек нәрсә түгел икән ул. Үз корсагын гына кайгыртып, ачлы-туклы яшәүдән зарланган кешене ул көннәрдә, гомумән, очратмадым. Яңаклар тартылды, каешлар кысылды, әмма рухи көч һичкемне ташламады.

Азык-төлек хакында сүз чыккач, тагы бер якташ — Сергей Шашуринны искә алмый узу гөнаһ булыр. Ишетеп-күреп кенә белә идем үзен. Депутатлар арасында шушы егет чын легендага әйләнде бит ул көннәрдә. Мәскәүлеләр таба алмаган юлларын табып, Югары Совет бинасына күпләп-күпләп азык-төлек китерде ул. Үз язмышын куркыныч астына куеп башкарды моны. Аннан сөт ташу өчен җайланган машина белән берничә мәртәбә дизель ягулыгы алып керде. Бусы инде башка сыймаслык зур батырлык иде. Бина эчендә авария очраклары өчен дип хәстәрләнгән двигатель, нәни электр станциясе булган икән. Шашурин китергән ягулык берничә төн дәвамына бина эчен җылытып торды, яшәү өметен ныгытты.

Яхшы яктан булмыйча, кай яктан искә аласың шундый ир-егетне.

Шулай да, чолганышта калган көннәрдә иң нык тәэсир ясаганы ни булды икән соң? Ачлык түгел. Кабинетларның суыклыгы да түгел. Утсызлык һәм сусызлык та түгел. Элемтә һәм информациясез калу авыр икән. Анысына да түзәр идең әле... Ялгышмасам, 25 сентябрь иртәсеннән башланды иң нык тәэсир ясаган газап. Әйләнә-тирәдәге йортларның түбәләренә чамадан тыш гайрәтле тавышкөчәйткечләр урнаштырылды. Югары Советны бэжра сыман әйләндереп алган милиция, ОМОН һәм чәнечкеле чыбыкларың бер читтә торсын. Бина эчендәгеләр коточкыч көчле тавыш боҗрасында торып калдылар. Иртәдән кичкә кадәр, хәтта төн уртасында шул көчәйткечләрдән кинәт Россия Президенты Б. Ельцинның Парламентны ташлап качкан тәкъдирдә депутатларга биреләчәк вәгъдәләре укылды. Тау-тау акча, Мәскәү үзәгендә фатир, ял йорты һәм санаторийлар, пенсия һәм иң югары даирәләрдә үзең теләгән эш... машина... Әллә нильәр тагы...

Тын гына үз уйларыңа чумып утырган чак була. Уйламыйм дисәң дә, уйланыла, икеләнмим дисәң дә, икеләнелә икән инде ул барыбер. Казанны уйлыйсың, гаиләңне, туган-тумача, дус-ишләрне искә төшерәсең. Язучылар оешмасын... Алар ничек икән анда?.. Эчләре поша торгандыр... Көненә берничә мәртәбә хәл белешеп, хәбәрләшеп ала идек бит. Инде менә ничәнче көн телефон шалтырата алган юк. Ярый ла мондагы хәлләр турында дөрес информацияләре булса. Мәскәү телевидениесе һәм радиосына ышанып булмый. Аларның акны — кара, караны — ак итеп сөйли һәм күрсәтә белү сәләтенә бер түгел, йөз мәртәбәләр инанган бар...

Уйлар гүя чоңгылга тарта. Кабинетта тын гына утырган җирдән йокымсырый ук башлыйсың. Инде ничәнче көн, ничәнче тәүлек өстәге киемне салган юк, кеше рәтле йоклаган, рәхәтләнеп бер чәй эчкән яисә юынган юк. Кинәт... Күк күкрәп, яшен яшьнәгәндәй булып китә. Гүя таш бина калтыранып куя. Утырган җиреңнән сискәнеп сикереп торасың. Теге тавышкөчәйткечтән әлеге дә баягы очсыз-кырыйсыз вәгъдәләрне кабатларга керешәләр. Колакны каплап кына котылып булмый ул тавыштан, аяк табаннарыннан үтеп кереп, баш миеңне актарып ала...

Русча сөйлиләр... Әмма, әллә махсус, әллә очраклы рәвештә, чит бер акцент белән. Әүвәлге СССРда булмаган бер акцент белән халык депутатларын юмалыйлар, куркыталар. Һәм сүз арасында янап та куялар... Без үсмер чакта карап үскән киноларда еш очрый торган иде әлегедәй күренешләр. Бер-бер чолганышта калган, бирелмәгән партизаннарга яисә Совет солдатларына шул рәвешле тавышкөчәйткечләрдән психик атака ясыйлар: «Рус здавайся... Курить дам, шнапс дам...»

28 сентябрь иртәсендә Мәскәү хакимияте каршындагы мәйданда бер соры БТР пәйда булды. Ул, артына нашатыр кыстыргандай, арлы-бирле чабулап түбәсенә урнаштырылган тавышкөчәйткечләрдән бер үк сүзләрне кабатлады: «Бирелегез!... Бирелсәгез, икмәк һәм су бирәчәкбез...» Һич арттырмыйм, нәкъ шулай диде...

Геббельс пропагандистларыннан һич аерырлык түгел. Үзалдыңа көлемсерәп куясың, куюын. Әмма шулай да ачуны чыгара, нервларны шактый ук какшата...

Кәефең нык кырылса яисә төшенкелеккә бирелгән чакларың булса, иң яхшысы урамга чыгып, Югары Совет бинасы каршындагы мәйданнарны бер урап керү. Тәүлек дәвамында ыгы-зыгы тынмый, халык умарта кортлары сыман борөзлексез кайнап тора анда. Югыйсә, инде ничәнче көн чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган боҗра эчендә яшиләр. Ачлы-туклы һәм салкында. Сентябрь ахыры ич, төннәрен шактый ук суыта. Ятыйм дисәң, урын-җир, баш өстендә түбәләре юк. Шулай да түзәләр. Бер ялгызым мәйдан буйлап йөрим. Күзәтәм... Кемнәр генә юк монда. Яшьләр бар, өлкәннәр һәм хәтта карт-карчыклар. Һәммәсенең үз шөгыле, һәммәсе үзенчә дөнья көтү җаен тапкан. Анда-санда учаклар ягылган, ботка пешерәләр, чәй кайнаталар, җылыналар. Гитара чиртеп җырлап утырганнары бар. Гармун тартып ил белән идарә иткән (дөрес-

рәге идарә итә белмәгән) сәясәтчеләргә атап чыгарылган чәнечкелешырпылы частушкаларын әйттерәләр. Анда-санда гармунсыз гына үзалдына такмак чыгарып торган өлкән яшьтәге апалар очрап куя. Төркем-төркем әңгәмә корып торучылар адым саен. Йә үзара бәхәсләшәләр шунда, йә кемнедер сүгәләр, йә бер-бер депутат-фәләнне тыңлыйлар. Парламент бинасы стена газеталары һәм берсеннән икенчесе гыйбрәтлерәк сәяси лозунглар, фоторәсемнәр белән урап алынган. Шунда гына авторы да басып тора. Йомарланган йодрыкларын болгый-болгый Ельцинның яисә Гайдарның, һич булмаса, Чубайс, Шахрай, Бурбулис сыманнарның арт сабакларын укытыпмы укыта!

Икенче бер читтә зур бер түгәрәк төркемне журналистлар уратып алган. Кем дисәм, Ленинград телевидениесендә «600 секунд» тапшыруын алып барган журналист А. Невзоров икән. Бирепме-бирә кирәкләрен, ишепме-ишә хакимият башында утырганнарны.

Бер сүзе аеруча ошады:

— Нәрсә төртешәсез,— диде ул.— Бик эшлекле кыяфәт белән үзеннән сорау алган журналистларга усал күзләре белән карап.— Ник төшерәсез, барыбер күрсәтмисез ич.

Янәшәдә генә икенче төркем. Анысының уртасында коммунист Геннадий Зюганов. Һәрвакыттагыча тыйнак һәм уйлап сөйләшә ул. «Демократияне коммунизм белән чагыштырыгыз инде менә...», дигән кинаяле сүзе чалынып калды колакка.

Шунда ук урам лидеры — Виктор Анпилов көрәшкә чакыра. Күнитекләре белән шак-шок басып генерал Макашов үтеп китә. Икенче бер читтә Бабуринны уратып алганнар.

Ә иң зур төркем, мөгаен, Жириновский тирәсендә булгандыр. Һәммәсе дә өнәп бетерми үзен. Әмма тыңларга яраталар. Кызык сөйли, мавыктыргыч сөйли бит, нәләт. Дусны да, дошманны да авызына карата да тора. Сәгатьләр буе сөйли, теле-телгә йокмый. Нинди сорау бирсәң, шуңа тапкыр җавап таба, һич югалып кала белми.

Бу сәясәтчеләрнең һәммәсенә минем дә үз карашым бар. Төрлетөрле шартларда очрашып, күзгә-күз генә калып сөйләшкәнем бар аларның һәммәсе белән. Аерым-аерым алганда һәм үзләре белән генә калганда, кызыклы һәм матур кешеләр. Болар заман җимеше, илдәге сәяси ыгы-зыгы һәм тотрыксызлыкның лидерлары. Үзләрен тыңларга әзер булган төркем күрсәләр, шундук үзгәрәләр, уенчыга әвереләләр. Һәммәсе төрле-төрле, әмма бер нәрсәдә уртаклыклары бар. Милли мәсьәләдә алар безне аңларга теләми һәм аңлый да алмый. Демократия һәм кеше хокуклары дип, сәгатьләр буена сөйли алалар. Телләре телгә йокмый. Әмма татарга яисә башкортка, чеченгә яисә калмыкка ниндидер хокук, мөстәкыйльлек бирү турында сүз чыкса, тимер-бетон баганага әвереләләр. Башка милләтләр бутафория өчен генә аларга, сүз өчен генә... Бу минем күп тапкырлар сыналган фикерем.

Владимир Жириновский белән ун минутлар чамасы икәүдән-икәү генә сөйләшкәнем хәтердә:

— Син бит безне яратмыйсың, татарларны Монголиягә куам, дип әйткәнсең түгелме?— дидем үзенә.

— Дөрес түгел,— диде, шундук сүземне бүлеп.— Мин татарларны яхшы беләм, яратам. Алар чын россияннар. Россия Президенты булган көнне үк үзәк телевидениедән мин аларга булган мөнәсәбәтемне татар телендә үзем җиткерермен. Дошман телевидениесе һәм радиосы сүзләрен сөйләмәгез.

— Татар телендәме?— дип кайтарып сорадым...

— Әйе, татар телендә һәм кирәксә Казанга барып та сөйләрмен,— диде Жириновский.

Хикмәт шунда, ул миңа чын-чынлап татар телендә җавап бирде. Бу юлы акценты бар иде, барын, әмма татарча.

Сөйләр идеме икән? дисез инде. Юк, кирәкми. Россия җитәкчесенең авызыннан бер-ике татар сүзе ишетү кызык булыр иде, әлбәттә. Әмма, кызганыч булуы да ихтимал. Берсе килде бит инде Казанга. Башына түбәтәй киеп бөтен татар зыялылары каршысында «Күпме телисез, шул кадәрле алыгыз ирекне»,— диде. Кылган гамәлләре сүзләреннән ерак йөри шул. Әнә, күрсәтте үзенең ирекка омтылган милләтләргә булган чын мөнәсәбәтен. Чечен Республикасында кылган вәхшилекләрен күздә тотам.

Сәяси ыгы-зыгыдан гарык булган чак, җәт-җәт атлап арырак китәргә ашыгам. Мәйданның ерак почмагына ук барып җитәм, тимер-томыр, бетон ватыкларыннан корылган баррикадалар янына ук. Йөз илле — ике йөз метрлар чамасы арада «Мир» кунакханәсе һәм Америка Кушма Штатлары илчелеге урнашкан. Анда милиция, БТРлар. Кыскасы, анда да халык мәш килә. Ә бу тарафта исә хәрби бушлат киеп алган ике егет арматура кисәгеннән сөңге ясап маташалар. Игәү белән игәп... Сәер тоелды бу миңа. Аргы якта ОМОН, милиция, БТРлар. Ә монда сөңге очлап Россия Федерациясенең Югары Советын, гамәлдәге Конституциясен якларга ниятләгәннәр.

Ул да түгел, икенче бер читтә алты-җиде яшь-җилкенчәкнең чиләктән ярты литрлы шешәләргә ниндидер сыеклык агызып ятуларын күреп хәйран калдым. Инде ун-унбиш шешә хәстәрләп өлгергәннәр. Шартлаткыч әзерлиләр, күрәсең.

— Бу нәрсә?— дидем мин, үзләренә якынрак килеп.

Араларында берләнбер хатын-кыз җавап кайтарды:

— Атом бомбасы,— диде.

Үзләренә дә кызык булып китте, миңа да... Көлешеп алдык.

Каршы якта, Югары Совет бинасы белән Мәскәү елгасы арасындагы мәйданда ниндидер ыгы-зыгы дәвам итә иде. Ул мәйданга теләсә-кемне кертмиләр. Депутатлык кенәгәсен күрсәтеп, шунда уздым. Очраклы рәвештә тарихи бер вакыйга шаһиты була язганмын бит. Үз ирекләре белән Югары Советны һәм Халык депутатларын сакларга килгән хәрбиләрдән төзелгән полкны рәсмиләштерү эше бара икән.

Килүемне күргәч тә, кемдер таныл алып (яхшымы-яманмы, мин дә Югары Совет Президиумы әгъзасы бит әле), җитәкләп дип әйтерлек бер төркем халык депутатлары янәшәсенә китереп бастырдылар. Янәшәмдә генә генерал Ачалов туры килде. Ике-өч кеше аша Руцкой басып тора иде.

— Парад, смирно!— дигән әмер яңгырады.

Погонсыз бушлат кигән бер офицер төз атлап безгә якынлашты.

А. Руцкой парад кабул итте. Аннан, ялгышмасам, ике-өч йөз чамасы хәрбиләр маршка атлап узды. Берсенең дә өс-башы алай мактанырлык түгел иде. Әмма, сизелеп тора — болар профессионал хәрбиләр яисә хәрби хезмәт узган ир-атлар. Килде-китте кешеләр түгел инде болар, һәркайсының йөзләре һәм килеш-килбәтләре җитди.

— Россия Федерациясенең чын егетләре болар,— дип пышылдады генерал Ачалов. Һәм бераз тынлыктан соң өстәп куйды:— Арада татар егетләре дә бар.

— Хәтәр булган җирдә татар була инде ул,— дидем, үзалдыма уйланып.

Ачалов җилкәмнән кагып куйды һәм балкып елмайды. Ә бераздан үзенең тагы бер яңалыгы белән уртаклашырга кирәк тапты.

— Между прочим,— диде ул.— Татарстан җитәкчелеге Мәскәүгә ОМОН җибәрүдән баш тарткан. Андыйлар күп түгел...

Куанычлы яңалык иде монысы. Чөнки инде ничәнче көн Татарстаннан һичниди информация алган юк. Күңелгә җылы кереп китте.

Хәер, Татарстан белән элемтә юк, дип әйтү бик үк төгәл булмаска мөмкин. Чөнки Югары Совет бинасы каршысындагы мәйданда даими яшәгән халык арасында бер төркем казанлылар бар. Үзләрен хезмәт

иялəре блогы вəкилләре дип таныштырдылар. Руслар гына түгел, татарлар да бар араларында. Һәммәсе утыздан илле яшькә кадәрле аралыктан. Аек акыллы, таза егетләр. Элгәредән күреп таныган кешеләрем булмагач, алай чишелеп китеп аралаша алмадым үзләре белән. Ни гаҗәп, Октябрь вакыйгаларыннан соң аларның берсен дә очратырга туры килмәде. Югыйсә, хәбәрләшеп, аралашып яшәргә вәгъдәләр биреләшкән идек. Аллам сакласын, әллә барысын да юк иттеләрме диган шөбһә кереп куя күңелгә. Белмим, егетләр беркадәр серле күренәләр иде, башка бер-бер хикмәтләре дә булуы ихтимал.

Гомумән, мәйдандагы халык та, шул исәптән Югары Совет бинасына керү хокукы булган кешеләр дә төрле-төрле, аларны һич кенә дә тоташ бер тукымадан тукылган дип хаталанырга ярамый. Мисал өчен, Югары Совет бинасында калырга карар кылган депутатлар үзләре генә дә ничә төркемгә бүленә. Әйтик, бер үк сәгатьтә, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган шушы Ак йорт эчендә өч-дүрт киңәшмә баруы бик ихтимал. Алай гына булса әле?! Һәм аларның һәммәсен Югары Совет Президиумы әгъзалары җитәкли.

Кремльдә дә шушы ук Югары Советның элгәре Президиум әгъзалары: Б. Ельцин, Президент аппараты җитәкчесе С. Филатов, аның беренче урынбасары С. Красавченко, В. Шумейко, С. Шахрай, Ю. Яров, әле ике-өч көн әүвәл генә теге якка күчеп киткән С. Степашин, Н. Рябов һәм башкалар.

Табигый ки, Р. Хасбулатов кабинетында алга таба «Ни эшләргә?» дигән сорау эленеп тора булса кирәк. Аның янәшәсендә Ю. Воронин, В. Агафонов, В. Сыроватко, В. Исаков кебек президиум әгъзалары булу бик ихтимал.

А. Руцкой штабында инде югарыда искә алынган өч генерал — Ачалов, Баранников, Дунаев булыр һәм хәрби депутатлар — генерал Макашов, контрадмирал Рәфкать Заһидулла улы Чеботаревский. Рәфкать миннән берничә айга гына өлкән. Чиләбедә туып-үскән татар егете. Хәрби су асты флотын җитәкләгән. Гомере буе чит җирләрдә, океандиңгезләрдә йөрсә дә, татарча камил белә, яратып сөйләшә торган иде. Югары Советта ул, С. Степашин китеп баргач, Куркынычсызлык комитетының рәисе булып калды. Парламент бинасын саклаучылар арасында иң калку фигураларның берсе булды. Кулларыбызны артка каерып куйган хәлдә чолганыштан бергә чыктык.

Санаулы гына көннәр узды кебек. Аяз көндә яшен суккан кебек хәбәр куып җитте үземне. Югославиягә ниндидер комиссия әгъзасы булып барган җиреннән Рәфкатьнең йөрәге тибүдән туктаган, диделәр. Цинк табутка бикләп кайтарганнар да, туганнарына да күрсәтмичә күмеп куйганнар... Ышанмыйм... Үтерсәләр дә ышанмыйм! 46 яшьлек таза, сәламәт пәһлеванны юк итү, белмим, кемгә кирәк булгандыр?! Татарстанга кайтып яшисе килә иде әле аның. Серле хыял булып үзенә тартып торган, соң чиктә аның өчен хыял гына булып калган Татарстанга...

Шундый ук серле шартларда бераздан икенче якташыбыз — Алабуга районында туып үскән генерал Виктор Баранников хушлашмый да китеп барды. Илле яшьлек, типсә тимер өзәрлек таза ир-ат. Бу очракта да, имеш, «йөрәк» дип сөйләделәр. Россиянең Эчке эшләр министры һәм Дәүләт куркынычсызлыгы органнарын җитәкләгән намуслы рус егете иде бусы.

В. Исправников Югары икътисади совет җитәкчесе. Үзе Югары Совет бинасында, ә күңеле дәүләт идарәсе тирәсендә. Китәргә дә базмый, калырга да шикләнә кебек. Аның тирәсендә шактый акыллы депутатлар төркеме килеп туган шартлардан конфликтсыз гына сәяси җиңүче булып чыгарга юл эзләү белән мәш киләләр. Кызганыч, аларга форсат чыкмады...

Хасбулатов һәм Руцкой кабинетларында барган сөйләшүләр, хәтта Исправников эшчәнлеге дә бер-береннән яшерен түгел иде, әлбәттә.

Әмма, шул ук вакытта, Югары Советның ике палатасы рәисе дә үз сәясәтләре белән мәш килә. Р. Абдулатыйпов берәм-берәм генә очрашып депутатларның күңел кылларын чиерткәләү белән мәшгуль. Ике-өч кеше җыелдымы — дәшми, дәшмәс булды. Соңгы араларда инде күзгә туры карап сөйләшүдән тайчына башлады ул. Ельцинны сүгә үзе, аның аппаратын ахмаклыкта гаепли. Ә күңелендә башка нәрсә, башка уйният... Серме, мәкерме — ул көннәрдә ачык кына аңлый алмадым үзен.

Ә Республика Советы Рәисе Вениамин Соколов үз әйләнәсенә шактый ук көчләр туплап, турыдан-туры Р. Хасбулатовны җитәкчелектән азат итү мәсьәләсен хәстәрләү белән мәшгуль. Принциплардан чигенү, тайчыну түгел аның максаты, ә Югары Совет җитәкчелеген тамырдан үзгәртү. Һәм ул бу мәсьәләне урынлы булгандырмы-юкмы, анысы башка эш, көннәрнең берендә сессия барышында ачыктан-ачык күтәреп чыкты.

Сессия бара иде. Хәлләр соң дәрәҗәдә киеренке. Депутатлар ачлытуклы, кырынмаган, юынмаган. Бүген булмаса, иртәгә Югары Совет бинасына һөҗүм башлана дип торган көннәр. Ә монда, әлеге дә баягы хакимият бүлешү мәсьәләсен кузгаталар. Хасбулатовны алыштырырга диләр... Соколовның чыгышы ялкынлы һәм шактый дәлилле дә иде. Шундук бу тәкъдимне күтәреп алучылар да булды.

Хасбулатов каршылыклы шәхес, сүз дә юк. Искә алдым кебек, үз вакытында, 1990 елның маенда беренче съездда Б. Ельцин үзенең беренче урынбасары итеп сайлауларга өч кандидатура, шул исәптән, мине дә тәкъдим иткән иде. Сайламадылар, рәхмәт төшкерләре... Шул вакытта Р. Хасбулатов кандидатурасы калкып чыкты. Тар бер киңәшмәдә Асланбек Аслахановның үтенечен истә тотып, (ул да Чечен-Ингуш Республикасыннан сайланган депутат. Эчке эшләр министрлыгында Мәскәүдә эшли, генерал) мин хәтта Р. Хасбулатовны яклап чыгыш та ясадым әле. Ике тапкыр яндырдылар үзен. Зур авырлык белән, өченче мәртәбә сайланганнан соң гына үтте ул да. Чөнки күпчелеге рус милләтеннән булган депутатлар ташкыны, яшерен-батырын түгел, башка милләт вәкилләрен, бер сүз белән әйткәндә, бик үк өнәп бетермиләр. Иван белән Мөхәммәт янәшә куела икән, ник шунда пәйгамбәр булмыйсың, сине барыбер сызалар. Иванны калдыралар... Рус милләтенә хөрмәт белән карыйм мин үзем, аеруча рус әдәбиятына хөрмәтем зур. Дусларым бик күп руслардан. Югары Советта эшләү дәверемдә рус әдәбияты-сәнгате әһелләренә даими ярдәмле булырга тырыштым. Ә менә күп кенә рус туганнарга шулай да интернациональ рух җитеп бетми кебек.

Хасбулатов — Ельцинга хезмәт итте. СССР таркатылуда да бар Русланның роле һәм күп кенә башка җинаятьләрдә. Ельцинның Президент булуында да... Эшчәнлегенең беренче ике елында ул күлмәгеннән чыгардай булып Ельцинга хезмәт итте. Үзен яклап чыккан милли республикалар хакында онытты. Милли азатлык, республикаларның суверенлыгы дигән сүзләргә күркә кызылга ташлангандай иң элек ул ташланды.

1990 елның 9 декабрь көне иде бу, яхшы хәтерлим. Чөнки кичен Мәскәүнең матур бер почмагында минем иртәгәсен булачак туган көнемне билгеләргә җыенган идек. Б. Ельцин Югары съезд трибунасыннан котлады, чәчәк тапшырды. Кулымны кысып, унбиш-егерме секунд селкеп торды.

Ә Хасбулатов дустым, әнә, үзенчә тәбрикләде. Кремльнең Зур сарае трибунасыннан Татарстанның бәйсезлеге мәсьәләсен күтәреп сөйләргә чыккач, ул мине өч-дүрт мәртәбә бүлдерде, сөйләргә бирмәде. Микрофонны өзеп, трибунадан кууга кадәр барып җитте. Шулай да бераздан съездның таләп итүе белән, миңа ул чыгышымны йомгаклау форсаты барыбер бирелде.

Тарихи көн иде бу минем өчен. Беренчедән, кем ни сөйләмәсен, татар халкының тигезлеккә, милли дәүләтчелеген торгызуга тулы хокукы барлыгын ачыктан-ачык сөйләп чыктым. Моны Кремльнең Зур сараенда съезд делегатлары гына түгел, бөтен ил тыңлады. Форсат бар иде,

сөйләдем. Атмадылар да, кисмәделәр дә... Аның каравы, иртәгәсен Кремль Сараена үземне тәбрикләп илебезнең төрле төбәкләреннән мине таныган һәм танымаган кешеләрдән йөзгә якын телеграмма килде. Рәхмәт сүзләре белән... Ул кадәр рәхмәт сүзен минем башка һичкайчан ишеткәнем булмады...

Шул көннән Югары Совет куып таратылганга кадәр Хасбулатов белән миңа төрле шартларда һәм күп мәртәбәләр күзгә-күз очрашырга, икәүдән-икәү генә калырга туры килгәндер. Әмма шул гамәле өчен мин аңарга тамчы да үпкә сакламадым.

— Беләсең ич, Ринат, мин шулай эшләмәсәм, мине бу урында бер көн дә утыртмыйлар иде бит,— дип үзе искә төшерде ул бу хакта. 1993 елның июнь башларында Истанбулда икәүдән-икәү генә Хилтон кунакханәсендә сөйләшеп утырган кичтә әйтте. Аннан, акланасы килгәндәй, өстәп куйды:

— Татарстанга каршы күп гамәлләр кылынды. Әмма мин һәрчакта ике араны йомшарту, көйләү ягында булдым. Сүз белән каршы сөйләгәндә дә, эштә сезгә зыян китермәскә тырыштым.

Ул вакытлар минем күз алдымда узды. Шуңа да, «түгел» дип каршы төшәргә нигезем юк иде.

Беләм, Хасбулатовның да күңелендә миңа хөрмәт бар. 1992 ел кышында иде булса кирәк, Югары Совет Президиумының Куркынычсызлык Советы белән берләштерелгән ябык утырышында Чечнягә хәрби көчләр кертү мәсьәләсе каралды. Берсен икенчесе уздыра-уздыра, кичекмәстән сугыш башларга кирәк, ди-ди сөйләделәр. Бер очтан, Н. Медведев иде булса кирәк (Мордва Республикасыннан сайланган куштан егет), Татарстанда да тәртип урнаштырырга, ә Шәймиев белән Мөхәммәтшинны кулга алырга кирәк, дигән тәкъдим кертеп маташты. Табигый ки, мондый сүзләр яңгыраган җирдә, мин дәшми кала алмыйм. Җаныма тигәч, кайнарланып чыгыш ясаганмын. Милли сәясәтне көч кулланып хәл итү мөмкин түгеллеге һәм Чечнягә хәрби көчләр кертү хакындагы тәкъдимнең тамырдан хата булуын дәлилләп сөйләгәнмен. Бер очтан Татарстан җитәкчелегенең халык тарафыннан сайлануын искәртеп, Н. Медведевтан урынсыз сүзләре өчен гафу үтенүен таләп иткәнмен.

Фикер алышу шул мизгелдән икенче юнәлеш алды. Тагы берничә Президиум әгъзасы мине яклап чыгыш ясады. Чечен халкын яклап, кайгыртып сөйләгән шул чыгышымнан соң, Хасбулатовның мөнәсәбәте үземә карата тамырдан үзгәрүен сиздем. Ачыктан-ачык рәхмәт әйтмәсә дә, үзгәрде.

Хәер, болары сүз уңае чыккач кына сөйләнде. Р. Хасбулатовны алып ату, аның урынына башка берәүне сайлау турындагы тәкъдим, мөгаен, ул елларда аеруча еш тавышка куелган мәсьәләләрнең берсе булгандыр. Иң башта коммунистлар, соңрак, русларның милли патриотлары кертә иде ул тәкъдимне. Ә инде 1992 елның икенче яртысыннан башлап бу эшкә радикал-демократлар кереште. Тәкъдим кердеме, ике дә уйлап тормый башлады Руслан Хасбулатов, үз язмышын хәл итү турындагы мәсьәләне тота да яшерен тавыш бирүгә куя. Бер ел, ел ярым ара эчендә ун-унбиш мәртәбә генә тавышка куелмагандыр бу мәсьәлә.

Ә бу юлы, Югары Советның язмышы кыл өстендә торганда В. Соколовның әлеге дә баягы иске мәсьәләне өстерәп чыгаруы нигә кирәк булгандыр?! Мөгаен, Хасбулатов урынына башка бер иплерәк, тынычрак кеше куелса, бәлки, Югары Советны коткарып калу мөмкин булмасмы дип, өметләнгәндер. Шулай уйласа, хаталанган, әлбәттә.

Кадрлар мәсьәләсе белән шөгыльләнер вакытмы?! Болай да парча-парча бүлгәләнеп беткән парламент ул очракта, гомумән, үзеннән-үзе таркалачак иде. Ә бу хәлдә исә, демократия дигән төшенчәне, парламентчылыкны әле азмы-күпме саклап калу ихтималы бар. Анысы да бик чамалы гына. Чөнки илнең җитәкчелегенә ничек булса да үз юлында торган соңгы киртә — Югары Советны юк итәргә кирәк. Юкса,

үзләренең язмышы көннән-көн хөртиләнә бара. Халык массалары күзгә күренеп бөлгенлеккә төшә. Җитмеш-сиксән ел дәвамында бөтен халык көче белән дәүләтнеке дип тупланган ил байлыгы җәмгыятьнең дүрт-биш процентын тәшкил иткән елгыр җитәкчеләр һәм җинаятьчел төркемгә күчеп бара. Моны күрмиләр дисезме? Һәр кеше күрә. Әмма алар аерым-аерым. Һәр кешенең үз борчуы, үз язмышы. Кайберәүләрне әле өмет ташламый торгандыр. Бөлгенлек кешене үз-үзенә бикләнергә, йомарланырга мәҗбүр итә. Ә соңгы араларда акылга килгән Югары Совет шул бәхетсезлек һәм җинаятьләрнең асылын фаш итә башлады түгелме?! Әнә ни өчен таратырга кирәк булды аны.

26 сентябрьдә Югары Совет бинасында шомлы хәбәр таралды. 27сенә каршы төндә депутатлар утырган бинага штурм булачак икән. Икеләнүчеләр яисә куркучылар булса, чыгарга мөмкин, дигән рөхсәт тә булды. Гомумән, бина эчендә һичкемне көчләп тотмадылар. Ак йортны әйләндереп алган җиде катлы божрада милиция тарафыннан тар бер аралык ачылган, диделәр. Хәрәкәт бер яклы — чыгучылар өчен генә. Ә Югары Совет тарафына әүвәлгечә, чебен дә очып керерлек түгел. Ярдәм көтү урынсыз...

Ачлы-туклы яшәү һәм суык диварлар артында яту да сындырмаган икән депутатларны. Өлкән яшьтәгеләр бар, хатын-кызлар да күп. Арадан ник берсе ялгышып кына: миңа җитәр, сез калыгыз, ә мин чыгыйм инде, дисен. Күренеп тора югыйсә, авырулар бар, сессияләр залына җыелгачтын тоташ йөткерү авазлары ишетелеп тора. Бина эчендә урын-җир, гомумән, юк. Кайнар чәй турында хыяллану урынсыз. Йокы урыны — эш кабинетлары. Нинди өс киемнәрең булса, шуларны берсе өстенә икенчесен киясең дә, йә бер-бер креслога чүмәшәсең, яисә урындыклардан күңелең теләгәнчә ятак хәстәрлисең. Мин үзем, урындыклардан рәт чыгара алмадым, үз кабыргаларың өстендә ятудан да яманрак икән ул. Аз гына борылып куярга өлгермисең, гүя кабыргаларың бер-береннән аерыла башлый, урындыклар шыгырдап шуып китә. Суык булса да идәндә, келәм өстендә йокладым. Хәер, йокладым дип әйтү төгәл булмас, черем итеп алырга ниятләнеп газап чиктем.

27 сенә каршы кичтә, давыл хәбәрчеләре сыман, үзләрен демократ санаган журналистлар төркем-төркем качышып беттеләр. Димәк, чынлап та һөҗүм сәгате якынлаша икән. Кем-кем, әмма журналистлар белә. Чөнки аларның яртысыннан артыгы информация туплау өчен махсус органнар тарафыннан кертелгән монда. Кемнән нинди мәгълүмат алырга кирәк булса, кинокамераларын яисә диктофоннарын тегенең борынына китереп төртәләр. Сорау артыннан сорау яудыралар. Ә инде сәяси тәҗрибә һәм культуралары чамалы гына булган Россия депутатлары кармакка тиз каба. Белгәннәрен дә, белмәгәннәрен дә сөйли алар — экранда күренүне, популярлыкны бик яраталар.

Югары Советны яклап килгән хәрбиләр һәм хәрби булмаганнар урамдагы баррикадалар артында булды ул көнне. Нәрсә, нәрсә, әмма утлы корал юк иде аларның кулларында. Дөрес булса, радиотелевидение ул көннәрдә ни генә сөйләмәгән, диләр. Имеш, автоматлар саны берничә меңнән узган, пулеметлар һәм гранатометлар да исәпсез-сансыз икән... Ул гынамы, зенит ракеталары, стингерлар һәм тагы әллә ниләр бар дип сөйләгәннәр. Депутатлар атом бомбасы белән коралланган, дип әйтергә нигәдер фантазияләре җитмәгән берсенең дә. Ә нинди эффект булыр иде бит, ә?! Ул көннәрдә сөйләнгән башка бик күп ялган һәм уйдырмалар сыман, болары да тоташ әкият иде.

Мин үзем дә журналист булып эшләгән кеше, дус-ишләрем бик күп журналистлар арасында. Әмма арабызда ул кадәрле ялганга сәләтле сатлык җаннар мыжгып ятадыр, дип уема да кертеп караганым юк иде. Цензура чәчәк аткан Совет дәверендә дә юк иде ул кадәрле икейөзлелек.

Төнге сәгать 11ләр тирәсендә Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгыннан тәгаенләнгән хәбәр алынды. Штурм иртәнге сәгать 4 тә башланачак...

Ул төнне күзгә йокы кермәде. Караңгы тар коридорлар буйлап арлы-бирле йөренде халык депутатлары. Кайсыларының кулында шәм, кайсылары стеналарга тотына-тотына капшанып йөрү сәләтен үзләштерә. Әмма, ни хикмәт, бернинди паника һәм тәртипсезлек юк. Кадерләрәк әйберләрне һәм язу-сызуларны сейфка яшердем. Һәм кулыма шәм тотып мин дә сессияләр залына таба сәяхәткә чыктым.

Төнге 3 сәгать 30 минутта, йоласын китереп, съездны дәвам итү турында карар кабул ителде. Шул рәвешле һөҗүмне, бәлки гомеребезнең соңгы сәгатедер, эш урыннарында каршы алабыз. Шомлы һәм серле көтү минутлары... Шәм яктысында бер-бер артлы трибунага таныш депутатлар күтәрелә. Чувашстаннан Анатолий Леонтьевны, Якут-Саха иленнән икътисад фәннәре докторы, каһарман йөрәкле Зоя Корнилова алыштыра. Аннан, тыныч, сабыр холыклы очучы, мәгълүм язучы Валерий Хайрюзев сүз ала. Владимир Исаков дәвам итә. Ихлас сөйлиләр... Телевидение юк, радио юк, хәтта беркетмә алып баручы да булмагандыр, дип уйлыйм... Тарих турында, хакимият турындагы уйлар онытылды. Җирдә яшәү бар. Яшәү... Һәм үлем куркусы...

Ә күңел, барыбер, шомлы көтү белән яши. Бер колак залда сөйләгәннәрне тыңласа, икенчесе, сагаеп, урам тарафына тартыла.

Сәгать угы 4 кә килеп төртелде, үзенә таба әрсезләнеп чапкан минут һәм секунд укларын көтү белән мәшгуль. Сәгатькә ни?.. Аның югалтыр нәрсәсе юк...

Ниһаять, сәгать, минут һәм секунд уклары очрашты. Алга таба нишләргә, вакыт санауны дәвам итәргәме-юкмы, дигән сыман бер мизгелгә тукталып, каударланып калгандай тоелды алар миңа...

Йөрәкләр кысылган, сулышлар кысылган. Шул кадәрле сүзчән халык — депутатлар дәшми тынып калган. Ник берсе урыныннан торып, микрофон янына килсен шунда... Хәтта берөзлексез ишетелеп торган йөткерүләр сирәгәеп калды залда. Ни тикле генә батыр булып кыланма, күңелдә була торгандыр ул курку...

Нәрсәдән атарлар икән иң элек?!. Автоматтанмы? Әллә, алдан ук янаганча, тупка ук тотарлармы? Әгәр дә мәгәр, беренче бомба шушы зал уртасында ярылса?!

Әйләнә-тирәмдә утыручыларга күз йөртеп чыктым. Һәркайсы үз уена чумган... Тынлык... Шомлы тынлык... Депутат генераллар һөҗүм көтә! Фән докторлары бар монда, язучылар, дин әһелләре, гади колхозчылар, хуҗалык җитәкчеләре, космонавтлар... Һөҗүм көтәбез...

Халык ышанычын соң сәгатькә кадәр акларга омтылган Халык депутатлары, кара инде, нинди көнгә төшерелде. Нинди түбәнлеккә. Тамаклары ач, туңганнар, йончыганнар. Санаулы мизгелдән соң үзләре белән ни буласын беркем белми. Язганы булыр! Бу кадәресе чарасызлыкка, мескенлеккә тагы кайчан, кайсы илдә, кайсы халыкларның депутатлары төшерелде икән?! Исең-акылың китәр, Россия халыклары «эх» тә итми, мондый җинаятьләрне берсе артыннан икенчесен күтәрә тора бит... Күтәрә... Шул рәвешле кыргый джунгли кануннары белән яшәү тагы кайчангача дәвам итәр?!

Ул төнне һөҗүм булмады. Ни өчендер кичектерделәр. Бәлки сынаулары, куркытып караулары гына булгандыр...

Мөгаен, һөҗүмгә әмер бирергә тиешле иң зур генерал янсә башка бер-бер җитәкче исереп йоклаган булгандыр. Уятып караганнардыр-караганнардыр да, уята алмагач, йокласын инде, дигәннәрдер... Шул сәбәпле һөҗүм башланмый калгандыр...

Төн узды. Яктырып кояш чыкты. Утырышлар залында керфек тә какмый төн уздырган депутатлар Югары Совет бинасының балконына чыктылар. Мәйдандагы халык, белмим, ни өчендер, безне

«Урра» кычкырган авазлар белән каршылады. Бу безнең беренче җиңү идеме?.. Һәрхәлдә, үземнән чыгып әйтә алам, олыгаеп, тормыш тәҗрибәсенә баеп киткәндәй хис ителде ул иртәдә.

* * *

Мәйданга чыгып бераз арлы-бирле йөренеп кайткач, кабинетка кереп өстәл артына утырдым. Әйтүем генә инде, эш кайгысымыни... Телефоннар җансыз, телевизор эшләми, радио өзелгән, газета-журналлар юк. Китап укый торган вакыт түгел. Кулга каләм аласы килми...

Шул рәвешле чарасыз утырган бер мәлдә ишекне киереп ачып Югары Совет Президиумы секретаре В. Г. Сыроватко килеп керде. Әле Милләтләр Советы палатасы рәисенең урынбасары заманыннан ук үз итә идек бер-беребезне. Ә инде Россия Федерациясенең Австралиягә, Сингапурга һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә рәсми делегациясе белән барып кайткач, без тагы да якынайдык. Үз вакытында Брянск өлкәсендә беренче җитәкче булып эшләгән кеше ул. Тыйнак, сабыр, ипле, кешеләр белән сөйләшә, эшли белә. Аның шулай көтмәгәндә килеп керә торган гадәте бар.

— Бу юлы эш белән,— диде керә-керешкә. Һәм каршыдагы урындыкка килеп утырды.

— Нигә алай коры тотасыз... Бераз сөйләшеп утырыйк булмаса,— дим.

Гадәтенчә, маңгай астыннан хәйләкәр елмаеп кеткелдәп алды ул.

— Утырудан ни файда... Суыткычың да эшләми икән әнә.

— Әллә ният бармы, Виталий Григорьевич,— дип, өстәл тартмасына ымлаган булам. Анда берни юк, әлбәттә. Ихтыяҗ юклыгын да беләм. Әмма ике ир-ат арасындагы сөйләшү, телибезме-юкмы, шул каһәр суккыры шешәгә барып төртелгәндә, җанланып китә бит, гадәттә.

— Ярый, Ринат,— ди ул.— Башка чакта шаярырбыз. Анда берниең дә юклыгын яхшы беләм бит. Синдә аның булганы бармы?! Мин җитди йомыш белән идем бит әле.

— Тыңлыйм...

— Степанков белән яхшы мөнәсәбәттә бит сез, шулаймы?

— Беләсез ич, бергә эшләдек. Күршеләр буларак, тату эшләдек. Ә Генераль прокурор булгач йомыш төшкән юк үзенә...

Үз вакытында Валентин Степанков белән Милләтләр Советында күрше комиссияләрне җитәкләдек. Кабинетларыбыз да янәшә иде. Бер-беребезне аңлап, ярдәмләшеп эшләдек. Һәрхәлдә, түрә булып утыргач та, чабатасын түргә элә торган гадәте юк кебек иде аның.

— Киттек. Хасбулатов чакыра,— диде Сыроватко.

Караңгы коридор буйлап Югары Совет рәисе кабинетына юнәлдек. Урамда якты көн, югыйсә, ә монда караңгы. Чөнки ике яклап кабинетлар тезелеп киткән. Аларның ишекләре ябык, яктылык төшәр җир юк.

Хасбулатов ялгызы гына түгел иде. Янында Михаил Захаров белән Алексей Орлов утыра. Дөнья күргән, олы яшьтәге Президиум әгъзалары.

— Кремльгә кереп оялаган җинаятьчеләр тынгысызлана,— дип башлады Хасбулатов сүзен.— Республикалар һәм өлкәләр үзләренең Конституция яклы булуларын раслады... Армиядә дә икеләнү көчле. Дөнья җәмәгатьчелеге фикере дә үзгәрешләр кичерә. Урыннарда ризасызлык күрсәтәләр. Ельцин тарафында ялган сөйләүче журналистлар калды һәм Клинтон тагы... Вакыт безнең файдага эшли. Тагын берничә көн шулай түзсәк, бөтен җәмәгатьчелек безнең тарафта булачак... Ләкин... кул кушырып утыра торган чак түгел.

Безгә, өч Президиум әгъзасына, кайбер җаваплы бурычлар йөкләнә икән. Шул исәптән, Генераль Прокурорны шәхсән күреп сөйләшү...

Шулай итеп, 28 сентябрь көнне төштән соң, без өч кеше Югары Совет бинасы камалышын үтеп, аргы якка чыктык. Җиңел эш түгел иде бу. Иң элек чолганышта калучыларның кинаяле карашын күтәрү авыр иде. «Курыктыгызмы? Түземлек беттеме, интеллигент кисәкләре»,— дип әйтәләр иде төсле үзебезгә. Ни өчен һәм нинди максат белән чыгып баруыбызны һәркемгә дә сөйләп булмый бит.

Икенчедән, милиция чытырманын үтеп чыгу түбәнсетте. Капшауларны, тикшерүләрне һәм, җай чыкса-чыкмаса да, сине түбәнсетергә омтылуларын күтәрү авыр иде.

Озак еллар буе завод директоры булып эшләгән А. Орлов түзмәде, егетләргә нидер аңлатырга омтылып карады. Шундук күн итек белән тез астына китереп типтеләр.

— Нишлисез сез, егетләр, ул бит өлкән кеше,— дип, дәшми булдыра алмадым.

Һәм җавапка муен тамырына милиция «дубинка»сы белән китереп сыладылар. Ай-һай, куркыныч нәрсә икән ул, әле булса шул җир авыртып тора.

Документларны тикшереп торган милиция полковнигы да:

— Тебе че надо, татарин,— дип, үзенчә тешләп алды.

Үзебез хаталандык. Без дәшмәскә тиеш идек. Безне махсус оскырталар. Бер-бер сәбәп табып, алып китү кирәк безне. Ябып кую кирәк. Ун-унбиш минут дәвамында тагы ничек кенә кимсетергә тырышмасыннар, башка берни дәшмәдек. Шул коткарды.

Ә инде иң авыры, ОМОН катламын узып, урам һәм мәйданнарга тулган халык арасына килеп чыгу булды. Шундук уратып алдылар үзебезне. Гади кешеләр, әби-бабайлар, журналистлар сорау артыннан сорау яудыра.

— Нәрсә, курыктыгызмы?..

— Анда ничек соң, ачтан үлүчеләр күпме?..

— Сезне ничек чыгардылар?.. Руцкой, чыгучыларның аркаларына атарга, дип приказ биргән, ди түгелме?..

Ничек-кирәк алай, боларыннан да котылдык. Һәм «Баррикадная» метро тукталышына юл тоттык. Урамдагы хәлләрне сөйләп-аңлату өчен сүзең җитмәслек, чын мәхшәр. «Кая карама милиция һәм ОМОН. Каскалар, калканнар белән капланганнар да урамда җыелып торган әби-бабайларны, яшь җилкенчәкләрне дөмбәсләпме дөмбәслиләр резин таяклары белән. Әйткәнемчә, исеме генә «резин» икән ул таякның... Егылып калганны таптан үтәләр, кешенең башы ярылган дип тә тормыйлар. Бу ОМОН егетләренең күзләрен кан баскан икән бит, болар тәмам азынган... Каян килгән соң әле боларга ул кадәрле явызлык?! Үземнең дә милициядә эшләүче якыннарым, таныш-белешләрем, дусларым байтак. Өмер булса, алар да шулай ук дөмбәсләрме үз халкын... Моның тамыры каян килә? Сәбәбе нидә?.. Коммунизм төзегән елларда юк иде кебек бит бу явызлык.

Сорау куйганмын икән, инде җавабын да эзләргә кирәктер. Хикмәт шунда: милициядә җәмгыятьнең интеллектуаль әзерлек җәһәтеннән артык югары булмаган бер катламы тупланды соңгы араларда. Һәм аларга, гадиләргә караганда, күбрәк хезмәт хакы түлиләр. Дөресен әйтергә кирәк, күпләре өчен ул акча җиңел бирелә. Урман кисеп, тимер кырып, иген игеп алган хезмәт хакы — тир бәһасы түгел бу. Шул рәвешле, милиция үзгә бер социаль катлам булып формалашты... Яшерен-батырын түгел, шуның өстенә алар нык кына комсызландылар да бит әле. Акча тагы акча сорый. Хезмәт хаклары бер хәл, анысын дәүләт түли. Шуның өстенә, милициядә ришвәтчеләр дә җитәрлек. Һәр тәртип бозу, һәр җинаятьнең үз «такса»сы бар, диләр бит хәзер. Хакын түләсәң, дүрт ягың кыйбла. Ул гына да түгел, юк гаебеңне бар итеп, куркытып, шантаж юлы белән байлык казанучылары да хәйран... Һәм турыдан-туры мафиоз структуралар, җинаятьчеләр белән элемтәдә булып, шуларга хезмәт итүчеләре байтак...

Намуслы милиция хезмәткәрләре дә бар, әлбәттә. Алар мине гафу итә күрсен! Сезгә хөрмәт вә рәхмәттән башка сүз юк, халык иминлеге сагында торган фидакарьләр!

Менә шул рәвешле, илдә барган анархия дәверендә, көтмәгәндә-уйламаганда үзе бер сыйныф, каста булып формалашты да куйды бит. Кыйныйлар, әлбәттә, рәхәтләнеп кыйныйлар. Чөнки алар акча эшли. Кеше иминлеген саклаган өчен түләмиләр. Түрәләрне саклаган өчен түлиләр. Гади халыкны кыйнаган өчен түлиләр. Хак сүз булса, Югары Совет бинасын камауда һәм Мәскәү урамнарын дөмбәсләүдә катнашкан өлкән офицерларга һәр эш көне өчен йөздән — ике йөзгә кадәр доллар күләмендә «хезмәт хакы» түләнгән, имеш. Ә инде гади милиционерларга сәгатенә биш доллар чамасы...

— ОМОН дигәннәре ни була тагы? — дип, сораган иделәр берзаман. Мин үзем дә яхшы гына белмим бу ОМОН дигәннәренең килеп чыгу табигатен. Әмма ул бар, һәм алар күп. Һәм ОМОНның, милиция белән чагыштыргысыз дәрәҗәдә, кансызрак, явызрак булуын беләм. Килеш-кыяфәтләрен күрүгә үк куркыныч үзләре. Ә теге Октябрь вакыйгалары заманында, ну, күңелләре булганчы кыйнап та карадылар инде мәскәүләрне!..

Илдә хакимияткә килгән «ялган-демократлар» бик күп нәрсәләрне җимерделәр, саттылар, үзләштерделәр, юк иттеләр. Әмма тудырган, булдырган нәрсәләре дә бар — ул ОМОН. Аны алар үзләрен һәм дәүләттән, гади кешеләрдән талап җыйган байлыкларын саклау өчен тудырдылар. Ә армиядән кайтып эшкә урнаша алмый йөргән егетләргә күп кирәкмени?! Акча гына түләсеннәр. Көч бар, акылың яисә белемең бармы дип сорамыйлар. ОМОН булып китәләр.

Россиянең Генераль прокуроры Валентин Степанков янына без — А. Орлов, М. Захаров һәм мин — өчәү бергә бардык. Мәскәүнең театраль үзәгенә урнашкан бу шомлы оешмага шул көнгәчә, Алла рәхмәте, өчебездән беребезнең йомышы төшкәне булмаган. Әмма җиңел таптык. Югары Совет бинасыннан чыккач та, артыбыздан койрык булып ияргән урта буйлы ир-ат урамда торып калды, ә без капка төбендәге будкага кердек.

Каравылда автоматлар белән коралланган өч-дүрт хәрби каршылады. Депутат кенәгәләрен чыгарып күрсәттек. Ни хикмәт, безнең килүгә гаҗәпләнүче, ник килдегез яисә, сез кем яклы, дип сораучы булмады. Бик мөлаем, ачык йөз белән кабул иттеләр.

— Килдегезме, рәхим итеп узыгыз,— дип, озатып калдылар.

Безнең килергә чыгу хакында боларга алдан ук хәбәр итеп куелган диярсең. Хәер, моның шулай булуы да ихтимал. Чөнки, Югары Совет бинасында сөйләшкән сүз һичкайчан сер булып калмады.

Степанков урынында түгел иде. Куркынычсызлык утырышында, берике сәгатьсез кайтмас әле, диделәр.

— Урынбасары Евгений Кузьмичка керегез алайса, ул урынында. Сезне хәзер үк кабул итәчәк,— диде, секретарь ханым.

«Хәзер үк кабул итәчәк», дигән сүзгә игътибар итеп, бер-беребезгә карашып алдык, һәм салмак кына атлап чыгар юлга борылдык.

— Нишлибез, Ринат,— дип, миңа мөрәҗәгать итте Захаров.— Син Степанковны яхшырак беләсең. Урынбасарлары нинди кешедер бит аның?..

— Лисовка керү файдасыз булачак,— дидем. Чөнки аның Генераль прокурор кешесе түгеллеге миңа мәгълүм иде.— Бераз көтик, бәлки үзе кайтыр.

Ул арада каршыда гына икенче бер ишек ачылып, аннан кыска итәкле кыз килеп чыкты. Кара инде, без чолганышта ятабыз анда. Ә монда кыска итәк кияләр икән...

— Евгений Кузьмич сезне көтә,— диде ул кабаланып. Исәнләшергә дә онытты хәтта.

— Безнең бераз киңәшләшеп аласыбыз бар әле. Соңрак керербез, гафу итегез,— дидек. Һәм ишектәге язуларны укый-укый ары киттек. Урынбасарлары шактый күп икән бит бу Генераль прокурорның: «Славгородский М. Д.», «Шаклеин Н. И.»,— ди-ди, укый барабыз. Берочтан баш кагып, ымлап киңәшеп тә алабыз.

Чираттагы ишек янына килеп җиткәч «Бәтәч...» дип әйтә яздым. Юлдашларым йөзенә дә яктылык иңде.

— Безнең Сабир Гаджиметович Кехлеров та монда эшли икән бит,— диде А. Орлов.

Аның монда икәнлеген мин белә идем. Чөнки, лезгин егете Сабир белән «Россия» кунакханәсендә ике елга якын күршеләр булып яшәдек, чәйләребез уртак иде. Аны бу сәяси ыгы-зыгыга катыштырасы килми иде минем. Эчкерсез һәм ачык егет, кунакчыл егет.

Бәхетенә каршы, Сабир ниндидер коллегия утырышына киткән булып чыкты.

— Ә бәлки безгә кеше төсле бер ашап алу да зыян итмәс иде,— дигән тәкъдим кертте Михаил Львович Захаров.

— Чынлап та... Бәлки шул арада Степанков та кайтып житәр,— дип күтәреп алдык.

Эчкә җан керде. Онытылып барган җылы аш хәтергә төште. Иң элек борынны кытыклап узды аның исе. Аннан ашказанына йөгерде...

Ашханәгә юлны таптык кына дигәндә каршыбызга Генераль прокурор үзе килеп чыкмасынмы! Күзләребез маңгайга менде. Һәм, табигый инде, ашау кайгысы онытылды. Юк-юк, алдыйм икән, онытылмады, әлбәттә, гел истә, хәтердә торды ул. Әмма ара табылмады.

Степанков безнең килү хакында хәбәрдар иде кебек. Нигә? Нинди максат белән? дип сорап тормады, кабинетына чакырды. Хөрмәт күрсәтергә омтылды, кофе кертергә кушты. Һәм, гомумән, башын юләргә салып, качышлы уйнап маташмады.

— Мин сезнең нинди максат һәм таләпләр белән килүегезне беләм,— диде, турыдан ярып. Һәм, беркадәр уңайсызлана, тартына төшеп, дәвам итте: — Әмма ярдәмче була алмыйм...

Менә сиңа мә, дигәндәй, бер-беребезгә карашып алдык. Чәчләренә чал кергән өч ир-ат, Югары Советның Президиумы әгъзалары, без шушы җавапны ишетер өчен килдекме?!

Арабыздан иң өлкәне Михаил Захаров әле авызына якын да китерергә өлгермәгән кофены читкә этәреп куйды.

— Без монда кофе эчәр өчен килмәдек,— диде ул.— Сез — Генераль прокурор. Илдә Конституция һәм кануннарның үтәлеше сагында торырга тиешле кеше. Без үтенеп яисә сорап түгел, Югары Совет исеменнән таләп итеп килдек. Конституцияне бозучыларга мөнәсәбәттә ни өчен әле шушы көнгә кадәр җинаять эше кузгатылмаган?!. Сезне бит без — Югары Совет сайлап куйды. Ельцинга һәм Черномырдинга түгел, Югары Советка буйсынырга тиешле кеше сез. Генераль прокурормы сез, юкмы?

Михаил Львович дөрес сөйли иде. Аның хаклы икәнлеген Степанков үзе дә белә. Әмма кануннар белән яши торган илдә түгелбез. Шуңа күрә, канун бозган өчен эштән алмыйлар бездә. Югыйсә, Конституция һәм кануннарны бозу иң олы җинаять саналырга тиешле... Ә инде зур түрәгә ярый белмәсәң, ул теләгәнчә кануннарны әвеш-түеш иттерә белмәсәң — беттең, чемоданыңны тотыра тор, башка эшкә күчерәчәкләр. Әнә шулай...

— Аңлагыз, зинһар, минем җинаять эшләре кузгатуым-кузгатмавыма һичкем игътибар итмәячәк. Күрмисезмени, Конституцион судны да санга сугучы юк,— дип, йөрәк ачысы белән әйтеп куйды Валентин Степанков.— Әле генә куркынычсызлык Советыннан кайт-

тым. Анда исә, киресенчә, Югары Совет җитәкчелеге һәм сезгә мөнәсәбәттә бүген үк эш кузгатуымны таләп итәләр. Өстәлгә сугып таләп итә...

— Соң, кузгат алайса. Йомышчылары бул, тарихка үз Парламентын кулга алырга рөхсәт биргән Генераль прокурор булып кереп калырсың.

Степанковка да җиңел түгел иде, күренеп тора. Кушканны гына үтәп тормаса, аны монда бер көн дә тотмаячаклар. Ләкин ул партия аппаратларында чыныгып бозылган кеше түгел, чагыштырмача яңа буын вәкиле. Шуңа күрә дә, өндә булмаса да, төшендә хокукый җәмгыять турында хыялланганы бар аның. Өмет белән яши.

— Мин бернинди «ордер»га да кул куймаячакмын,— диде ул, катгый рәвештә. Бу аның безгә җавабы булудан бигрәк, Ельцинның әмерен үтәмәячәкмен, дигән сүзе иде.

Сөйләшү, үгетләүләрдән файда булмаячагы һәммәбезгә дә мәгълүм иде. Орловның папкасында яткан рәсми кәгазьләрне тапшыргач, хушлашып, китәргә чыктык. Әмма ишекне шапылдатып ябудан рәхәтлек кичерә торган очрак түгел иде бу. Кәефләребез, дөресен әйтү кирәк, яхшы түгел. Генераль прокурорның исә безнекеннән дә яманрак. Ни тыныч һәм иплe кеше югыйсә, әмма түземлеге калмаган.

— Миңа үпкәли күрмәгез, зинһар, аңлагыз хәлемне,— диде Степанков, кулларыбызны кысып. Иң соңгы чиратта минем янга килде.— Бәлки, бер биш минутка калып торырсың,— диде, ишетелер-ишетелмәс пышылдауга күчеп.

М. Захаров һәм А. Орлов моны күрделәр, әлбәттә. Аларга күтәрелеп карадым.

— Биш минут кына көтәрсез, бәлки...

— Әлбәттә... Әлбәттә, көтәрбез,— диде өлкән агайлар.

Валентин Георгиевич, җитәкләп диярлек, мине ишек катындагы сейф торган караңгы почмакка әйдәде.

— Монда тынычрак булыр, Ринат,— диде, халыкка ялган сөйләүче «Маяк» программасын бар көченә ачып.— Беләсең килсә, без монда барыбыз да пешкалар... һәм без — пешкаларның нинди йөреш ясавына беркем игътибар итмәячәк. Хәтта Ельцин үзе дә үзгәртә алмаячак вакыйгалар барышын. Ул чарасыз күренә. Димәк, шулай кушылган, шулай хәл ителгән... Югары Совет бинасында кан коелачак... Син шуны белеп тор һәм үзеңчә саклык чараларын күр.

— Ни өчен кан? — дидем дә, телсез калдым.— Кансыз... үлемсез генә булмыймы?..

— Хәтерегездәме, 1991 елда, шул рәвешле, тамаша ясап КПССны һәм СССРны таркаттылар. Ә бу юлы Советлар системасын һәм парламентаризмны юк итәчәкләр. Беләсең, кан түгелми генә эшләнми андый эшләр... Кан — куркыта һәм буйсынырга мәҗбүр итә.

— Валентин, син ни өчен боларны миңа сөйлисең?! Мөгаен, безнең сөйләшүне барыбер ишетәләр булса кирәк.

Кулын селтәде Степанков.

— Мондый чорда бу урында эшләү өчен җинаять артыннан җинаять кылуың кирәк. Ә мин креслога ябышмаган. Ни кылсам да, мәңгелек түгел мин монда.

— Беләм. Әмма, әллә ни файда китерә алмаса да, бу урында намуслы кеше утыру барыбер яхшырак... Ярый, мине көтәләрдер, чыгыйм инде,— дип, ашыгуымны белдерттем.

Бармагын күтәреп, бер генә минут көтүемне үтенде Генераль прокурор. Һәм кабинетының түренә үк барып, өстәл тартмасыннан ике кәгазь кисәге тартып алды. Урталай бөкләде... Әмма кесәгә сыярлык җыйнак конверт таба алмады. Секретарена ул-бу сиздерергә теләмәде, эзләпэзләп тә таба алмагач, кулын селтәп, кәгазьләрне миңа сузды.

— Үзең укысаң ярый. Сыроваткога яисә башка берәүгә бирерсең,— диде.

Хушлаштык... Һәм без, юлдашларым белән бергә, камалышта калган Югары Советның чираттагы йомышын йомышларга диган омтылыш белән ашыгып китеп бардык.

* * *

Кич житте. Караңгы төшеп килә. Без үзебезгә йөкләнгән бурычларны үтәргә омтылып, барасы жирләребезне йөреп чыктык.

— Инде нишлибез, егетләр? — диде Михаил Захаров, арабызда иң өлкән кеше буларак.— Өйләргә кайтып, кеше төсле рәхәтләнеп бер йоклыйбызмы әллә?..

— Башкалар Ак йортта камалышта утырганда килешмәс бит. Кире кайтырга кирәктер.

Икәүләшеп көлеп куйдылар үземнән. Моның булмас хыял икәнлеге үземә дә аермачык мәгълүм иде ләбаса. Әмма, акыл белсә дә, күңел ышанмый. Ничек инде Халык депутатын эш урынына кертмәскә мөмкин. Депутат өчен ил эчендә генә түгел, чит-ят мәмләкәтләргә чыкканда да яшел юл ич һәрчак. Милиция хезмәткәреме син, хәрбиме, әллә чик сакчысымы — һәммәсе халык депутатына «честь» биреп, аңарга итагатьлелек күрсәтеп, юл бирергә тиешле. Канунда шулай язылган... Шаяртырга теләмәгән идем.

— Кызыл Пресня район Советына барыйк иң әүвәл, үзебезнең кайда икәнлегебезне хәбәр итик,— диде Алексей Орлов.

Килештек. Без чынлап та Кызыл Пресня район Советына барырга тиешле идек. Камалышның аргы тарафында калган һәммә халык депутатлары шунда көн үткәрә.

Метрода барабыз. Бер карасаң, мәскәүлеләр көндәлек ыгы-зыгы белән яши, һәркемнең үз мәшәкате. Ә инде игътибар беләнрәк баксаң, алай түгел һич тә. Метро вагоннарында, тәрәзәләрендә кая карама — анда листовка. Ике сүзнең берендә: «Фашизм не пройдет!» яисә «Ельцин — палач». Ике кеше үзара сөйләшә икән, алар шәһәрнең әле теге, әле бу почмагындагы митинг, анда кыйналган кешеләр хакында әңгәмә кыла. Үзалдына газета укып бара икән, анысын да Мәскәү үзәгендә барлыкка килгән фронт сызыгыннан хәбәрләр кызыксындыра.

Метро станцияләрендә төркем-төркем жыелып Ельцинны, Лужковны, Черномырдинны тетепме-тетәләр. Ул да түгел, аларны резин таяк һәм калканнар белән коралланган милиция куып таратырга керешә. Төркем шундук тарала һәм юк була. Нәкъ менә яр читендә йөзеп йөргән балык көтүе инде, тотыйм диеп, кулың суга тыксаң, алар да шул рәвешле юк булалар.

Кораллы милиция чит бер тарафка китәргә өлгерми, теге төркем әллә кай арада яңадан, тагы да зуррак булып тупланырга өлгерә. Әбиләр листовка ябыштыра, егетләр яшерен типографияләрдә басылган газета тарата. Такмаклый-такмаклый Ельцинны, Бурбулисны, Чубайсны һәм Шахрайны сүгәләр. Ул да түгел, метро станциясенең ерак почмагыннан тагы милиция төркеме килеп чыга. Умарта оясымыни, бөтен шәһәр аяк өстендә, шәһәр мәш килә.

Кызыл Пресня метросы. Югары күтәреләбез. Урам... Юлларда машина йөрерлек түгел. Халык, мәйданга сыеша алмый, урамнарга бөселеп чыккан, бакча-паркларны тутырган. Монда митинг бара икән... таныш йөзләр дә байтак. «КамАЗ» кузовын биек сәхнә һәм үзенә күрә бер трибуна итеп жайлаштырганнар, тавышкөчәйткечләре дә шактый гайрәтле күренә. Әшли торганнардырмы-юкмы, иллә дә мәгәр сөйләргә өйрәнгән бу Мәскәү халкы. Кайсын карама, шул тел остасы, трибун. Укытыпмы-укыталар Кремльгә кереп оялаган житәкчеләрнең арт сабакларын. «Житәкче» димиләр, әлбәттә, «жинаятьче» диләр...

Кызыл Пресня паркында нинди халык төркеме икән дисәң, алар милиция һәм ОМОН икән, ләбаса. Ким дигәндә, егерме-утыз машинага төялеп килгәннәр. Митингның башланып, кызып киткәнен генә көтеп торганнар икән. Болар тәртип сакларга, ул-бу килеп чыга күрмәсен дип килгәннәрдер инде, дип уйлыйсыздыр. Ялгышасыз. Мин дә беркатлылыгым белән, чираттагы мәртәбә ялгыша яздым.

— Машиналардан төшәргә! — дигән әмер яңгырады берзаман.

Каскалар, тимер калканнар артына яшеренгән ир-ат белән тулды бакча. Борынгы грек заманыннан килгән рыцарьларны хәтерләтеп куйдылар.

Әмма болар рыцарь түгел һич тә. Күз ачып йомганчы, өч-дүрт шеренга булып, митингны өч тарафтан уратып та алдылар. Халык күрми дә, абайламый да калды үзләрен. Аларга ни, трибунадагыларның берсеннән-икенчесе остарак сөйли бит әнә. «Демократия» һәм «кеше хокуклары» хакында акыл саталар. Ә гавам авызын ачып тыңлый, онытылып...

Ябык түбәле тимер машинага кереп оялаган милиция полковнигы әмер бирде берзаман: «Урап алырга һәм метро тукталышына кысрыкларга!».

Йөзәрләгән-меңәрләгән кирза итек берьюлы атлауданмы, мәйдан сыкрап сөрлеккәндәй булды. Тимер калканнар белән кысарга, кысрыкларга керештеләр дөньясын онытып «кеше хокуклары» хакындагы нотыкны тыңлаган халыкны. Чигенергә, борылып йөгерергә өлгерми калганнарын шунда ук резин күсәкләр илә дөмбәсләргә үк керештеләр. «Чырый»лап кычкырырга кереште әбиләр, ир-атлар сүгенә, каршы килмәк була, тегеләрне иманнарына килергә чакырып үгетләмәк булалар. Ачылган авызлары ябылырга өлгерми, маңгай урталарына кирәмәйләп китереп тондыралар. Авыз-борыннарыннан шаулап кан агарга керешә. Карышып, кулыңны күтәрсәң, беттең — муен тамырыңа тимер калкан кыры белән китереп чабалар. Таптыйлар... һәм узалар... Син пенсионермы, Бөек Ватан сугышы ветеранымы, күп балалы герой-анамы, сорашып тормыйлар монда. Изәләр... Сыталар... Китәләр...

Әнә, анда бер бабай онытын ияртеп килгән булган. Бите канга баткан, аягы да сынган, ахры, атлый алмый. Сикереп тормак була да егыла, тагы тормак була — тагы егыла. Әмма оныгын ычкындырмый барыбер. Сабый ярдәм сорап елый, кычкыра.

— Үтерәләр... Бабакайны үтерәләр...

Без бер читтә басып тора идек. Әллә үз кешеләре санадылар, тимәделәр. Түзмәдем, йөгереп барып, теге бабайны күтәреп торгыздым. Ниятем мәхшәрдән алып чыгу үзләрен. Авыр гәүдәле түгел иде карт, инсәмә таянды да, бер аягы белән сикергәли-сикергәли барды.

— Оныгым... Оныгымны калдырмагыз, — дип үтенде берөзлексез.

Алып чыктым чыгуын. Әмма шулай да муен тамырыма бер-ике мәртәбә бәргәләп өлгерделәр. Кирәмәйләп сугалар. Куркыту өчен түгел, имгәтәм дип сугалар икән. Тимер таяк яисә утлы корал бирсәң үзләренә, «эх» тә итмәячәк, ике уйлап тормаячаклар, атачаклар да үтерәчәкләр икән болар...

Агайны оныгы белән парк эчендәге эскәмиягә илтеп утырттык. Балалар бакчасыннан кайтып килүләре булган икән, мәйдан тулы кеше күргәч, табигый инде, әйләнеп уза алмаганнар, колак салганнар. «Зил»да кою цехында эшләп пенсиягә чыккан кеше икән. Ни гаҗәп, исеме дә хәтергә уелып калган үзенең — Семен Денисович. Кунакка да чакырган иде әле хәттә.

— Бу нинди хәл бу? — дип, гаҗәпсенеп, үзе белән ни кылганнарын әле булса аңлый алмыйча, безгә текәлде Семен Денисович. — Халыкны ни өчен кыйныйлар?! Фашист солдатлары түгелдер ләбаса болар... Кыяфәтләре үк куркыныч бит әнә.

Үзе сөйләнә, үзе авыз-борыныннан шаулап аккан канны туктату өчен кесәсеннән кулъяулык эзли иде пенсионер карт. Таба алмады. Булмагач, муенындагы шарфны тартып чыгарып, шуңарга сөртенә башлады.

— Егетләр, карагыз, ни эшлиләр...— дип, игътибарыбызны М. Захаров яңадан мәйданга юнәлтте.

Гаҗәп хәл, күзләрем күргәнне язу мөмкин түгел. Восстание мәйданы тарафыннан дүрт-биш КамАЗ чабып килгән шәптән кискен борылдылар. Һәм бер шеренга ясап, артка таба хәрәкәт итәргә керештеләр. Кузовлардан сикерешеп төшкән милиция хезмәткәрләре — яшь кенә егетләр мәйданда тапталган яисә яраланып егылган әби-бабайларны кул-аякларыннан өстерәп китерәләр дә, берсе башыннан, икенчесе аякларыннан тотып бер-ике атындырып алгач, машина кузовына тотып ыргыталар. Авыррак кеше булып чыкса, шундук өченчесе ярдәмгә килеп җитә. «Ай-вай»га, сыкрануларына карап тормыйлар, тоталар да ыргыталар. Алар анда барып төшкәч, нишли, утын пүләннәре кебек берсе өстенә икенчесе өеләме, кан саркып үләме — белүче, кызыксынучы юк.

Без малай чакларда авылга эт атучылар килә торган иде. Шулай кыралар-кыралар да, үле этләрне ат чанасына, шул рәвешле, алгы һәм арткы аякларыннан тотып, болгап торып ыргыталар иде. Төяп китеп тә баралар. Авыл халкы, бахырларым, авыз ачарга да белми куркып, югалып кала. Үзләрен тотып атмасалар, башкасына түзә инде ул.

Биш-ун минут дигәндә, мәйданны чистартып та куйдылар. «КамАЗ»лар, шомлы үкерү авазлары чыгарып, билгесез тарафка тизелешеп китеп барды.

Безнең авызлар ничек ачылган булса, шулай хәрәкәтсез калган.

— Рәхмәт, улым,— дип, миңа таба борылды пенсионер карт. Үзенең дә шул «КамАЗ»ларның берсендә булу ихтималын аңлаган иде ул.Күзләре күргәнгә ышанмый.— Менә бит ни кыланалар. Үзебезнең кешеләр, урыслар бит... Славяннар, югыйсә...

«Бабай,— дип әйтәсем килде үзалдыма.— Сине коткарган кеше татар бит. Игътибар иттеңме шуңарга».

Әйләнә-тирә беркадәр тынычлана төште. Мәйданның ерак почмагындагы метро тукталышы тарафында гына ыгы-зыгы, «ух-ах» дәвам итә иде. Өч яктан урап алганнар да метро ишекләренә кысрыклыйлар халыкны. Лап та лоп ишәләр резин күсәкләр белән. Этешәләр, төртелешәләр, ишекләргә сыймый изалана, бәргәләнә кеше. Башлыча әбиләр һәм бабайлар калган. Яшьрәкләр, елгырраклар күптән качышып беткән инде. Алар бит замана балалары. Мәрхәмәт, кешелек, иман төшенчәләрен белми, кечкенәдән мат ишетеп, матур сүзләргә алданмый үсәләр. Джунгли кануннарында тәрбияләнәләр — көчле көчсезне ашый, югалып калсаң — кабып ук йота.

Ә әби-бабайлар кайда да бер, Мәскәүдә дә бик беркатлылар икән. Сүз белән аңлатмакчы, иманга китермәкче булалар ОМОНны. Имансызны, бар көт, китерерсең иманга...

Соңрак, шул мәхшәрнең уртасында булган кешедән ишетеп белдек: таза-таза ОМОН егетләре метро бинасы эчендә тәмам кансызлык күрсәткән. Кыйнау гынамы соң, кая барырга, ничек качып котылырга белмәгән кешеләрне тимер калканнар ярдәмендә эскалаторга кысып керткәннәр. Кеше өстенә кеше өелгән. Эшләп торган эскалатор баскычларыннан олы яшьтәге әбиләр баштүбән тәгәрәшеп төшкән диләр хәтта. Ә эскалатор баскычлары, күреп беләсездер, карап торышка гына матур алар. Чынлыкта исә, иттураткыч машиналардан бер дә кайтыш түгел.

Кызыл Пресня метросын вакытыннан элек япканнар ул кичне. Аннан төн буе сабынлап юганнар. Әмма ничек кенә тырышмасыннар, җинаять эзләре, кан таплары икенче көнне дә бетмәгән иде әле анда.

Без Кызыл Пресня район Советы бинасын эзләп киттек. Орлов белән минем Мәскәүне белүебез чамалы, чөнки даими яшәгән кешеләр түгел. Ә соңгы өч ярым елга килсәк, ул вакыт та, нигездә, Югары Совет бинасы белән Кремль арасында һәм «Россия» кунакханәсендә узды. Захаров — Мәскәү кешесе, танылган икътисадчы-галим. Элек-электән Үзәк Комитет һәм Совмин кебек югары даирәләрдә бөтерелгән, район Советлары белән вакланып тормаган.

Таптык. Кызыл Пресня район Советы Ак йорттан күп булса, ярты чакрым ераклыкта, Мәскәү елгасыннан күтәрелгән калкулыкта урнашкан икән. Кызыл кирпечтән салынган өч катлы затлы бина. Ишекне ачып кергәч тә чирканып киттек. Каршыбызда тагы әлеге дә баягы шул автоматлар белән коралланган ун-унбиш ОМОН басып тора. Баскычларда һәм югары катларда да шулар. Чормага тикле менеп кунаклаганнар. Әмма болары, урамда кеше таптаучылардан аермалы буларак, һәммәсе өлкәнрәк яшьтә һәм тазалар. Соңрак кына мәгълүм булды, болар һәммәсе — «спецназ» офицерлары икән.

— Сезнең тынычлыкны һәм тәртип саклыйбыз,— диде үзләре. Аз сүзлеләр. Депутатларга каш астыннан сөзеп карыйлар. Автоматлары һәрчак муенда. Кергәндә-чыкканда, документ тикшерәләр. Әмма бәйләнмиләр, авыр сүз әйтмиләр — анысы өчен дә рәхмәт инде.

Икенче катка күтәрелдек. Утырышлар залында алма төшәр урын да юк. Депутатлар һәм төрле-төрле сыйфаттагы сәясәтчеләр. Билгеле инде, Президиум өстәле. Бу илдә башкача булмый да торгандыр. Һәм ул өстәл, табигый ки, буш түгел. Аның артында утыручылар, гәрчә бернинди сайлау узып вәкаләт алган булмасалар да, инде Хасбулатовка охшатып, түрәләрдәй килештереп сөйләшәләр.

— Сез ничек монда килеп эләктегез, Ак йорттагылар исемлегендә дип белә идек сезне,— дип, башын күтәрде өстәл артында рәислек иткән иң зур түрә. Ул үзе халык депутаты иде, әлбәттә. Әмма Югары Совет әгъзасы булмагач, фамилиясен өчебездән беребез хәтерли алмады. Ә «җитәкче» кешенең үзеннән сорау, ничектер, уңайсыз.

— Без шәһәргә чыккан идек. Кире кереп булмады,— диде арабыздан беребез.

— Әнә, ишек катында кызлар утыра, шунда барып теркәлегез. Бу — съездның филиалы. Ак йортка һәр көн мәгълүматларны тапшырып торабыз. Утырышларга йөрү мәҗбүри... дип әйтә алмыйм, әмма намус эше,— диде ул.

Димәк, элемтә бар, дигән мәгълүмат алдык. Ишек катында утыручы кызлар безгә таныш, алар Югары Советның оештыру бүлегеннән. Инде өчебезнең дә исем-фамилияләребезне исемлеккә теркәгәннәр. Имзаларыбызны куйдык. Кызыл Пресняда теркәлгән йөз алтмышынчы депутат идем булса кирәк. Шунда ук Югары Советта эшләүче аппарат хезмәткәрләре теркәлгән икенче исемлек.

Үзенә күрә бер кызык табып яисә махсус күзәтеп йөрүчеләр шактый икән монда. Журналистлар, шул исәптән, чит ил журналистлары байтак. Кемдер, безнең әле генә Югары Совет бинасыннан чыккан булуыбызны хәбәр иткәнме, алар өчебезне дә аерым-аерым уратып алды. Сораулар яудырырга керештеләр.

«Бинада ничә депутат калды? Көчләп тоталармы? Ашарга-эчәргә бармы? Хасбулатовны кем белән алыштырырга җыеналар? Депутатларга автомат өләштеләрме? Стингер ракеталарын кайда, түбәгә урнаштырдыгызмы?»

Соңрак, үземне бер читкә алып китеп, Рейтер агентлыгы һәм Аргентина телевидениесе журналистлары шактый сораштырып маташтылар.

— Сез Татарстаннан, Татарстанның бәйсезлеген яклап чыгыш ясый идегез. Югары Совет сезне якламады. Шул консерватив парламентны ташлап чыгып китәргә тиеш түгел идегезме сез? — дигән сораулары күңелгә уелып калган.

Җавабым төгәл генә хәтердә түгел. Әмма түбәндәге фикер әйтелгән булса кирәк: «Бүген дә Татарстанның бәйсезлеге тарафындамын. Әмма Россиядә демократия һәм кеше хокуклары сакланмый икән, бу хәл Татарстанга да турыдан-туры тискәре йогынты ясаячак...».

Рейтер агентлыгы бу интервьюны файдаланган булып чыкты. Аны телевидение аша күргән Равил Бохараев бу хакта бераз соңрак Лондоннан шалтыратып хәбәр итте.

Анысы бер хәл. Октябрь вакыйгалары узып, ике-өч ай гомер кичкәчтен, миңа Америка Кушма Штатларына барып чыгарга туры килде. Көннәрнең берендә күптәнге танышым, АКШтагы төрки халыклар ассоциациясе президенты Әхмәт Али Арсланның Вашингтон читендәге ял йортында чәй эчеп утырабыз. Бер читтә телевизор эшләп тора. Әмма аңарга игътибар итүче юк.

Көтмәгәндә Әхмәт Али тавышын күтәрде:

— Бак, Ринат кардәшем, бак, сине күрсәтәләр...

Кызыл Пресняда бирелгән интервьюны тулысынча кабатладылар. Һәм шунысы гаҗәп, гаеп эзләп түгел, минем фикерләремне куәтләп сөйләде алып баручы, Россиядәге башбаштаклыкка офтанып сөйләде...

Кызыл Преснядагы мохит күңелләребезгә хуш килмәде. Монда ихласлык түгел, уен атмосферасы тантана итә иде. Без кайтырга җыенып чыгу юлына юнәлдек. Каршыбызга кара канга батырып кыйналган ике-өч халык депутаты кайтып төште. Константинов, Уткин һәм тагы кемдер. Болар теге Кызыл Пресня мәйданында без очраклы рәвештә тамаша кылган митингны оештыручылар арасында булган икән. Берничә депутатны вәхшиләрчә типкәләп тимер читлекле автомашиналарга ыргытып алып киткәннәр икән, дигәннәр иде. Дәрескә чыккан. Менә бит ничек?!.

Ишек төбендә үзем җитәкләгән даими комиссия әгъзасы, Иркутскидан халык депутаты булып сайланган Валерий Хайрюзов белән очраштык. Гомер булмаган эшлеклелек белән каядыр ашыга иде. Тиз генә хәл белешеп алдык. Ул мине читкәрәк тартып китерде һәм сер итеп кенә колагыма пышылдады:

— Ак йортка кереп барышым,— диде.

Минем өчен сенсациягә тиң мәгълүмат иде бу.

— Нинди юл? Анда керү мөмкин түгел ич?

— Мөмкин. Җир өстенә сак куйсалар, җир асты юллары бар,— диде ул, бер горурлык белән, эре генә. Ир-ат вакыт-вакыт сабый бала сыман була икән бит ул. Гомер пошмас, гаҗәпләнмәс Валерий тәмам дәрткә кергән. Иллене узган, очучы булып пенсиягә чыккан, ә күңелендә сабыйлык җуелмаган.

— Җир асты юлларын ОМОН саклый түгелме,— дидем ярымпышылдап.

— Алар белмәгән юл бар...

— Мине дә алыгыз булмаса. Минем дә анда буласым килә,— дидем.— Җитәкчелеккә тапшырасы хат та бар иде кесәмдә.

— Миңа гына бәйле түгел, Ринат,— диде Валерий.— Иван Савельев белән элемтәдә тор. Ул сиңа ярдәм итәр.

Һәм үзен көтеп торучылар артыннан йөгереп китеп тә барды. Боегып, Валерий Николаевичтан беркадәр көнләшеп тә карап калдым. Шул сәгатьтә минем өчен Югары Совет бинасында, анда тоткынлыкта калган танышларым янына кире әйләнеп кайтудан да әһәмиятлерәк нәрсә юк иде. Нинди максат белән һәм кая китүемне белүчеләр аз. «Татарин сбежал янсә Ринат качкан» дигән сүз чыгарсалар, башыңны кая куяр тишек тапмассың...

М. Захаров белән А. Орлов өйләренә, гаиләләре янына кайтып киттеләр. Минем ашыгыр җирем юк. Күңелемә, кичекмәстән Югары Совет бинасына әйләнеп кайтырга кирәк, дигән уй кереп оялады. Иван Савельев — танылган рус шагыйре. Аны Югары Советка эшкә урнаштырган кеше мин бит. Керү юлларын белүе хак икән, димәк, кемгә-кемгә, ул иң элек миңа ярдәм итәчәк.

Иван Савельевны ул кичне таба алмадым. Аның каравы якташым, Түбән Кама егете, халык депутатларыннан иң яше саналган Наил Махияновны очраттым. Хәер, ул да каядыр китәргә ашыга иде, минем генә бер барыр җирем юк. Тынчу залда утыра алмадым, коридордагы сәясәтчеләр һәм журналистларны күрәсем килми. Сәгатьләр буе интервью

алырга мөмкин Россия журналисты, шул сәгать эчендә бер төгәлсезлек яки эмоциональ сүз ычкындыруың ихтимал. Башкаларын йомып, алар шул сүзне аерып алып халыкка күрсәтәчәк, сөйләячәкләр. Андыйлар белән иң яхшысы көрешмә дә, белешмә дә.

Наил Махиянов белән ичмасам уңга-сулга каранмыйча рәхәтләнеп бер татар телендә сөйләшеп, эчне бушатырга була. Яшьлегенә карамастан, ул гаять әзерлекле, туры һәм мөстәкыйль үз фикере булган кеше. Сәясәттә исә ул аеруча әзерлекле. Кызганыч, шундый егетләрнең кадерен белү юк бездә. Татарстан дәрәҗәсен теләсә кайсы югарылыкта яклар-лык, сакларлык бит ул. Ә аны, дөм сукыр авыру әнисен карап гомер иткән яклаучысыз буйдак егетне, 1995 елдагы Татарстан һәм Россия сайлауларында кирәксез таптылар. Халык түгел, аппарат кирәксез тапты. Таш йөрәкле булсаң да әрнеми түзеп булмас...

Наил белән байтак кына ара янәшә сөйләшеп бардык. Табигый инде, Кызыл Пресня метросы ябылган. Анда ватылган-сынган кешеләрне җыештыралар, бер-ике сәгать кенә элек безнең күз алдында булган кыямәттә коелган кан эзләрен юалар иде булса кирәк. Читләтеп, әйләнгеч юллар белән, «Баррикадная»га киттек.

Кайчакта, безнең Наил белән сәяси карашлар килешми, төрле-төрле була. Ул да үзсүзле, мин дә үҗәт. Әмма соңгы арада Мәскәүдә барган вакыйгаларга мөнәсәбәтебез уртак иде — илдә фашист режимнарына гына хас вакыйгалар дәвам итә. Һәм бу хәлләр болай дәвам итсә, безнең Татарстанда да чагылыш тапмый калмас...

Метрога юл берьяклы гына булып чыкты. Кертүен-кертәләр, әмма һичкемне чыгармыйлар. Шуңа күрә тукталышка барып җиткәнче үк хушлашырга, аерылышырга мәҗбүр булдык. Наил Махиянов бераз иләбөгелә төшеп, гадәтенчә дәү-дәү атлап чайкалгалап китеп барды. Ә мин калдым. Кичке унберләр тирәсендә, Мәскәүнең үзәгендә урам читендә бер ялгызым торып калдым.

Хәер, бер ялгызым түгел, кая карама, анда милиция. «Минем милиция — минем сакта», дигәнме әле шагыйрь. Булган бит заманалар. Ә бу милиция миңа арка куйган. Рәт-рәт булып тезелгәннәр. Югары Совет бинасына таба борылыш басканнар. Юк, бу теге блокада түгел әле, алары ике йөз метрлар чамасы эчтәрәк, алары янына якын да җибәрмиләр хәзер.

Башымда фуражка, өстемдә күн куртка, кулларым кесәдә. Әкрен генә, ипле генә атлап барам. Миңа аркалары белән торган милиция егетләреннән ике-өч метр читтәрәк булырга тырышам. Ә күзләрем һәм игътибарым аларда. Ни уйлый икән болар, ни сөйләшә икән... Чынлап торып баксаң, болар да бит безнең кебек үк авыл мужигы яисә эшче балалары.

Кинәт, ни хикмәт, татарча сөйләшкән аваз ишетәм. Тавык төшенә тары керә дигәндәй, ялгыш ишетәмме әллә, дим. Юк, хакыйкатьтә икән. Янәшә басып торган милиция формасындагы ике егет үзара татарча гәпләшә. Туктап калдым. Һәм ипле генә якынлаштым боларга. Татарстаннан милиция булсын, ОМОН булсын, җибәрелмәгән дип ишеткән идем, югыйсә.

— Егетләр,— дим,— сез кайдан?

— Нижгардан...

— Ни эшләр бетерәсез монда?

— Менә сүләшәбез әле. Монда кызлар күп безнең авылдан. Кичен качарга да, шул кызлар янына таярга дип, сүләшеп торабыз.

— Соң, тотыгыз да китегез,— дигән булам башымны җүләргә салып.— Без яшь чакта кызлар дигәндә ике уйлап тормый идек.

Мин егетләргә якынрак килдем. Алар хезмәт урынында ич, ташлап китә алмыйлар. Кешечә сөйләшеп тордык беркавым. Безнең татарча сөйләшкәнне күреп, тагы бер-ике егет аваз биреп алды. Янәшәләрендә торган рус егетләренең дә исләре китмәде.

— Якташыгызмыни? — дип, кызыксынды берсе.

— Мәскәү — безнең шәһәр. Арбат — үзебезнеке,— дип җавап кайтарды аңарга татар егете.

Байтак ара сөйләшеп торгач кына егетләрнең берсе сорап куйды:

— Ә сез, абый, үзегез кем соң, Казан татарымы?

— Әйе,— мин әйтәм.— Каян белдегез?

— Сөйләшүегез безнеңчә, чын татарча түгел,— диде, әзмәвердәй таза егет һәм көлеп куйды.— Сез, бәлки, безнең авылдан Хәйдәр Бегичевны ишеткәнегез бардыр әле. Җырчы ул. Хатыны да җырлый.

— Беләм,— мин әйтәм.— Яхшы беләм Хәйдәрне.

— Үзегез кем соң? Әллә тоже артистмы?

— Артист түгел, язучы.

— А-а-а,— дип, язучының кем булуын хәтергә төшерде ул.— Писательмени...

Хәйдәрне дә белгәч, Нижгар егетләре арасында мин тәмам үз кеше булып киттем. Ничек булса шулай, монда ни эшләп йөрүемне аңлаттым. Минем халык депутаты булуым аларны үземнән читкә тибәрмәде, киресенчә, кызыксыну һәм хөрмәт беләнрәк карый башладылар. Тамаклары ач икәнлеген сөйләделәр. Ике сәгать басып торгач, үзләренә алмаш килә икән. Аннан ике сәгать машина кузовында утырып ял итәчәкләр. Һәр ике сәгать саен шулай кабатлана икән. Инде өч тәүлек җылы ризык күрмәгәннәр... Мәскәүдә яшәүче авылдаш кызларны искә төшермәс җиреңнән төшерерсең шул.

Иртәгесен Кызыл Пресня район Советы бинасында Иван Савельев мине үзе эзләп тапты.

— Сез өчәү чыккан булгансыз, әмма Югары Совет бинасына берегезне генә алып керә алам,— диде, бик эшлекле кыяфәт белән.

М. Захаров, А. Орлов һәм мин бер-беребезгә карашып куйдык. Тозактагы Парламент бинасына әйләнеп кайту теләге беребездә дә сүрелмәгән. Әмма «мин керәм» дип әрсезләнергә ашыкмадык.

Савельевның вакыты тар иде, күрәсең.

— Барыгыз да керергә тели, шулай бит? — диде ул, бер карарга килеп.— Әмма, бик теләгән очракта да мин берегезне генә ала алам. Җир асты юлы әйләнгеч, кысан һәм тынчу...

Башкалар дәшмәде. Миңа да килешмәс иде әрсезләнү.

— Алай булгач, мин үзем Ринат Сафиевичны алып керергә теләр идем. Ул яшьрәк тә... Һәм минем турыдан-туры буйсынган җитәкчем дә бит әле. Юкса, ахыры яхшы булмас,— диде Савельев, шаярган атлы булып.

Өлкән агайлар безгә хәерле юл теләп калдылар. Югары Совет бинасыннан ярты чакрым чамасы ераклыкта урнашкан чиркәү идәне астындагы подвалдан башланды җир асты сәяхәтебез. Өч кеше идек. Иван Савельев, мин һәм тагы миңа таныш булмаган бер кеше. Юл күрсәтүче булгандыр дип уйлыйм. Кулларыбызга кесә фонарьлары тоттык. Дөм караңгы, монда урам себерүчеләр дә юк икән, аяк астында таш һәм түмгәк, баш очында төрле юанлыктагы торбалар сузылган. Билгесез кеше хуҗаларча кисәтергә кирәк тапты. Юлда ух-ах килмәскә, борын тартмаска һәм пышылдап та сөйләшмәскә. Юкса капкынга эләгүебез дә бик ихтимал икән. Чөнки шул көнгәчә фаш ителми калган бердәнбер юл иде бит бу.

Миңа, башлыча, иелә төшебрәк барырга туры килде. Беренчедән, буй бәласе. Икенчедән, юл тегеләрнең икесенә яхшы таныш. Аннан, гомумән, җир астыннан курку яши минем күңелдә. Балачактан, кар базына төшмәс өчен дә, төрле хәйлә эзли торган идем. Ә бу башка очрак, монда җир өстен танк һәм БТРлар урап алган булса, җир астын автоматлар белән коралланган ОМОН һәм махсус өйрәтелгән овчаркалар саклый. Ул-бу була калса, иман китмә. Очрамадылар, Алла рәхмәте. Ул юлны алар без

үтеп тагы ике көн узгачтын гына эзләп тапканнар. Монысы соңрак мәгълүм булды.

Югары Совет бинасындагылар бер-берсен яхшы таный. Мине дусларым, танышларым кочаклап диярлек каршы алды. Аларга буш кул белән кермәдем, әлбәттә. Өч бөтен икмәк, ике кисәк колбаса һәм байтак кына сыр алган идем. Ай күрде, кояш алды ризыкларны... Хатлар кичекмәстән адресларына җиткерелде. Алар арасында Полтаранинның Россия вакытлы матбугат органнарына юлланган яшерен телеграммасы күчермәсе дә бар иде. «4—5 нче октябрь көннәрендә Мәскәүдә булачак вакыйгаларны тыйнаграк яктырту киңәш ителә» — дип язылган иде ул документта. Сүзгә сүз шулай.

Ишетүемчә, бу телеграмманың эчтәлеге Руцкой һәм Хасбулатовка инде алданрак та мәгълүм булган. Паника уянмасын дип, хәбәр итәргә ашыкмаганнар.

Шулай итеп, 3—4 октябрь вакыйгалары өчен Югары Советны гаепләргә тырышу ул урынсыз. Әлеге канлы көннәр һәм вакыйгалар Россия Президенты һәм аның яраннары тарафыннан шул рәвешле алдан ук планлаштырылган булуы бәхәссез иде. Һәм бу факт документлар белән раслана.

Россия Федерациясенең барлык субъектлары да диярлек Югары Советны яклап чыккан иде инде. Мәскәүгә блокада, забастовка белән янадылар. Мәскәүгә төрле төбәкләрдән килештерү группалары килгән. Ингушетия Президенты Руслан Аушев, Калмык Республикасы Президенты Илюмжинов һәм Коми Республикасы Югары Советы рәисе Виктор Степанов аеруча активлык күрсәттеләр ул җаваплы һәм шомлы көннәрдә. Дин әһелләре, аерым алганда, Алексей II инициатива күрсәтте. Әмма Кремльдә хакимият башында утыручылар өчен һичнинди килешү кирәк түгел, алар канга сусаган. Радио-телевидение көн-төн халыкны гадәттән тыш вакыйгаларга, кан коюга әзерли. Имеш, Югары Советка илнең төрле төбәкләреннән фетнәчеләр килеп тупланган, коммунистлар һәм фашистлар... Үзләре дөньяда ни бар, шуның белән коралланган икән, атом бомбалары да юкмы икән әле, ди-ди тәкерек чәчәләр.

«Илне, дөнья халыкларын якынлашып килгән фашизмнан коткару» бәрабәренә, бик теләмәсәк тә, янәсе, көч кулланырга туры килмәгәе. Әнә шулай, каракның бүреге яна икән!

Мәскәү халкын ике атна дәвамына дөмбәслиләр. Гарипләнүчеләр, ОМОН итәге астында калып җан тәслим кылучылар да дистәдән артып киткән. Октябрь аена кергәч тә бермә-бер явызланды, кансызланды ОМОН. Сизәм, билгеләнгән көн, сәгать якынлаша. Хакимият кылган вәхшилекләргә каршы торырга әзер булучыларның саны, аның саен, көне белән түгел, сәгате белән арта бара. Бу исә хакимияткә теш-тырнак белән ябышканнарны тәмам пошаманга сала. Чаралары һаман шул бер: кызганмаска, уңга-сулга карамыйча кыйнарга, сытарга, таратырга. Рәсәйдә тупас көчкә генә буйсыналар...

2 октябрь көнне Бакчалар боҗрасындагы Смоленск мәйданына йөз меңләгән халык туплана. Митинг башланып китүгә, төрле яктан уратып алалар һәм кысырыкларга керешәләр үзләрен. Һәр тарафтан кысырыкланган халык чара күрергә мәҗбүр була, ике арада бәрелешләр башлана. Машиналар яндырыла, тимер кисәкләре һәм ташлар белән коралланган яшьләр милициягә каршылык күрсәтә. Нәтиҗә — көндәгечә, митингка килүчеләр арасыннан да, милиция хезмәткәрләре тарафыннан да үлүчеләр була, шифаханәгә эләгүчеләр саны йөздән уза. Көпә-көндез һәм илнең башкаласы Мәскәүнең үзәгендә бара бу хәлләр. Телевидение һәм радио ниләр сөйли торгандыр, Ходай үзе генә белә... Камалышта калган Югары Советны гаеплиләрдер, әлбәттә. «Бөтен гауга, фетнә шулардан» бит. Хуш, шулай да булсын. Ә бит әлеге 2 октябрь көнне булачак митингның урыны, сәгате һәм максаты берничә көн алдан ук билгеле иде

хакимият органнарына. Шулай булгач,халыкны җыелганга кадәр кисәтеп яисә таратып булмый идемени?
Була иде! Максат бүтән! Ыгы-зыгы, шау-шу кирәк. Корал куллану өчен сәбәп кирәк, сәбәп җитми.
3 октябрь. Бусы инде хаклы рәвештә «Канлы якшәмбе» саналырга тиеш көн. Мәскәүнең берничә мәйданында, көндезге берләр тирәсендә митинг башланырга тиешле иде. Соңыннан анда катнашучылар тыныч колонналар булып Югары Совет бинасына, Кремльгә һәм Останкинода урнашкан телевидениегә юнәлергә җыеналар икән. Бу хакта депутатлар мәгълүматлы иде. Мәскәүлеләргә дә радио һәм җирле матбугат аша әллә кайчан житкерелгән чакыру бу. Димәк, милиция һәм Дәүләт куркынычсызлыгы органнары алдан ук аякларын киенеп куйган булырга тиешле. Көтелмәгән яңалык түгел.
Көндезге 11 ләр тирәсендә кабинетыма таныш бер депутат килеп керде. Ул әле бүген дә Дәүләт Думасында җаваплы эштә эшли, шуңа, аның үз үтенечен истә тотып, исемен атамыйм.
— Нигә монда утырасың?—диде ул, сәлам бирергә дә онытып.— Мәскәү аяк өстендә, ә татар егете тик утыра. Килешә торган эш түгел бу, Ринат Сафиевич...
— Уйланып утырам әле менә. Эшсез утыру туйдырды, кайчан тайга кисәргә җибәрерләр икән, дим.
— Өлгерерсең,—ди бу.—Киттек... Бүген безнең җиңү көнебез булуы ихтимал.
— Ә иртәгә үзебезне тупка тотарга җыеналар, ди, әнә...
— Иртәгәсе көн өчен ишәк кайгырган, Ринат, әйдә, кузгалдык, Октябрь мәйданына. Анда йөз меңләп халык җыелачак икән.
— Кичен ни эшләрбез,—дим.—Монда керү юллары ябык икәнлекне беләсең ич.
— Халык белән булу хәерле. Кем белә, бәлки, блокаданы да өзә алырлар.
Бүген, менә хәзер генә, уйлап куйдым—минем әңгәмәдәшем йә әүлия булса кирәк, йә алдан ук хәбәрдар кеше... Юкса, бар көт, җиңел генә җибәрерләр идеме үзен хакимият органнарына. Гаҗәп нәрсә бу дөнья дигәнең...
Тәвәккәлләдек һәм шәһәргә чыгып киттек. Гадәттәгечә, чыгу юлы ачык. Ни хикмәт, таяк белән дә сукмадылар, күткә дә типмәделәр бу юлы. «Баррикадная» тукталышында утырып метро белән Октябрь мәйданына юнәлдек. Метро тукталышы ачык, милиция тәртип саклый: «Тизрәк чыгыгыз, җәмәгать, тизрәк»,—дип дәрт биреп, куәтләп үк тора.
Мәйданда зур митинг буласы. Бөтен Мәскәү хәбәрдар бу хакта. Әмма шәһәр администрациясе аны уздырырга санкция, ягъни рөхсәт бирмәгән, имеш. Рөхсәт район Советыннан алынган. Тукталыштагы өч үзйөрешле баскычның икесе югарыга таба хәрәкәт итә. Алар шыгрым тулы. Хатын-кыз юк диярлек, егетләр һәм ир-атлар буылып-кысылып югары күтәрелә. Ә өченче, түбәнгә таба хәрәкәт итүче баскыч буп-буш, ник бер кеше заты булсын. Гайрәтләре чамадан артып ташып торган яшь җилкенчәк, үзенә бер уен табып, каршы тарафка хәрәкәт иткән шул баскычтан югары йөгерә. Кызык күренеш, җан-фәрман йөгерәләр, ә алга китеш бик чамалы гына. Әмма, барыбер, максатларына ирешәләр...
Кысыла-төртелә югары күтәрелдек. Кояшлы, якты мәйданга чыктык. Анда инде алма төшәр урын да калмаган. Юк-юк, митингка җыелучылар түгел, бронежилет, каска һәм тимер калканнар белән сакланган милиция, ОМОН гаскәрләре тулган. Килүчеләр дулкын-дулкын булып тротуарлар, ишегалларына шыплап тулган. Тукталышның каршы тарафында җидесигез ашыгыч ярдәм машинасы тора, аларга кемнәрнедер носилкаларга салып ташыйлар.
«Ельцин—фашист. Кеше үтерүче...»—дигән авазлар дөньяны яңгырата. Анда-санда милиция хезмәткәрләренә якынлаша алган әби-

бабайлар агитация-пропаганда эше алып бара... Кызыксынып колак салам.

— Кемгә хезмәт итәсез, сез?

— Дәүләткә...

— Дәүләт кем соң ул — Кремльгә кереп оялаган бандитлармы, әллә халыкмы?!

— Безгә дәүләт акча түли, әби. Без эш урынында.

— Сезгә дәүләт түгел, халык түли, улым. Безнең кесәдән, налог түләүчеләр кесәсеннән.

— Бар, кит, әби, кит моннан, безгә сөйләшергә ярамый,— ди милиция хезмәткәре.

Җәт-җәт йөгереп килгән офицер нокта куя бу әңгәмәгә.

— Бу карт ана этне алып китегез,— дип әмер бирә егетләренә.— Нәрсә сөйләшеп торасыз аның белән.

Әбине ике култык астыннан әләктереп өстери башлыйлар. Әби кычкыра, акылга чакыра үзләрен. Ул да ялгыз түгел, аңарга ярдәмгә йөгерешеп киләләр. Резина күсәкләр хәрәкәткә килә. Әбигә ярдәмгә килүчеләр тарафында йодрыклар. Китә тартыш, китә сугыш. Әби онытыла. Ул йә китеп котыла, йә аяк астында калып таптала. Кемнәрдер канлы борыннарын кысып читкә тайпыла, кемнәрнедер алып китәләр. Кемнәрдер ятып кала.

Адым саен, почмак саен әнә шундый күренеш. Мин игътибар иттем, пропагандист әбиләр, ни хикмәт, милициягә якын киләләр, ә ОМОНга юк. Соңгыларының кыяфәтләре үк куркыныч чөнки.

— Нигә шулай? — дип сорадым берсеннән.

— Тегеләре бит, улым, кешегә охшамаган. Килеш-килбәтләрен кара инде, Әмиркә киноларындагы кебек бит,— диде өлкән ханым.

Хәер, мин үзем дә, хәтта тыныч-имин заманнарда да куркып, шикләнеп узам ул ОМОН дигәннәре яныннан. Дөресрәге, юлымда очрасалар, урамның каршы ягына чыгарга, урап узарга тырышам. Алла сакласын...

— Монда митинг булырга охшамаган,— дим, юлдашыма.

Әйтеп булмый, дигән кыяфәт ясап иңбашларын сикертеп куйды җавапка. Ул да дөньясын онытып әйләнә-тирәне күзәтә.

— Күрәсең ич, мәйданга берәүне дә кертмиләр,— дим, тынгысызланам. Белмим, ни кирәк булгандыр үземә. Тик кенә күзәтеп йөр дә, башың исән булганга рәхмәт укып, кайт та кит бит инде, югыйсә.

— Ринат... Ринат, кара, теге якта ни кыланалар,— дип, уйларымнан бүлде юлдашым.

Ни рәвешледер, Ленин проспектына килеп чыккан җиде-сигез ир-атны калкан, каскалар артына яшеренгән егерме-утыз ОМОН хезмәткәре уратып алган да дөмбәсләпме-дөмбәслиләр. Башларына резин таяк белән кундыралар иң элек. Теге бичара аңгы-миңге килеп торган арада аяк чалып асфальт юлга аударалар. Һәм кансызланып типкәләргә, таптарга керешәләр. Башларын калкытып, торырга азапланганнарының исә, эшләре тагы да харап: тимер калканның кыры белән китереп бәрәләр үзләренә. Муен тамырына әләгәме, башкамы, умыртка сөягенәме, анымоны уйлап торучы юк, чалгы белән чапкандай, тоташ кыралар гына. Канга батып җансыз яткан гәүдәләрне дә калкытып-калкытып тикшереп уздылар, юри генә үлгәнгә сабышып ятмыйлармы, янәсе...

Зур эш кырган сыман, өс-башларын рәтләштерә-рәтләштерә ОМОН читкә тайпылып, үз ишләре сафына барып кушылды. Кайсы әле генә кеше үтергән, ә кайсы гөнаһсыз, һич аерырлык түгел. Әнә, ничек җиңел икән. Бил каешын һәм каскаларны рәтләштереп куясың да, башкалар янәшәсенә килеп басасың икән. Җавап сораучы юк...

Якында гына торган өч ашыгыч ярдәм машинасы килеп тукталды җансыз гәүдәләр янына. Исәнлекләрен тикшереп, фәлән итеп тормады-

лар, носилкаларга тәгәрәтеп менгерделәр дә, машиналарга тыгып та куйдылар. Өч машина бер-бер артлы тезелешеп шомлы, ачы аваз салa-сала шәһәр үзәгенә таба китеп барды.

Шунда, әле генә мәйданда вәхшилек кылган ОМОН егетләреннән икесенең безгә шактый ук якынлаша төшүен абайлап алдым. Алар үзләрен халык төркеменнән аерып торган тимер рәшәткәгә килеп сөялде. Маңгайларыннан тир бәреп чыккан, битләре кызарган. Килгән шәптән үзара нидер гәпләшеп көлешеп алдылар. Арадан берәве күн итеген салып аягын хәстәрләү белән мәшгуль иде.

— Нәрсә булган, авырттырдыңмы әллә?— дип, хәлен сорашты янәшәдә торган, бу үтерүдә катнашмаган иптәше.

— Бармакны канаттым, ахры. Башына типкән идем, башы сөякле булып чыкты «стерваның»

Өлкәнрәге, тәҗрибәлерәге киңәш итте:

— Башка аяк очы белән тибәләрмени... Бармаксыз калуың бар. Итекнең үкчәсе ни өчен?!

Колак ишеткәннәрдән тән чымырдап куйды, эсселе-суыклы булып китте.

Бу әңгәмәгә колак салган бер әби тегеләрне үзенчә аптыратырга керешге.

— Ни эшлисез сез? Ни эшлисез?..

Җавап кыска.

— Поразмялись,— диде берәве, шаркылдап көлә-көлә, «Буыннарны йомшартып алдык» дигәе, янәсе.

Тротуарга сыеша алмый дулкынланган халык ни эшләргә, ни кылырга белми. Нәфрәтләре бердәм аваз булып яңгырый: «Үтерүчеләр... Фашистлар. Үтерүчеләр... Фашистлар...»

Башкаларның хәлен үземнән чыгып та аңлау кыен түгел. Тимер калкан диварларны үтеп, әгәр шул мәйданга йөгереп чыга алсам, үз-үземне белешмичә бер-бер ОМОН егетенең бугазына кыргый арыслан булып ташланыр идем кебек. Кулыма таш эләксә, аны өсләренә атар идем. Йөрәк күкрәккә сыеша алмый тибә... Минем дә башкаларга кушылып кычкырудан тыш чарам юк. Мин дә кычкырам: «Үтерүчеләр... Үтерүчеләр...»

Ни гаепләре булды икән ул егетләрнең... Нигә шул дәрәҗәдә кансыз булырга?! Күпме кеше карап торганда?! Көпә-көндез?! Үзен демократик ил дип игълан иткән Россия башкаласы Мәскәүнең үзәгендә?! Ленин проспекты башында, Ленин һәйкәле каршысында...

Ярый, мәйданга чыгу тыелган ди. Килешәм. Соң, үзләрен кире тротуарга куып чыгару да мөмкин иде бит, югыйсә. Инде, һич булмаса, кулга алырга да, машинага төяп алып китәргә үзләрен, закон бозганнар икән — җавап бирсеннәр. Хөкем итеп утыртсыннар үзләрен. Канга сусаган булсалар, соңрак та кыйный алган булырлар иде бит.

Юк, алай эшләмиләр. Шаһитлар да куркытмый үзләрен, адым саен очрап торган чит ил журналистлары һәм кинокамералардан да качмыйлар. Рәхәтләнеп, һичкемнән шикләнмичә изәләр, сыталар. Үз-үзләренә ышаныч гаять зур икән боларның. Ныклап тотынганнар. Һәм озакка... Озакка булыр бу!

Бер вакыйга келт итеп хәтергә төште шунда. 1992 елның май ае иде. Бер төркем язучылар — Андрей Вознесенский, Евгений Евтушенко, Борис Можаев һәм мин — Америка Кушма Штатларына каләмдәшләребез белән очрашуга килдек. Очрашулар Калифорния штатында Лос Анжелес шәһәрендә узарга тиешле иде. Без Нью-Йоркка килеп төшкәч кенә Лос Анжелес шәһәрендә гадәттән тыш хәл игълан ителде. Шул рәвешле, өч көн дәвамына безнең конференция кичектерелеп, Нью-Йоркта тоткарланырга мәҗбүр булдык. Монхеттенда Бродвей урамы чатындагы затлы Шератон кунакханәсендә көтеп яттык. Мин Нью-Йорктагы татар клубында очрашу уздырдым. Татарлар җәмгыяте рәисе

Илдар Агиш фатирында һәм Рөстәм белән Гата Камскийларда кунакта булдым.

Хакыйкатьтә болай булган. Лос Анжелес полицейскийлары, юк сәбәпне бар итеп, урамда бер кара тәнле шоферны кыйнап үтергәннәр. Ә җирле хакимият гаеплеләрне яклап калырга маташкан. Шуңа протест һәм нәфрәт йөзеннән урамга берничә йөз меңләгән халык чыгып бер тәүлек эчендә шәһәрнең астын-өскә әйләндереп ташлый — җимерә, вата, яндыра... Бунт күтәргән кара тәнлеләрне тынычландыру өчен күп кенә тәртип саклау органнары, полицейскийлар, хәрбиләр, янгын сүндерүчеләр чакыртыла. Штатның губернаторы һәм АКШның Президенты бөтен ил һәм дөнья каршысында кара тәнлеләрдән гафу үтенә, башкача андый вәхшилек кабатланмас дип, вәгъдәләр бирелә. Бары шуннан соң гына урамнарда тәртип урнаша, халык массалары өйләренә таралыша.

Без Лос Анжелеска килеп төшкәндә әле урамдагы тәртипсезлекләрне җыештыра да башламаганнар иде. Анда-санда кара күмергә әйләнгән биналардан төтен исе аңкып тора, ватык витриналар, кая карама, анда киеренкелек. Һәм менә шунысы гаҗәп: бунтка күтәрелгән халыкка күпме полицейский каршы торып та, ник берәүне кыйнасыннар яки яраласыннар икән.

Бөтен дөнья сөйләде ул вакыйгалар турында, ачынып сөйләделәр. Америка җәмәгатьчелеге тәүбә итте.

Ә бездә бер-бер заман тәүбә итү булырмы икән?! Әллә мәңге дәвам итәрме бу вәхшилекләр. Көчленеке — замана дип, җинаятьчеләр мәңге шулай туй итәрме?!

Мәскәү күз яшьләренә ышанмый икән шул. Алай гына да түгел, Мәскәүнең таш урамнары бер генә мәртәбә кан белән юылмаган. Гомумән, Россиядә кеше гомере чүпкә дә тормый икән ул. Хәтерегездәме, Сергей Ковалев атлы берәү Чечен Республикасындагы кеше хокукларын яклап бөтен илгә, дөньяга чаң суккан иде. Җинаятьчеләр түгел, Дәүләт Думасыннан торып читләштерделәр аны бу эшеннән. Россиядә кеше хокукларын яклау, иминлеккә чакыру — үзе җинаять эш булып чыкты кебек. Нишлисең...

3 октябрь. Мәскәү. Октябрь мәйданына әйләнеп кайтыйк.

Балтасы суга төшкән мужиктай онытылып торган чагым иде. Янәшәмнән җил-җил атлап Россия депутаты Илья Константинов узып китте. Таныды. Әмма туктап тормады, «әйдә-әйдә», дип үзе артыннан чакырды. Аргы тарафта шул ук миссияне шулай ук Россия депутаты Уражцев башкара икән. Ул да җил-җил атлый. Урам уртасыннан! Иярмәдем. Мин, гомумән, сакаллы кешеләрне артык өнәп бетермим. Һәм үзләренә ышануым да шул кадәрле генә. Ә инде чем кара сакаллы Ильяга үзенә бер үпкәм булмаса да, әйтим, ни сәбәпледер җитди карамадым. Аның өчен сәясәт бер уен кебек кенә тоела иде булса кирәк. Ул иң элек СССРны актив таратучыларның берсе булды. Инде «торгызырга керешә».

Ләкин ул тынгысыз. Аңарда бетмәс-төкәнмәс әрсезлек һәм гайрәт ташкыны бар. Менә хәзер дә, тротуар һәм ишегалларына шыплап тулган халыкны үзе артыннан ияртү өчен аның бер оран салуы җитә калды:

— Туганнар, кузгалдык,— диде, Илья Константинов. Һәм Ленин проспекты буенча бер квартал югарырак буылып торган халык, ташкын сыман, милиция төркемен урталай ярып алга — Октябрь мәйданына таба ыргылды. Каян килеп, кай арада тупланып өлгерде ул халык, әкияттә дә алай булмый торгандыр...

Әле генә дивар сыман торган ОМОН да сибелде, чәчелде як-якка. Милиция полклары да бернинди каршылык күрсәтә алмады. Әллә каршылык күрсәтергә теләмәделәрме икән?.. Ихтимал, бик тә ихтимал.

*Ахыры бар.*



# ШАГЫЙРЬ ҺАМАН ЮЛДА

Татарстанның халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе
**Гамил Афзал** —
журналыбызны укучыларның да
яраткан шагыйрьләреннән берсе.

**Менә 40 елдан артык инде аның әсәрләре — үзенчәлекле көлке һәм һөҗү шигырьләре, җылы, тирән хисле лирикасы, үзенә хас өслүбтәге, фәлсәфи-уйлы парчалары — иң әүвәл «Казан утлары» битләрендә дөнья күрә килде. Елдан ел сүз-сурәт дөньясын баета гына барган, үткен, саллы акыл-фикерле, аксакалларча зирәк һәм моңсу, иронияле, хәтта усал да... ә кайчакта Хуҗа Насретдиндай мәзәкчел, шук, тапкыр, халыкчан — күпкырлы бу шагыйребез бүген дә яза, мәйданга өр-яңа шәлкемнәрен, китапларын чыгара тора. Язары күп, «базары» да — аллага шөкер, аны кабул итә тора. Шигырь тулпары да — һаман дәртле, олы максатлы юлга ашкынган яшьләрчә җитез, һәр бәйгедә баш бирмәс горур...**

**Шуны да әйтеп үтик: бу шагыйребез хакында саллы-җитди зур мәкаләләр, эссе-күзәтүләр матбугатыбызда шактый күп булды. Ихтимал, инде монографияләр, китаплар да дөньяга килер — ул, һичшиксез, һәр яктан өйрәнүгә һәм тәкъдир итүгә лаек зат.**

**Ә без бу санда — үзебезнең даими авторыбызны һәм өлкән каләмдәшебезне олуг юбилее белән ихлас котлап (мөбарәк булсын чын мәгънәсендә халык шагыйренең 75 еллык бәйрәме!), укучыларыбызга Г. Афзалның яңа шигырьләреннән бер бәйләм тәкъдим итәбез.**

## ЯН, ЙОЛДЫЗЫМ, ЯН...

### Халык дусы

Уйчан-уйчан ак болытлар күрдем,
Болыннарым яшел келәм кебек.
Гел шатланып, гел сокланып йөрдем,
Мин бу җирдә бер дә үлмәм кебек.

Сөрәм, чәчәм, урам... Урман, буран —
Уйлап ятам шигырь сыйфатын.
Мин «халыкның дусы» булып торам,
Халык минем «баштан сыйпасын».

Тату торыйк, диеп еллар дәшә,
Мөлдерәмә илләр янәшә.
Кырлар алтын, болыннарда рәшә,
Шат пәйгамбәр булып йөз яшә!

Дин-әфиүн диеп сөйләшкән дә,
Фәйләсуфләр акыл өләшкән;
Бактың исә диннәр явызлыкка,
Кыргыйлыкка каршы көрәшкән!

## Өч юл чатында

Турыга китсәң — түрә буласың,
        Типтереп яши түрәләр,
Нотыклар сөйләп, ришвәтләр алып,
        Алар да төрмә күрәләр.

Уң якка китсәң — план куасың,
        Эшлекле кеше буласың,
Әллә уңасың, әллә туңасың,
        Гөнаһлы эшләр кыласың.

Сул якка китсәң — сулагай эшләр,
        Серле сукмакта югалма.
Хәвефле таңнар, борчулы кичләр,
        Кая барырга, уф алла!

Иң авыр эш ул — алдашып тору,
        Сәясәт кушкан уңайга,
Илне таларга планнар кору —
        Бармыймын, шөкер Ходайга!

## Шат егетләр

Үткәннәргә борылып карый-карый,
        Киләчәккә юллар эзлибез.
Бөек даннар булмаса да ярый,
        Яхшылыктан өмет өзмибез.

Итәк кисеп, җиңне ямый-ямый
        Тәртә буе алга киткәнбез.
Бөек даннар булмаса да ярый,
        Без өметле яшьләр икәнбез.

Алга таба кыю бар, диделәр,
        Собраниегә йөгер һәр кичен,
Озын-озын бурычлар өйделәр,
        Ярышып эшлә, имеш, ни өчен?

Гомер буе дус булабыз, дидек,
Гарасатлы җилләр искәндер.
Шат егетләр идек, кызлар сөйдек,
Еллар үтте, кемнәр исәндер...

## Яз җилләре искәндә

Яз җилләре исә, җылы җилләр,
Кар сулары агып китеп бара,
Җир яшәрә, бәхет көтә илләр,
Шик-шөбһәләр эреп бетеп бара.

Елмаясың җылы язгы җилгә,
Зәмһәрир суыклар калды артта.
Җылы, якты көннәр килә илгә,
Күңелләрдә өмет, шатлык арта.

Завод каршындагы мәйдан иде
Көн үткәндә ызгыш-талаш белән,
Зәңгәр күзле кыз елмайган иде,
Бик ягымлы, серле караш белән.

Завод каршындагы түтәлләргә
Әле һаман язлар килә кебек,
Әллә миңа, әллә бүтәннәргә
Шул сылу кыз һаман көлә кебек...

## Иманлы юл

Кемгә сыек шулпа, кемгә куе,
Табигый шарт иде кысанлык.
Шәп торабыз, диеп гомер буе,
Алдана-алдана ышандык.

Миһербанлы, әдәпле бул, дидек,
Тәкәббер булырга кушмадык.
Каян килде мәкерле мин-минлек,
Таш бәгырьле, көнчел дошманлык!

Манкорт татар туган телен белми,
Урысчаны белә ипи-тозлык.
Урыс телен белгән ачтан үлми —
Дия-дия, без милләтне боздык.

Татар теле нигә кирәк, ди ул,—
Халык булу өчен кирәктер,
Туган телдә генә иманлы юл,
Теләкләргә изге терәктер.

## Аңгыра патша бәете

Надан кеше патша булса ниләр булгай,
Әләкчеләр, ришвәтчеләр килеп тулгай,
Алабайлар коерыкларын болгай-болгай,
Каршысында ләббәйкә дип торыр имди.

Тик торганда терсәк буе шөһрәт килгәч,
Шуны юып, баш авырткач, иләс-миләс,
Казнадагы акчаны да саный белмәс,
Мин зур диеп, горурланып торыр имди.

Пинжәгенә түш тутырып тәңкә тагар,
Син шәп, диеп салам кыстырырлар аңар,
Дәүләт эше ничек барса, шулай ярар,
Бер урында гел таптанып торыр имди.

Казнадагы акчаларны «песи ашар»,
Яраннары алдау-талау юлына басар,
Халык яшәр бигрәк ярлы, бигрәк начар,
Әдәп әһеле гәзет күшәп ятар имди.

## Робот кебек

Газета карап куйдың да,
Яңа күрсәтмә көтәсең.
Стандарт булып тудың да,
Стандарт фикер йөртәсең.

Яңа фикер көткән күзең
Җансыз хәрефкә төртелде.
Аяклы автомат үзең,
Нәкъ робот кебек бертөрле.

Сәясәттә — без шәп инде,
Каян килсен яңа фикер.
Иң оятсыз заман килде:
«Көн үтте — аллага шөкер!»

Барыбер алдарлар сине,
Без шәп диеп ура кычкыр,
Иң кабахәт заман килде,
Сүзе ялган, бите — ыштыр!

## Яңа шагыйрь

Яңа шагыйрь килер, яңа сүз әйтер,
Көтмәгәндә, уйламаганда.
Безнең зиһенне, хисне киңәйтер
Көтмәгәндә, уйламаганда.

Бәхетләр артыр, хыяллар артыр,
Яктылык артыр бу урамда.

Мәгънәләр тулы өметләр балкыр,
Бәхетләр көтеп тик торганда.

## Курганнар төш күрә

Шумерлар, Хәзәрләр, Скифлар,
Кыпчаклар, Аланнар — кайда сез?
Яшәгән, югалган бик күпләр,
Эзләрен эзләү дә файдасыз.

Кылычка ябылып торганнар,
Шом салып шаулаган урманнар.
Җиңелгән халыклар күмелгән,—
Далада төш күрә курганнар...

* * *

Җидегән йолдыз җем-җем итә
Җиде юл чатларында.
Җидегән чишмә җәлеп итә
Җирсәгән чакларымда.
Җиде бабам җиде якта
Болгарым, Бортасымда.
Җиде ятып, җиде торам
Җиде төн уртасында.

## Хәтер

Заман агышларын сизәсең дә,
Хәтер күлләрендә йөзәсең.
Әллә кайчан сүнгән учакларның
Яктысында мәрҗән тезәсең.

Бәйрәм түгел иде, әйрән эчеп,
Зур зуратлар куйды ир-атлар.
Уралларда утлар-сулар кичеп,
Еракларда калды зиратлар.

## Ефәктәй гомерләр

Дуңгыз баласын кочаклап,
Фотога төшкән чибәр,
Черек системаны мактап,
Ирәеп җырлап җибәр...

Якты тормыш көтә-көтә,
Ефәккә төренмәдең,

Тирескә капланып үтә
Ефәктәй гомерләрең.

## Көмеш шигырь

Алтын каләм белән көмеш шигырь,
Көмеш төсле шигырь яз, иптәш.
Әллә кемнәр сөенеп укыр әле,
Сагынып сөйләр әле без киткәч.

Яңа чорга кереп бара-бара,
Иске бәет казып чыгардык.
Еракларга, тирәннәргә кара,
Бик катлаулы икән чынбарлык.

* * *

Басуларда җир тырнагач көзле-җәйле,
Шөкер әле, өстәлебез ипи-чәйле.
Җиребезгә ятлар килеп хуҗа булса,
Нишләрбез, дип утырабыз әйле-шәйле.

Шөкер әле, чишмәбез бар су эчәрлек,
Бер кишәрлек җиребез бар гөл үсәрлек.
Илне яклап, утка кердек, суга кердек
Шушы тормыш өченме, дип ис китәрлек!

* * *

Бик матур төш күреп уяндым.
Урамда болытлы соры көз.
Кайларга киттең дә югалдың,
Сихерле, сөйкемле, соры күз?

Олы шул, озын шул безнең ил,
Сагышлы сыкрана көзге җил,
Кояшлы, чәчәкле көннәрдә
Сөйкемле көләсең кемнәргә?

## Шик-шөбһә

Шик-шөбһәдә еллар үтеп бара,
Кара төннәр кебек күңел кара.

Ышанмау һәм курку җанга сеңгән,
Бүгенгесе кыйммәт һәммәсеннән.

Ил күгендә кара болыт та бар,
Зәгыйфь кенә нурлы өмет тә бар.

Кит әле син, шомлы, кара болыт,
Нурлы кояш чыксын өмет булып!

## Пәйгамбәрдәй затлар

Казан арты шәп егетләр биргән.
Абзар арты шәп бәрәңге биргән.
Ал чәчәкләр, гөлчәчәкләр бердәм
Үсеп чыга тирес түккән җирдән...

Арыш уңган, диеп сөенеп йөргән
Чабаталы, гади халыктан
Туган ягын үлмәс данга төргән
Пәйгамбәрдәй затлар калыккан.

* * *

Карт шагыйрьләр белән бәхәсләшәм,
Яшь шагыйрьләр үсә тора,
Һәр шагыйрьнең моңы истә тора,
Җилләр исә тора.

* * *

Ян, йолдызым, ян, дисең син,
Йөрәкне тотасың да,
Алла оныткан далада,
Җиде төн уртасында.
Ян, йолдызым, ян!

## Бар иде

Җитмеше җитеп килә,
Аңа да кызлар карады
Хәйләкәр итеп кенә.

Ямаулы толып кигән,
Аңа да кызлар елмайды
Астыртын өмет белән.

Яшь иде, матур иде,
Өздереп гармун уйнаган
Елларга кайтыр иде.

Киң урамнар тар иде,
Ак бәхетләр өмет иткән
Айлы кичләр бар иде...

* * *

Безгә каш сикерткән кызлар
Лаек ялга киткән инде,
Үтте язлар, акты бозлар...
Күптән инде.

* * *

Ямьле көннәр булды үткәннәрдә,
Нәфис гөлләр үсте түтәлләрдә,
Хәзер калды үткәннәрне уйлап,
Ачы дару эчеп ютәлләргә...
Үткер-тапкыр, шаян яшьлек белән,
Ак бәхетләр телик бүтәннәргә!

* * *

Сандугачлар канат каккан
таңнарым ерак калды.
Офыкларга карап яткан
тауларым ерак калды.
Агым суга башын иеп,
талларым елап калды.



# ШИГЪРИЯТ



**Фәрит Габдрәхим**

## ВАТАНДАР ХИС

### Бераү генә

*...Ватан катлы-катлы булмый.*

Р. Фәйзуллин.

Ничәү була икән анаң-атаң,
Ничәү була икән изге Ватан?..

Мең дә биш йөз илле икенче ел...
Ватаныннан татар мәхрүм калган.
Илем күкрәгеннән төшкән калкан,
Айлы манаралар төшкән чалкан.
Баш калкытсаң — кяфер башны чапкан,
Җиде катлам җиргә аккан ал кан.
Ерак бабам «Ватан!» дисә, Мәскәү
Аркасына камчы белән тарткан.
«Татар — хәтәр! — дигән. — Әйдә алдан!»
Басып алган җирләр һаман арткан.
И татарым! Ничә гасыр буе
Корыштың син Империя — «Ватан»...
Шулмы синең Ватан — канга баткан?!
Халыкларны кетәкләргә япкан?!
Имеш, олы Ватан, кече Ватан...

Бераү генә була анаң-атаң,
Бераү генә була изге Ватан!

## Алдану

«Житте! — диде атлар.— Күпме мөмкин
Чиләнергә кысан аранда?!»
Тышауларын өзеп, кушаяклап
Чыгып чапты иркен яланга.

Ишетелә: «Ирек! Ирек!» — диеп
Йөрәкләрнең бердәм типкәне.
Каян белсен атлар бу яланның
Бары зуррак утар икәнен.

Атлар хуҗасының йөзе көләч,
Ниятләре мәкер-тозаклы.
Бер кулында — корык, ә берсендә
Яңа тышау — богау йозаклы.

## Империя

Империянең барсы да
Яши ала читексез.
Империянең берсе дә
Яши алмый читлексез.

## Әйтерсезме?

Үз итмәде безне Империя,
Тәтемәде җылы кочагы...
Оста хирургтай, хәтерләрне
Торды телеп үткен пычагы.

Шуңа күрә без — инвалид халык,
Шуңа күрә — манкорт, хәтерсез.
Империя галиҗәнапләре,
«Кичер!» диеп кайчан әйтерсез?!

Юк, әйтмәссез, ахры...

## Илләр

Диңгез исе килгән илләр бар,
Дуңгыз исе килгән илләр бар.

Ал таң исе килгән илләр бар,
Ал кан исе килгән илләр бар.

## Кайчан үтәр?

Чатнама суык тынны куыра,
Бөтен нәрсә кысыладыр кышын.
Тимерчыбык хәтта кыскарадыр,
Нык кыскара юлы очар кошның.

Ничәмә гасыр чатнама суык,
Бик-бик кыска барыр юлларыбыз.
«Хуҗа ничек карар эшебезгә?» —
Шуннан ерак китми уйларыбыз.

Ачы язмыш ярыгына кемдер
Шүрәлене түгел, безне кыскан.
Башка аебыз юк — гел декабрь,
Көннәребез безнең ифрат кыска.

Иңен-буен кисеп кыскарттылар,
Ил диярлек түгел илебезне.
«Каравыл!» — дип хәтта кычкырмыйбыз:
Кыскарттылар туган телебезне.

Кайчан үтәр икән татар кышы?

## Кол фаҗигасе

Ничә гасыр инде Хуҗа абзый
Бертуктаусыз колын камчылый.
«Чаж-чож! Чаж-чож!» — тәне куырыла,
«Чаж-чож! Чаж-чож!» — каны тамчылый.

Хуҗа абзый сөртеп ала тирен,
Изү ачык, җиңен сызганган.
— Абзыкаем, бераз хәл җыеп ал! —
Кол Хуҗасын ифрат кызгана.

## Кылыч вә йөзек

### I

Гаугалы булган заманнар,
Аяусыз булган, кырыс.
Еллар катламы астында
Саклангаи канлы кылыч.

Казанны суйган кылыч ул.
Җаннар һаман дерелди.
Тапты аны Колшәрифнең
Хак оныгы Гөргөри.

Гасырлар туты алмаган,
Коелган шәп корычтан.

Яңа сәмруг кошны койды
Гөргөри шул кылычтан.

II

Барысын да вакыт тигезли,
«Яңара» Колшәриф нигезе:
Бабасы келәтен сүткәндә
Гасырлар чүп-чарын түккәндә
Гөргөри күзенә ташланды
Бер йөзек — якуттыр ташлары.
Кәләшкә Колшәриф бүләге,
Аһ, затлы — көнләшеп үлмәле!
Гөргөри аңлаган төсле бик:
«Мөселман әбкәем төсе бит...»
Йөзекне кәләше Машага
Кидерде ашыга-ашыга.

Ниргәләр сүтелә, ниргәләр...
Ят моңнар нигезгә иңәләр...

## Исә җилләр

Исә җилләр хәтер үтәли,
Гасырларның өреп тузанын,
Тапмак булып исән кузларны.
Көннәр йончу — милләт ютәлли.
Исә җилләр хәтер үтәли.

Исә җилләр бәгырь үтәли.
Суынганмы учак көлләре,
Бабайлардан мирас гөлләрнең
Кемнәр туздырганнар түтәлен...
Исә җилләр бәгырь үтәли.

Исә җилләр тарих үтәли.
Убаларның сөйли кылганы
Җәлладларның ниләр кылганын.
Шәһит җаннар нигә үпкәли?
Исә җилләр тарих үтәли.

Исә җилләр заман үтәли,
Терелтмәкче сүнгән кузларны,
Дөрләтмәкче каен тузларын:
Җылы кирәк — халкым ютәлли.
Исә җилләр заман үтәли.

## Хәзинә

Тәре таккан чирү килә. Тиздән
Кол булачак Казан каласы.
Кая яшерергә?! Илбасарга
Эләгерме ханлык казнасы.

Кара төндә, хәтта шаһит Ай да
Юк чагында Казан күгендә
Мичкә-мичкә алтын-көмешләрне
Батырганнар Кабан күленә.

Риваятьләр сөйли... Риваятьләр
Күпме серен саклый халкымның.
Кан эчеп күбенгән җан кыючы
Хәзинәсен эзли ханлыкның.

Эзли — таба алмый!
«Ул хәзинә
Булмагандыр,— ди ул.— Кем белә...»
Ә мин әйтәм: «Булган!»
Эзлә, катыйль,
Мичкәләрне Кабан күленнән.
Ә син, халкым, эзлә күңелеңнән:
Бар байлыгың
Күңелеңә синең күмелгән.

## Синең белән мин

Берәү безнең телебезне кисә...
Телкисәрнең үтәп теләген,
Тирен сөртә, симез калҗа суза —
Кем дисеңме? — синең белән мин.

Бер кавемдәш югарыга үрли,
Җәһәннәмнән чыгу — теләге.
Чыгармады, аягыннан тартты —
Кем дисеңме? — синең белән мин.

Тәгәрмәчләр изеп уза үзен[1]:
«Юлда үсүен дә теләмим!»
Күтәрелә, кабат чәчәк ата —
Кем дисеңме? — синең белән мин.

## Рәхмәт!

*«Чабаталы морза» Әмирхан Еникигә*

«Динең яки малың?» — Илсуярлар
Куйган сорау кискен, янаулы.
Тота сынау татар морзалары,
Язмыш-ихтыярлар камаулы.

«Малым өчен түгел, динем өчен...
Лә илаһы...»— кемдер укынды.
«Динем өчен түгел, малым өчен...
Господи...»— дип күпләр чукынды.

---

[1] Татарник — шайтан таягы күздә тотыла.

Чукындылар — хәрам чукыдылар,
Мал-мөлкәтле дөнья — түгәрәк.
Илсуярлар чирүенә кучкәч,
Тәфтиләүләр булды дүәрән.

«Динең яки малың?» — Ошбу сорау
Ачып салды чын вә ялганны.
Чукынганнар итек-читек киде,
Чабатасын киде — калганы.

«Лә илаһы...» төшми телләреннән.
Җилдермәсәләр дә шәп атта,
Гомер буйларына җәяү генә
Йөрсәләр дә киеп чабата,
Җиталдылар барып, җиталдылар
Күңеленә туган халкының.
Бөтен байлыклары — гыйлем нуры,
Ник аларга көмеш-алтының?!

Рәхмәт, «чабаталы морзалар»!

*1994*

## Тел төбе

*Кәрим Яушевка*

Хәтәр юлга җыенабыз,
Ходай бирсен чыдамлык.
Әле менә ат җигәбез,
Җан тирләре чыгарып.

Холыксыз ат килде туры:
Тешләшә вә тибенә.
Җикмәгәнгә мондый атны
Дүрт гасыр бар кимендә.

Барасы юлларыбызны
Шул гасырлар җимергән.
Курганнар башында козгын:
«Җебегәннәр җиңелә!»

Яңа корбаннар көтсәң дә,
Искәрттең, козгын, рәхмәт!
Максатыбыз изге безнең,
Изгегә тимәс зәхмәт.

Сөембикә-ханбикәбез
Ни гомер тоткынлыкта.
Тәхетебез-бәхетебез,
Тарихыбыз коллыкта...

Коткарырга!
Тиешлебез
Максатка җитәргә без.
Үткәнебез тоткын икән,
Иректер — иртәгәбез?

Мәсхәрәле көлә козгын:
«Анда юл юк, тиләләр!»
Ә тел төбен аңлаучылар
Безгә ак юл телиләр.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Әнәс Галиев**

## ҖИМЕРЕЛГӘН ХЫЯЛЛАР

РОМАН[1]

### XIII

Сания «пожар, янабыз» дип кычкырган тавышларны ишетеп йокыдан уянды. Күзен ачу белән тәрәзәгә ташланды. Әле бик иртә, яңа көн яктырып кына килә иде.

Әбрар эштән арып, соң гына кайтты. Берни белешми йоклый. Сания аны уята алмый алҗыды. Алар икесе бергә, ярым ялангач килеш урамга чыктылар. Янгын аргы башта икән.

— Безнең йорт яна! — Сания йөрәк ачыйгысы белән кычкырып җибәрде. Урамда берән-сәрән кеше күренә башлады. Бар да капка төпләренә басып, нәрсә эшләргә белмичәрәк аптырап тора.

Әбрар белән Сания килеп җиткәндә, әле йортлары янында беркем дә юк иде. Ут өйгә сылап эшләнгән лапастан чыккан булса кирәк. Лапас бөтенләй янып бетеп килә, ялкын инде өй түбәсенә үрләгән.

— Янгын сүндерүчеләр кайда? — Галләм тавышы. Ачы тавыш белән ул кычкыра. Колхоз рәисе беренче булып килеп баскан. Бераздан чиләк, балта тоткан берничә кеше күренде. Ут, көчәйгәннән көчәеп, бөтен өйне чорнап алды. Янгын сүндерүчеләр һаман күренми иде әле. Менә карчыгын ияртеп Зариф хәзрәт тә килеп җитте. Тәкбир әйтеп як-ягына карап торды та, утның күрше йортка үрләү ихтималын сизеп, ике арадагы бушлыкны көрәк белән казырга тотынды. Аңа тагын берничә кеше иярде.

Ниһаять, насосны өстерәп алып килделәр. Янгын сакчысы булып эшләүче Чүкер Җәләе дөм исерек, аягында басып торырлык та хәле юк. Бертуктаусыз нәрсәдер лыгырдый, сүзләрен аңлый торган түгел. Ике егет аны насос яныннан төшереп, тиз генә эшкә тотындылар.

Ел коры килгәнлектән инеш кипте. Суны чишмәләрдән, коедан көянтә-чиләк белән ташырга туры килде. Су ташырга авылның аягына басып торган барлык хатын-кызы чыкты. Фатыйма да башкалар белән бергә ару-талуны белми эшләде.

— Бу кадәр бәхетсез кеше булыр икән, — диде ул, Әбрарны кызганып. — Яңа тормыш корып җибәргәч, кирәк бит шушындый хәлгә калырга!..

[1] Ахыры. Башы 4 нче санда.

Янгынның күрше йортларга үрләү куркынычы артканнан артты. Иң якыны салам түбәле Гажби карчык йорты. Түбәсенә очкын төшсә, дөрләп яна башлаячак! Ярый әле җил каршы яктан.

Халыкның бер төркеме шушы йортны саклап калу чарасына кереште. Җитмеш яшьлек ялгыз карчык йортсыз калса, ничек көн күрер? Аның бер таянычы юк. Баласы булмады. Ире белән икесе генә гомер иттеләр. Ул сугышта бер аягын калдырып кайткан иде, моннан берничә ел элек дөнья куйды.

Озын Зиннәт баскыч белән менеп Гажби әбинең өй түбәсен суга коендыргач, очкын төшеп кенә ут кабарлык булмады. Ул янгын басылганчы түбәдән төшмәде. Хатын-кызлар аңа чиләк белән суны өзлексез биреп тордылар.

Янгын басылыр алдыннан Чүкер Җәләе дә килеп җитте. Ул «баш төзәтеп» кеше рәтенә кергән иде инде. Бернәрсә булмаган кебек, эшкә керешге. Алар янгын сакчысы булып ике кеше эшлиләр иде. Аның алмашчысы Пәтти Шакирҗаны — алтмышка җиткән карт, атнадан артык инде эшкә чыкканы юк, авырып урын өстендә ята.

Җәләй карамагында ике ат бар. Ул атлар янгын сараенда, махсус абзарда асрала. Аларны хуҗалык эшендә файдалану катгый рәвештә тыела. Ә Җәләй тартынып тормый, таныш-белешләренең үтенечен тиз генә башкарып ташлый. Әлбәттә, бушка эшләми. Хезмәт хакы — иң кимендә бер ярты.

Партоешма секретаре Фатыйма Җәләйдән утын алып кайтып бирүен үтенгән иде. Гамәлдәге закон буенча, авыл җирләрендә эшләүче медицина работниклары түләүсез ягулык белән тәэмин ителә. Өенә дә түләүсез китереп бирергә тиешләр. Тиеш дип язып языла языла языла языла язылуын, кара белән акка ачык итеп языла. Әмма...

Фатыймага утын алып кайтырга хәбәре килде килүен, тик колхоз кайчан ат бирә дә, алып кайтырга кемне җибәрә? Кәтеп тормаска булды, Җәләйгә мөрәҗәгать итте. Аның икеләнеп калганын күреп:

— Курыкма, курыкма! Буш итмәм,— диде,— коры чакта кайтарып калырга кирәк. Колхоз алып кайтып бирергә тиеш тә бит, аларга ышансаң, ягулыксыз калуың бар...

Җәләй карышып тормады, утынны алып кайтып бирде. Фатыйма да вәгъдәсендә торды, буш итмәде. Ул башкалар кебек «ярты» чыгарып тоттырмады, кунакка чакырды. Кунак дигәч тә, алай авыз тутырып әйтерлек түгел, кич белән, кешегә сиздермичә генә кереп чыгарга кушты. Җәләйне өйрәтәсе юк. Мөмкин кадәр сак маташырга тырыша. Болай да инде, гайбәтнең чиге юк...

Бер кичне, ындыр артлатып кына, билгеләнгән вакытта Фатыйма яшәгән йортка барып керде бу. Хуҗабикә әзерләнеп көтеп тора иде. Сый мулдан түгел, йомырка белән кыздырылган бәрәңге һәм бер шешә. Шешәдәге болганчык сыекчага күзе төшеп, Җәләй йөзен чытты. Көмешкә булса, авызга да алмаска кирәк, дип уйлап куйды. Саранланмасын әле, шулкадәр хезмәт күрсәтеп көмешкә эчеп утырыргамы? Җәләй тартынып тормады, шешәне кулына алып аның эчендәге сыекчаны карады.

— Спирт ул, спирт,— диде Фатыйма тынычландырырга теләп,— мин аның рәтен беләммени?

Фатыйма Җиһан карчыкта фатирда тора. Үз сүзле кырыс карчык. Фатирга керткәндә кисәтеп куйды:

— Туры атлап йөрсәң генә килешеп яшәрбез, мутлыгыңны сизсәм, бер минут та тотмам,— диде.

Ялынып сорагач кына Җәләйне өенә чакырып сыйларга ризалыгын бирде. Ялынып сорауга да карамас иде, Җәләй зур эш башкарды ич. Кышка утын кайгысы бетте. Изгелеккә изгелек белән җавап бирергә кирәк! Тагын шунысы: Җәләй яшь кеше түгел. Яшь вакытында да хатын-кыз белән мутланып йөргәне булмады.

— Чүкернең сыер төсле «шайтан суы» чөмергәнен карап торып, йөрәгемне бозасым килми, өйдән китеп торам,— диде әби.— Сыйла шунда үзең. Ләкин озаклап утырмагыз!

Җәләй, килеп керү белән, Җиһан әбинең юклыгына игътибар итте:

— Кая олакты теге җен карчыгы? Күренми,— дип сорады.

— Түбән очтагы Язилә әби кунакка чакырган. Җәләйне күреп сөйләшеп утырасым килгән иде, кызганыч, булмады инде дип, шунда китте.

— Маладис! Акылы җиткән, болай булгач иркенләп утырырга мөмкин.

Ул стакан тутырып шешәдәге сыекчаны агызды да, тын да алмый эчеп бетерде:

— Су кушып бозгансың, спиртне аны чиста килеш эчсәң яхшырак...

Фатыйма эчемлекне күбрәк күрсәтергә теләп су кушкан иде, хәйләсе барып чыкмады. Шулай да, спирт — спирт инде ул! Икенче стаканны эчкәч, ирнең бөтен тәне рәхәтләнеп, кыюрак сөйләшә башлады:

— Сеңлем Фатыйма! Гаеп итештән булмасын, турысын әйтеп сөйләшик: гомереңне әрәмгә уздырасың...

— Нишләп алай дип әйтәсең?

— Ялгыз йөрмә, тап үзеңә бер иптәш!

— Бик кияүгә чыгар идем дә, сезнең авыл егетләре мине алырга теләмиләр...

Җәләй Фатыйманың тел төбен аңлап алды:

— Әллә Әбрар гына дигәнме? Шушындый чибәрлегең белән мескенгә сабышып йөрмә?

— Сыйнфый дошман безгә көн бирәме соң?! Иң элек шуларның тамырын корытырга кирәк, аннары кияү турында уйларбыз.

— Кем инде ул сыйнфый дошман дигәнең?

— Мулла кызы...

— Һи, аларның кикреге шиңгәнгә биш былтыр! Совет власте кергән бирде аларның...

— Дөрес, кергән бирде бирүен, әмма тамырлары исән. Борын төртер өчен җай чыкканны көтеп кенә торалар.

Җәләй Фатыйманың салпы ягына салам кыстыруны дәвам иттерде:

— Мулла кызы Сания синең тырнагыңа да тормый, маха бирдең... Гәп кызганнан кызып, өстәл өстенә флакон белән чиста спирт чыгып утырды.— Су кушып дәрәҗәсен төшерә күрмә,— диде Җәләй,— мин аны шулай гына җиффәрәм...

— Төптән уйлаганда Әбрар сиңа өйләнергә тиеш иде. Егет ялгышты...

— Җаны теләгән җылан ите ашар диләрме? Торып карасыннар инде.

Фатыйма эчендәге утны тышка чыгармаска, үзен тыныч тотарга тырышты. Менә күпме вакыт инде, төн йокысы күргәне юк, тамагыннан аш үтми. Шундый ябыкты, чыра кебек булып калды. Кулыннан килсә, Санияне өзгәләп ташлар иде. Ачуын эти-әнисеннән алырга теләп, аноним хатлар җибәреп карады. Советка каршы халыкны котырта, колхоз умартачылыгында эшләп бал урлый, дип язды. Якмаган яла калмады. Берсе дә расланмады. Тикшерүчеләр мәми авыз дип уйлады Фатыйма. Сугышка кадәр бала гына булса да, хәтерендә: мулла өстеннән әләк язылса, тикшереп тә тормыйлар, таш капчыкка илтеп тыгалар иде. Дөрес, бертуктаусыз әләкләп яза торгач, Зариф мулланы умарта караудан бушатырга күрсәтмә бирелде бирелүен — эшли алырлык кеше табылмады. Тотырыклы рәвештә керем бирә торган тармакны юклы-барлы кешегә тапшырып тар-мар итәргә ярамый диделәр. Бал сатудан кергән акча вак-төяк «кесә чыгымнарын» капларга ярап тора. Аеруча банктагы хисапта арест ятканда!

Аноним хатлар белән эш барып чыкмагач, Фатыйма Әбрар турында гайбәт таратырга керешге:

— Җәләй абый, җаным,— диде,— ишеткәнең бармы? Әбрар каенатасы белән намаз укый дип сөйлиләр. Әллә, хәзрәт бу дөньядан киткәч, авылга мулла булып калырга җыена микән?

Җәләйнең әлләни исе китмәде:

— Анысы, сеңлем, һәркемнең үз эше инде,— диде дә бетерде. Җавап Фатыйма теләгәнчә булып чыкмады, кәефе кырылды. Ризасызлыгын белдереп:

— Менә шулай агулыйлар безнең халыкны,— диде,— ашыгыч чара күрелергә тиеш.

Җәләй өстәл өстеннән күзен йөртеп алды. Җитеп бетмәде. Тагын берәр стакан салып бирсә, шәп буласы иде дә, саранлана. Сорап алырга яхшысынмады, китәргә җыенып урыныннан кузгалды.

Җитеп бетмәвен Фатыйма да сизә, өстәргә курка. Начар гадәте бар бу кешенең: исерсә — өенә кайтып, хатынына бәйләнә.

— Җәләй абый, җаным, зур рәхмәт инде сиңа,— диде озатырга чыккач. Аннан үзенчә каты итеп кисәтте:— Ишетсен колагың, тавыш чыгарасы булма!

— Тавыш чыгарырлык эш юк әле монда, кече телгә дә йокмады.

Фатыйманың исәбе, Җәләйне ындыр артлатып кына озатып җибәрергә иде, тыңлатып буламы соң ул киребеткәнне? Урамга чыгып китте. Каян булса да аракы табып, аяктан егылганчы эчәчәк. Фатыймада спирт җитәрлек анысы, акчага алган мал түгел, кызганып тормас иде, авызыннан акканчы эчертер иде. Ярамый. Анын Фатыймада сыйлануын беркем белергә тиеш түгел!

Фатыйма өйгә кереп караватына йөзтүбән капланды. Йөрәгенең януына чыдый алмый шактый озак ятты. Әбрарны болай калдырырга ярамый! Ничек итеп үч алырга? Хәзер аны Саниядән аерту мөмкин түгел. Пар күгәрченнәр төсле гөрләшеп яшиләр. Уйлар, уйлар! Очы-кырые юк. Нишләргә?

Озакламый Җиһан карчык кайтып җитәргә тиеш. Сикереп торды да өстәлне җыештырды. Ул кайтышка бөтен җир пөхтә булсын...

Аны тагын Әбрардан үч алу уе биләп алды. Тәрәзә каршына басып урамны күзәтте. Моңа кадәр игътибар иткәне юк иде, тәрәзәдән Әбрарның йорт түбәсе күренә икән. Нинди матур итеп эшләп куйдылар, курчак өе кебек. Үзенең генә көче җитмәс иде, каенатасы булыша. Сәдакага килгән акчага эшләнә ул йорт. Нишләп мулланың керемен исәпкә алып, налог салмыйлар икән? Фатыйма үзе гаепле. Бу турыда күптән тавыш күтәрергә кирәк иде. Дөрес, ул йоклап ятмады. Хәбәр итте. Райфодан килеп тикшереп тә карадылар. Налог салырлык кереме табылмады. Юк, Әбрар белән Сания яңа салынган йортта тынычлап яшәмәсеннәр әле! Алар хәзергә абыйлары Шәрәфи йортында торып торалар. Үз йортларына күчкәнче, вакыттан файдаланып калырга кирәк. Йорт эшләгәндә, Әтүтән лапаска тутырып барган йомычка күз алдына килде. «Кызыл әтәч» җибәрергә аннан да уңайлы урынның булуы мөмкин түгел. Бер шырпы өйнең көлен күккә очырачак! Куркып тормаска, тәвәккәлләргә! Иң яхшысы бу эшне таң алдыннан, халык тәмле йокыда вакытта башкару. Бу уй аның күңеленә бүген түгел, алар йорт эшли башлаган чакта ук килгән иде. Әллә юкка гына Әтүтән йомычка тутырган лапасны барып карап йөрдеме ул?

Фатыйма шулай янып-көеп утырганда, Җиһан карчык кайтып керде.

— Абау, теге айнымас китте дәмени әле? Ничек бик тиз...

Сүзләренә игътибар булмагач:

— Чүкер авыр сүз әйттеме, әллә? — дип сорады,— кәефең киткән төсле...

— Чүкер әйткән сүзгә кәеф китеп торса, дөньяда яшәсе дә юк!

— Гаеп итмә, кызым,— диде, сорау Фатыймага ошамады дип уйлап,— сүз югында сүз булсын, ата казың күкәй саламы, кодагый дип сораган ди бер хатын, мин дә шуның шикелле...

Фатыйма аның йокларга ятуын түземсезлек белән көтә иде.

Җиһан карчык боргаланып-сыргаланып, озак йокыга китә алмый ятты. Ниһаять, көтә торгач гырлаганы ишетелде. Йоклый. Фатыйманың сынаганы бар: йокыга китсә, колак төбендә барабан кагып торсаң да уянмый ул. Хәзер тынычлап өйдән чыгып китәргә була, сизелмәячәк. Ашыкмады, карчыкның хәйләли торган гадәте исенә төшеп, йокыга китүенә тәмам ышанганчы, баш очында басып торды.

Мөмкин кадәр сак булырга тырышып ишегалдына чыкты. Күкне кара болыт каплаган, төн гадәттән тыш караңгы. Янына килеп җитмичә кешене танырлык түгел. Әлегә бар да Фатыйма теләгәнчә бара. Әбрар йортына «кызыл әтәч» җибәрергә моннан да уңайлы вакытның булуы мөмкин түгел. Ашыгырга, ашыгырга! Күптән әзерләп куйган бер шешә керосины бар. Үзе белән шуны алды. Шырпы куенында.

Ындыр артлатып Әбрар ишегалдына барып кергәндә йөрәге күкрәгеннән атылып чыгарлык дәрәҗәгә җитеп тибә иде. Йомычка тутырылган лапас ишеген бәйләп куелган тимерчыбыкны чишкәндә, кабаланып кулын канатты. Тез буыннарына кадәр калтырап, күзе ак белән караны аермады. Ничек йомычкага керосин сибеп ут төртүен, ничек өйгә кайтып керүен хәтерли алмады...

— Кызым, Фатыйма, тор әле, тор! — Җиһан карчыкның тавышын ишетеп, аңына килде. — Урамда нигәдер шаулашалар.

Ул бер нәрсә дә белешмичә йоклаганга салышты. Урамда шау-шу көчәйгәннән, көчәйде.

«Пожар» дип кычкырган тавыш аермачык ишетелде. Урамда ни өчен тавыш күтәрелгәнне аңлап, Җиһан карчык белгән догаларын укырга тотынды. Фатыйма карават астыннан чемоданын тартып чыгарды. Бөтен байлыгын шул чемоданга бикләп тота. Кешелеккә кия торган күлмәк белән җон кофта, паспорты белән училище тәмамлау турындагы таныклыгы да шул чемоданда.

Җиһан карчык Фатыйманың чемодан күтәреп өйдән чыгып китүен күрми дә калды. Белеп булмый, утның бу тирәгә сикерүе бар. Медпункт авыл кырыенда, янгын чыккан җирдән шактый ерак. Чемоданны шунда илтеп кую хәерлерәк булыр дип уйлады Фатыйма.

Ул медпунктта тоткарланмады. Барлык булган даруларын алып Әбрар ишегалдына, янгын сүндерүчеләр янына юнәлде.

## XIV

Атна буе авыл өстендә көйгән ис аңкып торды. Янгынның сәбәбен ничек аңлатырга да белмәделәр. Кем дә булса ут төрткән дип уйлар идең, Әбрарга авылга үчле кеше юк кебек. Кулыннан килгән кадәр кешегә ярдәм күрсәтеп, тату яшәргә тырыша.

Районнан килеп тикшереп киттеләр. Нинди нәтиҗәгә килгәннәрдер, белүче юк.

Халык арасында шикле бер хәбәр таралды. Имеш, янгын чыгасы кичне, шул тирәдә Әтүтәнне күргәннәр. Ул бик еш кына йомычка тутырылган лапаста олылардан качып, тәмәке тартып утыра торган булган. Хәтта, әти-әнисеннән куркып, тәмәкесен шунда яшереп тоткан.

Дөрестән дә, Әтүтәннең әтисе кырку кеше, балаларын төрле мутлыктан тыя, тыңламасалар суккалап алырга да тартынмый.

Янгын Әтүтән сүндерми ташлап калдырган тәмәке төпчегеннән чыккан диган хәбәрне ишеткәч Әбрар «ялган» диде, катгый рәвештә бу гайбәтне кире какты. Ул белә, күптән инде Әтүтәннең тәмәкене кулына да тотып караганы юк. Кыш көне, әтисе яхшылап кыздыргач, башка тәмәке тартмаска ант итте. Ә ул сүзендә тора торган малай. Әбрар районнан килгән тикшерүчеләргә дә шулай язып аңлатма бирде.

Партоешма секретаре Фатыйма исә: «Башка беркем дә түгел, Әтүтән эше»,— дип әйтеп, сүзендә нык торды.

— Күргән-белгән кеше юк, зинһар, берәүгә дә нахак бәла яга күрмәгез,— диде Зариф мулла кияве белән кызын үгетләп,— Ходайның хөкеме тугры, гаеплегә ул җәза бирсен. Каргышы үзенә булмаса баласына төшәр.

Әбрар янгынның сәбәбен эзләп бик нык уйланды. Ул Фатыймадан шикләнде. Аның шикләнүе үзенчә иде. Фатыйманың төнлә барып, өенә ут төртеп йөрүен күз алдына да китермәде. Бәла Фатыйма каргышы аркасында килде дип уйлады.

Әбрар хәзергә уйларын беркем белән дә уртаклашырга теләми, аларның гомергә сер булып калуы да ихтимал.

Янгыннан бер Әбрар гына зыян күрмәде. Авыл советы һәм колхоз рәисләренә, райбашкарма утырышына чакырып, шелтә бирелде. Янгын сакчысы Җәләйне эшеннән колак кактырдылар. Мондый эшне ул елап эзләсә дә, таба алачак түгел, Фатыймага «ярдәм ит» дип әйтеп караган иде, «тавышыңны чыгарасы булма, бусы сәдакасы гына»,— дип кырт кисте теге.

— Кара аны, кызый, артын-алдын уйлап сөйләш!— диде Җәләй агулы елмаеп.— Үкенергә туры килмәсен!

— Нәрсә өчен мин үкенергә тиеш?

— Сасы спирт эчертеп, янгын сакчысын аяктан еккан өчен...

Чыннан да, эшнең зурга китүе ихтимал. Фатыйма шуны аңлап, Җәләйне юмаларга тотынды:

— Минем сиңа ярдәм итмим дип әйткәнем юк ич әле,— диде еламсыраган тавыш белән.— Бераз халык тынсын, җайлы-җайсыз булмый бит...

— Миңа хәзер кирәк!

— Ашыктырма, кайчан сине эшеңә кире кайтару турында сүз кузгатырга кирәклеген мин үзем белермен.

— Белеп тор, йомгакның очы миндә!

Фатыйма Җәләйне нәрсә әйтсәләр шуңа ышана торган надан бер мужик итеп күз алдына китерә иде, менә ул нинди икән!

— Җәләй абый, бәгърем, болай сөйләшергә ничек телең бара? Каян белим ди мин, сине сыйлаган көнне Әбрар йортында янгын чыгасын? Белгән булсаммы?..

— Бәлки шулайдыр, белмәгәнсеңдер! Әмма минемчә уйлауның да нигезе бар. Синең Әбрар артыннан чапканыңны, авылның бала-чагасына кадәр белә. Ул әнә, тотты да мулла кызына өйләнде. Брач булып йөрүеңне әйтер идем, төкерде башыңа...

Каты әйтте Җәләй, Фатыйма еларга да, көләргә дә белмәде.

Аннары көчле куллары белән тотып, каршына китереп бастырды:

— Кеше теләсә ничек уйласын, Әбрар йортында янгын чыгу белән мине сыйлавың арасында бәйләнеш булуында шигем юк,— диде. Ул бу сүзләрне куркытыр өчен генә әйтте. Ләкин Фатыйманың акбур кебек агарган йөзенә күзе төшеп, әллә чыннан да шулай микән, дип уйлап куйды. Яңа гына кукыраеп, горур басып торган фельдшерның мескен кыяфәткә керүе күңелендә нииндидер рәхәт тойгы уятты:

— Язмышың минем кулда, иптәш доктор,— диде һөҗүмне дәвам итеп.— Үзеңә тиешлесен кабул итәргә әзерләнеп тор!

Фатыйма яшь бала кебек үксеп еларга тотынды:

— Җәләй абый, җаным, зинһар, мине батырма!

Янгын чыгуда гаебе булмаса, бу кадәр өзгәләнмәс иде! Димәк, гаепле. Юк, юк, моны ачыклау Җәләй эше түгел, андый эшнең үз кешеләре бар, шулар шөгыльләнсен!

— Спиртең бармы?— Фатыйма актык акчасына ике шешә аракы сатып алып китерде. Җәләйнең авызын капларга хәзергә шул җитеп торды. Алда тагын күз күрер...

## XV

Габделхәйләр белән ресторанга кереп утырганнан бирле Шәфиканың ашавы ашау, йокысы йокы булмады. Берәр таныш кешесе күреп калып, иренә әләкләүдән курыкты. Шул турыда дусты Сөембикәгә сөйләгән иде, тегесе кычкырып көлде.

— Нәрсәсе бар аның куркырлык — «легкий флирт», диде урысчалатып,— җае чыкса, тагын барырга кирәк!

Шәфика дустының болай җиңел уйлавына гаҗәпкә калды.

— Ул да безнең кебек бер хезмәт хакына яши, хатыны, балалары бар, акча каян алсын?

Сөембикә аптырап калмады, бу сорауга да җиңел генә җавап бирде:

— Безнең кебек чибәр хатыннар белән йөрисе килсә, тапсын! Акча табу аның эше...

Шәфика белән Сөембикә кечкенәдән бергә аралашып үстеләр, кияүгә чыккач та, ташламадылар, сирәк булса да очрашып торалар.

— Элек бер дә болай түгел идең, әллә җен алыштырдымы сине? — диде Шәфика аның сүзләренә ышанасы килмичә.

— Тормыш үзе өйрәтә ул! Әйдә ачыктан-ачык сөйләшик әле: бала карап өйдә бикләнеп яткан өчен ирең рәхмәт әйтер дип уйлыйсыңмы? — Шәфика аптырап калды.— Ул да анда тик ятмый торгандыр әле!

Иренең туры атлап йөрүенә чын күңеленнән ышана Шәфика. Юк, юк, Галләм хыянәт итми! Ләкин дустының бу сүзләрен дә җавапсыз калдырды.

— Хәзер үз хисабына сөяркә тотучы ирләр юк дип әйтерлек. Синең Габделхәең порядочный кеше күренә әле...

— Син бик тирәнгә кереп киттең әле, мин алай булдыра алмыйм, теләмим дә...

— Җүләр син! Мөмкин булганда файдаланып калырга кирәк, гомер ике килми.

Сөембикә чынлап торып Шәфика күңеленә вәсвәсә салды. Кадыйров белән күрешмәгән көнне аңа нәрсәдер җитмәгән кебек була башлады. Күрешер өчен җае да чыгып тора бит! Көндезге тәнәфес вакытында райбашкарма хезмәткәрләре күршедәге ашханәгә йөриләр. Кадыйров тәкъдиме белән Шәфика дә көндезге ашауны шул ашханәдә көйләп җибәрде. Анда шактый зур чират була. Шәфиканы Габделхәй чират торудан да коткарды. Билгеле булганча, налог инспекторының эше — йөреп эшли торган эш. Ул райфодан участокка дип чыгып китә дә, ашханәгә иртәрәк килеп Шәфиканы көтеп тора. Кайсы көнне «синең хисапка иртәгә ашарбыз» дип аңа акча да түләтми. Әмма халык күзе үткен, аннан бер нәрсәне дә яшереп булмый. Иртәме соңмы, ул барысын белә. Аларның шул ашханәгә бергә йөрүдән башка гаепләре булмаса да, гайбәт таралды. Шәфика куркып калды. Гайбәткә чик куярга теләп, ашханәгә йөрүдән туктады.

Габделхәй исә күрешүнең башка юлын эзләде. Гыйшык уты шундый көчле: Шәфика белән күрешмәгән көнне үзенә беркайда урын тапмый. Кирәк бит ике балалы хатынга шулай гашыйк булырга! Ул аның аяк астында туфрак булырга әзер. Ни өчен икәнен үзе дә белми. Чибәрлек ягына килсәң, үз хатыны да Шәфикадан ким түгел инде. Дөрес, Зәйтүнә Габделхәйдән берничә яшькә олы. Яшь аермасы шактый булса да, икесен янәшә куйсаң, ул яшьрәк күренә. Авыл һавасын иснәп, яшел чирәмдә аунап үскән кыз шул ул!

Зәйтүнә ирен көнләшеп борчымый. Тагын бер яхшы ягы бар: кайбер хатыннар кебек кием-салымга хирыслеге юк. Нәрсә бар, шуңа риза. Акчаны үзе таба. Эшләгән җирендә абруе зур, һөнәрен бөтен нечкәлекләре белән үзләштерде. Чимал базасында җаңлек тиресе сайлый. Бик тә четерекле эш. Тиренең сортын сортка аерып кабул итә. Тапшырырга килүчеләр аның алдында дер калтырап тора. Чөнки сорт

дөрес билгеләнмәсә, зыян кила. Зыян йөзләгән мең сум тәшкил итәргә мөмкин!

Зәйтүнә гадел булырга тырыша. Гаделлеген буш итмиләр. Берсеннән дә сорап алганы юк, телиме-теләмиме, акча калдырып китәләр. Болай эшләү закон буенча катгый рәвештә тыела. Тик язмаган законнар да бар бит әле!

Ул кырын кергән акчадан иптәшләренә дә өлеш чыгара. Калганын күрше карчыкларына сәдака итеп өләшә. Карт-корыга, гарипләргә ярдәм кулы сузу нәселдән килә. Ата-бабасы да кешегә ярдәмле булу белән тирә-юньдә дан тоткан иде.

Менә Габделхәй шундый хатын белән яши. Яратмаслык хатын түгел, бөтен яктан килгән. Дөресен генә әйткәндә, Габделхәйнең аны ташларга уйлаганы да юк. Ә менә Шәфиканы ярата, өзелеп ярата! Ялгыш кына кулы тиеп китсә дә, бөтен тәне рәхәтләнә. Нәрсә бу, үзенә күрә бер авырумы? Бер нишләр хәле юк, шашып ярата!

Шәфика ашханәгә йөрүдән туктагач, очрашуның башка юлы табылды.

Райбашкармадан ерак түгел бер бакча бар. Кайчандыр гөрләп торган бу бакча хәзер ташландык хәлдә. Берән-сәрән этләрен һавага алып чыгучылар гына күренгәли.

— Борын төбендә нинди уңайлы урын бар икән! — диде Шәфика, бакча аның да күңеленә хуш килде. Көндезге тәнәфес вакытын шул бакчада үткәрә башладылар.

Бакчага кереп утыруларын сиздермәс өчен саклык чаралары да күрелде.

— Әни әзерләп көтеп тора, кайтып ашап киләм,— дип китә Шәфика тәнәфес вакытында, ә Габделхәй участокта йөргән җирендә туры шунда килеп, аны көтеп тора. Ул бакчага буш кул белән килми, тамак ялгарга нәрсә булса да кыстырып килә. Шәфика бик нәзберек, тәмлене генә ярата.

Габделхәйнең кесә такыр. Ләкин сер бирергә ярамый. Сыйны көннән-көн яхшылатты. Тора-бара Шәфика шулкадәр күнекте, ул моны яратышкан кешеләр арасында була торган гади бер күренеш итеп кабул итте. Кадыйровның ничек, кайдан акча табуы турында уена да кертеп карамады.

Бакчада сөйләшеп утыру гына Шәфиканы канәгатьләндерми башлады. Бер сәгать вакыт нәрсә ул, күз ачып йомганчы уза да китә.

— Җаен табып, тагын ресторанга кереп утырырга кирәк,— диде.

Габделхәй аның тарафыннан мондый тәкъдим булыр дип көтмәгән иде. Кесәсендә сукыр бер тиен акчасы юк, ләкин югалып калмады:

— Әйдә, хәзер киттек! — диде.

— Син бигрәк ашыгыч инде!

— Андый эшне сузарга ярамый...

Шәфика Габделхәйнең уң битеннән үбеп алды. Ул сул битен дә куйды.— Җитеп торыр, күпкә китә! — Аның нәүмизләнгәнен күреп кызгану хисе туса да, башка үпмәде.— Бу юлы кеше өстерәп йөрмибез,— диде, сүзен дәвам итеп,— Сиңа авырга килә...

— Акчаны үзебез табабыз, ул турыда кайгырма...

— Алай булмый инде ул, сиңа да акча күктән яумый торгандыр ич.

Икесе дә уйланып тынып калдылар.

— Минем бер тәкъдимем бар,— диде Шәфика сүз башлап,— шәһәрдән читкәрәк китеп, йөреп кайтсак ничек булыр икән? — Габделхәй үзе дә шул турыда хыяллана иде, тик үпкәләтермен дип, әйтергә куркып йөрде.

Хәзер чакырып торганда бармый калырга ярамас, мондый мөмкинлек сирәк була. Бөтен җитдилеге белән акча мәсьәләсе алга килеп басты. Бурычка алып булса да, Шәфика әйткән җиргә барырга кирәк!

Районда чиркәү бар. Анда хезмәт итүче дин әһелләренең керемнәреннән салым алу Кадыйров карамагында. Аерым-аерым райфога чакырып

сорау алу юлы белән һәркайсының еллык керемен исәпләп чыгара ул. Соңгы вакытта бу эш җиңеләйде. Элегрәк шактый катлаулы иде. Хәзер аларга дәрәҗәләренә карап хезмәт хакы билгеләнде. Акчаны чиркәү бухгалтериясеннән алалар. Габделхәй сорау алганда актка «окладтан башка кереме юк» дип язып куя да, шуның белән вәссәлам! Белә, бик яхшы белә, чиркәү кассасыннан алган акчага калсаң, аягыңны сузарга мөмкин. Чөнки хезмәт хакының иң кимендә яртысы салым түләүгә китә.

Чиркәү кассасыннан түләнгән акчадан тыш алынган керемне ачыклар өчен, йорт саен йөреп, кемдә нинди дини йола үтәлгәнне тикшерергә кирәк. Габделхәйнең шымчылык итәсе килми. Шуңа күрә дин әһелләре аннан бик канәгать, очрашкан саен кунакка чакырып теңкәсенә тияләр. Ә салым инспекторына аларның өенә бару катгый рәвештә тыела.

Габделхәйне өлкән поп-настоятель чакырып йөри. Милләте буенча чуаш, кайчандыр семинария бетергән. Евтропов Николай Иванович, чиста киенеп йөри, кара сакаллы, яше җитмешләр тирәсендә. Һәр сүзеннән укымышлы кеше булуы сизелеп тора.

Габделхәй уйлап-уйлап йөрде дә, йә мал, йә җан, дип туры Николай Ивановичның өенә барып керде. Ул шәһәрдән читтә, үз йортында яши. Йортны яңа гына сатып алды. Алты почмаклы, калай түбәле бүрәнә йорт. Алма бакчасы да бар.

Габделхәйгә ишекне юан гәүдәле бер хатын ачты. Өстендә ефәк халат. Агарып килә торган чәчен кыска итеп кистергән. Ул Габделхәйне өйгә кертмәде, Николай Ивановичны чакырып чыгарды.

— О, иптәш Кадыйров! Нинди җилләр ташлады сезне? — диде саф татарча, чуашларга хас акцент белән.— Әйдә, өйгә узыгыз!

Габделхәй өйгә кереп тормас, шушында ишек төбендә әйтәсе сүзен әйтер дә, китеп барыр дип уйлады булса кирәк, эчкә узгач шатланды. Туры залга барып керделәр.

Зал кыйммәтле мебель белән җиһазландырылган, стенага төрле зурлыктагы иконалар эленгән.

— Кайда сез болай татарча сөйләшергә өйрәндегез?

— Минем хатыным да татарча сөйләшә белә, без Аксу ягыннан...

— Сез татарча сөйләшә белә торгансыздыр дип уйламаган идем...

— Безнең авылның бер ягында татарлар яши, инеш кенә аерып тора.— Ул Габделхәйгә диваннан урын тәкъдим итте.

— Утырсам озакка китә, әйтәсе сүземне әйтәм дә китәм.

— Әллә нигә бер килеп, чәй дә эчми китәргәме? Беркая җибәрмим.— Аннары хатынына мөрәҗәгать итеп:

— Тося, ишекне бикләп куй! — диде.

Хуҗабикә Антонина Васильевна исемле икән, тиз генә өстәл әзерләргә тотынды. Иң әүвәл биш йолдызлы коньяк чыгып утырды. Аның янына ваза белән шоколад конфет куелды.

Николай Иванович түрдәге серванттан ике хрусталь рюмка алып, эчемлек койды:

— Кайнар аш әзер булганчы берәрне тотып куйыйк!

— Минем аның белән дуслык юк,— дигән булды Габделхәй йөзен чытып,— әмма мондый затлы эчемлектән баш тартсаң, гөнаһ булыр...

Габделхәй, рюмкадагы коньякны җиңел генә йотып куйды да, борчып йөрүенең сәбәбен аңлатырга кереште:

— Сез гафу итегез,— диде түбәнчелек белән,— соңгы вакытта мине бик нык кыса башладылар, шул турыда сезне кисәтеп куярга кирәк дип уйладым, сүз бер булсын...

Николай Иванович аны бүлдерде:

— Нәрсә сөйлисез сез? Нинди гафу үтенү ул! Килүегезгә мин бик шат! Бер сөйләшеп утыру үзе бер гомер...

— Бәлки гаеп итәрсез, сезгә үзебезнең эштәге бер серне чишәм, мине дин әһелләренең керемен тулысы белән исәпләмәүдә гаепләргә җыеналар...

— Нигә килеп тикшермиләр? Тикшерсеннәр...

— Менә шул тикшерүдән куркам да инде мин! Дин әһелләре арасында төрле халык бар, дөресен әйтеп эшне бозулары ихтимал.

— Дин әһелләре керемнәрен налогтан яшерә дип уйлыйсызмы?

— Анысы көн кебек ачык...

— Сез моны, очраклы рәвештә, дин әһелләренең үз кулына бирелгән сәдаканы күз алдында тотып әйтәсезме? Ул вакытта урамда хәер эстәп утыручыларның да керемен исәпкә алып налог салырга кирәк.

Габделхәй аптырап калды, җавап бирә алмады. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшү куркыныч. Ышанычлы кешеләрдән ишетеп белә: дин әһелләренең күбесе КГБга эшли. Төрле юллар белән куркытып мәҗбүр итәләр. Илдә КГБга эше төшмәгән берәр кеше бар микән, дип уйлый Габделхәй. Аның үзен дә, машинага утыртып, берничә мәртәбә КГБга алып бардылар. Йорттан йортка кереп халык арасында йөргән исәпкә алып, күргән-белгәннәрен хәбәр итеп торырга мәҗбүр итмәкчеләр иде. Имеш, шәһәр капиталистик илләрдән җибәрелгән шпионнар белән мыжлап тора, алар белән көрәш — совет кешесенең изге бурычы. Кеше авызыннан чыккан һәр сүзне исәпкә алып барырга кушмакчылар иде. Көчкә котылды:

— Берәр шикле кеше очраса, минуты белән хәбәр итәрмен, ләкин агент булып тормыйм,— диде.

Үзен КГБга чакырып сөйләшүләре турында беркемгә, хәтта хатынына да әйтмәскә кушып, чыгарып җибәрделәр.

Габделхәй Николай Ивановичның чиркәүдәге хәлләр турында даими рәвештә хәбәр итүенә шикләнми. Ул үзе дә моны яшереп маташмый. Никах, балага исем кушу һәм башка йолалар паспортсыз башкарылмый бит. Алар бар да махсус исемлеккә теркәлә. Исемлек исә райкомның пропаганда бүлегенә җибәрелә.

— Кайвакытта безгә Сахалинда, Курил утрауларында хезмәт итүче офицерлар килеп никах укыта, баласын чукындыра,— диде Николай Иванович авыр сулап.— Ерак булгач, хезмәт иткән урыннарында белмәсләр дип уйлыйлар, күрәсең...

Габделхәй залга күз йөртеп чыкты да, сүзне икенчегә борды:

— Мебельнең берәгәен тапкан сез, импортный...

— Сез тагын аларны минем керемгә алынган дип уйламагыз!

— Бушка килмәгәндер инде?

— Улым Германиядә хезмәт итә, ул җибәрде.— Сөйләвенә караганда, улы ниндидер штабта хезмәт итә, подполковник.

Николай Иванович сүз уңаенда чиркәүдә урнаштырылган яңа тәртиптән ризасызлыгын белдерде.

— Бөтен керем староста белән бухгалтер кулында, акча тирәсенә безне якын да җибәрмиләр,— дип зарланды.

Вәгазь сөйләү аерым контрольдә тотыла. Тексты язмача әзерләнеп, махсус тикшерүне үткәннән соң гына халык алдында сөйләргә рөхсәт ителә икән.

— Сәясәткә хилаф берәр сүз ычкындырудан Алла сакласын,— диде Николай Иванович,— аннан соң чиркәүгә аяк басармын дип уйлама.

Сүз белән бер шешә коньякның юкка чыгуы сизелми дә калды. Николай Иванович хатынына ымлый башлаган иде, Габделхәй туктатты:

— Сез нәрсә, мине аяктан егып, хур итмәкче буласызмы?

— Шушы яшькә җитеп, аңлы рәвештә кешегә начарлык эшләгәнем юк, Алла сакласын!

Габделхәй китәргә җыенды.

— Вакытыгыз булса, бераз утырыгыз! Сезне ничек күреп сөйләшергә дип уйлап йөри идем, үзегез килеп яхшы иттегез.— Николай Иванович сүздән туктап уйланып торды.— Зинһар, әләк дип кабул итмәгез, сер итеп кенә әйтәм: чиркәү акчасын урлыйлар...

— Ник юл куясыз? Фаш итегез!

— Безнең көч җитә торган түгел...

Ул Министрлар Советы янындагы дин эшләре буенча комитет рәисенең староста белән бер булып чиркәү кассасына «кул тыгуы» турында сөйләде:

— Төпле ревизия кирәк, моны бары сез генә булдыра аласыз.

Иң зур керем шәм сатудан алына икән. Янып бетмәгән шәмнәрне җыеп, икенче мәртәбә сатуга чыгаралар ди. Бу турыда Габделхәйгә хәбәр иткәннәре бар, тик ничек тикшерергә икәнен генә белми иде. Николай Иванович бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Ул тиз генә икенче бүлмәгә чыгып керде.

— Бу сезгә юл аягы,— Габделхәй кесәсенә гәзиткә төрелгән әйбер тыкты.— Алыгыз, ал! Соңгысы булмас,— диде кулыннан тотып, аңа төргәкне кесәдән чыгарырга ирек бирмәде.— Миңа үзеңә ышанган кебек ышан! Беркем беләчәк түгел.

Николай Иванович кунагын арткы ишектән озатты:

— Каршыдагы күршеләр чебен дә очырмый, күрми торсыннар әле...— Башка вакытта килергә туры килсә, шушы ишектән керергә кушты. Яшерен кыңгыравы да бар икән...

Габделхәй урамга чыгу белән шундый ашыкты, кая басканын белмәде. Поп янына килүенә үкенеп бетә алмады. Уйлый торгач шундый нәтиҗә ясады: «Николай Иванович акча бирүе турында сөйләп йөрергә тиеш түгел. Законда алган кеше белән бергә биргән кешене дә җавапка тарту каралган».

Ничек кенә булмасын, кесәдәге төргәк аның тынычлыгын югалтты. Нигә соң әле ул Николай Иванович күз алдында төргәкне ачып карамады? Чуаш халкы саран була, бәлки бер дә юкка кармакка эләккәндер? Акча санарга җайлы урын эзләп китте. Кая гына барып утырмасын, аны күзәтәләр төсле тоелды.

Акча ресторанга кереп бер утыруда гына бетә торган түгел иде, поп шактый күп тамызган. Тукта, ни өчен әле ул бу кадәр күп акча бирә? Матур күзләре өчен түгел, әлбәттә. Димәк, нәрсәдер өмет итә. Габделхәй хәзергә ул турыда уйлап баш ватмады. Биргәннең битенә бакма дигән сүз бар. Алып яхшы итте. Тир түгеп тапкан акчасы түгел, нәрсә өчен налог инспекторына биргәнен үзе беләдер.

Ашкынып Шәфиканың ресторанга чакырганын көтә башлады. Яхшыга була күрсен, болай ашкынганы юк иде...

## XVII

Галләм муеннан эшкә чумды. Көн дими, төн дими — һаман кырда, вакытында ашаганы да юк. Хәнифә аны чын күңелдән кызгана, үзенчә бөтен көчен куеп тәрбияләргә тырыша. Ә Галләм моңа игътибар да итми кебек. Әзерләгән ризыгы аның әллә бар, әллә юк: көтә-көтә тәмсезләнеп бетә. Рәтләп ашамагач, бик ябыкты да.

Элекке рәисләрнең берсенә дә ошамаган, аракыны сөйми. Тагын шунысы гаҗәп: ярты елга якын авылда яши, хатынының килеп караганы юк әле. Хәнифә аның гаиләсе барлыгына да шикләнә башлады. Ирен ир иткән хатынга бер килеп хәлен белеп китәргә була торгандыр ич инде! Этнең коерыгын кем киссә, шул яхшы, дип белеп әйтәләр шул, әгәр башкалар белән чуалса, хатынын авылдан куып та җибәреп тә булмас иде! Галләм исә чит хатыннарга борылып та карамый, яшь гомере әрәмгә уза.

Хәнифә шулай уйлап, үз тормышын аныкы белән чагыштырып куйды. «Ишек, нинди зур тишек дип, тәрәзәдән келә» дигән сүзләр исенә төшеп, ирексездән елмаеп куйды. Ә үзе? Яшь гомере уза гына түгел, узып бетте. Һай, бер дә генә Хәнифә оныта алмый шул. Сугыш беткәнгә дә

ничә ел, исән булса хәбәре килер иде, исән түгелдер, исән түгелдер... Бер вакытта да башына мондый уй кергәне юк иде, Галләм фатирда тора башлагач, шулай вәсвәсә килде. Әллә акылга җенләям инде дип, үз-үзен битәрләп алды. Ни хакы бар аның хатынлы иргә күңелен сузарга? Алла сакласын, бөтен дөньяга рисвай булудан! Аннары Миңзифа әбинең сүзләре исенә төшеп, үзен аклап куйды. «Гомер ике килми, килсә дә берсе безгә тими,— дип дөрес әйтә ул,— матур вакытында үз җаеңны үзең кара».

Менә кызы Сәкинә үсеп җитә, быел унны бетерә. Бар теләге: югары белем алдырып, аны врач итү. Кияүгә чыкса — ул сыярмы, юкмы? Сәкинә ятимлек белән генә таныш, үгилек белән таныш түгел. Әнисенең ир белән торуына риза булырмы, юкмы — анысы да бар бит әле!

Кыз чибәр. Аны әнисе янында озак тотмаячаклар. Хәзер үк артыннан йөрүчеләр бар. Әмма институт тәмамлаганчы Сәкинәгә кияү турында уйларга да ярамый. Хәнифә кактырып-суктырып шул турыда кызының исенә төшереп тора. Туйдырып та бетерде бугай инде, егетләр турында сүз чыкса, кызы ачулана башлый.

Әйе, иртәме соңмы, Сәкинә аны ташлап китәчәк. Бер караганда кызларның вакытында урнашып калуы хәерле анысы. Дөнья шулай бара бит инде, кыз бала анасын саклап утыра алмый, үз тормышын корып җибәрергә тиеш. Телиме, теләмиме — Хәнифә ялгыз калачак. Алда картлык көтә, аңынчы яшәп булса? Ничек диләр әле: утыз улың булганчы, нинди ирең булсын диләр? Ничек кенә уйлап карамасын, үз аягында басып торганда лаеклы иптәш табарга кирәк, дигән фикергә килде Хәнифә.

Уйлар, уйлар... Очы-кырые юк. Шулай янып-көеп утырганда Галләм кайтып керде. Бер дә болай вакытлы-вакытсыз кайтып йөргәне юк иде, әллә, авырый микән? Иртән районга барам дип чыгып киткән иде, соң гына кайтыр дип уйлап, ашарга да әзерләп тормады.

Алар бер-берсенә тәмам ияләшеп җиттеләр, бертуган күк яшиләр. Ашау-эчүне бергә көйләп җибәрделәр. Галләм «үзеңә нәрсә әзерлисең, миңа шул ярый», дигәч, Хәнифә каршы килмәде. Баштарак аңа яраклы итеп әзерли алмам дип курыккан иде, әлегә кадәр ул әзерләгән ризыктан ризасызлык күрсәткәне юк, Галләмнең.

Сәкинәне дә якын итә, аның укуы белән гел кызыксынып тора.

— Юлыгыз уңмаган, ахры,— диде Хәнифә, Галләмнең күңеле төшенкелеген сизеп.

— Шулайрак шул...— Ни өчен икәнен аңлатып тормады, ак өйгә кереп китте. Хәнифә аптырап калды. Тиз генә керосинкага чәйнек куйды да, ул да аның янына керде. Галләм өстен дә чишенеп тормаган, диванга яткан. Йөзендә — хәлсезлек, күзләрендә моңсу караш.

— Сез мине гафу итегез инде, бераз көтәргә туры килер.

— Нәрсә сөйлисез, сез? — диде Галләм сүзнең ашау турында barганын аңлап.— Нинди сүз булырга мөмкин? Ашау качмас, өлгерербез, үз җаегыз белән әзерләрсез әле.

Диван кырыенда урындык бар иде. Хәнифә Галләмнең баш очына куелган шул урындыкка барып утыруын үзе дә сизми калды. Бер вакытта да бер-берсенә болай орынып утырганнары юк иде.

— Сезнең кәефегез юк, ахры, әллә фельдшерны чакырыйммы?

— Зинһар, мәшәкатьләнә күрмәгез! Фельдшер чакырып кына кәефем яхшыра торган булса иде...

— Сер булмаса әйтегез, башка чарасын күрербез.— Хәнифәгә ялгыш кына Галләмнең кулы тиеп китте. Икесенә дә шулкадәр рәхәт булды, ләкин сиздермәделәр.

— Райком бюросында шелтә чәпәделәр,— диде Галләм,— партбилеттан колак кактырырга чамалыйлар.

Идарә карары белән колхозчыларга шәхси хуҗалыклары өчен хайван азыгы әзерләргә рөхсәт ителде. Елга кырыйларын, юл буйларын, башка

ташландык җирләрне бүлеп биргәннәр иде. Галләмгә кадәр эшләгән рәисләр колхозчы мәнфәгате турында уйлап та карамаганнар, үзләренә җил-яңгыр тимәсә шул җиткән.

Фатыйма Галләмгә каршы килеп, чәпчеп караган иде, идарә әгъзалары тарафыннан яклау тапмады.

— Бөтен илдә шәхси милекчелеккә каршы аяусыз көрәш барганда, без аңлы рәвештә кешеләргә баерга юл ачабыз,— диде Фатыйма.— Мине батырыр өчен эшләнә бу эш.

«Ленин» колхозындагы шәхси хуҗалыкларны хайван азыгы белән тәэмин итү турындагы яңалык, яшен тизлеге белән бөтен районга таралды. Озак көтәргә туры килмәде, колхоз җитәкчеләре райком бюросына чакырылды. Гадәттән тыш бу хәлне тикшерү өчен бюро тулы составында җыелган иде. Галләм белән Фатыймага сәгатьтән артык аяк өстендә басып торырга туры килде.

Беренче булып рәис аңлатма бирде:

— Партоешма секретарен катнаштырмагыз,— диде ул, үзенчә Фатыйманы якларга теләп.— Ташландык җирләрдән шәхси хуҗалыкларга печән җыярга кушканны ул белми калды.

— Ничек инде мондый эшне белми калырга мөмкин?! — дип чәрелдәде бер хатын.— Сәяси сукырлык! — Аның чын исеме Мәгъфүрә, русларга ярашырга тырышып, үзен Мага дип атап йөртә.— Әйтегез әле, сез ВКП (б) тарихының кыскача курсы белән танышмы? — дип сорады, сүзен дәвам иттереп, үзе үк җавабын да бирде:— Минемчә, сез бу изге китапны укымагансыз! Укып өйрәнгән булсагыз, партиянең явыз дошманы Бухарин юлы белән китмәс идегез.

Галләм каршы дәшмәде, аңлый: бәхәскә керешсәң, сүз тагын да зурга китәчәк. Аның үзен тыныч тотуын күреп, Мага бөтенләй чыгырыннан чыкты:

— Игътибар итегез әле,— диде,— бер нәрсә булмаган кебек, ничек кәпрәеп басып тора! Минемчә, ул акылга киләчәк түгел, аны партиядән куарга тәкъдим итә!

Мага Галләмнең калтырап төшеп, ялына башлавын көткән иде, ә тегенең йөзендә үзгәреш күренмәде, үзен элеккечә горур тотты.

Бюроның иң актив әгъзаларыннан берсе — Билалов та Фатыймага ташланды. Ул аны колхоз рәисе канаты астына сыенып яшәүдә гаепләде.

— Кара аларны, бер-берсен ничек яклыйлар! Мондый партоешма секретаренең булганнан булмаганы артык.— Бусы каты шелтә биреп, Фатыйманы партоешма секретаре вазифаларын үтәүдән азат итүне сорады.

Фатыйма куркудан чак кына астына җибәрмәде. Бер агарды, бер күгәрде, авыз ачып сүз әйтерлек хәле калмады. Бюро әгъзалары шулкадәр кызып киттеләр — беренче туктатмаса, утырыш көне буена сузылачак иде.

— Сәяси сукырлык күрсәтелгән — анысы факт,— диде ул, сүзенең һәр иҗегенә басым ясап.— Ләкин аңлы рәвештә эшләнгән эш дип уйларга нигез юк. Ничек диләр әле? «На ошибках учимся» диләрме? Каты шелтә белән чикләнергә тәкъдим итәм.

Бюро утырышы Галләм күңелендә авыр тәэсир калдырды. Әйтергә генә ансат: ярты ел эчендә ике шелтә! Ярый әле утырышта беренчесен искә төшермәделәр. Әллә оныттылар инде? Онытырлар, көтеп тор! Анда һәр адым исәпкә алынып, акка кара белән теркәлә!

Бервакытта да үзен болай начар сизгәне юк иде Галләмнең. Шуңа күрә өйгә кайтып керү белән диванга барып түнде. Баш очына Хәнифә килеп утыргач, аңа ничектер җиңелрәк булып киткән төсле тоелды.

— Шулкадәр кайгыга бату кирәкмәс иде, партбилетсыз да дөньяда яшәп була торгандыр ич! — диде Хәнифә. Сорау Галләмне өнсез итте. Дөресен әйтсә, ышандыра алырмы икән, дип уйга калды. Партия сафында, шул исәптән җитәкче оешмаларда эшләүчеләр арасында да, бары

җылы урын биләү өчен генә кесәсендә кызыл билет йөртүчеләр күп. Халыкның коммунистлардан йөз чөерә башлавының беренче сәбәбе — шушы.

— Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк,— диде Галләм житди рәвештә,— партиядән чыгарсалар, минем өчен яшәүнең бер кызыгы да калмый.

Хәнифәнең коммунистлар авызыннан чыккан мондый сүзләрне күп мәртәбәләр ишеткәне бар иде. Аны һәркем үзенчә аңлап фикер йөртә. Галләм үз сүзләренең Хәнифәгә тәэсир итмәгәнен сизеп, кызып китте:

— Мин партиягә җиңел тормыш эзләп кермәдем, коммунистик идеяне җаным-тәнем белән кабул итәм. Кешелек дөньясын социализм, бары тик социализм гына бөлгенлектән чыгарачагына чын күңелдән ышанам.

Авылга кайтып эшли башлаганнан бирле Галләмнең беркем белән дә болай ачылып сөйләшкәне юк иде. Юкка өзгәләнеп аңлатып маташты ул, сүзләре Хәнифә күңеленә үтеп кермәде, хатын боларны шул елларны модага әйләнгән гади сөйләшү дип кабул итте.

Кеше якын туганы белән уй-фикерен уртаклашырга курка, совет властен күккә чөеп мактарга мәҗбүр. Алла сакласын, онтылып китеп тормыш авырлыгыннан зарлансаң — кара исемлеккә теркәләсең һәм күзәтү астында яшисең. Һәр адымың исәпкә алып барыла.

Хәнифә урта белемле — ун класс тәмамлады. Мәктәп бусагасын атлап керү белән, социализмда кеше җәннәттә яшәячәк, дип балаларның колагына тукыдылар. Ниһаять, ул мәктәптә укыган дәвердә, илдә социализмның түбәндәге, беренче фазасы төзелде дип игълан ителде. Ә тормыш кирегә тәгәрәп авырайганнан авырайды. Бар да коры хыялга әйләнде.

Хәнифә дәреслекләр буенча кешелек тарихында барлыкка килгән төрле чорлар белән таныш. Колхозчының хәлен феодализм чорындагы крепостной крестьянныкы белән чагыштырып карый да шашып китә. Капитализм чорын искә алып торуның кирәге дә юк...

Колхозчының тормышы кара буяуны кызганмый сурәтләнгән крепостной крестьянныкыннан да авыррак түгелме соң? Ярый, җир мәңгелеккә колхозларга беркетелде. Бөтен авыл халкын клубка җыеп, тантаналы рәвештә бу турыдагы актка кул куелды.

Фактта нәрсә? Колхозчы җирдә көне-төне эшләргә генә хаклы. Хезмәте өчен бер тиен түләнми. Түләнмәсә дә, ниндидер нормативлар уйлап чыгарылган, эш көне языла. Көлке түгел диген?..

Колхозчының үзе теләгәнчә хайван асрарга да хакы юк. Асрар иде — налог белән җанын алалар, ашатырга азык табып булмый. Колхозчы көчләп ялкаулыкка чыгарыла. Авылдан китәргә талпынып карый — паспорты юк!

Хәнифә Галләмнең күтәренке тон белән әйтелгән сүзләренә каршы дәшми түзә алмады:

— Гаеп итсәгез итәрсез, бигрәк эт тормышына калдык бит, кемне тыңларга да белгән юк,— диде. Галләм аннан мондый сүз көтмәгән иде.

— Сез ялгышасыз! — Сикереп торып утырды.— Шуны ачык аңлагыз, авырлыклар алар, бар да вакытлыча, сугыш тудырган авырлыклар. Аннан шуны да онытмыйк: әлегә кадәр без ерткыч капиталистлар чолганышында яшәдек. Ышаныгыз, озакламый үзгәрәчәк, партия халыкның көнкүрешен яхшыртыр өчен бөтен көчен куя.

Хәнифә Галләмне башкачарак итеп күз алдына китерә иде. Бактың исә, ул да шул үз заманының җимеше икән. Өстән бирелгән күрсәтмәне үтәргә әзер торучы. Ләкин башкалардан аерылып торган бер сыйфаты бар — халык мәнфәгатен кайгырта.

Эш башында утыручыларның күпчелеге үзенә яхшы булса, шуңа риза. Алар өчен халыкның тормышы авыр булу яхшырак та әле. Чөнки, эт симерсә, хуҗасын талый. Ач, ялангач яшәгән халыкны буйсындыру ансатрак. Аңа сирәк-мирәк бирәр калҗа ыргытсаң, шул җитә. Совет

илендә тормыш шул вәзгыятькә корылган. Хәнифә аны болай катлаулы итеп уйламый, үзенчә гадиерәк итеп күз алдына китерә.

Илдә шау-шу куптарып, ел саен аз-маз товар бәһаләрен төшергән булалар. Мохтаҗлыкның чигенә җиткән халыкка калҗа ыргытуның бер мисалы түгелмени бу?!

Галләмнең халык мәнфәгатен кайгыртуы район җитәкчеләре тарафыннан «яхшы атлы булу» дип бәяләнә. Хәнифә моны яхшы аңлый:

— Төкерегез барысына! Колхозчыга тормыш шартлары тудырам дип үзегезне бетермәгез,— диде.— Барыбер рәхмәт ишетмәссез...

Шулай дип әйтте дә, үкенеп куйды:

— Сез тагын йомырка тавыкны өйрәтә дип уйламагыз...

Киңәш итеп әйтелгән сүзләр Галләмгә ошамады, әлбәттә. Әмма каты бәрелеп хуҗабикәнең гайрәтен чигерергә дә теләмәде.

— Башкача булдыра алмыйм, шулай гадәтләнеп үстем. Гадәт китмәс, чир китәр, дип юкка гына әйтми торганнардыр...

Хәнифә өстәлгә кайнар чәйнек китереп утыртты. Галләм ирексездән аны хатыны Шәфика белән чагыштырды. Аерма җир белән күк арасы. Югары белемле булса да, Шәфика аның кебек фикер йөртә алмый. Гомерен заяга уздыра, мескен! Теләсә кайсы ирне бәхетле итә алыр иде. Әгәр марҗа йортыннан куылып, каңгырып йөргән вакытында очрашкан булсалар... Ул үз башына шундый уйлар килүдән куркып, сискәнеп китте. Юк, юк, һәр кайсы үз урынында яхшы. Шәфиканың үзенә генә хас башка өстенлеге бар. Җүләр уйлар белән баш әйләндерер вакытмы соң? Чәй эчкәндә Хәнифәгә күтәрелеп карарга оялып утырды...

«Нигә Галләмнең хатыны килми икән?» — дип уйлады Хәнифә. «Шундый ирем булса, җәһәннәм астына җибәрсәләр дә, калмас идем»,— диде эченнән генә.

## XVIII

Габделхәй белән Шәфика бер-берсенә шулкадәр ияләштеләр, күрешмәгән көннәрендә икесенә дә тормышның яме беткән төсле тоела иде. Габделхәй белән күрешкән көнне Шәфика эшкә кояш кебек балкып килеп керә. Иптәшләре аның болай күтәренке күңел белән йөрүен дә игътибарсыз калдырмый. Ире кайтып күңелен күреп киткән дә, шуңа күрә шатлыгы эченә сыймый, дип уйлыйлар.

Без капчыкта ятмаган шикелле, аларның яшерен элемтәсе дә беленәчәк, әлбәттә. Ләкин аның бу турыда ныклап уйлаганы юк. Үзен һичкенә дә гаепле санамый. Ире янында булса, Габделхәй белән өстерәлеп йөрер идемени соң ул?! Аптыраганнан эшләнгән эш бит. Уртак сүзләре булганда тормыш авырлыгын бүлешеп, сөйләшеп йөрүнең ни гаебе бар? Юк, ул бер вакытта да шуннан артыгын рөхсәт итәчәк түгел. Галләм алдында йөзе ак, ул аны аңларга тиеш. Шулай да кеше күзенә күренеп йөрмәү хәерлерәк. Ул ресторанга барудан баш тартты.

Ә Габделхәйнең ярты юлда туктап кала торган гадәте юк. Дөрес, ул да хатынын ташларга җыенмый. Ләкин Шәфикадән читләшергә исәбе юк. Күпме акча тотты бит инде ул аны сыйларга?

Шәфика бергә тагылып йөрүне туктатырга тәкъдим иткәч, нишләргә дә белмәде. Иртән эшкә барганда алар яшәгән урамга килеп каршы ала башлады.

— Аңла! Минем яратуым бер кемнекенә дә ошамаган, кара аны: мәхәббәт утында янып үлсәм, җавап бирергә туры килмәсен,— диде.

Габделхәйнең өзгәләнеп әйткән мондый сүзләре, Шәфиканы чынлап торып ышандыра башлады. Аңа карата булган тискәре фикере минут эчендә үзгәрде. Тегесе моннан оста файдаланды:

— Син бер көнне кырга чыгып йөрү турында сүз кузгаткан идең,— диде.— Һава матур көнне сайлап шәһәр читенә китсәк, ничек булыр?

Чыннан да, җәй узып бара, нигә бер иркенләп күңел ачып кайтмаска? Мин сине табигатьнең иң матур җиренә алып барам, ул тирәгә әле шәһәр кешесенең аяк та басканы юк.

Гомер буе шәһәрнең сасы һавасын иснәп яшәргә димәгәндер ич? Мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк дигән фикергә килде Шәфика.

...Шәфика вокзалга килгәндә Габделхәй аны дүрт күз белән көтеп тора иде инде. Бу яктан аңа тел-теш тидерерлек түгел, очрашасы урынга һәрвакыт алдан килеп баса.

Алар, шәһәр яны поездына утырып, Арча ягына киттеләр. Хәзерге кебек электричкалар юк иде әле. Вагоннарга баш тыга торган түгел. Ата улны, ана кызны белми. Авыл халкы иңенә асып шәһәрдән икмәк ташый. Монда Габделхәй белән Шәфикага игътибар иткән кеше юк. Танышбелеш очрар дип курка торган түгел.

Менә аларга төшеп калыр вакыт та җитте. Вагоннан чыкканда манма тиргә баткан иделәр. Габделхәйнең куллары буш түгел, сумка аскан. Шәфика аны-моны уйлап тормады, кулъяулыгы белән аның маңгаендагы тирне сөртте. Габделхәйгә рәхәт булып китте.

Көн искиткеч матур. Иртәдән үк кояш кыздыра башлады.

Станция кырыеннан ук урман башлана. Нарат урманы. Габделхәй Шәфиканы бер сукмак белән шул урманга алып кереп китте. Берсеннән берсе узышып, башлары күккә тиярдәй булып үскән нарат агачлары арасында һава салкынча, суларга җиңел.

Шәфикага гүя канат тактылар, тәпиләп түгел, очып баралар төсле тоелды. Аның болай хозурланып йөргәне юк иде әле. Күпме гомер әрәмгә узган! Бер дә еракка, җәһәннәм астына китеп йөрисе юк, шәһәр янында да менә дигән урыннар бар икән. Ярый әле Габделхәй алып чыкты, югыйсә күрмичә үлгән булыр иде.

Бара торгач, таллар арасыннан бормаланып аккан су кырыена килеп чыктылар. Көмеш кебек саф сулы елга! Тын гына ага да ага.

Габделхәй Шәфиканы бер кырыйдагы куак астына алып керде. Шундый куе булып үскән, юклы-барлы яңгыр да үтә торган түгел. Җиргә гәзит җәеп, сумкадагы ризыкларны бушаттылар. Шулар белән маташкан арада Габделхәй өстен чишенеп тә ыргытты.

Шәфика баштарак нишләргә белмәде. Күз алдына Галләм килеп басты. «Нинди йөз белән аңа күренермен?»,— дип уйлады ул.

— Булмый миннән, кайтып китәм,— диде кырт кисеп.

— Үзеңә кара,— диде Габделхәй тыныч тавыш белән.— Поезд кичкә таба гына була.— Ул Шәфиканың характерын яхшы ук өйрәнеп өлгергән иде инде. Аны ачуланып, яки ялынып көйгә китереп булмый. Шуңа күрә юри битараф булырга тырышты.

Пешкән тавыкны кисәкләргә бүлгәләде дә, бер ботын Шәфикага тәкъдим итте.

— Башта тамак ялгап алыйк, бәйләп тотар хәлем юк, китсәң аннары китәрсең!

Шәфика мескен генә булып җиргә утырды.

— Бигрәк кыргый инде син, шәһәр кызы булуыңны әйтер идем! — Ир кеше сумкадан тозлы кыяр белән гөмбә чыгарды.— Мин тагын чатыр чабып, базардан менә боларны эзләп йөргән булам. Синең тарафтан үземә хөрмәт юк та юк инде! Ризык хакы бар...

Сарымсак һәм төрле үләннәр салып тозланган кыярның хуш исе Шәфиканың борынын кытыклап, ашыйсын китереп җибәрде:

—Шулкадәр расходланмасаң да була иде инде!

— Синең өчен җанымны да кызганмаганны беләсең ич...— Коньяк шешәсен ачты.— Рюмкалар юк, ничек эчәбез? — Ясалма рәвештә кычкырып көлде дә, стаканга эчемлек агызды:— Менә бусы сиңа, бер ике тамчы йотып җибәр! — Шәфика баш тартты.— Эчмәсәң эчмәссең, чишенеп утыр, тәнең һава суласын.

Шәфика әкке көлмәктән генә калды. Габделхәйнең аны болай ярым ялангач хәлдә беренче мәртәбә күрүе иде әле. Һич тә балалы хатын дип әйтерлек түгел, кызлар шикелле. Таушалмаган. Теләсә кайсы ирне гашыйк итәрлек. Ташып торган зур күкрәк, нечкә билле нәфис гәүдә, аяклары дисеңме — килешмәгән җире юк. Ходай бирсә, бөтенесен дә тигез итеп бирә шул!

Габделхәй ничек кенә булса да аны коньяктан авыз иттерергә тырышты.

— Моны бит дару өчен генә эчәләр, шуны да белмәскә инде?!

Шәфика стаканны тотып та карамады.

— Беренче мәртәбә очрашуыбыз түгел бит! Хатын-кызга ябыша торган гадәтем юклыгын беләсең, курыкма!

— Аек баштан гына сөйләшеп утырыйк әле! Шайтан суы белән төмен җибәрмик...

— Минемчә...— Сүзен бүлеп туктап калды Габделхәй. Киресен әйтсә, исереккә санаячак, дип уйлады, Шәфика исә үзенчә дәвам иттерде:

— Минемчә, икебезне дә яткырып чыбыкларга кирәк, безнең болай йөрүне Алла да, мулла да гафу итәчәк түгел. Теге дөньяга барасыбыз бар бит әле!

— Дөнья яралганнан бирле кешеләр шулай яшәгән, дөнья беткәнче шулай яшәячәк. Теге дөньяга килгәндә, аннан кайткан кеше юк, баргач күз күрер...

— Болай сөйләү үзе зур гөнаһ! — Шәфика кулы белән аның авызын каплады.— Синең янында утырырга да куркыныч!

Ул чын күңелennән Аллага ышана. Болай ярым ялангач ят ир янында утыруның ояты ни тора! Өйгә кайткач нинди йөз белән әнисенә, балаларына күренер? Уеннан уймак чыга, дип бик белеп әйткәннәр. Бүгеннән үк барысына чик куелырга тиеш! Алдын артын уйламый башланган эш шулай үкенечле була ул.

— Синең белән шаяруым иремә беленсә, бер минут торачак түгел...

— Бик әйбәт, икәү бергә тора башлыйбыз.

— Минем балаларыма әти була алырсыңмы соң?

— Сине яраткач, балаларыңны да үземнекеләр кебек якын итәргә тиеш булам.

Габделхәй тарафыннан болар бар да теләгенә ирешер өчен генә әйтелгән сүзләр иде. Чөнки күпме тол хатыннар белән йөреп, Шәфика кебек үз сүзендә нык торучыны очратканы юк иде әле аның. Каты чикләвек. Ничек итеп булса да ул аны ватарга тиеш. Шул максатны күздә тотып, вәгъдәгә саранланмады. Аның мондый комсызлыгы Шәфикага айнырга ярдәм итте. Торып басты да тиз генә күлмәген киде.

— Нәрсә, боларны ташлап калдырабызмыни? — диде Габделхәй, җиргә җәйгән газит өстендә өелеп яткан сыйга ымлап.— Бушка килгән әйбер түгел, акча түләп алдым.

— Рәхмәт инде! Бәлки хатының, балаларың авызыннан өзеп мине сыйлап торгансыңдыр, гаепне үз өстемә алам... Мин синең нәрсә теләгәнеңне җаным-тәнем белән сизеп торам, өмет итсәң — ялгышасың.

— Пар күгәрчен төсле гөрләшеп утырсак, миңа шул җитә...

Алдашты әлбәттә. Күреп тора: дөресен әйтсә, Шәфика бүтәнчә мондый очрашуга барачак түгел.

— Болай чишенеп, аулак җирдә утыра башласак, тегесенә дә ерак калмас...

Бу сүзләр Габделхәйгә җан кертеп җибәрде. Бөтенләй өметне өзәргә кирәк түгел икән, дип уйлады:

— Шулай булгач, нигә бер-беребезне газапларга? Мөмкин вакытта рәхәтләнеп калырга кирәк...

— Бер дә оят юк икән синдә!

— Нәрсә оялып торырга? Картайгач сагынып сөйләрлек булсын.

— Әгәр аңа барып җитсә, бөтен гомерем үкенеп узачак.

— Халык телендә: тизәкнең кырыена бастың ни, уртасына бастың ни — барыбер, дигән сүз бар. Менә бүген монда килеп утырдык, бер нәрсә булмады дип әйтсәң — ирең ышаныр микән?

— Менә син нинди, рәхим-шәфкать көтә торган кеше түгел икәнсең! Башка сүз озайтып тормады: «Мин киттем!» — диде катгый итеп.

Ул куаклыктан чыгып, шактый җир киткән иде инде, Габделхәй куып җитте.

— Һәр сүздән гаеп табарга гына торасың! Алай үпкәчел булырга ярамый.— Бетте, бетте, гаеп миндә!

Нәрсәгә әле болай сөйләшә? Гаеп итәрлек сүз чыкканы юк бит! Нәрсә өчен Шәфика аны гафу итәргә тиеш? Ул үзе гаепле. Риза булмаса, Габделхәй көчләп аны монда алып чыга алмый иде бит. Ике балалы хатын төрле хәйләләр корып, эшен калдырып, урамда күңел ачып йөрсен инде! Җинаять... Шундый уйлар башына килеп, чәче үрә торырлык булды. Төптәнрәк уйлап карасаң, акланырлык сәбәбе дә бар икән: ир белән хатынны аерым яшәргә мәҗбүр итәләр.

— Үпкәләргә хакым юк, минем өчен кулыңнан килгәннең барын да эшләдең, рәхмәт!

— Мөмкинлегем булса, моның белән генә чикләнер идемме?

— Мин синеңчә булдыра алмыйм. Уйлап-уйлап карыйм да, иремнән бер гаеп тә тапмыйм. Ул синнән ким кеше түгел...

Габделхәйнең аны ахырына кадәр тыңларга сабырлыгы җитмәде, бүлдерде:

— Ул яктан без пар килгәнбез, икебез дә бер төсле...

— Шулай булгач безгә нәрсә җитми?

Габделхәй сорауны аңламаганга салышты.

— Тыңла сүземне, дуслыкны бозмыйча гына аерылышыйк...

— Судан коры чыкмакчы буласыңмы? — Дары кебек кабынып китүен сизми дә калды Габделхәй, ләкин үзен бик тиз кулга алды:— Күрәм, мине яндырып үтерергә исәбең,— диде еламсыраган тавыш белән.

— Үлмисең! Тагын минем кебек ничә хатынның башын әйләндерергә өлгерерсең әле.— Габделхәй ирексездән елмаеп куйды. Сүз дә юк, акыллы хатын! Аны коры килеш кулдан ычкындырсаң, хурлыгы ни тора?

Станциягә барып җитү белән Шәфика кассага йөгерде һәм ике билет алды. Габделхәй акча чыгарган иде, баш тартты:

— Соңгы минутта бурычлы булып каласым килми...

— Әйе, бурычың акча белән генә түләп бетерә торган түгел, алай ансат кына котылырга уйлама,— диде Габделхәй усал елмаеп.

Вагонга кереп утыргач, Шәфикалар күршесендә яшәүче бер хатын очрады. Күрмәмешкә салышып бер почмакка поскан иде, күзе очлы икән, кешеләрне этеп-төртеп, аның янына килеп басты:

— Абау, күрше, син түгелме соң? Каян килеп чыктың бу якка?

Шәфика да югалып калмады:

— Райбашкармадан тикшерү эше белән җибәргәннәр иде,— диде. Габделхәй сүзгә кушылыр дип курыккан иде, тәртипне бозмады. Читкәрәк китеп, аны белмәгәнгә салышты. Алар транспортта йөргәндә шулай сак булырга өйрәнделәр.

Поездан төшкәч Шәфика тукталып тормады, күзе белән ымлап хушлашты да китеп барды.

Өйләренә кайтып кергәндә вакыт шактый соң, ишегалдында йөк машинасы тора иде. Аның янында бер яшь егет кайнаша. Шәфика аңа игътибар итмәде, ашыгып өйгә кереп китте.

Галләм кайткан. Ике баланы алдына утырткан да, шулар белән гәпләшеп утыра.

— Озак, озак эшләтәләр сине! Эшеңә кереп чыктым, машинага утыртып алып кайтмакчы идем.

Шәфикә кызарды, бүртенде, җир ярылса җир тишегенә кереп китәрлек булды. Алла коткарды, Галләм аның кайда йөргәе турында тәфтишләп сорап тормады. Әгәр сораса, валлаһи, гаебен сөйләп бирәчәк иде Шәфика!

— Нигә өс киемнәреңне салмадың? Бигрәк читләтә башладың инде!

— Безгә бүген кайтып җитәргә кирәк, сине күрмичә китәсем килмәгәнгә генә утырам.

Шәфика аны кочаклап, бертуктаусыз үбәргә тотынды. Кайнар күз яше Галләмнең битен яндырып алган кебек иттерде:

— Юк, юк! Бер кая да җибәрмим! Бүген үземнең янда кунасың.

Галләм аптырап калды. Күпме гомер итеп хатыны тарафыннан мондый сүзләр ишеткәне юк иде. Хәзер машинабыз бар, ешрак кайтып йөрермен, дип әйтеп карады, ишетергә дә теләмәде. Сүзләрен әнисе Фатыйма абыстай да тыңлап тора икән:

— Нигә бу кадәр хатыныңны аздырасың? Әллә алыштырып кайтардылармы үзеңне? — диде кызын әрләп.

Фәрит белән Фәридә әниләрен якладылар:

— Беркая җибәрмибез,— дип, Галләм алдыннан төшмәделәр.

Шәфика һаман күз яшен тыя алмады. Галләм ишегалдыннан шоферны чакырып алып керде:

— Әбрар, нишлибез, Шәфика апаң китәргә рөхсәт итми.

Уйлаштылар да, иртән таң белән юлга чыгарга исәпләп, кунарга калдылар. Аларга кайтышлый Шәрәфи янына кереп чыгарга кирәк иде. Әбрар шунда, Шәрәфи абыйсы янына барып кунарга булды. Аңа янгыннан соң йортын аякка бастырырга кирәк, Шәрәфи абыйсы ярдәме белән бүрәнә юнәтеп булмас микән, дип уйлады.

## XIX

Габделхәйнең Шәфикага бүгенге кебек ачуы чыкканы юк иде. «Юк, алай ансат кына минем кулдан ычкына алмассың,— диде ул эченнән генә.— Мин сине матур күзләрең өчен генә дуңгыз урынына сыйламадым».

Шулай уйланып, трамвай тукталышында басып торганда, «Гриша» дип эндәшкән тавышка сискәнеп китте. Таныш тавыш. Рус милләтеннән булган кешеләр аны шулай атап йөртәләр. Кечкенәдән өйрәнелгәнгәме, мулла кушкан Габделхәй белән беррәттән, Гришаны да үз исеме итеп кабул итә ул. Кысыр кайгыга батып, нишләргә белми аптырап торганда, таныш тавышны ишетеп күңеле күтәрелеп китте.

— О, Катя, милая, каян килеп чыктың?

Катя, шактый олы яшьтә булуына карамастан, чибәрлеген саклый белгән тол хатын. Җитеп килә торган кызы белән үз йортында яши. Ире сугыштан кайтмаган.

— Нишләп торасың монда, әллә хатының куып чыгардымы?

— Тукта, тукта, нишләп әле син минем белән болай дорфа сөйләшәсең?

— Бетте, бетте, гафу ит! Шаярам гына, нишләп йөрисең болай кичләтеп?

— Эштән кайтып барам...

— Тагын берәрсен елаткансыңдыр әле...

Катя үз аршыны белән үлчи. Ул — яхшы тегүче. Яшеренеп эшли. Үз сүзе белән әйтсәң, капканы бикләп куя да, налог инспекторыннан качып энә белән баз казый. Тикшерергә килүчеләр дөбердәтәләр, дөбердәтәләр дә — китеп баралар. Койма биек. Кем әйтмешли, кош та очып үтәрлек түгел!

Ялгыз йөреп эш чыкмагач, Габделхәй бер кечне милиционер ияртеп килде. Аны күргәч, Катяның капканы ачмый хәле булмады.

Гамәлдәге закон буенча налог инспекторына кичләтеп йөрү тыела. Законның мондый нечкәлекләренә игътибар итә торган заманмы соң? Гади халык бу турыда башына да китерми ич!

Райфо рөхсәтеннән башка эшләгән өчен штраф салып, налог исәпләгәч, шактый зур сумма килеп чыкты. Һәм түләп бетерә торган да булмады. Таяк ике башлы бит: недоимканы эзләп алмаган өчен җыелыш саен Габделхәйнең үзен эттән алып, эткә салып сүгә башладылар. Судка биреп, налог түләмәгән өчен Катяның милкен алып чыгып, сатарга була. Монда да законның нечкә ягы бар: хуҗалыкта көндәлек тормышны алып барырга кирәкле милекне налог түләмәгән өчен алып чыгып сатарга рөхсәт ителми. Катяның йорт эче шалтырап тора. Утырып ашарга бер өстәл, ике урындык, ятып йоклар өчен карават, тагын шуның ише вак-төяктән башка әйбере юк. Габделхәй, куркытырга теләп, йортыңны сатабыз, дип әйтеп карады, тик тегесе андый янауларга чыныккан иде инде.

— Фронтовик семьясын урамга куып чыгарырга хакыгыз булса, сатыгыз! — дип тыныч кына тыңлап торды.

Габделхәйгә Катяны ничек итеп налогтан котылырга өйрәтүдән башка чара калмады. Икесе бергә утырып, министр исеменә гариза яздылар.

Катя — укымышлы хатын. Сугыш алдыннан ун класс бетергән. Заманы өчен бу зур белем иде. Тагын шунысы, үзенең фикерен аңлаешлы итеп язарга да булдыра икән. Гаризаны язып бетергәч, Катя өстәлгә ак башлы шешә чыгарып утыртты. Халык телендә аны «Уну» дип атап йөртәләр иде. Моның үзенә күрә кечкенә генә тарихы да бар. Шул елларны Хрущев чакыруы буенча СССРга Бирма премьер-министры Уну килгән иде. Ул ак башлык киеп йөри икән. Бәлки, бәйләнеше дә юктыр, әмма Бирма премьер-министры киткәннән соң кибетләрдә аракы тутырылган ак башлы шешәләр пәйдә булды. Халыкка көләргә сәбәп табылды.

Дөрестерме, юктырмы: бу ак башлы шешәләрдәге эчемлекнең сыйфаты да яхшырак дип сөйлиләр иде. Сатуга чыгу белән халык шул шешәләргә ябырыла торган булды.

Өстәлгә ак башлы шешә чыгып утыргач, Габделхәйнең авызы колагына җитте. Мондый сыйны калдырып китәргә ярыймы соң? Ялындырып тормады, өстәл артына кереп утырды. Кабарга да начар түгел — тозлы гөмбә белән помидор.

Бер-ике рюмкадан соң Катяның теле ачылды. Ялгызлыктан зарланып суган суы да сыгып алды:

— Яшьлегем әрәмгә үтә,— диде.

— Шушы кадәр чибәрлегең белән нигә берәр кеше тапмыйсың?

— Кемне? Ник дәшмисең, әйт!

Бу хатын белән эш барып чыгачак дип мыегына чорнады Габделхәй. Гапь кызганнан кызды. Катя тагын бер шешә чыгарды:

— Ярый әле күңелне юатырга бу бар,— диде шешәгә ымлап. Габделхәй күкрәгенә кулын сузгач, авызын ерып якынрак елышты. Кызышып җиткәч кенә кызы кайтып, бөтен эшне бозды.

— Ничек иртә кайттың? — диде Катя аның вакытсыз йөрүенә ризасызлыгын белдереп. Ул техникумда укый икән, җидене бетереп финанс техникумына кергән. Кыз өлгереп килә, бөтен җире балкып тора.

Габделхәй үзен кулга алып, җитди кыяфәткә керде. Кайчан да булса бу кызый белән очрашырга туры килүе бар, дип уйлады. Финанс техникумын тәмамлаучылар райфога эшкә җибәрелә. Эшнең рәтен белмәсәләр дә аларга мактау һәм хөрмәт: махсус урта белемле кешеләр, имеш.

— Люда, әйдә, утыр безнең белән!

Кыз әнисенең тәкъдименнән баш тартты:

— Тагын шешәгә тотынгансыз! — Җенләнеп икенче бүлмәгә чыгып китте.

— Утырмаса, бик яхшы,— диде Катя, рюмкаларга аракы койды.— Яшь чагында без дә шулай булдык микән?

Габделхәй, яхшы чакта чыгып ычкынырга кирәк, дигән фикергә килде. Тиз генә рюмканы бушатты да урыныннан торды. Катя кыстап караган иде, артык тоткарланмады. Озатырга чыккач, кем белән утырганын кызына белдермәскә кушты.

— Андый эшне бала-чагага белдерәләрме соң? Тыныч бул, сер саклый беләбез.— Башка вакытта иркенләп килергә чакырып калды. Шәфика белән мавыгып, чакыру онытылды. Сөмсере коелып, уңышсыз сәяхәттән кайтып килгәндә үзе очравы яхшы булды әле.

— Мин эш белән йөрим, ә син менә каян кайтып киләсең?— диде Габделхәй серле итеп. Катя җавап бирергә уңайсызланып калды:

— Сиңа дөресен әйтергә ярамый инде, ялганлый торган гадәтем дә юк, асып куймассың әле...

— Кайчан әле дөресен сөйләргә өйрәндең?

Катя кинаяле сүзләргә игътибар итмәде:

— Бер начальникның хатынына күлмәк теккән идем, өенә илттем...

— Менә ничек?! Тегеп тә бир, өенә дә илт...

— Аның рәте бар, өенә итсәң, чәйлекне күбрәк тамыза. Аннан, ни әйтсәң дә, начальник хатыны бит...

Ул заманнарда ательеләр бармак белән санарлык кына һәм анда җүнле тегүчеләр дә эшләми иде. Хәллерәк кешеләр кием-салымны, райфодан яшереп, өйдә эшләүче кустарьларга тектерделәр.

— Үзләре килеп алса аяклары калмый торгандыр, ич,— диде Габделхәй бу эшкә нәфрәтен белдереп.

— Үзләре килеп алмауның тагын бер яхшы ягы бар: күршеләр килгән-киткәнне күзәтеп кенә тора.

Катя нишләгәнен сизмичә Габделхәйнең кулын тотты. Аңа рәхәт булып китте:

— Син, мадам, сак маташ! Икенче мәртәбә эләксәң, миңа ышанма, коткара алмыйм...

— Мескенләнмә, мескенләнмә!

— Рөхсәт алып эшлә!

— Бар тапканны налогка биреп барыргамы!

— Анысы менә минем кулда, налогны үзеңне ничек тотуыңа карап исәпләрбез!

Катя сүзне икенчегә борды:

— Гриша, әйдә киттек безгә!— диде. Менә ичмаса хатын дисәң дә хатын, үзе чакырып тора, Шәфикадән бер дә ким җире юк. Кинәт исенә төшеп:

— Ә кызың?— диде. Катя өйдә ялгызы гына калган, кызы ниндидер походка киткән, каникул вакыты.

Кайтып житәрәк, трамвайда икесе генә калдылар. Аларга иң ахыргы тукталышка кадәр барырга кирәк. Ул тирәдә халык үз йорты белән яши. Бар да — бер катлы, юан бүрәнәдән салынган калай түбәле йортлар. Ишегалларында зур-зур җиләк-җимеш бакчалары. Капка-койма сары буяуга буялган, урам башка төбәкләрдән чисталыгы, саф һавасы белән аерылып тора. Бу тирәдә төтен пыскытып утыручы завод-фабрикалар юк. Йорт хуҗалары, башлыча, урыслар. Дөрес, сугыштан соң берничә йортта татарлар пәйда булды. Марҗага өйләнгән татарлар. Балалары татардан бер чакырымга качып, читтәрәк йөрергә тырыша.

Трамвайдан төшкәч, Катя алданрак китте:

— Сине бу урамдагылар бар да таный, күрмәүләре хәерле,— диде. Акыллы киңәш бирә, Габделхәй берсүзсез килеште. — Капка ачык булыр дөбердәтеп, тоткарланып торма!

Ул барып кергәндә Катя өстен чишенеп ташлап, кыска җиңле күлмәктән генә калган иде. Тутырган тавык кебек. Ягымлы итеп сөйләшә, биеп кенә йөри. Җитезлеге дә бар икән, шул арада өстәл дә хәзерләп өлгерде.

— Син мине бу бозык хатын дип уйлыйсыңдыр инде,— диде ерактан килгән сәер тавыш белән.— Ирем сугыштан кайткан булса, башкаларга борылып та карамас идем! — Ирле хатыннар да кимен куймый анысы,— диде Катя сүзен дәвам итеп.— Андыйларны һич тә гафу итә алмыйм, аларны асларына җибәргәнче суктырырга кирәк!

— Шулай усаллана да беләсеңмени әле син? — диде Габделхәй аның ирененнән үбеп.— Минә син нинди шәфкатьсез хатын икәнсең! — Ул бу сүзләрне Шафиканы күз алдында тотып әйтте. Хатыннарның аларның шундыйлары да бар бит әле! Коры мунчала белән юып, ирләрне үзләренә гашыйк итәләр. Гашыйк итеп кенә калмыйлар, акылдан шашырлык дәрәҗәгә җиткерәләр.

— Син мине дөрес аңла,— диде Катя,— бәлки, ирләр турында да шулай хөкем итә дип уйлый торгансыңдыр? Ирләргә чит хатыннар белән йөрү гафу ителә, шуннан соң алар ирләр.— Бу юлы Катя үзе Габделхәйне суырып үпте. Ул шундый кызып китте: маңгаеннан, битеннән, бармакларын аерым-аерым, бертуктаусыз үбә башлады.

— Яратам, яратам! Син — минеке! — диде. Сикереп торды да күлмәген салып ташлады.

— Ничек уйлыйсың? Мин тере кеше ләбаса...— Ул аны караватка өстерәде. Мамык түшәккә кереп чумгач, дөнья кайгысы онытылды. Бераздан ак җәймә, каз мамыгы тутырылган юрган идәнгә очты.

## XX

Янгын хәленнән соң Әбрар җанына урын таба алмады. Безнең халыкта нигез килешми дигән ырым бар. Әллә, чыннан да, шул ырым дөрес микән? Нишләп соң әле бәхетсезлек берсе артыннан берсе, алар гаиләсенә генә килеп тора? Әтисе сугышта һәлак булды. Әнисе, ачлы-туклы яшәп, кырык тулганда дөньядан китте. Инде менә дәртләнеп тормыш итә башлагач кына йорты кара күмергә әйләнде. Әнә, Гажби карчык: «Аңа нигезне алмаштырырга кирәк, шунсыз тыныч тормыш күрәчәк түгел ул мескен егет»,— дип әйтеп әйтә, ди.

Кайберәүләр бәхетсезлекнең сәбәбен тагын да эчкәрәк кереп эзлиләр. Имеш, аның башын Сания генә ашады. Мулла кызы аңа тиң хатын түгел, артка тәгәри башлады, имеш.

Менә ничә көн инде Әбрарның төн йокысы күргәне, җүнләп тамагына ашаганы юк. Янгынның сәбәбен эзләп баш вата. Мичкә якканда саксызлык күрсәтүдән яки электрдан дияр идең, йортка мич чыгарылмаган. Янгын — үчле кешенең эше, кем дә булса ут төрткән, ахрысы...

Төрлечә уйлап карады Әбрар. Авылны ташлап китсәләр ничек булыр икән? Хатыны Саниягә әйткән иде, ул ишетергә дә теләмәде.

— Ни күрсәм дә, авылда күрәм! Озакламый бәбиебез булырга тора, беркая да кузгалмыйм! — дип кырт кисте.

Китәр өчен иң җайлы вакыт, югыйсә. Авылда Әбрар — бердәнбер паспортлы кеше. Бу турыда Саниядән башка белүче юк югын. Паспортны, армиядән демобилизацияләнгәч, хезмәт иткән шәһәрендә калырга уйлап, шунда алган иде. Авылга кайткач, хәрби хисапка кергәндә яшерде. Паспорты биш еллык, срогы чыкканчы китеп калмаса, аңа башка паспорт эләгәчәк түгел!

Очсыз-кырыйсыз уйлар белән башы тубал була. Ничек соң алардан әзрәк арынып торырга?

Әбрарның үз нигезенә бармый калган көне юк. Дошманнарга үч итеп йортын бастырасы килә. «Шунсыз авылдан китмәскә кирәк!» — дигән фикергә килде ул... Төзү материалы кирәк. Бер тиен акчасы юк. Кайнатасының запасы булырга тиеш. Бәлки, ул ярдәм итәр дигән өмет туды.

Менә бүген дә эштән кайтышлый үз нигезенә сугылды. Бригадир Мөбәрәкша килергә тиеш иде. Озак көтәргә туры килмәде, килеп тә

китте. Һәрвакыттагыча кызмача. Аны күргәч кенә, Әбрар бер ярты кыстырып килмәвенә үкенеп куйды. Әйе, татар акылы төштән соң шул!

Мөбәрәкша өйнең арт ягыннан әйләнеп чыкты да, эчкә кереп китте. Күзенә күренәме дип тора, шулвакыт Әбрар янына Әтүтән килеп басты. Ул аны кибеткә җибәрде:

— Тиз генә безгә кереп, Сания апаңнан акча ал да, кибеткә йөгер,— диде.

Мөбәрәкша өй эчендә шактый озак торып чыкты.

— Монда әлләни зур эш юк, идәне, түшәме үз урыннарына бара, ә менә түрдәге берничә бүрәнәне алмаштырырга кирәк,— диде. Ул, МТС директоры белән сөйләшеп, ярдәм итәргә вәгъдә бирде. Әбрар аннан моны көтмәгән иде, күңеле күтәрелеп китте.

Шул арада Әтүтән кибеттән әйләнеп кайтты. Аның кулында шешәне күреп, Мөбәрәкшә назланып маташты:

— Кирәкмәс иде,— хәлегезне болай да аңлыйм...

Мөбәрәкша, Әтүтән аракыны үз белдеге белән алып килде, дип уйлады: —«Яшь булса да эшнең рәтен белә егет,— диде аны мактап. Шешәнең артына кулы белән сугып, бөкесен чыгарды.— Нишлибез, авызыннан гына җибәрәбезме?» Җавап көтеп тә тормады, голт-голт йотып, Әбрарга тоттырды. Шешәнең яртыдан күбрәге бушаган иде.

— Үзе ачы, үзе сасы — эчәбез бит шул агуны! — дип сөйләнә-сөйләнә балык коерыгы кимерде.— Нәрсә шаккатып торасың? Эчеп җибәр, кайгыларың таралыр,— диде Әбрарга.

Бер йотым аракы Әбрарны рәхәтләндереп җибәрде. Аруы бетеп җиңеләеп калды. Аның аракыны үзе генә авызына да алганы юк, кеше белән аз-маз эчкәли.

— Җитеп бетмәде бугай, әллә йөгереп кенә тагын кибеткә барып киләсеңме? — диде ул Әтүтәнгә.

— Мин норманы тутырдым, сез үзегезгә карагыз,— диде Мөбәрәкша. Алар өчесе өч якка таралдылар.

Әбрар кайтып кергәндә өйләрендә кайнатасы Зариф мулла утыра иде. Ул сирәк килә. Әтисе килү хөрмәтенәдер инде, Сания коймак пешереп маташа. Әбрар уңайсыз хәлдә калды. Аракы эчкәне сизелсә, эш харап...

Сәлам биреп ике куллап күреште. Аракы исен сиздермәскә теләп, авызын еракка тотарга тырышты. Сания тиз генә комганга җылы су тутырып, аны юынырга ишегалдына алып чыкты.

— Нигә болай саташып йөрисең, нәрсә булды сиңа?

— Исе киләме?

— Бер чакрымга аңкый,— дип кат-кат авызын чайкатты.

Аш янында Зариф мулла сүзне ерактан башлады.

— Дөнья мәшәкать йорты,— диде ул. Шул мәшәкатьләргә биреш-мәсә генә, кеше кеше булып кала.— Ул чын-чынлап киявенә үгет, нәсихәт укырга керешге.— Тормышта авырлыклар берсе артыннан берсе туып кына тора. Аны һәр кеше үзенчә кичерә. Авырлыкларга аяусыз көрәшкән кеше генә яшәргә хаклы. Кайберәүләр, аз гына кырын килсә, калтырап төшә, хәмер эчеп күңеленә юаныч таба. Шуннан бик сак булырга кирәк, китап хәмерне «еммел хабаис» — начарлыкның, кабәхәтлекнең анасы дип атый. Исереккә диңгез тубыктан! Исерек адәм иң явыз ерткыч хайваннан да яманрак, үз күңелен күрер өчен бер нәрсәдән дә тартынып тормый.

Әбрар җир ярылса җир тишегенә кереп китәргә әзер иде. Әйе, Зариф хәзрәт аның бакчасына таш ыргыта. Һәр сүзе дөрес, чынлап та, бер минутлык рәхәт өчен, үзеңне үзең мәңгегә тәмуг кисәве булырга хөкем итәргә ярамый.

Зариф мулла коры сүз белән генә чикләнеп калмады, гыйбрәтле бер вакыйганы сөйләп күрсәтте.

Моннан күп еллар элек, әүлиялардан берәү, малаен ерак юлга озатканда әйтә: улым, ди, мин сиңе өч нәрсәдән — угрылыктан, зина кылудан, хәмер эчүдән катгый рәвештә тыям, ди. Егет чит шәһәргә барып төшкәч,

күңелен канәгатьләндерерлек кәсеп таба алмый. Ташып торган көчен кая куярга белми, аптырап йөри. Хәмер сатылган кибеткә күзе төшә. Бер касә шәраптан әллә нәрсә булмас әле дип, эчемлектән авыз итә. Кибеттән чыгу белән чибәр бер хатын очрый. Ялындырып тормый, аны өенә алып кайта. Беренче минуттан ук тагын хәмергә тотыналар. Гыйшык-гашрәт... Хатынның икенче бер сөяркәсе бар икән. Зинаның иң кызган чагында шул килеп керә. Китә ызгыш, тарткалаш! Егет күп уйлап тормый, башта хатынның үзен, аннан сөяркәсен чәнчеп үтерә...

Әбрарның кайнатасы белән болай барысын уртага салып, озаклап сөйләшеп утырганы юк иде әле. Сүз аның авылны ташлап китү мәсьәләсенә күчте:

— Китеп йөрмәскә киңәш итәм,— диде кайнатасы.— Беркайда да әзерләп куймаганнар. Чакмы, чокмы — туган җирдән чыкма, дигән сүз бар. Ни күрсәк тә, бергә күрербез.

— Сез шулай дисез дә бит, без кеше өендә яшибез, озакламый кайтулары ихтимал...

— Җан биргәнгә җүн бирә ходай, урамда калмассыз. Сезгә безнең янга күчеп торырга да мөмкин. Әмма, уйладым-уйладым да, хәзергә аерым яшәвегез хәерлерәк дигән фикергә килдем.

Моны Әбрар үзе дә чамалый. Әгәр күчсәләр, аңа көн күрсәтәчәк түгелләр. Әле аерым яшәп тә, мула кияве дип тере килеш ашарга торалар.

Зариф хәзрәтнең күз алмасы кебек саклап тоткан балы бар. Шуны сатып, акчасын кияве белән кызына бирергә җыенуын әйтте.

— Карап торган бар байлыгым шул, иш янына куш булыр,— диде.

Кайнатасы белән булган әңгәмә Әбрарга яшәү дәрте бирде.

## XXI

Күп тырыша торгач, колхоз машиналы булды.

Ниндидер хәрби частьне таратканнар да, аларның автомашиналарын авыл хуҗалыгына җибәргәннәр. Фронт юлларын узган машина. Иске булса да, ярап торырлык.

Машина булды булуын, икенче мәсьәлә туды: йөртергә кеше юк. Читтән ялласалар гына инде.

Мәсьәлә идарә утырышына куелды. Хисапчы Таһир машина йөртергә читтән кеше яллауга катгый рәвештә каршы чыкты. «Үзебезнең кешене, авыл кешесен шоферлар курсына укырга җибәрергә кирәк»,— диде. Уйлаштылар да Әтүтәнне укырга җибәрергә булдылар. Тик, ул курс бетереп кайтканчы, машинаны тик яткырыргамы?

— Кеше эзләп баш ватмагыз, Әбрар белән сөйләшеп карагыз,— диде авыл советы рәисе Сабиха.— Ул машина йөртә белә, документларын үз күзем белән күрдем, армиядә өйрәткәннәр.

Идарә әгъзалары аның тәкъдимен хупладылар. Шунысы гына бар, ничек аны МТСтан йолкып алырга?

— Ул авылны ташлап китәргә җыена, иптәш Җиһаншин үзе сөйләшсә, бәлки, аны тыңлар...

— Коры сөйләшү белән эш чыкмый, йортын торгызырга булышырга кирәк!

Бу сүзләрне ишетүгә, Фатыйманың зәһәре йөзенә чыкты:

— Шул гына җитми,— дип акырды ул,— китәсе килә икән китсен, тотмагыз, мулла киявеннән башка да кеше табылыр...

Икенче көнне Галләм Әбрарны кәнсәләргә чакыртты. Күптән күрешкәннәре юк иде. Бик нык ябыккан, ничектер боегып калган. Утырырга урын тәкъдим иткәч, баш тартты:

— Әйтәсе сүзегезне әйтегез дә, китим,— диде.— Вакытым тар, тоткарламагыз! — Галләм аның сүзләрен ничек аңларга да белмәде:
— Минем белән сөйләшергә теләмисез булып чыкты, егет кешегә алай килешми, әйтегез, миндә нинди ачуыгыз бар?
Сорау Әбрарны стенага терәде, озак фикерен җыя алмый торды:
— Беркемгә дә ачуым юк, үзем гаепле...
— Нинди гаеп ул тагын?
— Авылга кайтып ялгыштым, безнең татар халкы белән эшең төшмәсен! — Галләм чын күңелдән әрнеп, текәп карап торды:
— Бу сүзләрне әйтергә ничек телең бара? Кайда сине үзеңне тудырган халыктан ваз кичәргә өйрәттеләр?
— Тормыш үзе өйрәтә...
— Хәзер нишләргә уйлыйсың?
— Китәм,— диде Әбрар кырт кисеп.
— Алай ансат кына чыгып китә алмассың әле! Элек паспорт алырга кирәк.
Әбрар чак кына «минем паспортым бар» дип ычкындырмады.
— Ул турыда уйланган...
— Бер кая китмисең! Башыңнан чыгарып ташла андый җүләр уйларны!
— Торырга урының булмасын, ничек итеп монда көн күрергә кирәк?
— Әкренләп бар да булыр! Анадан бала шәрә туа, шуны аңлыйсыңмы син?
— Минем әкеренләп көтәргә мөмкинлегем юк. Күзе бар кеше күрә торгандыр, яңа кеше туарга тора...
Галләм аның бу сүзләр белән хатынының йөкле булуына ишарәләвен аңлады:
— Исән-сау котылсын дип теләктә тор,— диде,— хәзергә түбәңнән яңгыр үтми.
— Миңа үземнеке кирәк.
— Шул турыда сөйләшергә чакырдым да инде мин сине.— Галләм аңа машинага утырырга тәкъдим итте.— Әгәр мин уйлаганча барып чыкса, сиңа йортны әр-яңадан салабыз.
Халык телендә «гөбәдиягә арт ягыңны куярга ярамый» дигән сүз бар. Яхшымы, яманмы — Галләм колхозның хуҗасы. Нигә әле аның тәкъдименнән баш тартырга? Аннан тагын шунысы: автомобиль — трактор түгел, эше җиңелерәк булачак.
— Хатын белән киңәш итеп карармын, ул тагын нәрсә әйтер,— диде Әбрар. Белә, бу хәбәрне ишеткәч, Саниясе шатланачак кына. Үз бәһасын күтәрергә чамалады ул.
— Әгәр риза булсаң, сузма, машинага утырсаң, оттырмассың,— диде Галләм. МТС белән сөйләшүне ул үз өстенә алды.
МТСта тракторчылар җитәрлек иде. Галләм үзе сөйләшкәч, Әбрарны тоткарламадылар.
Машинага утыру белән Галләм аны шәһәргә алып чыгып китте. Бер көндә әйләнеп кайтырга исәпләгән иде, барып чыкмады. Шәфиканың кәефе кырылган чагы туры килде. Сагыз булып ябышты иренә. Моның артында нәрсә ятканын Галләм күз алдына да китерә алмады. Кирәк бит туры килеп торырга? Күрәсең, Ходай кешенең күңеленә сиздерә. Бер дә болай вакытсыз кайтып йөргәне юк иде. Шәфика Габделхәй белән кырда күңел ачып йөргән көнне кайтып керде. Юк, Шәфиканың йөрәгендә тузан кадәре дә Галләмгә хыянәт итү теләге юк иде. Ләкин, ят ир белән икесе генә көне буе урманда йөргәч, аның иренә хыянәт итмәвенә кем соң ышаныр икән? Ире алдында тезләнеп гафу үтенергә җыенган иде, тыелып яхшы итте. Үзе башлап чит ирләр белән өстерәлеп йөрүен әйтсә, эшнең зурга китәсен көт тә тор!
— Алып кит мине,— диде ул Галләмне озатканда.— Монда мине батыралар, ахыры аяныч булачак.

Кунтән түгел генә теше-тырнагы белән шәһәргә ябышып яткан хатынының йөз сиксән градуска борылыш ясавы Галләмне гаҗәпләндерде гаҗәпләндерүен, ләкин моңа артык игътибар итмәде. Хатын-кызның чираттагы капризы дип кенә уйлады.

Дөресен генә әйткәндә, Галләм авылда төпләнеп калуына ышанып бетми иде. Юк кына нәрсә өчен дә бәйләнергә генә торалар. Ул җанытәне белән колхозчыларга уңайлы тормыш шартлары тудырырга тели. Әмма изге теләген кирегә алалар. Имеш, аерым кешеләрне баетып, шәхси милекчелек психологиясен чәчәк аттырырга юл ача. Кайда инде ул баю?! Көне-төне эшләп, ачлы-туклы яшәп яталар бит!

Әбрар Галләмне алырга таң белән килеп җитте. Шәфика кайнар күз яше түгеп озатып калды. Галләм ешрак кайтып-килеп йөрергә вәгъдә бирде.

Алар юлга чыкканда шәһәр халкы яңа йокыдан уянып килә иде әле. Шулай да, трамвайлар йөри иде инде. Сугыш вакытынннан калган вагоннарны әкренләп алмаштыралар. Яңа Рига вагоннары кайткан. Галләм шуңа игътибар итте: элеккеләре ярым җимерек, кузгалып киткәч дөбер-шатыр килеп, җир селкетә, аннан адым саен туктый иде. Күренеп тора, шәһәрдә тормыш яхшыга таба үзгәрә. Юкка гына авыл халкы шәһәргә ыргылмый, күрәсең...

Юл уңаенда Галләм урманчылыкка кереп чыгарга уйлады. Алар барып җиткәндә Шәрәфи юан бүрәнәләрдән яңа гына өеп куелган бура тирәсендә маташа иде. Монда Галләм соңгы мәртәбә булып киткәннән соң шактый зур үзгәреш булып алган. Ни арада төзеп өлгергәннәр: урман каравылчысыннан читтәрәк, тагын өч йорт калкып чыккан!

— Болар нинди йортлар?

— Шәһәрдән күчеп килгәннәр,— диде Шәрәфи, мыек астыннан елмаеп.— Шәһәрне макта, авылда яшә...

Галләм артык төпченеп тормады, үзен кызыксындырган мәсьәләгә күчте:

— Шушымы? — диде бурага ымлап.

— Сезгә атап буралды, белмим, ошатырсызмы?

Галләм бураның эченә кереп карап чыкты:

— Бишкә-алты дип әйтимме?

— Ошаса, тизрәк алып китегез! — диде Шәрәфи.— Яман күздән Алла сакласын...

Галләм кискен бер карарга килде. Авылда йә кала, йә юк, әлегә түбәсенә су да үтми әле. Йорт салып мәшәкатьләнмәскә булды.

— Бураны сиңа бүләк итәм,— диде. Әбрарны беренче мәртәбә күргән төсле башыннан аягына кадәр күзеннән үткәреп.— Иртәгә үк ташырга тотын! — Аннары Шәрәфигә мөрәҗәгать итеп: — Машина белән ничә рейс ясарга туры килер икән? — дип сорады.

— Сез нәрсә, иптәш Җиһаншин, шаяртасызмы? — Әбрар аның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

— Берәр вакыт минем шаяртып сөйләшкәнне ишеткәнең бармы?! — Ә өй хакын бетем белән түләрменме?

— Тыныч бул, анысын мин үзем кайгыртырмын.

Шәрәфи бер якка да катнашмады, сөйләшү шуның белән тәмам дип уйлап, кунакларны өйгә чакырды. Галләмнең керергә исәбе юк иде.

— Минем карчык итәгенә ут капкандай, кабаланып аш әзерләп йөри, аны үпкәләтергә телисезме? — диде Шәрәфи.— Аннан мондый эшне болай калдырырга ярамый, юарга кирәк.

Хәмсәнә таба пәрәмәче пешергән. Хуш исе хәтта ишегалдына чыккан. Хәмсәнә аны өстәлгә зур табак белән китереп куйды. Шәрәфи коньяк чыгарды:

— Кирәкми, алып куй! — диде Галләм.— Энекәшең руль артында, үзең беләсең, аңа рөхсәт ителми. Ә мин иртәнге сәгатьтә исерткечне авызыма да алмыйм.

— Ничек биздерергә инде бу карт тилене?—диде Хәмсәнә сүзгә кушылып.—Кеше килдеме, аракыга тотына, бер сүз тапканнар: юалар, имеш!..

— Безнең татар халкында андый гадәт юк иде,—диде Шәрәфи.—Теләсәң теләмәсәң, урысларга ияреpгә туры килә...

Аннары сүз яңа көчеп килгән күршеләргә күчте:

— Күршең үзеңнән яхшы булсын, дип юкка әйтми торганнардыр,— диде Галләм.—Нинди халык?

— Дөнья күргән кешегә охшыйлар, кайчандыр колхоздан качканнар.

Галләм ничек итеп аларга монда килеп йорт салырга рөхсәт ителүе белән кызыксынды. Шәрәфи, бармагы белән ишарәләп, акчаны аңлатты:

— Алдан йөри торганнары бар, шул булса, юлы табыла. Аңа бернинди закон да киртә кора алмый.

Шәрәфи сөйләгәннәрдән шул аңлашылды: урманчылыкта җир сатыла икән. Кем рөхсәте белән сатылганын бер Алла үзе генә белә, очына чыгарлык түгел.

Шәһәрдә караңгы, юеш подвалларда яшәгән халык, бик теләп табигать кочагына килеп чума. Шәрәфигә акмаса да тама икән.

— Озакламый монда зур бер бистә барлыкка киләчәк,—диде ул.— Шәһәргә җәяүләп йөрергә мөмкин, трамвайга ярты сәгатьлек юл!

— Мин килеп йорт салырга теләсәм, урын табылырмы?

Уены-чыны белән бирелгән сорауны Шәрәфи елмаеп кабул итте:

— Үзеңне ничек тотасың бит!..

— Юк, авылны аякка бастырмыйча, без беркая да кузгалмыйбыз! Шулай бит, Әбрар?

Ул, үз уйларына бирелеп, нәрсә турында сүз барганын абайламый калды. Чыннан да, Әбрар алдында зур мәсьәлә килеп басты. Ничек итеп тиз генә бураны авылга күчереп кую мәсьәләсе. Тимерне кызуында сугып калу дигән сүз бар. Хуҗа үзе ярдәм итәргә кулын сузып торганда файдаланып калырга кирәк!

...Галләм, вакыт табып, көндәлек матбугат белән танышып барырга тырыша. Шәһәр юлында йөреп берничә көн инде кулына гәзит тотып караганы юк иде. Район гәзитендә аның турында зур мәкалә урнаштырылган икән. Үзе белән гаиләсен авылга алып килмәве тәнкыйть ителә. Мәкалә авторы тозлы-борычлы сүзләрне кызганмаган. Рәиснең ярты гомере авыл белән шәһәр арасында йөреп узганлыктан, колхоз белән җитәкчелек итәргә вакыты калмый, диелгән. Мәкалә «безгә авылга төпләнеп, үзебез белән аралашып яши торган рәис кирәк» дип тәмамлана. Авторның фамилиясе күрсәтелмәгән. Имза урынына «бер төркем колхозчылар» дип кенә язылган.

Ул заманда аноним мәкалә язуның кызган чагы иде. Дөресме, дөрес түгелме—тикшереп тору юк, бастырып чыгаралар. Бу мәкалә аның кытыгын китерсә дә, Галләм игътибар итмәскә тырышты. Гаиләсен үз янына алып килмәве—чынмы, чын! Шулай булгач берничек тә колхоздан читкә чыгып вакыт үткәрмәвен исбатлый алачак түгел.

Гәзит төпләмәләрен бер читкә авыштырды да өстәл тартмасындагы «үз кулына бирергә» дип язылган конвертны кулына алды. Анда шакмаклы дәфтәр битенә язылган хат бар иде. Кемнән икәнен белдермәскә теләп булса кирәк, хат басма хәрефләр белән язылган. Озын түгел, ярты дәфтәр битен генә чуарлаган. «Хатының Шәфика ят ирләр белән ресторанга йөри, аннан урманга чыгып китәләр. Сөяркәсе үзе белән бергә эшли. Гомерегезнең кем белән узганын беләсезме,юкмы?» Хат язучы имзасын куймаган. Бер көнне—ике аноним хәбәр!

Галләм кемдер шаярта дип уйлап, хатны ертып мичкә ыргытмакчы иде, кулы тартмады. Тукта! Болар арасында берәр бәйләнеш юкмы? Юк, юк, икесе ике чыганактан! Гәзиттәгесен үзе белән бергә эшләүче авыл кешесе язган, икенчесе шәһәрдән җибәрелгән булырга тиеш... Чөнки бу

авылда аның хатынының исемен белүче кеше юк. Хатта аның тормышы ачык итеп сурәтләнгән. Мондый хатны Шәфиканың үзе белән бергә эшләп, аралашып йөрүче кеше генә яза алачак.

Галләмнең хатта язганнарга ышанасы килмәде. Бу турыда хәзергә беркемгә дә сиздермәскә кирәк, дигән фикергә килде. Ашыгып, тормышын бозып ташларга мөмкин. Сабыр итсә, яхшырак булыр...

Аноним хатларга никадәр генә игътибар итмәскә тырышмасын, Галләмнең күңел тынычлыгы югалды. Борчулы булуын фатир хуҗасы Хәнифә дә сизенде. Кичке ашка итен мул салып бәрәңге пешергән иде, Галләм бер-ике генә капты да, тәлинкәсен читкә алып куйды.

— Бу арада начар ашый башладыгыз әле,— диде Хәнифә.— Әллә мин әзерләгән ризыкны яратмыйсыз инде?

— Бик тәмле, җиренә җиткереп әзерләнгән! Моны да яратмасаң, гомереңә аш чырае күрмәссең.

— Нигә ашамыйсыз соң?

— Нигәдер аппетит юк...

— Кәефегез юклыгы йөзегезгә чыккан, әллә теге гәзиттәге мәкаләгә борчыласызмы?

Галләм сискәнеп китте. Димәк, колхозчылар укып та өлгергәннәр!

— Юк-бар белән баш катырып үзегезне бетермәгез! Халык хәзер сезне таныды, мәкаләнең яла ягу икәнен аңлыйлар...

— Төрлесе бардыр инде.

— Көнчелек белән язылган мәкалә ул!

— Миңа, хатынлы кешегә, гыйшык тотучы да бар микән әллә?

Көнчелек сүзенең икенче мәгънәдә әйтелүен аңлап, туктап калды, ничектер уңайсыз булып китте аңа.

— Авылны Фатыйма болгата,— диде Хәнифә, сүзен дәвам итеп.— Әбрар белән эше барып чыкмагач, сезгә тотынды.

— Мәкаләне Фатыйма язган дип уйлыйсызмы?

— Аның эче тулы хәйлә, кемне булса да әгъвалагандыр...

— Шулай да, кемне булыр икән?

— Этнең аның иярченнәре күп була.

Галләм иртәгесен эшкә килгәндә, идарә капка төбендә басып торган Шәфиканы күреп егылып китә язды.

— Синме бу, әллә күземә генә күренәсеңме? — Кулында кечкенә бер чемодан, эшкә йөри торган киемнән, күзләрендә боек караш.

— Куып җибәрмисеңме?

— Нәрсә сөйлисең син?! — Галләм аның биленнән кочып алды.— Ничек минем янга килеп чыгарга уйладың? Озаккамы?..

— Бөтенләйгә килдем, күпме аерым яшәргә була?..

— Балалар, әнкәй?..

— Сөйләшербез, фатирыңа алып кайт!

Алар җитәкләшеп кәнсәләргә керделәр. Анда Таһир ялгызы, бик тырышып, исәп-хисап кенәгәләренә нәрсәдер язып утыра иде. Сәламне алды да, Шәфикага текәлеп, аптырап калды. Ул аны берәр эш белән районнан килгән дип уйлады. Килеш-кыяфәтенә караганда, районнан гына да түгелдер әле. Югарыдан булса, эш харап! Колхозда бер грамм атланмай юк. Узган атнада райком инструкторы килгән иде, өч көн буена шуны «тыгындырдылар». Таптылар бер савым сыер! Авылга килгән вәкилләрнең олысы-кечесе колхоз өстеннән ашап-эчеп яталар. Берәр файдасы тисә икән!

Ниһаять, Таһирның түземлеге бетте:

— Кем дип белик бу иптәшне?

Галләм белән Шәфика бер-берсенә карашып алдылар.

— Йә, әйтеп кара әле, кемгә охшаган?

— Гаеп итә күрмәгез тагын, шуңа соравым: фатир кертү мәсьәләсен хәл итәргә туры килмәгәе...

Галләм ирексездән елмайды:

— Егет тә кеше инде үзең,— диде,— дөрес кайгыртасың, фатир кирәк булачак. Тик син уйлаганча бер-ике көнгә генә түгел, озакка...
Таһирның гаҗәпләнүе тагы да артты:
— Әллә, безнең авылга эшләргә килгәнме?
— Уйлашырбыз, яраклы эш табылса...
Таһир Галләмгә әйтә башлаган сүзен ахырына җиткерергә ирек бирмәде:
— Хуплыйм, хуплыйм! — дип каршыларына килеп басты.— Бөтен колхозыбыз белән көтә идек.
Колхозда шәһәрдәге кебек аерым билгеләнгән ял көннәре юк. Эш булганда колхозчы көн дими, төн дими, эшли бирә. Галләмгә дә шул тәртипкә буйсынып яшәргә туры килә иде. Бүген ул хатыны Шәфика килү хөрмәтенә ял итәргә уйлады:
— Иптәш хисапчы! Әгәр мин хәләл җефетем белән өйгә кайтып китсәм, прогул язмассың бит? — дип сораган булды.
Алар көлешә-көлешә кәнсәләрдән чыгып киттеләр.

## XXII

Авылның югары очында яңа йорт калкып чыкты. Нарат бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы йорт. Салам түбәле өйләр арасында балкып тора. Янында ак мунча да бар. Иске йорттан калган бүрәнәләрдән оештырдылар.
Эшләп бетерү белән Сания мунча ягып, тирә-күршедәге карчыкларны юындырды. Халык юыныргә мунча таба алмый тилмерә, ягулык кытлыгы үзәккә үтә иде.
Әбрарның яңа йорт төзүе үзенә күрә бер бәйрәмгә әйләнде. Ул авылның олы яшьтәге кешеләрен җыеп, нигезгә Коръән укытты. Мәҗлескә Галләмне дә чакырды. Мондый мәҗлестә аның үз гомерендә беренче мәртәбә катнашуы иде. Шәфика да ияреп килде. Ул Коръән укытылган мәҗлестә хатын-кызның үзен ничек тотарга тиешлеген яхшы белә. Озын җиңле күлмәк киеп, башына кырыйлары чигүле ак яулык бәйләп килде. Мөселман тәртипләрен бөтен нечкәлекләре белән әнисе өйрәткән иде. Яулык чите белән авызын каплап, кунакларга аш өләшеп йөрде.
Зариф хәзрәт Коръән укыганда һәркем тын да чыгармыйча Аллага согындылар. Коръән уку тәмамланганнан соң, изге теләкләр белән дога кылучыларга ияреп, Гәлләм дә ике кулын күтәрде.
Соңыннан хәл-әхвәл сорашып, бик озак кызыклы сөйләшү дәвам итте. Күбесенчә узганнарны искә төшерделәр. Хәзерге көн, илдәге хәл турындагы ләм-мим. Зариф мулла читкә тайпылып сөйләшергә ирек бирмәскә тырышып, саклык чаралары күреп утырды.
Галләм бер нәрсәгә игътибар итте: «шайтан суыннан» башка да күңелле итеп утырып була икән, аек баштан сөйләшүгә ни җитә?! Ул элек тә, мәҗлестә аракы эчеп, дуңгыз урынына тыгынып утыруны өнәми иде.
Күршеләре Әбрарга йортны ялгыз калдырмаска, иртәдән үк күчеп, шушында яшәп башларга тәкъдим иттеләр.
— Үзе юкның күзе юк, тагын әллә нинди бәла-каза килеп чыгуы мөмкин,— диделәр.
— Әбрар абый, җаным, ятма кеше йортын саклап,— диде Әтүтән.— Хәзер сезнең урамда йөрүе дә куркыныч, тагын берәр хәл килеп чыкса, миңа ягарлар...
Бер якка да катнашмыйча тын гына утырган Шәвәли дә сүзгә кушылды:
— Ныклап тикшерүче булмады, теләсәләр, янгынның сәбәбен ачыклый алалар иде анысы,— диде.— Кем кулы уйнаганы билгеле...

Мәҗлестә утыручылар серле итеп бер-берсенә карашып алдылар да, шуның белән бетерделәр, бу турыда сүз куертмадылар.

Караметдин Галләмгә үпкә белдереп алды:

— Иптәш Җиһаншин, нишләп сез бөтен эшне шул Фатыйма белән килештереп хәл итәсез?

— Безнең илдә бөтен эшне партия хәл иткәнне белмисезме әллә?— диде Галләм.— Фатыйма партия кешесе, аны узарга рөхсәт ителми.

Ул Караметдинның соравына башкача да җавап бирә алган булыр иде, әлбәттә, ярамый.

— Партия җитәкчесен үзегез сайлап куя торгансыздыр ич, халык мәнфәгатен яклый торганрак эшлекле кеше сайларга кирәктер...

Бусы инде тагын да четерекләрәк сорау иде.

— Сайлавын без сайлыйбыз, ләкин кемне сайларга кирәк икәнлеге югарыда хәл ителә.

Сүзнең болай тирәнгә керүе Зариф мулланы сагайтты. Ул яхшы аңлый, монда сөйләшкәннәр иртәгә үк чәчми-түкми югарыга җиткереләчәк. Үзе өчен кайгырмый, яшен яшәгән, ашын ашаган дигәндәй, монда яшьләр дә бар, аларны кайгырта.

— Җәмәгать, күп сүз, юк сүз,— диде ул сөйләшүгә нокта куярга чамалап.— Берүк хуҗаларга тел тидерә күрмәгез, хуҗаларыбыз бик әйбәт, илне менә дигән итеп алып баралар.

Мәҗлестә утыручылар мулланың бу сүзләре чын күңелдән әйтелмәвен ачык аңлый, ләкин бәхәсне дәвам иттерүдән файда юклыгын да беләләр. Үз чиратында Галләм дә Зариф мулла белән килеште. Аның мондый юл белән куркынычлы сөйләшүне икенчегә борып җибәрүен акыл эше дип бәяләде.

Әбрар икенче көнне үк үз йортына күченде. Күченде дип, авыз тутырып әйтерлек эш юк, әлбәттә. Шулай да, Шәрәфи өендә тора башлаганнан бирле җыелган вак-төякне иңбашына күтәреп ташый башлагач, ярты көн вакыт үтте. Ике өйнең арасы ерак булмагач, ат җигеп тормадылар. Машина белән дә күчереп була иде, югыйсә. Нәрсәдер, берәмләп ташу кулаерак күренде. Һәрвакыттагыча бу юлы да аларга Әтүтән булышты.

Яңа өйгә иң элек Әбрарның үз кулы белән эшләгән агач караватт, өстәл, урындык кереп утырды.

Зариф мулланың пыяла шкафы бар иде. Яңа өйне котлап, кияве белән кызына ул шул шкафны бүләк итте.

Урын-җирне, савыт-сабаны Сания ташыды. Пыяла шкафны түргә, ике тәрәзә арасына кертеп куеп, савыт-сабаны шунда тутырдылар. Караватка ак чыбылдык корып куйгач, өй эче танымаслык булып үзгәрде. Өй эче генә түгел, хуҗалар үзләре дә үзгәрде. Җиргә нык басып, канатланып йөри башладылар.

Шәрәфи йортына да йозак салынмады. Галләм белән Шәфика шунда күчтеләр. Хатыны килгәч, аларга Хәнифәнең ак өендә яшәү мөмкин түгел иде инде. Турыдан-туры әйтмәсә дә, аңлаган кешегә аңларлык: хуҗабикәнең гаиләле кешене яшәтәсе килми. Шәрәфи йортының бушап калуы бик вакытлы килеп чыкты.

Яңа фатирга күчү белән икенче мәшәкатьләр барлыкка килде. Хәнифәдә яшәгәндә, башканы әйткән дә юк, урын җиргә кадәр анықы иде. Ашыгыч рәвештә шәһәргә барырга туры килде. Алар шәһәргә Шәфика белән икесе бергә киттеләр. Газикның кабинасына, шофер янына бер генә кеше сыя. Галләм Әбрар янына хатынын утыртты, үзе кузовка кунаклады.

Бик тиз әйләнеп кайтырга уйлаганнар иде, барып чыкмады. Балаларны көйләп шактый вакыт үтте. Фәрит белән Фәридә сагыз булып ябыштылар. Һич әйткәнне аңламыйлар, безне дә алып китегез, диләр.

Фатыйха абыстай да көтмәгәндә, кинәт кенә кызының үзен ташлап китүенә риза түгел.

— Балалар бик көйсез, бер үзем аларны карар хәлем юк,— дип зарланды.

Шәфика эштән киткәндә хезмәт кенәгәсен алмаган иде. Юл уңаенда райфога керделәр. Галләм урамда калып торды. Шәфика райбашкармага үзе генә кереп китте.

Биш минут та тормыйм, хәзер әйләнеп чыгам дип кереп китсә дә, Шәфика озаклады. Галләм түземлеген югалтып машинадан төште һәм урамда марш атлап йөри башлады. Аның каршына бер хатын килеп басты.

— Иптәш Җиһаншинмы? — диде усал елмаеп.

— Мин булам Җиһаншин...

— Җиһаншин булсагыз, менә тыңлагыз! — Пулеметтан аткан кебек такылдап, «хатынысгыз Шәфика зиначы, коры зиначы гына түгел, эче тулы мәкер, ике бала атасын юлдан яздырды» — дип телгә алмаслык әшәке сүзләр тезеп китте.

— Сез нәрсәдер бутыйсыз,— диде Галләм тыныч тавыш белән.— Мин үз хатынымның кем икәнен яхшы беләм...

— Сөяркәсе бездә эшли, Шәфика белән ресторannan ресторанга йөреп эчкечегә сабышты...— Хатынның һич тә туктарга исәбе юклыгын күреп, Галләм читкә тайпылды һәм машинага таба юнәлде.

— Тукта, тукта! Качып котыла алмассың! — Ул тәфтишләп Шәфиканың эчке күлмәге, трусигы нинди төстә икәнен, һәм бу турыда сөяркәсе авызыннан үз колагы белән ишетүе турында сөйләп китте.

— Хурлык валлаһи! Тфү, тфү...

Аңа карата Галләм күңелендә чиксез нәфрәт туды. Акылга тулы түгел бугай, дип уйлады. Шул арада райбашкарма ишегеннән чыгып килгән Шәфиканы күреп, фәрештәдән качкан шайтан шикелле читкә атылды.

— Әнә, теге хатынны таныйсыңмы?

Шәфика арт ягын гына шәйләп калды. Дөресрәге, ул хатынны күрерлек хәле юк иде. Сөмсере коелган, күзләреннән яшь атылып чыгарга тора.

— Нәрсә булды? Кәефең киткән...

— Исән булсам үз җаем белән сөйләрмен, зинһар, хәзергә калдырып торыйк.— Галләм аны бөтенләй аяктан егудан куркып сүз куертмады.

Әбрар билгесез хатынның сөйләгән сүзләрен ишетеп торды. Кабинага кереп утыру белән, барысын да түкми-чәчми Шәфикага җиткерүе ихтимал. Утырып кайтырга урын җайлау сылтавы белән аны кузовка чыгарып менгереп кисәтеп куйды:

— Әле генә теге хатын сөйләгәннәрнең син берсен дә ишетмәдең,— диде.

Шәфиканың үзе югында, нииндидер билгесез хатын тарафыннан иренә сөйләнгән сүзләр турында уена да кереп карамады. Ә менә бергә эшләгән иптәшләреннән ишеткән хәбәр тәмам тетрәндерде. Кайчан да булса Габделхәй белән типтереп йөрүе Галләмгә ишетеләчәгенә күңелендә шик калмады. Ул үзе моны гөнаһсыз бер шаяру гына дип исәпләгән иде дә бит, чын мәгънәсендә уеннан уймак чыккан икән шул...

Габделхәй эштән куылган, көне-төне исерек, урамда егылып аунап ятканын да күргәләгәннәр. Исерек баштан: «Шәфика минем сөяркәм, өенә барып кунып йөрдем, анадан тума чишенеп йоклый идек»,— дип мактана икән.

Ахыргы читтә бар гаеп Шәфикага аударып калдырылган. Райфога хезмәт кенәгәсен алырга кергәч, бергә эшләгән хатыннар аңа барысын да җиткерделәр. Арадан берсе — Люба исемле марҗа тартынып тормады, аты-юлы белән сүгенеп хурларга тотынды. Әйтмәгән сүзе калмады. Шәфика тал чыбыгы төсле сыгылды да төште.

— Игътибар итмәгез аның күз яшенә,— дип акырды Люба,— фахишәләр бар да елап ышандыра.

Мондый сүзне ишетү шулкадәр ачы булды, Шәфиканың күз алды караңгыланып, егылып китә язды. Ярый әле, күрше бүлмәдән кергән Суфия исемле хатын җитәклэп алып чыгып китте. Үзе белән валерианка йөртә икән, шуны эчкәч кенә бераз рәткә керде.

Ул юл буе ире Галләмгә башыннан үткән мажараларны кайчан, ничек сөйләп бирү турында уйлап баш ватты. Юк, акланырга теләми, ул гаепле! «Шул кирәк сиңа,— диде, үз-үзен битәрләп,— йөрмәссең өстерәлчек маржа булып. Әнә, аларның да җүнлесе ирләрне аздырган хатыннарны чәйнәп өзәргә тора». Аның үзен эттән алып, эткә салып әрләгән Любага тамчы да ачуы чыкмады.

Галләм Шәфиканы өйгә кертеп калдырды да, кәнсәләргә китте. Икесе генә калгач, кайнарланып кирәкмәгән сүз башланудан курыкты.

— Кич белән нәрсә калган инде анда, өйдә генә утыр,— дип әйтеп караган иде Шәфика, тыңламады.

Әйе, вакыт шактый соң, кәнсәләрдә кеше калмаган. Гадәттә, хисапчы Таһир караңгы төшкәнче утыра иде, ул да күптән чыгып сызган.

Ишекне ачышка эчтән сасы тәмәке исе бөркелде. Ул югында җыйналып тәмәке пыскытып утыралар. Ичмаса форточканы да ачып калдырмаганнар.

Керү белән утызлы лампага ут кабызды да, өстәл янына барып утырды. Өстәл өстендә «Коммунизм байрагы» гәзите аунап ята. Кем кертеп ыргыткан? Җене сөйми чүп-чарны. Бер минут күздән югалып торырга ярамый, тәртип бозыла.

Гәзитнең беренче битенә күзе төште. Зур мәкалә урнаштырылган. Мәкалә «Колхоз председателе яңа салынган йорт нигезенә Коръән укыта» дип атала. Сукыр кеше дә күрерлек итеп, зур хәрефләр белән язылган. Тукта, бу аның үзе турында түгелме соң?!

Бөтен дөньяны онытып гәзит укырга кереште. Тиз генә укып чыга торган да түгел, гәзитнең бөтен битен били.

Йортның мулла кияве өчен салынуына аеруча басым ясалган. Шундый сорау куела: яңа гына армиядән кайтып, арт ягы да җылынмаган кешегә йорт салырлык акча кайдан килгән? Шунда ук җавабы да бирелә — бар да кайнатасы Зариф мулланың хезмәт итмичә генә, бит сыпырып җыйган байлыгы, имеш. «Әлегә кадәр Зариф мулла байлыгын кеше күзеннән яшереп, мескенлеккә сабышып йөрде,— диелә мәкаләдә,— хәзер менә күгәреп яткан акчаларын эшләтү юлын тапты». Мәкаләдә язылганнарга ышансаң, үз кул көче белән көн күрүче яшь егет Әбрарның дин белән башын әйләндереп, мулла аңа кызын кияүгә биргән. Аннан шул намуслы егет исеме астында яшеренеп, халыкны алдап җыйган байлыгына, күзнең явын алырлык дворец төзеп куйган. Зариф муллага колхоз рәисе коммунист Галләм Җиһаншин бик теләп ярдәм күрсәтә икән, имеш. Алай гына да түгел, аның инициативасы белән дини мәҗлесләр оештырыла. Мисалга, Әбрар йортын эшләп бетергәч, нигезгә Коръән уку мәҗлесе үткәрү китерелә. «Мәҗлеснең түрендә колхоз рәисе Галләм Җиһаншин утырды, ул чапан, чалма киеп йөри башласа, бер дә гаҗәпләнмәгез»,— дип тәмамлана мәкалә.

Галләм мәкаләне кат-кат укыды. Район масштабында күтәреләчәк гауганы күз алдына китереп, кәефе тагы да ныграк кырылды.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, хатыны турында сөйләнгән гайбәт ачыкланып бетмәгән, инде менә икенчесе туды. Аяк астыннан килеп чыккан бәлаләр. Ялгышты, бик нык ялгышты. Коръән укыткан мәҗлескә кереп утырмаска кирәк иде аңа!

Галләм узган эшкә үкенергә яратмый. Бу юлы да холкына хыянәт итмәде. Ул турыда уйламаска тырышты.

Кайтып китәргә җыенгач уйга калды — нишләргә, гәзитне өстәл өстендә калдырыргамы, әллә чүплеккә ыргытыргамы? Шулвакыт кәнсәләргә хисапчы Таһир килеп керде:

— Син икәнсең әле,— диде,— төн уртасында кем ут яндырып утыра икән, дип, куркып киттем.
— Нәрсә бар ул кадәр кот алынырлык?
— Бүген гел район кешеләре кайнады, берсе килә, берсе китә.— Өстәлдәге газитне күреп алды.— Сиңа да кертеп калдырганнар икән: аларны Фатыйма кочагы белән күтәреп, очраган бер кешегә өләшеп йөри.
— Синеңчә ничек, дөрес язылганмы?
— Кайда инде ул дөреслек!? Явыз ният белән оештырылган эш...

## XXIII

Көн иртәдән үк шау-шулы башланды. Иң элек өлкән налог инспекторы килеп төште. Аның күңеле чиктән тыш төшенке. Кичә газиттә басылып чыккан мәкалә уңае белән беренче үз кабинетына чакырып бик яман сүкте. Аны сәяси сукырлыкта гаепләде.

— Партия бөтен көчен куеп шәхси милекчелеккә каршы көрәш алып бара, сезнең канат астында әнә, бөтен район халкы байлык җыя! Сөйлә: ни өчен Зариф мулланы налогтан коткарып киләсез! Әллә аның кеше алдап җыйган керемен, без барып исәпкә алганны көтәсезме?

Зәйнуллин бернинди аңлатма бирә алмады. Тез буыннарына кадәр калтырады. Шуңа күрә иртә таңнан торып чыгып чапты.

Менә салмак атлап кәнсәләргә Галләм килеп керде. Зәйнуллин аны табалап каршы алды:

— Озак, озак йоклыйсыз, иптәш председатель...

Галләм җавап бирүне кирәк тапмады — ул кырдан кайтып килә иде, ярты басуны әйләнеп чыкты инде.

— Урынны бушатыгыз әле, бу колхоз председателе өстәле,— Зәйнуллин бу сүзләргә акаеп карады да, теләмичә генә урыныннан торды.— Гомумән, сезгә әнә теге якка кереп утыру кулаерак булыр.— Зәйнуллинга һәм аның иптәшләренә икенче якка, авыл советы кәнсәләренә кереп утырырга тәкъдим итте.

Зәйнуллин чак кына дары кебек кабынып китмәде. Авылларга чыкканда үзен хуҗа итеп тотып өйрәнгән: беркемнән дә рөхсәт сорап тормый, кая тели шунда барып утыра. Аның бөтен кыланышына риза булып, ләббәйкә торалар.

Галләм Зәйнуллинның кәефе кырылганын сизмәгәнгә салышты, күрешергә кулын сузды:

— Ни эш бетереп йөреш? — Бер кырыйда басып торган налог инспекторларына күз төшереп алды да: — О-о, ялгыз түгел икәнсез әле,— диде, бөтен райфо аппаратын ияртеп алып килгәнсез дип әйтимме?

Аларның сүзләре бер эзгә кереп китә алмый, урамның икесе ике ягыннан бара иде. Зәйнуллин хуҗалар үзләре белеп әйтмәслеген аңлап, турыдан-туры сөйләшүгә күчте:

— Безнең атларны конюшнигә илтеп ашарына бирсеннәр әле,— диде. «Димәк, озаклап монда калырга җыеналар»,— дип уйлап алды Галләм. Нормага кергән: районнан килгән вәкилләрнең олысы-кечесе колхоз исәбенә яши. Мондый хәлгә Галләмнең күптән эче пошып йөри. Бу юлы алар өчен тотылган чыгымны, хөкүмәт бәһасы белән булса да, үзләреннән түләтергә уйлап куйды.

— Сезгә фатир кирәк булырмы? — дип сорады Галләм.
— Эш дәвамында күренер.— Зәйнуллин өзеп җавап бирергә теләмәде.
— Сер булмаса әйтегез әле, нинди эш белән килдегез?
— Шәхси милекне үстерүгә юл ачып бөтен районны аякка бастырдыгыз, кайберәүләрнең йонын кыркырга кирәк!
— Аңламыйм...

— Колхозчы теләгән кадәр хайван асрый, колхоз уставын бар дип тә белми!

— Каян уйлап чыгардыгыз әле бу сүзләрне?

— Уйлап чыгарасы юк, күзе бар кеше күрә. Хайван азыгы әзерләргә ирек, колхоз җире бай, иренмә генә...

«Җүкәдә икән чикләвек»,— дип уйлап куйды Галләм эченнән генә.

Зәйнуллин теләсә-теләмәсә дә авыл советы кәнсәләренә чыгарга мәҗбүр булды. Ул такта белән бүлеп алынган бер почмакны били, керәге дә шул кадәр генә. Бөтен эш колхоз идарәсе аша башкарыла. Гомумән, авыл советының власте төрле белешмәләр язып бирү белән генә чикләнә. Базарга барып ит, май сатарга туры килсә, үз хуҗалыгыңныкы икәнлеген раслый торган белешмә кирәк. Югыйсә, тотып алып керәләр дә, бер тиен түләми алып калалар.

Налог инспекторларын ияртеп барып кергәндә, рәис белән секретарь аларны көтеп утыра иде инде.

Кәнсәләрнең бөтен мебеле бер өстәл, стена кырыена тезеп куелган дүрт-биш урындыктан гыйбарәт. Рәис булып яше утыздан узган Сабиха атлы, карт кыз эшли. Секретарь белән кара-каршы бер өстәл артында утыра.

Секретарь, Мәһитап исемле имчәк балалы яшь хатын, эш урынында сирәк була, кирәге чыкса, өенә барып чакыралар... Районнан киләләр икән дигән хәбәрне ишеткәч, бүген кәнсәләргә алдан килеп утырды ул.

Рәис белән секретарь вәкилләрне аягүрә басып каршы алды.

Зәйнуллин исәнләшеп, вакланып тормады, сүзне кәнсәләрдәге күренешкә ризасызлык белдерүдән башлады:

— Совет властен ничек кысрыклаганнар,— диде башын чайкап.— Болай дәвам итсә, урамга куып чыгарырга да тартынмаслар! — Стена кырыендагы ярым җимерек шкафка ымлады: — Моны күптән чыгарып ташларга вакыт, урын тарайтып тормасын!

Мәһитап югалып кала торганнардан түгел, туры әйтеп сөйләшергә ярата:

— Чыгарып ташлавы ансат, эш кәгазьләрен кайда сакларга?

— Яңаны алыгыз!

— Үз акчабызга алсак кына инде,— диде Сабиха сүзгә кушылып.

— «Үзара салым» акчасын банкта җыеп яткырмагыз, тотыгыз!

— Сезнең хәтер дигән нәрсә саерак булса кирәк, смета төзеп баргач, үзегез бит борып чыгардыгыз.

Зәйнуллин нәрсәнедер исенә төшереп уйланып торды:

— Смета җиренә җиткереп төзелмәгәндер, өйрәнергә вакыт!

— Урысча язарга куштыгыз, нинди эш инде ул үзебезнең Татарстаныбызда да татарча язарга ярамагач?

Вәкилләрне утыртыр өчен урын җайларга кирәк иде, Мәһитап бер кырыйга барып басты:

— Утырыгыз, иптәш Зәйнуллин,— диде аңа үз урынын тәкъдим итеп.

— Ә сез?..

— Без басып торырга өйрәнгән инде...

Зәйнулла икенче урындык алып утырды. Бәлки үз гомерендә беренче мәртәбә булгандыр, ул моны хатын-кызга ихтирам күрсәтү теләге белән эшләде. Мәһитап басып торуын дәвам иттерде.

— Яшерә торган эш юк,— диде өлкән налог инспекторы Сәгыйтов.— Башлап сез чаң сугарга тиеш идегез, хәзер менә безгә йөрергә туры килә. Мулланың халыкны алдап зур керем алып ятуы турында нигә райфога хәбәр итмәдегез?

— Нинди керем турында сөйлисез? — диде Мәһитап.— Беренче мәртәбә ишетәм...

— Менә сөйләш син алар белән,— диде Сәгыйтов гаҗәпләнгән булып.— Мулла авыл советы канат астына ук кереп оялаган икән бит!

Рәис белән секретарь бер-берсенә карашып тынып калдылар. Маһитапның исә авыз йомып утырып, үзләрен басымчак иттерәсе килмәде:

— Нәрсә эшләгән әле без, мулланы канат астына алып?! — диде.

— Зариф мулла ничә мәет күмде, ничә балага исем кушты? Шуларның исемлеген бирегез безгә?

— Балага исем кушканда да, мәет күмгәндә дә безнең катнашыбыз юк! — диде Сабиха катгый итеп.

— Туу, үлү турында таныклыкны авыл советы бирә торгандыр ич?

— Шулай дип сорарга кирәк, — диде Маһитап, — эшнең эштие бар ди торган иде мәрхүмә әби, — ул өстәл астындагы тимер сандыкны ачып туу, үлү турыда бирелә торган таныклык бланкларының корешокларын чыгарды һәм инспектор алдына куйды.

Сәгыйтов портфеленнән дәфтәр битенә язылган исемлек алып, корешоклар белән чагыштыра башлады. Маһитап исемлеккә күз төшерде. Сәгыйтов күрсәтмәскә теләп кулы белән каплаганда соң иде инде.

Исемлек таныш кул белән язылган, партбюро секретаре Фатыйма кулы! Маһитап аны тозлап, борычлап сүгүдән чак кына тыелып калды. Авылдагы хәлләрнең тиешле оешмаларга хәбәр ителеп торылуы күптән сизелә иде инде. Исемлекне күргәч, инде шик калмады. Халыкны шул — Фатыйма дуңгыз бутап ята икән!

Сәгыйтов белән Зәйнуллин киңәшеп алдылар. Башта мәет чыккан, бала туган йорт хуҗаларын чакырып сорау алу мәгъкуль күрелде. Аннан соң гына Зариф мулланың үзе белән сөйләшү җиңел булачак, дип уйланды.

— Менә шушы йорт хуҗаларын берәм-берәм кәнсәләргә чакыртыгыз, — дип, корешокларны Сабихага тоттырдылар.

— Мәрхүмнәрнеме дә? — диде рәис хәйләкәр елмаеп.

Маһитап тиз генә дежур торучы хатынны чакырып алып керде дә авыл буйлап йөрергә чыгарып җибәрде.

Беренче булып кәнсәләргә таякка таянган карчык килеп керде — Садыйк Гайшәсе. Колагы ишетми, күзләре дә начар күрә. Карты үлгәч бигрәк тә бетерешге. Ул таныш булмаган кешеләрне күреп артка чигенде:

— Әллә дөрес кермәдем инде?!

— Дөрес, дөрес, әби! — Сәгыйтов аны җитәкләп алып килеп өстәл янына утыртты. Ничә мәртәбә кәнсәләргә килеп, бервакытта да болай зурлап каршы алганнары юк иде карчыкны.

— Әби, быел зур кайгылы булгансыз, картыгыз үлгән икән, — диде Сәгыйтов сүз башлап. Карчык шигәеп, аңа сүзен тәмамларга ирек бирмәде:

— Нинди заманага калдык соң без, җир астындагы кешегә дә тынгылык юк, нәрсәгә кирәк булды әле ул минем мәрхүм картым?

Әбинең болай кыю сүз башлавы райфо хезмәткәрләренең кәефен җибәрде. Димәк ул ансат кына алар теләгән җавапны бирәчәк түгел. Зәйнуллин да сүзгә кушылырга мәҗбүр булды.

— Монда сезнең картыгызга тигән кеше юк, бары шуны беләсебез килә: мулла чакырып күмдегезме?

Гайшә карчыкка бу сорау бөтенләй акылга сыймаслык булып тоелды:

— Әстәгъфирулла! Тәүбә! Тәүбә! Мөселман карчыгы ла мин, ничек инде гомер иткән картымны мулласыз гына җир куенына илтеп тыгыйм?..

Зәйнуллин сүзнең нинди юнәлеш алганын сизеп, карчыкның салпы ягына салам кыстыра башлады:

— Маладец әби икәнсең! Кемне, Зариф мулланы чакырдыгызмы?..

— Ярый әле ул бар! Картайды инде, озаклмый мәет күмәргә укымышлы кеше дә табып булмаячак.

— Муллага күпме сәдака бирдегез? Акча кызганмагансыздыр дип уйлыйм...

Карчык кинәт кабынып китте:

— Изге теләк белән бирелгән сәдаканы телгә кертмәгез! — Сабиха белән Маһитапка күзе төшеп, аларның җавапны хуплавын сизенде.— Минем акчаны санарга берегезнең дә хакы юк! Беләсегез килсә әйтәм, бер тиен дә бирмәдем, вәйт... Язгыз шулай дип!

Зәйнуллинның ачудан чигә тамырларына кадәр бүртеп чыкты. Дин белән агуланган бу карчыкны җиңел генә акылга угыртып булачак түгел, өстәл сугып сөйләшәсе килеп, кулы кычытты. Сәгыйтовның акылы җитте, күз кысып аны колхоз кәнсәләре ягына алып чыкты.

Кире әйләнеп кергәндә Гайшә карчык китәргә җыенып тора иде. Сабиха гына тотып калды. Китсә, аның артыннан тагын барырга туры киләчәк.

Сәгыйтов үз эшендә шактый тәҗрибәле кеше. Кем белән ничек сөйләшергә тәмам өйрәнеп җиткән. Бернәрсә белмәгәнгә салышып, мәет күмгәндә нинди сәдака өләшенүе турында сорашкан булды. Бигрәк тә гүр сәдакасы белән кызыксынды. Хәлле кешеләр якыннары үлгәч бөтен Коръән чыгарталар.

— Коръән чыкканга күпме сәдака бирәләр? — Картына Коръән чыгартканмы, юкмы, ул турыда ләм-мим сүз булмады. Бары, дин әһеле тарафыннан башкарылган хезмәт өчен, күпме сәдака бирелергә тиешлеген сорашып, актка теркәп барды.

Сорау алу тәмамлангач, актны әби алдына куйды:

— Бу кәгазьне миңа биреп җибәрәсеңмени? — диде әби. Барысы да дәррәү көлешеп алдылар.

— Сиңа түгел әби, безгә кирәк, үзең сөйләгәннәрне раслап кул куеп җибәр! — Язу карасын аңа якынрак китереп, каләм тоттырды:

— Мин сезнеңчә яза белмим бит...

— Ничек яза беләсең, шулай ярый! — Әби гарәп хәрефләре белән имзасын салды. Күптән кулына кәгазь, каләм тотып карамаган булса да, онытмаган икән әле. Хәрефләрне ак кәгазьгә тигез, матур итеп төшерде. Моңа Сәгыйтов та игътибар итте:

— Кара, укымышлы карчык икәнсең!

— Ике ел рәттән абыстайга йөреп укыдым. Элекке заманда кызларны язарга өйрәтмиләр иде, үзлегемнән өйрәндем.

— Комган хәрефләре белән өйрәнергә башың җиткән, хәзергесен дә өйрәнергә кирәк иде...

— Болай да гөнаһым муеннан, шайтан хәрефләре белән язарга өйрәнеп гөнаһымны арттырасым килмәде,— диде авыр сулап.— Моның өчен миңа нәрсә була инде? — диде кулына тотып. Сәгыйтов аны кабаланып тартып алды:

— Курыкма, курыкма! Синең белән эш бетте, китәргә мөмкин.

Рәис белән секретарь аларның һәр сүзен игътибар белән тыңлап торалар икән:

— Гайшә әби, актны укымыйча кул куймаска кирәк иде,— диделәр икесе бер авыздан.

— Өйрәтмәгез! — дип кычкырды Сәгыйтов.— Сезнең өйрәтүгә мохтаҗ түгел ул, мең дә берне белә торган карчык...

Сабиха белән Маһитапның шикләнүе нигезсез түгел иде, аларның укымыйча кул куйдырткан акт аркасында җәнҗал чыкканын күп мәртәбәләр очратканы бар.

Сорау алырга чакырылган кешеләрне кәнсәләргә берәм-берәм генә кертәләр. Әби чыгып киткәч, ишектә күсе Гатаулласы күренде. Ул тракторда эшли иде. Яңа туган баласына мулла чакырып исем куштырган өчен эшеннән колак какты.

Башта МТСның партоешмасында тикшереп, кызыл билетын алдылар. Минем балага исем кушуда катнашым, юк дип әйтеп карады, игътибар итүче булмады. Бу, чыннан да, шулай иде.

Аның этисе Галимулла абзый — биш вакыт намазлы, җаны-тәне белән Аллага ышанган кеше. Ул Гатауллага әйтеп тә тормады, ахшамнан соң чәй әзерләп Зариф мулланы чакырды да, оныгына исем куштырды. Алдагы көндә әле аның кем булып үсәсен белгән юк, ичмаса, үзенең мөселманча исеме белән кяферләрдән аерылып торсын дип уйлады. Эш болай зурга китәр дип, күңеленә дә китермәде карт. Икенче көнне үк хәбәре бөтен районга таралды.

Гатаулланың шәхси эшен карар өчен махсус ачык партия җыелышы үткәрелде. Партия җыелышын ачык дип игълан итеп, партиясезләргә дә сабак бирергә теләделәр.

Җыелышта Гатаулла адресына әйтелмәгән сүз калмады. Ул икейөзле имеш, тыштан кызыл булып, эчтән череп таралган, совет җәмгыятенә чит элемент. Җәзаның иң катысы бирелде. Гатаулла кебек дин сөреме белән агуланган кешеләрнең кесәсендә бөек Ленин сурәте төшерелгән билет йөртергә хакы юк, аны партиядән чыгарырга, дигән карар кабул ителде.

Шушы җыелыштан соң Гатаулла төн йокысын югалтты. Башка берәү аның урынында булса, эчкечелеккә сабышыр иде. Юк, ул юл белән китмәде. Бөтен көчен куеп баласына мулла чакыртып исем кушуда гаепсезлеген исбатларга кереште. Партиягә кире кайтаруны үтенеп язган гаризасы райкомда каралып, кире кагылды. Ниһаять, эш обкомга барып җитте. Бер ай көткәннән соң үтенече канәгатьләндерелде. Каты шелтә белән партия билетын кире бирделәр. Ә менә үз эшенә кире кайтару мәсьәләсе һаман сузыла иде әле.

Гатаулла, кәнсәләргә эш турында сөйләшергә чакыра торганнардыр, дип уйлап килгән иде. Сәгыйтов үз каршына утыртып, сорау ала башлагач кәефе кырылды:

— Бер балык башын күпме чәйнәргә була,— дип, урыныннан сикереп торды. Сәгыйтов бу кешене тозлап-борычлап сөйләшеп кенә җайга китереп булачак дип уйлады:

— Сез нәрсә, җавап бирергә теләмисезме? Икенче урынга чакыртып сөйләшергә дә күп алмабыз! — Икенче урынны атап әйтмәсә дә, кая икәне аңлашыла.— Яхшылык белән әйтегез, яшермәгез, балагызга исем кушканда Зариф муллага күпме сәдака бирдегез?

— Мулла белән алыш-бирешем юклыгым бер мәртәбә исбатладым бит инде, сезгә тагын нәрсә кирәк?

Егет курка торганнардан түгел икән, янап эш чыкмаслыгын аңлап, Сәгыйтов тонны үзгәртергә мәҗбүр булды:

— Безгә сезнең ярдәмегез кирәк, күрсәтегез чын коммунист икәнегезне! — Гатаулла аның кая таба сукалаганын сизенә башлады:

— Белмим, белмим,— диде башын чайкап,— ачыграк итеп әйтегез?

— Зариф мулла дин хезмәте күрсәтүдән килгән керемен яшереп, налог түләүдән баш тарта. Моны бары коммунистлар ярдәме белән генә фаш итеп булачак...

— Шулай дип уйлаган идем,— диде Гатаулла чиктән тыш әсәрләнеп, миннән, бирмәгән сәдаканы бирдем, дип әйттермәкче булалар дип...

— Кем әле андый сүз әйтте?

— Бигрәк инде аңгырага саныйсыз! — Ул башын тотып күрсәтте.— Монда чүбек тутырган дип уйлыйсызмы әллә? — Сәгыйтов кул селтәде.

— Зариф мулла хәленнән килгән кадәр колхозда эшли,— диде Гатаулла сүзен дәвам итеп,— мин аның башка керемен белмим.

— Әнә алар нинди йорт эшләтеп куйдылар!

— Мулла абзый эшләтмәде ич аны...

— Беләбез без аның кем акчасына эшләгәнен! Мулла кызына өйләнмәгән булса, андый йорт Әбрарның төшенә дә керәчәк түгел иде.

— Белсәгез, үзегез карагыз инде, болай да башым каткан, мине бутамагыз!

— Бит сыпырып алган акчага салынган йорт ул. Син әнә, авыр эштә йөреп тә, Әбрарныкы кебек эшләтә алмыйсың. Әрәмтамакларның тамырын корытырга кирәк.

Гатаулла Сәгыйтовтан җиңел генә котыла алмаячагына төшенде:

— Минем үз кулым белән муллага бер тиен сәдака биргәнем юк,— диде.— Кайтып сорап килим әле, әти күпме бирде икән...

Хәйлә барып чыкмады.

— Синең бер килеп, бер китеп йөргәнеңне көтәргә вакыт юк,— Сәгыйтов аның алдына бер бит кәгазь куйды:— Менә монда, балага исем кушкан өчен күпме сәдака биргәнемне әйтергә теләмимдип кул куегыз!— Гатаулла куркып калды. Юк кына нәрсә өчен тагын партия билетларыннан колак кактырулары бар.

— Нәрсәгә әле сез мине болай боргычлыйсыз? Үзегезгә күпме кирәк, шулай языгыз!

— Безгә кирәкми, дәүләткә кирәк. Халыкның наданлыгыннан файдаланып, паразитлар череп баемасын...

Гатаулланың алдына куелган кәгазьгә язылганнарны укырлык хәле калмаган иде, тәмам янып-пешеп чыкты. Сорап тормады, кул куйды.

Хәйрулла бабайны чакырып алып керделәр.

Ул ап-ак көрәк сакаллы. Башында каешланып беткән кәләпүш. Төптән юан чыккан озын гәүдә, кулында артыш таяк. Җиргә нык басып йөри.

— Әссәламегаләйкем!— дип сәлам бирде. Җавап булмады.— Мин тагын кыз димләргә чакыра торганнардыр дип уйлап йөгерә-йөгерә киләм.— Таягы белән идәнгә шакыды.— Әллә, барысы да чукракланган инде?..

— Мулла янына баргач шулай сәлам бирерсең!— Хәйрулла карт Зәйнуллага сүзен тәмамларга ирек бирмәде:

— Здрасти, алайса, мин сезнеңчә дә сәлам бирә беләм.

— Бабайга тел-теш тидерерлек түгел, урысча да, татарча да булдыра ул,— диде Сабиха.

Сәгыйтов аңа Гатаулладан бушаган урынны тәкъдим итте. Сүзне ерактан башлады:

— Карчыгың вафат булган икән, бик сагынасыңдыр инде,— диде аны кызганган булып.

— Ничек инде сагынмаска, илле ел бергә гомер иттек.

— Яшерми генә әйт әле, шул илле ел эчендә, башка берәүгә күзең төшмәдеме?

— Коръән тотып ант итә алам, андый гөнаһым юк. Хәзер генә бит ул зина кылуны бернәрсәгә санамыйлар. Алла каршында зинадан да зур гөнаһ юк ди, мулла абзый.

— Җитте, күңелне болгата башладыгыз,— диде Зәйнуллин сүзгә кушылып.

Хәйрулла карт ачылып сөйләшә башлагач, Сәгыйтовның күңеле күтәрелеп киткән иде. Ул ике ут арасында калды. Хуҗаның сүзен дә аяк астына салырга ярамый, Хәйрулла карттан да кирәкле мәгълүматны алырга кирәк. Ни булса да булыр, дип турыдан-туры сөйләшүгә күчте:

— Менә нәрсә бабай: син карчыгыңны зурлап күмгәнсең икән...

— Көч җиткәнчә тырышам инде...

— Кабер сәдакасына зур бер сарык биргәнсең икән.

— Сарык түгел, сарык бәтие бирмәкче идем, алмады...

— Ничек алмады?

— Шулай, дога кылды да кире бирде. Син бай кеше түгел, үзеңә сәдака тиеш диде.

— Менә дөньяда нинди яхшы муллалар бар икән?— Сәгыйтов белән Зәйнуллин шаркылдап көлгән булдылар.

— Нәрсәгә аңарга исегез китте? Муллалар алар шәфкатьле булды, халыкны тәртипкә өндәде.

— Җитте!— диде Зәйнуллин.— Телеңә салынып әкият сөйләп утырма, кулыңны куй да, өеңә элдерт!

Сәгыйтов бабай алдына акт куйды. Ул таракан йөргән төсле чуарланган кәгазь өстеннән күзен йөртеп чыкты:

— Укып күрсәт! — Дикъкать белән тыңлап торды, ләкин кулына каләм алырга ашыкмады.

— Нәрсәсе ошамады тагын?

— Мин мондый актка кул куймыйм.

— Телең белән сөйләгән сүзләрне расларга теләмисеңме?

— Актка мин сөйләгәннәр яртылаш кына язылган. — Сәгыйтов күзен Зәйнуллинга текәп, җавап бирергә аптырап калды.

— Ул, күрәсең, эшне прокурорга җибәргәнне көтә. — Карт урыныннан торды. — Әй, кая син?

— Элдертергә куштың бит! — Алар аны болай сүзгә тапкыр кеше итеп күз алдына китермәгәннәр иде. Куркытып эш чыкмаслыгын аңлап, җайлап сөйләшә башладылар.

— Бабай, сез бер нәрсәне аңлагыз, мулланың сарык бәтиен кире кайтарып бирүе турында актка язып торуның кирәге юк, эшнең ул ягы безне кызыксындырмый...

— Беләбез без, мулланың ни өчен сарык бәтиен кире кайтарып биргәнен, шул юл белән халык алдында абруен күтәрә.

Зәйнуллинның дуамалланып сүзгә кушылуы Сәгыйтовның бөтен планын бозды. Ул бернинди өстәмәсез актка кул куйдырып алырга теләгән иде. Муллага налог хисаплаганда, Хәйрулла бабай әйткәннәр буенча төзелгән сорау акты, иң кирәкле документ булачак. Ул актның азагына кабер сәдакасына бирелгән сарык бәтиенең кире кайтарылып бирелүе турында язарга мәҗбүр булды. Өстәп язу актка куелган имзалардан соң шактый буш урын калдырып башкарылды. Соңыннан аны бик ансат кына кисеп ташларга мөмкин булачак.

Хәйрулла бабай чыгып киткәч, Зәйнуллин бик кызып фикерләре белән уртаклашырга тотынды:

— Мондый халык белән ничек инде коммунизм төзергә кирәк, — диде ул. — Ой, озак чиләнергә туры киләчәк әле болар белән.

— Күп калмады инде алар, иптәш Зәйнуллин, — диде Сабиха, — сагынырбыз әле.

— Авыл советы рәисе шулай сөйләп утыргач, башкалардан нәрсә көтәргә кирәк?! Күп калмасалар да, тамырлары тирәндә, агулары тиз генә бетә торган түгел.

— Безнең татар халкы бигрәк динсезгә әйләнеп бара инде, яшьләр Алланы бар дип тә белмиләр.

— Урыслар әнә үз динен саклый, — диде Маһитап сүзгә кушылып. — Бер көнне Митрәйдә булган идем, кайсы гына өйгә кермә, почмакларында икона...

— Сез дә инде дин бетә дип зарлансагыз, бөтенегез Зариф мулла авызына карап торасыз, тапкансыз бер изге зат!

Кәнсәләргә Әбрар килеп керде. Кайнатасы турында сүз барганын сизеп, сагая төште. Түргә узарга шикләнде, бусаганы атлау белән туктап калды.

— Узыгыз, уз! — диде Сәгыйтов, — менә монда килеп утырыгыз! — дип каршындагы урындыкка күрсәтте.

— Мулла кияве шушы егет буламыни? — диде Зәйнуллин, аны башыннан аягына кадәр күзеннән үткәреп. Әбрарның бер минут та тоткарланасы килмәде.

— Кайсыгыз чакыртты? Әйтәсе сүзегезне әйтегез дә, китим. Мин эш кешесе. — Сәгыйтов, аның болай сөйләшүен игътибарсыз калдырырга теләп булса кирәк, сүзне үзенчә дәвам иттерде.

— Нихәл, баеп буламы?

— Аллага шөкер, нужага күршегә кергән юк әле, үзебездә җитәрлек!

— Мәчет кадәр итеп йорт салып куйгач, нинди нужа турында сүз булырга мөмкин?

— Йортыгызга ут төртеп яндырсалар сез нишләр идегез соң?

— Сезнеке кебек череп баеган кайнатам булса, мин да шундый йорт салдырып куяр идем.

— Тел төбегез аңлашыла, миңа йортны Зариф мулла салдырып бирде, дип әйтергә телисез.

— Әллә, йортны үз акчагызга эшләттем, дип әйтмәкче буласызмы?

Әбрар ике кулын күрсәтте:

— Ходай сәламәтлектән аермасын!

— Кайда күргәнең бар эшләп алган акчага синеке кебек йорт салдырганны?

— Минем кеше кесәсендәге акчаны саный торган гадәтем юк, күпчелек булмаса да, бар! Йорт салучылар да бар.

— Эшләп алган акчага гына йорт салып булмый! — Сәгыйтов кинәт туктап калды, ул әйтергә курыккан сүзләрне Әбрар әйтте:

— Кырын кергән акчага салалар дип әйтмәкче буласызмы? — Сәгыйтов җавап бирергә сүз таба алмый, аптырап калды.

— Минем алай дип әйткәнем юк,— диде бераздан авыз эченнән мыгырдап. Сәгыйтов үзенең сәяси хата җибәргәнен бөтен йөрәге белән сизде. Эшләп алган акчага яхшы яшәп булмый, дип әйтергә ярыймы соң?! Тиешле оешмаларга ишеттерсәләр, кая керергә тишек таба алмассың! Ул тиз генә сүзне икенчегә борып җибәрде:

— Бер дә кирәкмәгәнгә, еракка кереп киттек... Әйт әле, йорт салганда кайнатаң күпме акча бирде? — Әбрар чиктән тыш нәфрәтләнеп тынып калды. — Авызыңа су каптыңмы әллә, сөйлә!...

— Үзенә юкны каян алып бирсен ул?

— Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә диләр! Бөтен тирә-юнь халкын имеп яткан Зариф муллада акча булмасын, имеш...

— Мин әйткәнгә ышанмагач, үзеннән сорагыз! — Әбрар, шуның белән сүзне тәмамлап, китәргә җыенды.

— Тукта, тукта! Йортның нинди акчага салынганын әйтми китү юк...

— Нинди акчага салынганын бөтен авыл халкы белә, шулардан сорагыз.

— Өйрәтмә безне, кемнән сорарга кирәк икәнен беләбез! Зәйнуллин сүзгә кушылды:

— Бөтенесен үзе сөйләгәнчә язып, актка кул куйдыр,— диде,— закон нигезендә җавапка тарттырырга яхшы материал булыр. — Әбрарның мондый янауларны күп мәртәбәләр ишеткәне бар һәм куркудан узган иде.

Зәйнуллин шартлар дәрәҗәгә җитте:

— Әйт, бураны каян алдың? — дип акырды өстәл сугып.

— Бураны иптәш Җиһаншин китертте, үзенә дип эшләткән бураны бирде.

— Матур күзләрең өченме?

— Бәһасы әле сөйләшенмәгән, «үз җаең белән түләрсең» диде.

— Дөрес, дөрес,— диде авыл советы рәисе, Әбрарның сүзләрен раслап,— кирәк булса белешмә язып бирә алам. — Сабиханың сүзгә кушылуы Зәйнуллинның ачуын тагын да ныграк кабартты:

— Без мондый ярдәмгә мохтаҗ түгел! — диде. Шундый итеп текәп карап торды ки, Сабиха инәлеп китте.

Зәйнуллин Әбрарга йорт салуда колхоз рәисенең катнашы бардыр дип башына да китермәгән иде. Болай булгач мәсьәлә катлауланачак. Җиһаншинга теше үтмәячәк, әлбәттә.

— Димәк, сез йорт эшләткәндә кайнатагызның акчалата ярдәм итүен күрсәтүдән баш тартасыз?! — диде Зәйнуллин, ачудан тиресенә сыймас дәрәҗәгә җитеп. — Карагыз аны, үкенергә туры килмәсен!

— Куркытып баш катырганчы, үзегезгә ничек кирәк, шулай языгыз да куегыз!

— Кул куярсызмы соң?

— Юк, ялганга ничек кул куясың...

— Бу киребеткән белән бәхәсләшеп вакыт әрәм итмик,— диде Зәйнуллин.— Материалны тикшерү органнарына җибәрергә кирәк, анда телен ачтырырлар.

— Җибәрегез, җибәр! Тикшерү органнарында анда совет кешеләре утыра торгандыр, гадел хөкем итәрләр!

Әбрар бу сүзләрне чын күңелдән әйтте. Ул совет законнарының гадел булуына җаны-тәне белән ышана иде. Мәктәп бусагасын атлап керүгә, бертуктаусыз балаларның колагына шул турыда тукып тордылар. Хезмәтләре бушка китмәде. Көндәлек тормышта киресен күреп торсаң да, бала чагында баш миенә сеңеп калган ялганнан тиз генә арынып булмый икән.

— Миңа китәргә мөмкинме?

Сәгыйтов туктатып калмакчы иде, Зәйнуллин тоткарламаска кушты.

— Бу авылда халыкның аңы революциягә кадәрге дәрәҗәдә катып калган,— диде, ул чыгып киткәч.— Коммунистлар нәрсә карый торгандыр, сәяси яктан тәрбия эше тулысы белән Зариф мулла кулында икән!

Кәнсәләрдә утыручылар бар да сискәнеп киттеләр.

— Дөрес түгел,— диде Сабиха катгый рәвештә,— китаханәне, клубны кая куясыз? Алар көн дә халык белән тулып гөрләп тора. Зариф мулланың анда аяк басканы юк.

Маһитап ярсып сүзгә кушылды:

— Каян алып сез безнең авыл халкы өстенә шундый гаеп ыргытасыз?! Нинди дәлилегез бар?

— Әле генә каршыгызда басып торган егет шуның дәлиле түгелмени, сезгә тагын нәрсә кирәк?

— Әбрарны әйтәсезме? Ялганлап язылган актка кул куймаган өчен аның өстенә пычрак ташларга хакыгыз юк.

— Сез дә, кияве йорт эшләткәндә, Зариф мулла акчалата ярдәм итмәде, дип әйтмәкче буласызмы?

— Мин генә түгел, бөтен авыл халкы әйтеп тора.

Зәйнуллин папкасыннан таушалып беткән гәзит алды:

— Менә монда нәрсә язылган?

— Ялган ул, анда бер дөрес сүз юк.

— Партия органына яла якмакчы буласызмы?

— Яла яктырасылары килмәсә, басып чыгарганчы дөреслеген тикшерергә кирәк иде. Авторы имза да куймаган, курыккан...

— Сезнең авыл халкына кем язганын белгертергә ярыймы соң?

— Беләбез без аны кем язганын, партоешма секретаре Фатыйма эше!

— Юк сезнең авылда партоешма! Партоешма булса, тәрбия эше мулла кулына тапшырылмас иде.

Акланырга теләп, бәхәскә керешерләр дип уйлаган иде, каршы дәшүче булмады. Битарафлык тагын да ныграк ачуын кабартты.

— Мулланы чакырдыгызмы, нишләп килми ул,— дип акырды зәһәрләнеп.

— Монда мин, монда! — дигән тавыш ишетелде ишек артыннан.

Сабиха белән Маһитап аны аягүрә басып каршы алдылар. Ак күлмәк өстеннән кыска җиңле кара кәзәки кигән, аякларында читек-кәвеш, башында кара хәтфә кәләпүш. Көмеш төсле ак сакал, мыек кыска итеп кыркылган. Яше җитмештән узган булса да, төз гәүдәле. Сәламенә җавап булмагач, як-ягына каранып, нишләргә белмичә аптырап торды. Ниһаять, Зәйнуллин аны үз янына чакырып алды. Урын тәкъдим итмәде, аягүрә баскан килеш, сорау бирә башлады.

— Кем рөхсәте белән муллалык вазифасын башкарасың?

— Шушы авылның указлы мулласы мин, муллалыкны ташлаганым юк.

Җавап Зәйнуллинны аптырашта калдырды. Аның указлы мулла дигәнне ишеткәне бар, әмма указның кем тарафыннан бирелгәнен белми

иде. Төпченеп тормады, указны дәүләт органнары тарафыннан бирелгән берәр кәгазьдер дип кабул итте. Дөреслектә, Зарифулла указны, мәдрәсә тәмамлагач, Уфадагы диния нәзарәтеннән барып алган иде.

— Керемегез турында райфога декларация бирмәгәнсез, моны ничек аңларга?

— Муллалык вазифасын үтәүдән декларация язарлык керемем булганы юк, тишереп карадылар бит инде...

Зәйнуллин кычкырып көлгән булды.

— Син авыл халкын алдап өйрәнгәнсең, безне алдый алмассың!

— Ничек инде бернинди дәлилсез шулай дип әйтергә мөмкин?

— Синең кеременне тавык чүпләп бетерә алырлык түгел, бөтен тирәяк халкын имәсең!

Зариф хәзрәтнең үз гомерендә нахакка бәла яккан бик күп сүзләр ишеткәне бар — әллә картлык галәмәте инде, бүгенге кебек йөрәге әрнегәне юк иде.

— Үзеңне ни өчен монда чакырганны беләсеңме? — дип сорады Сәгыйтов.

— Чамалыйм...

— Чамаласаң шул: узган ел һәм быел нинди керемнәрең булган, шуларны бәйнә-бәйнә сөйләп бир! — Ул, аның керемнәре турында сорашып, акт төзергә тотынды. — Кисәтеп куям, — керемен яшергән кеше гамәлдәге законның 33 нче статьясы нигезендә, уголовный тәртиптә җавапка тартыла.

Зариф мулла сүзне кыска тотты:

— Сез дини йолаларны үтәү буенча мин хезмәт күрсәткән кешеләрне чакырып сөйләштегез, аларга өстәп бер сүз дә әйтә алмыйм.

Сорау актына кемдә, нинди йола үтәүне теркәү белән чикләнергә туры килде.

Зариф мулла кайтып киткәч, ураза аенда авыз ачтырган берничә кешене чакырып сорау алдылар. Алар да бер авыздан акчалата бер тиен сәдака бирмәдек дип нык тордылар.

— Инде нишлибез? — диде Зәйнуллин кәефе кырылып.

— Налог салабыз, — диде Сәгыйтов.

— Нинди керемгә?

— Ничә мәет күмгән, күпме балага исем кушкан, берсеннән дә баш тартмый, үзе әйтеп тора, тиешле сәдакасын алсын иде, безнең анда ни эшебез бар?

Сәгыйтов берьюлы бөтен эшне бетереп китәргә уйлады. Үзе фараз кылган керемнән налог исәпләргә тотынды.

— Кулына йөкләмә тоттырырга ашыкмаска кирәк, — диде Зәйнуллин, — мулладан сорау алганда рәис белән секретарь тыңлап утырдылар...

— Сволочь алар икесе дә, — диде Сәгыйтов, — сөйләш райкомда, укытсыннар арт сабакларын...

— Арт сабакларын укыту гына аз, куарга кирәк!

— Башта мулладан котылырга кирәк, шунсыз монда тәртип урнашачак түгел.

Керемнән алына торган налог турындагы указның 33 нче статьясына игътибар ителгәне юк иде. Чөнки авыл җирләрендә күзгә күренерлек керем алучы кеше калмады. Сәүдә итү катгый рәвештә тыела. Башканы әйткән дә юк, йорт арасында алыш-биреш итүчегә дә спекулянт ярлыгы тагып, уголовный тәртиптә җавапка тарталар. Кустарьлар юк дип әйтерлек. Алтын куллы кешеләр күп югыйсә, әмма берәрсе өендә эшләп халыкка хезмәт күрсәтергә теләсә, каты налогка тартып, артельгә керергә мәҗбүр итәләр. Колхоз белән һөнәр ияләрен берләштергән артельләр арасында аерма бары шунда гына: колхозда эшләгән өчен хезмәт көне язалар, артельдә акчалата түләү каралган. Ел азагында колхозчыга иген уңышыннан өлеш чыгарылса чыгарыла, чыгарылмаса юк, аңа беркемнең

дә исе китми. Артель членының көне-төне чиләнеп эшләп алган хезмәт хакы тәмәкесенә дә җитми!

Райкомда Зариф мулланы райфоның керемен яшергән өчен уголовный тәртиптә җавапка тарттыру буенча эш кузгатуын хуплап каршы алдылар. Суд ябык рәвештә үткәрелде. Ул өч елга ирегеннән мәхрүм итәргә хөкем ителде. Олы яшьтә булуын һәм сәламәтлеген исәпкә алып, хөкем карары шартлы рәвештә чыгарылды. Аерым карар белән, колхоз идарәсенә аны умартачылыкта эшләтмәскә күрсәтмә бирелде.

## XXIV

Быел иген котырып уңды. Авыл халкының күптән мондый уңышны күргәне юк иде. Сугыш алдыннан бер елны иген шулай уңган иде. Күбесенең хәтерендә: сугылган ашлыкны куярга урын булмагач, атка төяп өй саен өләшеп йөрделәр. Ишегалды, лапаслар икмәк белән тулды.

Ул заманда халык бөтенләй башка булган икән — колхоз милкенә кул сузучы юк иде. Колхозчы ындыр табагында, сугылган ашлык янында каравыл торуның нәрсә икәнен дә белмәде. Ә менә хәзер олысы-кечесе җае чыкканда чәлдерергә генә тора. Бу начарлыкка халыкны сугыш өйрәтте.

Тамак тәмугъка кертә, дип юкка гына әйтмиләр. Ач кеше бер нәрсә белән исәпләшми! Ел буе көнне төнгә ялгап эшләп, хезмәтең өчен бер тиен түләнмәгәч, телисеңме-теләмисеңме, урлап тамак туйдырырга туры килә. Урлап көн күрү гадәти бер күренешкә әйләнеп бара. Тормыш шуңа көйләнгәч, каты җәза биреп кенә урлашуны тыеп булмый шул.

Галләмнең колхозчы тормышының урлауга көйләнгән булуына ышанасы килмәде. Әмма...

Бер көнне ул ындыр табагында тау кадәр булып өелгән көшелгә, каравылчыга сиздермичә генә тамга салып калдырды. Икенче көнне килеп карагач нишләргә дә белмәде: көшел яртылаш кимегән иде! Каравыл торучы картка көшелдәге бодай кимүе турында бер сүз әйтмәде, сынап карап торды да китеп барды. Икенче көнне дә шул хәл кабатланды.

Бөкересе чыккан Сабирҗан картның ялгызы ашлык урлавы мөмкин түгел. Димәк, урлау оешкан төстә бара.

Галләм каравылчы картка берничә сорау бирде:

— Сабирҗан абзый, сез төнлә кая да булса китеп йөрми торгансыздыр ич?...

— Юк, улым, юк, Алла сакласын! Үзеңә тапшырылган изге постны ташлап китәргә ярыймы соң!? Нәрсәгә алай дип сорыйсыз, берәрсе җалу бирдеме әллә?

Бу юлы да Галләм картка серне чишмәде, тиз генә китеп барды.

Ул үзенең «ачышы» турында ревизия комиссиясе рәисе Шәриповка сөйләде. Теге тыныч кына тыңлап торды да:

— Милициягә хәбәр итәргә кирәк, шунсыз тыеп булмый аларны,— диде.

Галләм ирексездән елмаеп куйды:

— Үзебезнең өстән үзебез жалоба бирикме?

— Мин катнашмыйм, сез хуҗа, ничек телисез, шулай хәл итегез.

«Мин катнашмыйм», имеш! Ничек инде ревизия комиссиясе рәисе шулай әйтергә мөмкин? Бик борчылып йөрде Галләм. Төн уртасына кадәр боргаланып-сыргаланып ятты да, торып ындыр табагына китте.

Көшел янында җигелгән ат тора. Ике кеше капчыкка ашлык тутыралар. Берсен күрү белән таныды — Мостай Әхәте. Ул яңа гына тормыш корып җибәргән яшь егет. Хатыны игез бала тапты. Әти-әниләре белән

бергә яши. Гаиләләре ишле — ике сеңлесе, бер энесе бар. Алар әле мәктәп яшендә.

Капчыкка ашлык тутыручыларның икенчесе Галләмне күреп алды һәм читкә тайпылды. Галләм аны да таныды. Шушы авыл кешесе. Ревизия комиссиясе рәисе Шәриповның башка чыккан малае — Инсаф.

Каравылчы Сабирҗан карт аның юлына аркылы төште:

— Әйттем мин сезгә йөрмәгез ындыр табагы тирәсендә дип, хәзер менә җавап бирегез! — Аннан Галләмгә мөрәҗәгать итеп: «Карт дуңгыз, тавышыңны чыгарасы булма, дөмектерәбез!» — дип куркыталар,— диде.

Әхәт белән Инсаф башларын түбән иеп, катып калдылар. Галләм шуны аңлады, болар әле бөтенләй юлдан чыккан кеше түгел.

— Иптәш председатель, без монда булмадык, сез безне күрмәдегез,— диде Инсаф телгә килеп.

— Миннән башка күрүчеләр булса нишләрсез?

— Анысын без үзебез кайгыртырбыз.

Сүзләренең авыл кешесенекенә ошамавы Галләмнең бераз кәефен җибәрде. Инсафның урлашкан өчен төрмәдә утырып чыкканын белми иде әле ул. Алар белән сүз көрәштерүне кирәк тапмады. Хәтта бодай тутырылган капчыкларның кире бушатып бетерелүен дә көтеп тормады, китеп барды. Әлегә үзенең караклар белән очрашуы турында бер кемгә дә сөйләмәскә булды. Ләкин моны болай калдырырга ярамый иде.

Көннең икенче яртысында каракларның рәис тарафыннан тотылуы турында бөтен авыл халкына билгеле булды. Колхозчылар түземсезлек белән районнан милиция килгәнне көтә башлады.

Галләм бер кая да хәбәр итеп тормады. Җаваплылыкны үз өстенә алды. Әгәр, эш тикшерү органнарына барып җитсә, егетләрнең икесен дә кулга алып, ирекләреннән мәхрүм итәчәкләр. Моннан колхозга ни файда?! Алар әле карусыз гына иң авыр йөкне тарталар. Юк, урак өстендә үгез урынына җигелеп эшләүчеләрне читлек эченә илтеп тыгу ярап бетмәс! Шулай уйлап, урлашучылар өстеннән документ төзеп маташмады. Һәркайсын кәнсәләргә чакырып, аерым-аерым сөйләшү белән чикләнде.

Иң элек каравылчы Сабирҗан карт белән әңгәмә корды. Ул төнге вакыйга турында сүз башлау белән калтырый башлады:

— Зинһар, картайган көнемдә мине рисвай итмә,— диде яшь бала кебек үксеп.— Бер юлга гафу ит! Үземнең колхоз көшеленнән бер бөртек ашлык алганым юк!

Ат җигеп ашлык урларга килүчеләр белән сөйләшү катлаулырак булды. Инсаф гаебен танырга теләмәде:

— Мин артык та, ким дә түгел, үземә тиешлесен генә алам. Эшләгәнем өчен түләсәгез, төн уртасында качып-посып урлашып йөрер идемме?! — Галләм Инсафның хаклы булуына ышана. Ләкин югарыдан төшерелгән тәртипне бозарга рөхсәт ителми. Беренче чиратта икмәк дәүләт амбарларына илтеп тапшырылырга тиеш. Бөтен көчен куеп иген үстергән кешегә калса кала, калмаса юк — ул турыда бер кемнең дә башы авыртмый.

Икмәкне дәүләткә кызыл олаулар оештырып, җырлап-биеп илтеп тапшыралар. Ризасызлык күрсәтсәң, кайтмас җиргә илтеп тыгуларын көт тә тор! Мондый явызлыкны Иблис уйлап чыгарырга мөмкин.

Әхәт белән Инсаф үзләрен суд алдына басып җавап бирергә әзерләп бетергәннәр иде инде. Галләмнең кешелекле сөйләшүе бик гаҗәпкә калдырды. Әхәт оялды, үзенең гаебен ничек аңлатырга да белмәде. Хәтта суд алдында җавап тотуы җиңелрәк булыр иде дип уйлап куйды. Икесенең дә бүгенге көнгә кадәр үзенә тиң итеп, авызга авыз куеп сөйләшкән начальникны очратканнары юк иде. Шуңа күрә Галләм яныннан күтәренке күңел белән чыгып киттеләр.

Алар чыгып киткәннән соң Галләм ялгызы озак уйланып утырды. Кая барабыз? Әллә, чыннан да, ил белән корткычлар идарә итәме? Кызык та, кызганыч та: берәр авыр хәл чыкса, корткычларга сылтыйлар.

Имеш, житәкчелеккә, тышкы кабыгын алыштырган юха еланнар үтеп кергән! Акланыр өчен ансат юл, әлбәттә. Дөрес, сугыш тудырган авырлыклар һаман әле үзен сиздерә. Тик сугыш беткәнгә инде менә ничә ел узды ич! Крестьянның һаман әле үзе кайнар тир түгеп үстергән уңыштан беренче чиратта авыз итәргә хакы юк. Дәүләт мәнфәгате барысыннан да өстен. Колхозчы шәһәрдән икмәк ташып тамак туйдыра. Күпме шулай дәвам итәргә мөмкин?

Галләм быелгы уңыштан бераз аванс бирергә кирәк дигән фикергә килде. Эшкә килү белән хисапчыны янына чакырып алды:

— Эш көненә йөз грамнан ведомость төзе,— диде. Таһир колагына ышанмый аптырап торды.— Ашыгырга кирәк, ведомость бүген әзер булсын!

— Ашлык тапшыру бик сүлпән бара, үзегезгә мәгълүм... Тапшырылган икмәкнең күләменә карата чыгарылган процент эш көненә бүләргә җитәрлек түгел.

— Шуңа күрә әйтәм дә бит инде ашыгырга кирәк дип! Райондагыларга ишетелсә, хәзер килеп җитәләр.

— Килеп кенә калсалар ярар иде, алып китәрләр.

— Куркасың?

— Минем бит берсеннән-берсе кечкенә өч балам бар, аларны аякка бастырасы иде...

— Минеке дә ике...

— Син читтән килгән кеше, миңа монда яшәргә кирәк.

Әйе, Таһир хаклы. Колхозчының күңелен күрәм дип, аның тормышы җимерелергә мөмкин. Кулыннан бүтән бер эш тә килми. Ә хисапчы булып эшләп көн күреше җайга салынды. Куып чыгарсалар, кая барыр? Җиде класс белем белән бик сикереп булмый. Хисапчылык эшен үзенә күрә яхшы үзләштерде. Сыер, сарык асрый. Гади колхозчы кебек хайван азыгы эзләп чиләнми. Район житәкчеләре каршында азмы-күпме абруе да бар. Житәкче работниклар килгәндә чәй эчерми җибәрми. Чәй янында башкасы да була, әлбәттә. Ул алар өчен эчемлекнең иң яхшысын саклап тота. Гомумән, кулыннан килгән кадәр бөтенесенә дә яраклашып яши. Әгәр рәиснең әмерен үтәсә, бар да чәлпәрәмә киләчәк. Әмма аның белән дә бәхәскә керү ярап бетмәс. Ул ике ут арасында калды. Уйлый торгач юлын да тапты:

— Эш көненә ашлык бүләргә күрсәтмәңне язмача бир,— диде,— дөнья хәлен белеп булмый...

Сугыштан соң колхозда уңыш бүленгәне юк иде. Бөтен авыл гөр килде. Йөзәр грамнан гына булса да, күбрәк эш көнле кешеләр капчык тотып бодай алды. Гәрәбә кебек эре бөртекле бодай!

Уңыш бүлү белән икенче житди мәсьәлә туды. Тарттырырга тегермән юк! Авыл кырыенда җил тегермәне бар. Тик ул ярым җимерек хәлдә. Тирә-юньдә бердән бер тегермән булгангамы, Шәйхи тегермәне дип даны еракларга таралган иде. Мең газап белән төзәттеләр: он чыгарта башладылар.

... Халыкның шатлыгы озакка сузылмады. Колхоз күгендә яшен яшьнәп, күк күкрәде. Районнан тикшерү килеп төште, көтүе белән килделәр. Гадәттән тыш хәл, имеш! Дәүләткә ашлык тапшыруны туктатып, эш көненә уңыш бүлә башлаганнар! Кызу урак өстендә уңыш бүлү аркасында колхозчылар иген эшеннән читләштерелгән. Вакытларын тегермәндә чират торып үткәрәләр.

Тикшерүчеләргә партбюро секретаре Фатыйма ярдәм итеп йөри. Кайда гына булмадылар! Бөтен кырны айкадылар, хисапчының документларын тузгытып ташладылар.

Таһир аларның нәрсә эзләгәнен аңламый алҗыды.

ОБХСС работнигы сугылган ашлыкның керемен, чыгымын бик җентекләп тикшерде. Тикшерү тәмамланыр алдыннан гына сер бераз чишелде:

— Сездә ындыр табагыннан урланган икмәккә бернинди документ төзелмимени?—дип сорады. Менә нәрсә эзли икән ул?!

— Бездә әле андый хәлнең булганы юк.

Тикшерүче өздереп әйтелгән җаваптан ризасызлыгын белдереп:

— Каракларны яшереп калдырмакчы буласызмы? Барыбер табарбыз! Аның ачуы йөзенә күзе төшеп шүрләсә дә Таһир нык торды. Тикшерүче ындыр табагында каравыл торучы Сабирҗан картны ике мәртәбә чакыртып сөйләште. Куркытып карады, көйләп бакты. Җавап бер төрле булды, үзгәрмәде:

— Каракларны яшереп калырга башыма тай типмәгән,—диде ул.

Икенче мәртәбә сорау алганда партбюро секретаре Фатыйма да кәнсәләрдә утырды, өстәмә сораулар да биргәләде:

— Бабай, син бит динле кеше, дөресен сөйләмәсәң, Алла каршында ничек җавап бирерсең?—дигән булды. Картның дини хисләре кытыкланды, кытыклануын—ләкин ватылмады. Чикләвек нык булып чыкты. Ничек инде күрә торып, ике яшь егетне төрмәгә утыртырга кирәк!?

Сабирҗан карт үзенчә фикер йөртте. «Аларны чын карак дип әйтеп булмый»,—дип уйлады ул. Бер кайчан колхоз эшенә чыкмый калганнары юк. Тамак туйдырырга кирәк, ындыр табагында үзең үстергән иген өелеп ятканда, читкә китеп ашарга эзләп йөрергәме?

— Әйт, үзең күпме колхоз ашлыгын өеңә ташыдың?—дип җикеренде тикшерүче.

— Сораусыз кешенең энәсен дә алганым юк,—диде карт бик рәнҗеп.—Шушы яшемә җитеп мине болай мыскыллаганнары юк иде...

Сабирҗан картның өендә тентү ясадылар. Хезмәт көненә бирелгән аванстан башка ашлык табылмады.

Тентүнең иң катысы Әхәт белән Инсаф йортында үткәрелде. Еракта-гы кырда эшләгәнлектән, алар авансны да алып өлгермәгәннәр иде әле.

Тентү ясаганда понятой булып Фатыйма белән Әхәтнең күршесе, күп балалы хатын Әминә йөрде. Халык бар да эштә, кеше таба алмый алҗыдылар. Табылган очракта да күбесе катгый рәвештә баш тарта, понятой булып йөреп исемен былчыратырга теләми.

Инсафның прокурор рөхсәтеннән башка тентү ясарга хаклары юк дип ишеткәне бар иде. Ишеккә аркылы басып, милиционерны кертми маташты. Кайда ул күп сөйләшеп, вакыт уздырып тору? Шүрәленеке кебек озын кулы белән этеп кенә җибәрде:

— Син әле властька каршылык күрсәтәсеңме?—диде төкрекләрен чәчеп.—Монысына аерым җавап бирергә туры килер!

Тентү алар көткән нәтиҗәне бирмәде, әлбәттә. Актармаган җир калмады. Идән астын, очырманы кат-кат тикшерделәр. Ишегалдыннан, бәрәңге бакчасыннан казылган җир эзләрен. Имеш, урланган ашлык җиргә күмеп куелмаганмы? Гаепләрлек бер нәрсә табылмаса да, тозлап-борычлап акт төзеделәр. Гражданин Шәрипов Инсаф милиционерларга каршылык күрсәтте, өенә кертмәскә теләп балта белән кизәнде, төрле начар сүзләр әйтеп хурлады, дип яздылар актка. Гөнаһ шомлыгына каршы, алар килгәндә Инсаф ишегалдында утын ярып маташа һәм, чыннан да, кулында балта бар иде. Понятой булып килгән Фатыйма актка кул куйды. Әминә, мин балта белән кизәнгәнен күрмәдем, дип әйтеп торды.

— Без төзегән актка кул куймасаң, үзеңне җавапка тарттырабыз, дип акырды милиционер. Әминә куркудан сүз әйтә алмый тотлыга башлады һәм имзасын куйды.

Инсафны бер елга эш хакыннан 20 процент тотып калып мәҗбүри хезмәткә хөкем иттеләр.

Асылда тикшерүнең төп максаты: колхоз рәисе Җиһаншин Галләмне социалистик милекне урлаучыларны канат астына алуда, җәмгыятькә зыян китерүдә гаепләү иде...

## XXV

Колхозчылар алдында Галләмнең абруе көннән-көн артты.

Ул, халыкка таянып, эшне кыю рәвештә һәм үзенчәрәк дәвам итәргә тырышты. Шул ук вакытта халык мәнфәгатен яклап эшләгәне өчен баш очында кара болытларның куера баруы да сизелде. Иртәме-соңмы, аңа җавап бирергә туры киләчәк бит!

Хатыны Шәфика чын мәгънәсендә Галләм белән бер тән, бер җан булып яши башлады. Иренең йөзендә чагылган һәр үзгәреш электр тогы кебек тәэсир итеп, аның йөрәге аша уза һәм дулкынландыра. Тик алар мөмкин кадәр бу турыда бер-берсенә белдермәскә тырышалар. Гомумән, Галләм эштәге катлаулы мәсьәләләрне сөйләп хатынын борчырга теләми.

Соңгы вакытта Шәфика үзенең Габделхәй белән булган маҗаралары иренә ишетелмәде микән дип шикләнә башлады. Без капчыкта ятмый, дип бик дөрес әйтәләр. Ул турыда аңа кайчан да булса сөйләячәкләр ич... Ничек кенә әле мең мәртәбә арттырып, әлбәттә. Үзе сөйләсә яхшырак булмасмы? Акылсыз кеше түгел, аңлар! Хыянәт итмәгәнен аңлар. Чыны да шулай бит! Хыянәт итү аның уена да кермәде. Ире янында булмагач беркая чыкмый бикләнеп ятырга микәнни? Ә бертөрлелек бик туйдыра. Халык җырында әйтелгәнчә, «уйнамагач та көлмәгәч — бу дөнья нигә ярый?»

Ә ирләр... Якты йөз күрсәтсәң, ямаулык сорый. Ярый әле Габделхәйнең төп максатын аңлап, вакытында нокта куярга өлгерде. Югыйсә, алданган унҗиде яшьлек кыз кебек булып калачак иде. Ак тәүбә, кара тәүбә! Башка бер вакытта да, ят ирләр белән беркая аяк басачак түгел Шәфика. «Аллаһы Тәгалә гафури рәхим» ди әнисе, бу юлга кичерер микән? Габделхәйгә тагылып йөрүе исеме төшкән саен иреннән оялып, җир тишегенә керерлек була Шәфика.

Галләм исә башкачарак фикер йөртә.

Хатыны турында сөйләнгәннәрнең бөтенесенә дә ышанмады ул. Мөмкин, яхшы белә: Шәфиканың ирләрне шаяртырга хиреслеге бар. Ләкин кем дә булса шуннан артыгына ай-һай, ирешә алыр микән? Ул бер дә юкка, үзе теләп монда, авылга күченеп килмәгәндер. Эш урынында нинди дә булса гайбәт таралган, күрәсең.

Әйе, югалып калмаган, шәһәрне ташлап китеп дөрес адым ясаган. Галләмгә мөнәсәбәте дә үзгәрешсез. Хәтта элеккегә караганда да яхшырак! Аңа нәрсә кирәк тагын? Гайбәткә ышанып гауга чыгарыргамы? Ике бала бар — алар хәзер барысын да аңлыйлар. Тагын ул, яхшымыяманмы, шактый зур коллективның җитәкчесе. Юк белән баш катырмаска, эш турында уйларга кирәк.

Гаилә тормышында иң кирәге — бер-береңә ышану. Галләм Шәфикасына чын күңелдән ышана. Шулай булгач, көнчелек утында янып йөрергә кирәкме? Тормышның яме генә китәчәк. Язмыш аларның чәчләрен бәйләгән, кыямәт көнен дә бергә каршы алырга тиешләр.

Галләм шулай уйлап, гайбәткә игътибар итмәскә кирәк дигән фикергә килде. Сөйләрләр, сөйләрләр дә туктарлар әле...

... Урып-җыюны үз көчләре белән башкарырга булдылар. МТС хезмәтләреннән катгый рәвештә баш тарттылар. Кырга комбайн керсә, ярты икмәк аларга китә.

Ә бурычлар — муеннан. Сугыш беткәннән соң бер елны да дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгәннәре юк әле.

Урып-җыю әлегә уңышлы бара. Пар ат җигелгән лабогрейкалар тәүлек буена эштән тукгамый. Урак белән уручы хатын-кызлар да кырдан кайтып керми: төн кунып, ару-талуны белмичә эшлиләр. Урылган ашлык көлтәгә бәйләнеп, ындыр табагына ташыла. Ташырга өлгермәгәнен кибәнгә өяләр.

Нигъмәтҗан карт җитәкчелегендәге сыйфат комиссиясенең дә кырдан кайтып кергәне юк. Урылган җирдә бер башак кына табылса да тавыш күтәрелә. Куркытыр яки җәза бирер өчен түгел, аңлату юлы белән кеше күңелендәге нечкә кыллар хәрәкәткә китерелә.

Эш җайга салынгач кына Галләм баш очында тагын яшен яшьнәп, күк күкрәде. Бусы да эш көненә уңыш бүлүдән соң башланды. Рәиснең бер шелтәсе бар иде инде. «Нигә бер белән чикләнергә, өчкә тулганчы тырышырга кирәк!» дип уйлады ул. Аннан соң инде теләсә нишләсеннәр! Күпме куркып яшәргә мөмкин?! Урлау яки әрәм-шәрәм итү түгел, намуслы хезмәт өчен хакын түли ич!

Эш хакы түли дип әйтергә дә оят оятын, эш көненә йөз грамм бит! Әмма бу хәбәр сәгате-минуты белән райкомга барып җитте.

Райком бюросында, югарыдан рөхсәтсез, үз белдеге белән эш көненә уңыш бүлү «партизанщина» дип бәһаләнде. Колхозга килеп эшли башлаганнан алып саный китсәң Галләмнең гаебе шактыйга җыела икән. Партбюро секретаре Фатыйма аларны язмача хәбәр итеп торган. Социалистик милеккә кул сузучыларны канат астына алу... Мулла белән әшнәлек... Аның киявенә колхоз хисабына йорт салып бирү... Берсе дә калмаган!

Әбрар нигезенә Коръән укытканда Галләмнең түр башында утыруы аерым басым ясап искә алынды. Мулла Коръән укыгач, ул кул күтәреп дога кылган. Димәк, ул Аллага ышана. Ә Аллага ышанган кеше кесәсендә Ленин партиясенең билеты йөртергә тиеш түгел.

Бюро әгъзалары арасында: коммунист Галләм Җиһаншин колхозга рәис булып килгәнче үк мулла белән элемтәдә торган булса кирәк, дигән фикер туды. Югыйсә, аңа башка колхозлар да тәкъдим ителгән булган. Ә юк, ул аларда эшләүдән баш тарткан, шушы Ленин колхозын сайлаган!

Зариф мулла белән әшнәлекнең тамыры тирәндә, анысы белән тиешле органнар шөгыльләнер! Ярый әле вакытында фаш ителде. Авыл коммунистлары, бигрәк тә аларның җитәкчесе Фатыйма йоклап ятмаган. Аның сыйнфый дошманга карата сизгерлеге бюро тарафыннан югары бәяләнде.

— Безнең илдә социализм җиңеп чыкты,— диде беренче секретарь үзенең йомгаклау сүзендә.— Сыйнфый дошман моның белән килешергә теләми, аяусыз рәвештә мәкерле көрәш җәелдереп җибәрде. Бу көрәштә аларның таянычы — дин. Артта калган бер төркем надан халыкны дин белән агулап, үз кубызларына биетәләр. Коммунист Җиһаншин шулар җәтмәсенә эләккән. Бөек юлбашчыбыз бик дөрес билгеләп үткәнчә, дин ул әфьюн — халыкны агулап, яман шеш тудыра. Ә яман шештән бары хирург юл белән генә котылып була.

Беренче секретарь заманында медицина институтында укып йөргән иде, өлгереше начар булганлыктан өченче курстан куылды. Шул дәвердә үзләштереп калган медицина терминнарының менә хәзерге эшендә кирәге чыкты. Бюро утырышында, җыелышларда ул аларны үзенең чыгышында кирәксә-кирәкмәсә кулланып, халык алдында укымышлы кеше булып күренергә теләи.

Беренче озак сөйләнде. Лениннан цитаталар китереп сөйләде. Ул аларны яттан бикләгән иде.

— Җиһаншин партиядә очраклы кеше,— диде,— безгә аннан котылырга кирәк.

Галләм Җиһаншинны партиядән чыгару турындагы тәкъдим бер тавыштан кабул ителде.

Әгәр бу хәл моннан ярты ел чамасы алданрак булган булса, «мин партбилетны сездән алмадым, миңа аны сугышның иң кызган вакытында, һөҗүмгә барыр алдыннан бирделәр!» дип тарткалашып маташыр иде ул. Әмма хәзер күңеленең тыныч булуына шак катты. Дәшми, тынмый гына билетын куен кесәсеннән чыгарып, беренче секретарь өстәленә

салды. Бюро әгъзалары серле итеп бер-берсенә карашып алдылар. Галләм горур атлап ишеккә юнәлде.

— Кая?! — дип җикерсенде беренче. Ул игътибар итмәде, ишекне каты ябып чыгып китте. Юк инде, ялына торганнардан түгел! Исәнлек бирсен Ходай. Исән булса, урыны табылыр...

Галләм кайтып кергәндә Шәфика шәһәрдән кунакка килгән әнисе белән тәмләп көндезге чәйне эчеп утыралар иде. Әтиләре кайтканны күреп, балалар да өйгә керделәр. Бер-берсен узышып, чыр-чу киләләр.

— Нәрсә булды? Юлың уңмаган, ахры? — диде Шәфика гаҗәпләнеп. Гадәттә, районга чакырсалар Галләм ярты төн узгач кына кайта торган иде. Аның сер бирәсе килмәде булса кирәк, елмаеп карады да, шуның белән бетерде.

— Ник әйтмисең, берәр хәл бармы әллә? Төсеңә чыккан...

Артык яшереп торуны кирәк тапмады:

— Партбилетны биреп кайттым, — диде.

— Аңламыйм...

— Партиядән чыгардылар.

— Ни өчен?

— Соңыннан, соңыннан! Башта тамак ялгап алыйк.

Шәфика иртән өчпочмак пешергән иде, шуны җылытты. Каты итеп чәй ясап китерде.

Галләм никадәр генә үзен тыныч тотарга тырышса да, тамагыннан аш үтмәде. Чемченеп утырды да, яртылаш ашалган өчпочмакны тәлинкәсе белән читкә алып куйды.

— Иртәгә сезнең бөтенегезне шәһәргә озатам, җыеныгыз! — диде. Ни өчен ашыгуын да аңлатты.

Бу хәбәр Шәфикага аяз көндә яшен суккан кебек тәэсир итте. Партиядән чыгарылгач ирен колхоз рәисе урыныннан куачаклары аның аңына барып җитмәгән иде әле...

Ул авылны, аның кешеләрен чын күңелдән яратып өлгергән иде инде. Хезмәтеннән дә тәм тапты. Димәк, бар да коры хыял гына булып кала!

— Сине эшкә обком җибәрде бит, ник аларга мөрәҗәгать итмисең?

— Файдасы юк. Мондый партиядә әгъза булып тора алмыйм мин, үзләре чыгарып яхшы иттеләр.


Соңгы вакытта Галләм коммунистлар партиясенең халык мәнфәгатьләрен кайгыртмавын аңлап, тирән уйга батып йөрде. Әнә сугышка кадәр колхозчыга аз булса да эш көненә натуралата түлиләр иде. Ә хәзер бушка эшләтәләр! Крепостнойлар да мондый авыр хәлдә яшәмәгәннәрдер! Колхозчы мәнфәгатен яклаучыларны авылда тотмыйлар. Бөтен эш дәүләт мәнфәгатен күз алдында тотып кына башкарылырга тиеш. Зур шау-шу куптарып, утыз меңчеләр хәрәкәтедә шул максат белән оештырылды. Күпме кеше иләнгән җиреннән аерылып, яраткан эшен калдырып китәргә мәҗбүр булды. Күпме гаилә тар-мар килде.

Галләмнең эштән алынганын белгәч, авыл халкы кара кайгыга батты. Колхозчылар аны үз итеп өлгергәннәр иде инде. Бөтен халык исеменнән гариза язып, эшендә калдыруны таләп итеп карадылар. Игътибар булмады.

Авылны ташлап китү Галләмнең үзенә дә җиңел булмады.

Ул шәһәргә кайткач, таныш-белешләренә күренмәскә тырышты. Элек эшләгән җиренә барып та тормады. Белә: аны анда якын да китерәчәк түгелләр! Эшсез яшәү дә мөмкин түгел... Кабырга кыса! Уйлап-уйлап йөрде дә, эшкә урнашырга урманчылыктан да кулай урын булмас, дигән фикергә килде.

# ШИГЪРИЯТ



## Кави Латыйп

### СУРӘТЛЕ СҮЗЛӘР

* * *

Уйларым ак болытлар сымак,
салмак кына ага.
Үз агымын алар таба.
Киек каз юлыдай эзләре кала,—
җуелмас эзләр!

Менә-менә алар җиһанны бизәр,—
Адәм вә Галәм күзләр.

Уйларым — сурәтле сүзләр...

* * *

Кайчак,
бер сүз өчен
идел-дәрья кичтем,
таш кистем,
сират күперен үттем.

Юккамыни үземне
шагыйрь дип хис иттем!

* * *

Дендәш, диндәш Ичкерия,
синең өчен җаным яна,
җаным көя.
Уф, Аллам!

Бу соң каян —
дәүләт күләмендә — ялган?!
Дөнья күләмендә — ялган!

Жаның еламыймы, Аллам?!

* * *

Аһ, россиян — «олы туган»!
ниләр генә кылсаң да, гел
«чыгасың коры» — судан...

* * *

Бөгелмим, сыгылмыйм, тезләнмим...
Чигенмичә,
жиңелмичә,
алга барам Тукай эзеннән мин!

Ә бу юлга —
Фатиха алдым, Ходай, үзеңнән мин!

* * *

Туган тел өчен борчылам,—
олыгаю билгесеме? —
Тел язмышы — Ил язмышы,
борчый мин-карт кешене.

Денем диеп, динем диеп,
жиһанга сөрән салам...
Кяферләр кылыч йөрткәнгә,
телемне хөкем иткәнгә,—
«милләтче» булып калам!

* * *

... Гадимен һаман:
гади телдә аралашам,
аңлашам, санлашам.
Гафу итмәс гадилек тә мине —
үз-үземә ташлар атсам,—
ялган «гали» булып
яши башласам...

* * *

Яшәүнең ямь-тәме бетте,—
кеше «нуль» булып калгач,
түрә-«хөкемдарлар» аяк чалгач...

Аяк чала-чала,
безгә

богау сала-сала,
тәхет яулап алгач...

Шәфкатьсезлек — Җирдә...
Хода бәндәләре, исән килеш,
Керсеннәрме гүргә?!

## Авыргач...

«Кылдан да нечкә,
кылычтан да үткен
сират күперен» кичтем.

Йөрәгем тавышын ишеттем:
«Кави, сынма!»

Сынмадым,
йөрәгем кушканны тыңладым.

Үлемгә иде бер адым!

* * *

... Дуслар гына түгел,
дошманнар да әйтсен:
«Әҗәл чигенде,
Кави җиңде!»

Яшәүдән миңа — тагын да
ни кирәк инде?!

* * *

*(Җиңү көнендә бер уй)*

Минем язмыш — ир язмышы:
иргә ил-көн кагыла...
Ир-егет даны һаман да
батырлыкта табыла
(Илне сөю ялкыны да
батырлыктан кабына!).

Җаным белән тәнем тәңгәл,—
үземне шулай аңлыйм:
нинди генә халәттә дә
гел солдат булып калыйм...

Җиңүче ир батырлыгын —
«Кавилыгым»да таныйм...



# Нәҗип Мәдияров

## ТЫНДЫ ҖИЛЛӘР...

### Кадерле

Кадерле әйберләр күп ул,
Белсәң әгәр кадерен.
Белүең хуп, кадерләргә
Ирке зур ич Тәңренең.

Әйтәсең, барыннан да, дип,
Сөйгән яр бик кадерле...
Кемгәдер үзең кадерле
Булу да бит кадерле!..

### Михнәт

Еллар кырыс иде:
Бик күп җәфаларны
Әрдәнәләп өйде
Безнең өскә михнәт.
Белмим, шуңадырмы,
Бик тиз туза иде
Бала чакларымда
Өстемдәге бишмәт.

Очкынланып торган
Үсмер чакларымны,
Күп җәфалар чигеп,
Эшләп уздырдым мин.

Урам тегүчесе
Теккән бишмәтләрне,
Сатин чалбарларны
Бик күп туздырдым мин.

Еллар узды. Бала
Чакны хәтерләргә
Калдырылмаган шул
Хет бер иске бишмәт...
Әмма тузмый һаман
(Гомерлектер, ахры),

Гел яңарып тора...
Өстемдәге михнәт.

## Әйе, булды...

Кулны пыяла белән дә
Кискән чаклар булды...
Пычак белән кисүләрне
Әйткән дә юк инде!

Нахак сүзләр дә үзәкне
Өзгән чаклар булды...
Нахакмы, түгелмеләрен —
Әйткән дә юк инде!

## Кызларга

Кызлар үзара сөйләшә
Төш күрүләр хакында.
Ул төшләр сугарылганнар
Сөю дигән ялкынга...

Кызлар, кызлар! Әйбәтлеккә
Юрыйм төшләрегезне...
Сөюнең тик ак канаты
Сөйсен түшләрегезне.

## Йоклады көн

...Тынды җилләр, бодай башаклары
Селкенмәслек хәлгә килделәр.
Юкса, көндез алар шаулашудан
Туктый алмас кебек иделәр.

Сәер тынлык хәтта агачларның
Яфракларын алды уратып:
Йоклады көн — мәгърур күк йөзенең
Йолдызларын, Аен уятып...

## Бер хатирә

— Син үзеңнең кемлегеңне
Белеп эш итмисең,
Шуңа күрә дәрәҗәңә
Менеп үк җитмисең!..

Бер чибәр кыз шулай диде
Миңа егет чакта.
Бүген хәтерне яңартып,
Уйлыйм мин шул хакта.

Кемлегем дә, дәрәҗәм дә
Ул чак кирәкмәде.
Чөнки мине кәпрәергә
Тормыш өйрәтмәде.

Гафу итсен ул кыз.
Сүзен
Искә алмадым шул.
...Аны, ярты гасыр үткәч,
Соңлап аңладым шул.

## Мәхәббәт тәрәзәсе

Тәрәзәдә мескен чыпчык...
Пыяланы күрми.
Ул бит аннан очып китә
Алмаслыгын белми.

Мәхәббәт тәрәзәсе дә
Безгә шундый тозак.—
Анда күпләр бәргәләнеп
Җәфалана озак...

Тәрәзәне ачтым менә,
Китте чыпчык очып.
Ә мәхәббәт тәрәзәсен,
Их, булмый шул ачып...

Шуңа бугай — гомер буе
Үрсәләнә гашыйк.

## Көзге манзара

Суынды җәй. Гөлләр шәлперәйде.
Түрдә хәзер көзнең урыны.
Кырауларның салкын кулы тагын
Чәчәкләрнең күзен йомдырды.

Яңгырларга мохтаҗлыклар бетте,
Тәмам юмартланды болытлар.
Урамдагы каз, үрдәкләр өчен
Күбәйделәр күлләр-сулыклар.

Без күрмәгән ерак, җылы якка,
«Күздә тотып», ахры, китүне —
Пеләшләнгән агач башларында
Киңәш кора карга көтүе...

## Ашкын, әйдә

Кая ашкынасың, күңел!
Ашкынма, тыел инде.
Аңлыймын, тынычланырга
Сиңа бик кыен инде...

Омтылу җиңел түгел шул
Шигърият үрләренә.
Ыргыйсың — кыенлыкларны
Ышанып җиңәренә...

Һәм бүгенгемә, яшьләрчә,
Китерден мине, күңел.
Димәк «өлкәнлек җилләре»
Сине егарлык түгел.

Ашкын, әйдә: илһамың бар,
Уй-хисләрең сәламәт.
Канәгать булмавың өчен...
Мин дә синнән — канәгать!

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Җәмит Рәхимов**

## ӘҖӘЛ ВАГОНЫНДА

хикәя

Канатлы аргамакларың бер якта торсын! Ике дистә чамасы яшькелт вагон таккан корыч машина, әкияттәге азау ярган айгыр кебек пошкыра-пошкыра, һаман алга ыргыла. Әй, кая инде ул мескен хайванга ут-пар куәте белән хәрәкәтләнә торган бу албасты белән тиңләшергә! Әнә бит, һәркайсысына көнбатыштагы биш-ун дәүләт шыплап кереп утырырлык кырыкмаса-кырык өлкә-крайлар инде артта калды, күпләр география китапларыннан гына укып, кинолардан гына күреп белгән Приморье белән Хабаровск та, исемнәре мәшһүр декабристлар хакында язылган роман-повесть битләреннән төшмәгән Чита белән Иркутск та, җырларда җырланган Байкал-Ангаралар да үтелде, ә кайтасы юлның иге-чиге күренми әле.

Кысан купеның түбәнге ятагында гасабиланып барган Нәҗип торып урынына утырды, ул да түгел, кисәк калкып, вагон тәрәзәсенә капланды. Тышта исә һаман да бер үк күренеш: ябалдашларын басып-сыгып торган кар япмаларыннан яңа гына арынган чыршы-карагайлар күз иярмәс тизлек белән артка йөгерешә. Үзең мәһабәтрәк дип санаган берәрсенә күз сирпеп өлгермисең, ул инде кайдадыр соңгы вагон турында эреп юкка чыккан була. Кичә дә шулай иде, өченче көн дә... Һай, иге-чиге бар микән бу тайганың, очы-кырые күренә микән бу Себер дигән ерак-алысның?!

Егеткә тагы да ямансурак булып китте, кире урынына кайтты, ятагына утырды һәм тәрәзә буендагы киндер капчыгына үрелде. Аның элмәкләп бәйләнгән бавын бер тартуда чишеп җибәрде дә кара лакка буялган тальянын тартып чыгарды. Хак, аның ялтыравыклары инде күптән тоныкланган, гармун үзе дә шактый бушаган. Мәгәр тавышы ифрат та көр әле аның. Ә моңы,.. моңы!.. Юк, аныкыдай тылсымлы аһәң, назлы тавыш Рәсәйдәге башка бер генә гармунда да юктыр, мөгаен. Нәҗип күрекне тарттырып куйган элмәкләрне ычкындырды, киң каешны иңенә элде, тальянны киереп тартты да яңгыратып аккорд бирде һәм... кинәт телен тешләгән кешедәй, туктап калды. Ярый торган эш булмаса да, гармунның телләренә басмый гына күрекне кысты, шомланып ишеккә карады.

Чегәннеке кебек кара күзләрен күпе ишегенә текәп, кызларны көнләштерерлек озын кара керфекләрен һәм төн кошы канатыдай кара кашларын да селкетмичә шулай күпме утыргандыр, чандыр гәүдәсенә һәм кара-тут йөзенә салкын тир бәреп чыкканын тойды. Тирләрсең дә, ул

хезмәт итә торган авиация полкында инде айдан артыграк кара кайгы — матәм. Кая ул гармун тавышы, тыелып кына көлгән кеше дә юк. Хихылдау сиңа тагы, кычкырып сөйләшкән кеше булды микән? Эфир дулкыннары аша көне-сәгате белән Мәскәүдән килеп ирешкән коточкыч хәбәр аерым хәрбиләрне генә түгел, тулы бер полкны, хәтта Ерак Көнчыгышның төрле бистә-шәһәрләренә, кыр торлакларына сибелгән авиация частен өнсез итте. Итәр дә шул, анадан туганнан бирле бар һәм бер Алладан да бөегрәк кеше дип канына сеңдергән, туган атаңнан да газизрәк даһи дип миеңә тукылып торган илаһи зат — кояшка тиң Сталин үлсен әле! Кемгә дә булса дәшәргә шикләнгән, ни-нәрсә дип эндәшергә белмәгән гаскәриләр бер-берсеннән читләштеләр, тәмам бүкәйләргә әйләнделәр. Полкта көннәрне түгел, сәгатьләрне үткәрү дә искиткеч газапка әверелде.

Дөньяның ачысын-төчесен күп татыса да, бу ыгы-зыгылы тормышта ике дистә елдан артыграк яшәү дәверендә юлында гел генә җай чыгып тора иде Нәҗипкә. Бу юлысында да бәхет елмайды аңа. Җир читендәге Спасск-Дальний дип аталган бу калада байтактан торганлыктан, полк әледән-әле яңа биналар җиткерә. Киң иркен биналарның янә берсе сафка баскач, моңа кадәр кысан урында торган бомбаларны билгеләнгән урынга төгәл ыргыту күнегүләре уза торган тренажерны күчереп монтажларга булдылар. Нәҗип писарь булып хезмәт итә торган штабның оператив бүлек башлыгы Сударенко соңгы көннәрдә гел әнә шул хакта сөйли. Шулаен шулай да, бу катлаулы электр җиһазлары монтажланган тренажерны күчереп куючы останы тиз генә кайдан табасың? Владивостоктан яисә Хабаровскидан китертәсеңме әллә? Башлыгының әнә шул рәвешле пошынып сөйләгән мәлләрендә теле кычыткалап куйгалады Нәҗипнең, тренажерны күчереп монтажларга рөхсәт сорыйсы килде. Ни гаҗәп, тотынса, ерып чыгарына ышана иде ул. Авылда туып, яшьтән теләсә нинди эшкә күнегеп үскәнгәме, һәммә нәрсәгә кулы ятып тора иде аның. Чистайда авыл хуҗалыгы техникумында бераз укып алуы да эзсез калмагандыр, мөгаен. Кызганыч, аны тәмамларга гына ирек бирмәделәр — армиягә алып киттеләр. Алай да техника дөньясыннан нәрсәдер йогып өлгергән бугай. Һәрхәлдә, тотынса, тренажерны исән-имин күчереп куясына һәм аны кабат эшләтеп җибәрәсенә ышана егет. Тик менә бәла: илдә бөтен халык матәме башлаганнан бирле, Сударенко да тәмам телен тешләде, тренажер хакында ник кенә бер сүз кузгатсын. Мәгәр икәүдәникәү штабта утырганда да бүкәйләр сыман бер-береңә дәшешми торып булмый бит инде. Болай да кешеләр белән аралашырга ымсынып йөргән Нәҗип түзмәде беркөнне:

— Иван Егорович,— дип басынкы гына эндәште ул кара янып утырган бүлек начальнигына,— рөхсәт итсәгез, мин теге тренажерны күчереп монтажлар идем. Штабта эшләрнең дә сыек чагы...

Башлыкның күзләре җанланып китте, чыраена нур иңде, урыныннан торып, Нәҗип янына килде.

— Ни диим,— ул саллы кулын егетнең җилкәсенә салды.— Бер айда күчереп куя һәм эшләтеп җибәрә алсаң, юл вакытларыңны исәпләмәстән ун көн ял сиңа!

Көтмәгән бәйрәм булды бу Нәҗипкә: ялгызы аулак бүлмәгә кереп бикләнде, сәгатьләрне санамый гына тренажер белән әвәрә килергә тотынды. Чыннан да, ул туганда ук күлмәк киеп туган бугай, эш көтелмәгәнчә көйле барды. Карап-игътибарлап сүтүнең дә ярдәме тигәндер инде, һәр тимер үз урынына килеп, һәр үткәргеч тиешенчә ятып торды. Эш башланганның уникенче көнендә тренажер тулысынча яңа бинага күчеп утырган иде инде. Тагы да гаҗәбе шул: ул карусыз эшләп тә китте.

Нәҗип исә бүлмәдән китәргә дә, ял сорарга да ашыкмады. Авыл кешесенең ни, ул бит кылган гамәле, башкарган эшенең әҗерен сорый белми — егетебез башлыгы әйткәнне күптән онытkан иде инде. Ә яңа бинадагы тренажер янына бик теләп йөрде, ялгызы гына утырып

«дошман тылындагы объектларны бомбага тотты». Беркөнне шулай ялгыз башы уйнап утырганда аның янына оператив бүлек башлыгы үзе килеп керде һәм шатлыклы калын тавышы белән бөтен бүлмәне тутырды:

— Ба-а-а, Ханов ерып чыктың, ә? Менә молодец! Бар, йөгер, яз, ялыңны законлаштыр.

Авылның эш-мәшәкать белән төнәтелгән һавасы, җиде бала арасында һич иркәләнә белми тәгәрәп үсү, әтисе Дәүләт белән әнисе Фатыйманың, балалыкка һич кенә дә ташлама ясамыйча, ир кеше белергә тиешле бөтен һөнәрләрне өйрәтүләре бик тә ярап куйды бит, әй. Нәҗип карыша-карулаша белмәде, кушылганны җиренә җиткереп, хәтта арттырып үтәде. Ә инде тегенди-мондый дорфалык — кул озайту, тәртип бозу башына да килмәде, хәмер эчүне исә бөтенләй белми иде. Командирлары яратты үзен һәм менә өч елга — өченче ял...

Туган авылы исенә төшү галәмәтеме, әллә соң курка-өркә карап торган ишекнең ачылмавы, шулай ук аның артыннан бернинди кисәтү авазы яңгырамавы батырайтып җибәрдеме, Нәҗип акрын гына гармунын тартып куйды, күптән таныш һәм күңелгә сеңеп беткән авыл көен сызды. Алай да егет чагында урам әйләнгәндәй тальянының күреген киереп тартмады — сагышлы көй талгын гына агылды да агылды. Хисләнүе җиткән иде егетнең, үзеннән-үзе күңеленә җыру иңде:

Машинага бер утырсаң,
Бара да бара икән.
Хәсрәт уты бер кабынса,
Яна да яна икән.

Һәй, әттәгенәсе, кайдан башка килә диген шундый җыру! Хак, машина бар, ул бара да бара. Ә менә, шөкер, бернинди хәсрәте дә юк. Киресенчә, сагышлы шатлык йөрәгендә. Сүз дә юк, машина дигәнең ул өметләнгәннән акрынрак бара сыман. Тик зыян юк, кояш чыгып, ул баткан саен, поезд аны үзе туып-үскән Чирмешән буйларына якынайта лабаса. Әнә ич, инде Томск да артта калды, тиздән — Новосибирск. Насыйп булса, анда тиз генә күчеп икенче поездга утырырлар. Аннан инде тагы ике-өч тәүлек селкенсәң, Өфе каласы. Һай, Уфага житкәчме! Аннан инде Чирмешәнгә кул сузымы гына!

Үзеңне рухландыра белсәң, һәрчак күңелгә җиңел ул. Нәҗипнең дә кәефе күтәрелеп китте, кабат гармунын тартты — бәләкәй купены шахтер егетнең иңрәү моңы тутырды. Янә хис дөньясына чумса да, башындагы акылына күз-колак булып торучы «сакчы»сы уяу иде егетнең. Ул гармунын суза-суза, икенче кат сәндерәдә чалкын ятучы якташы һәм полкташы Мөстәкыймгә күз салды. Керфекләре йомык: әллә уйланып бара, әллә соң күптән тансыклаган туган як аһәңнәрен тыңлап ятамы? Ничек кенә булмасын, аның үзен тотышыннан канәгать Нәҗип: ник кенә бер зарлансын да, ник кенә бер ыңгырашсын. Ә бит хәле шәптән түгел Мөстәкыймнең. Ул әле күптән түгел генә бөеренә операция ясатты — җөйләре дә абылып җитмәгән, авырта, ди. Әнә шул сәбәпле бөтенләйгә өенә кайтып барышы. Шул шатлыгы тыеп торамы аны, кеше алдында сызланганын сиздерәсе килмиме?

Ярый, йокласа йокласын, тыңласа тыңласын. Нәҗип исә уйный менә. Күптән тотканы булмагангамы, онытылып-илһамланып уйный. Башы житте — гармунын үзе белән алды. Тагы бер ел хезмәт итәсе бар, калсын, дип уйлады башта. Әти-әниләргә, агай-энеләргә, апа-сеңелләргә бүләккә дип җыя торгач, вак-төяге дә шактый тупланган — чемоданы буаз тана, көчкә-көчкә генә ябып бикләде. Кыска вакытлы сәфәрдә гармун дигәнең артык иде, билгеле. Алай да, алды ул аны, авылда калдырып ук килә, янәсе. Аңардан аерыла алмаганга калдырмаганын яхшы белә бит югыйсә.

Шулай, гармун аның гомерлек юлдашы, иң якын сердәше. Шулай гына микән, юктыр, ул аның кайсыдыр бик кирәкле әгъзасы сыман. Кулында, янсә янында тальяны булмаса, тыны кысыла, йөрәге сыкрый Нәҗипнең, әлеге теге китапларда язган су кешесенең ярга чыкканы кебек хис итә үзен. Юк, һич тә яшерен-батырын түгел, гармун инде егетнең йөрәк тибеше, яшәеше.

Язмыштыр инде, атасы Дәүләт үз гомерендә уйнап караганы булмаса да, гармун дигән нәрсәгә битараф түгел иде. Гадәте — Чирмешәнгә, янсә башка берәр якка базар-ярминкәгә барды исә, бер-бер гармун күтәреп кайту. Рас, ул аны үзе шыңгырдатып та карамый, мәгәр гармунчыларга биреп-биреп тора. Моң чишмәсе еш кына өйгә атнасы-атнасы белән кайтып керми, аның ватылып калу очраклары да булып кына тора. Мәгәр авылның танылган ат духтыры Дәүләт һич кенә дә боекмый, базар-ярминкә җитүгә, яңа гармун белән әйләнеп кайта. Хәтерендә Нәҗипнең: әле ул үзен-үзе белә башлаган чагында да әтисенең ике тальяны бар иде. Аларның берсен гадәте буенча, башкаларга биргәләп торса да, икенчесен өйдән чыгармады. Тирә-якның оста гармунчылары аларга килеп кенә уйнап карыйлар иде анысын. Сыздырып-сыздырып алалар да әйтәләр:

— Ай, гармуның, Дәүләт агай!

Әнә шул сүзгә күңеле була торган иде әтисенең. Мактау авазын ишетүгә, йөзенә генә түгел, бөтен кыяфәтенә мәгърурлык иңә һәм ул вәкарь белән генә әйтеп сала:

— Телләре — чын көмеш!

Ни гаҗәп, туган нигезендә әнә шул рәвешле тальянга табыну яшәп килсә дә, малай чагында Нәҗип аларны кулына алып карамады, гармун кычкыртып карау башына да килмәде хәтта. Ходайдан вакыт җитте күрәсең, беркөнне исә кисәк кенә шул мактаулы уен коралы хакында уйлана башлады.

Аңа унбер тулып, ил өстенә зур афәт килгән — сугыш чыккан елның җәе иде ул. Кичен, гадәттәгечә, хуш исләр аңкытып торган печәнлеккә менеп ятты Нәҗип, һәрвакыттагыча, йоклап китә алмый аунады. Шулай җәфаланып ятканда, кинәт бер нәрсәгә игътибар итте. Бәй, урамнар тып-тын ич бүген. Башка төннәрдә авылның әле югары очыннан, әле су буеннан тальян моңы агыла, һәм кайчак кемдер аңа кушылып җырлый. Һәм бу хәл гел генә диярлек беренче әтәчләргә кадәр дәвам итә торган иде. Кичке урамда гармун тавышы ишетелүгә, өлкәннәрнең сөйләшкәннәрен үзе тыңлап торганы булды Нәҗипнең:

— Әхмәди Харисы моңая.

Харис кына түгел, бөтен авыл моңая иде әлеге тальян тавышыннан. Яп-яшь килеш егетләр кулы да тота алмый калган күпме кызлар, пешкән алма кебек чагында тол калган күпме хатыннар мендәр почмагын тешләп елаганнардыр ул кичке назлы авазлардан. Бүген исә урамнар тынып калган, ник кенә бер шылт иткән тавыш ишетелсен. Әллә соң Харис абыйны да алып киткәннәрме утлы җәһәннәмгә?!

Сорауларга җавап иртәгәсен үк табылды — әйе, сугышка алганнар авылның бердәнбер гармунчысын. Бу хәбәр исә малайлыктан чыгып килгән Нәҗипнең миендә буыннар әмере булып яңгырады. Шул көнне ул беренче тапкыр әтисенең көмеш телле тальянына үрелде.

Утырдым да уйный башладым дисә, ялган булыр. Мәгәр ул бик тиз өйрәнде гармунга. Туганда ук музыкант булып туган диярсең, ике-өч атнадан малай инде авыл көйләрен ярыйсы ук шома сыздыра иде. Юк, бөтенләй ятим калмады Түбән Кәминкә — оста Харис урынына яшь гармунчы Нәҗип басты. Алай да, мәшһүр авылдашы сыман, кичке авылны моңга күмеп урамнар урамый әле малай. Урамаса урамас, мәгәр мәҗлесләрдә, башка кирәкле урыннарда гармун тавышы чыгарырга ярар. Ә гармун дигәнең бик тә, бик тә кирәк иде ул елларда. Көн тудымы, Түбән Кәминкәдән кемнәрдер Чирмешәнгә комиссиягә бара.

Ерак юлга чыгасы атларга колхозның яхшы юртаклары җигелә, арбаларның дүрт ягына да ышкыланмаган каен такталардан утыргычлар ясала. Никрут егетләр тезелешеп, берсен-берсе җилкәләреннән кочаклап утыра шуларга. Нәҗипнең исә урыны түрдә, көмеш телле тальяны кулында.

Егетләрнең әле кичә, яисә өченче көн «күренергә» барганнары бүген инде яуга китә, комиссиягә башкалары җыена. Малай-гармунчыны олауларның берсеннән дә калдырмыйлар, җырлары исә тегеләренең дә, боларының да бер үк:

Без авылны чыккан чакта...

Гармунчы булу, аның данын күтәрү бик җиңелдән түгел. Аңа ирешкәнсең икән, ул исем-дан сине гомерең буе озатып йөри. Уен-көлкеле каз өмәләре, җырлы-биюле аулак өйләр, иске мәчетләрнең түрләренә тактадан әмәлләп куелган сәхнәләр, төрле конкурс-смотрлар... Әлеге мәшәкатьле даннан туган авылыңнан чыгып киткәч тә котылырмын димә.

Хәтерләми, полкташларына үзе сөйләп ташлагандырмы, аның гармунчы икәнен тиз белеп алдылар Ерак Көнчыгышта. Һәй, әйтеп торуның хаҗәте бар идеме соң?! Рәсәйдә татар булмаган тишек тапмыйсың: Спасск-Дальнийда да бар иде алар. Шәһәрнең бер читендәге цемент заводында аеруча күп иде татар яшьләре. Хәер, алар полкта да аз түгел, араларында якташлар да җитәрлек. Әнә ич, Мөстәкыйм Госманов Зәй-Каратае янындагы Үзбәк авылыннан, Фәһим Галимов шул тирәдәге Тимештән, Шөгер-Әлмәт егетләре дә күренгәли. Җае килеп, калага чыктылар исә, якташлар бергәрәк тә булырга тырышалар һәм инде, мәгълүм ки, аяклары үзеннән-үзе татарлар яши торган цемент заводы бистәсенә тарта. Килеп җитүләренә, Нәҗип кулына күпне күргән, баса торган телләре ашалып беткән бер-бер тальян китереп тоттырдылар. Нәҗипкә ни, уйный егет, сайрата — җае, урыны, тотарга коралы гына булсын. И, кинәнделәр дә соң биеп заводтагы татар кызлары.

Шулай бер көнне Нәҗип штабтагы бихисап кәгазьләре белән әвәрә килеп утыра иде. Сак шыгырдап, сыза гына ишек ачылды һәм аннан таныш мышнау ишетелде. Борылып карамаса да белде Нәҗип — якташы Мөстәкыйм. Аның тырпайган кыска чәчен күз алдына китерергә өлгермәде, тегенең ярымпышылдап дәшкәне ишетелде:

— Карале, Чирмешән, чыгып кер әле! — Әнә шулай үз итеп, «Чирмешән» дип эндәшә иде якташы.

Алар Фәһим белән икәүләр икән. Ашыкканнар, күрәсең, сулулары капкан. Бер-беренә өсти-өсти «сер»не чишteләр:

— Анда...

— Бер урыс...

— Гармун кычкырта,— диделәр икесе берьюлы.

— Нинди гармун?

— Чып-чын тальян,— дип кызуланды Мөстәкыйм.— Ну, малай, тавышы да тавышы...

Бу алыс җирләрдә урыс егетенең тальян тотып утыруына гаҗәпләнмәде Нәҗип. Ул инде белә: Себер һәм Ерак Көнчыгыш тарафларындагы күп кенә урыслар ике рәтле гармун белән түгел, нәкъ менә тальян белән мавыгалар. Шуңа да якташларының хәбәренә һич кенә дә исе китмәде:

— Шуннан ни? — дип кенә куйды.

— Ул бит адәм рәтле уйный да алмый,— дип кайнарлануында булды Мөстәкыйм.— Ә гармуны шә-әп! Кем белә, мужыт сатып та җибәрер.

Штабтан чыккач та күрделәр: аргы казарма янындагы ялгыз карагай төбендәге эскәмиядә, чыннан да, берәү гармун шыңгырдатып утыра. Сөйләшми генә шунда таба атладылар.

Такыр башлы, табак битле бүтәкә егет шәһәргә каршы якта рәшәләнеп торган офыкка карап дөньясын оныткан, үзе ниндидер көй чыгарып-

га азаплана — сагышлануы инде бахырның. Янына гаскәри егетләр килеп басканын тоемлап, ул туктап калды, зәңгәр күзләрен чакырылмаган кунакларга төбәде. Сипкелле битендә: «Йә, ни кирәк?.. Тыңлыйм»,— дигәне ярылып ята иде.

Күрде Нәҗип: гармунның тышкы кыяфәте әллә ни түгел, буяулары уңган, телләре ашалып шомарган, мәгәр тавышы искиткеч.

— Сат миңа тальяныңны,— диде ул урыс егетенә, бернинди керешсез.— Барыбер уйный белмисең бит...

— Шту син,— егет утырган урыныннан чәчрәп торды.— Ул бит әти төсе!

— Атаң... гармунчы идеме?

— Егет чагыннан уйнаган ул бу тальянда, кызлар йөрәген җилкеткән.

— Үзе ясаган алайса?

— Ясамаган, гармун аңа бабайдан калган. «Миңа кадәр кемнәр вә күпме уйнаганнардыр, мин ул хәтлесен белмим,— ди торган иде әти,— инде менә минем кулда чирек гасыр». Шунысын да өстим: әти беләбелгәннән бирле төзәтмәгәннәр аны.

Нәҗип ихтыярсыздан янә тальянга карап алды. Аның кыяфәтенә караганда, егетнең сүзендә хаклык барга охшый. Әй, эш тышкы ягындамыни соң. Тавышы диң, тавышы. Сандугачыңны көнләштерер, валлаһи! Телләре нәрсәдән икән? Көмештер, мөгаен.

— Сат миңа, күпме сорасаң да бирәм!

Алдашмый иде Нәҗип, акчаны мул алды ул хезмәтендә — аена 550 сум. Гаскәри кешенең исә чыгымнары юк диярлек: ашау — байдан, үлем — ходайдан. Акча дигәнең гимнастерка кесәсен бүлтәйтеп, уңайсызлап тора.

Мәгәр урыс егете дә акчага кызыга торганнардан түгел икән:

— Әткәй истәлеге дип әйттем ич мин сиңа! Истәлекне сатып була димени?

Сатулашуга Мөстәкыйм белән Фәһим дә кушылып киттеләр. Юмалап та карадылар тегене, үзең уйный да белмисең дип, гарьләндерәсе дә иттеләр, акча белән дә кызыктырдылар. Егет исә һаман да бер балык башын чәйни: истәлек һәм вәссәлам. Ярты сәгатьтән артык сөйләшү берни дә бирмәгәч, Мөстәкыйм соңгы хәйләсен айкап чыгарды. Аныңча, урыс кешесен җиңсә шул хәйлә генә җиңә алачак иде:

— Ярый соң, син уйный тор, туган,— диде ул, полк урнашкан шәһәрчекне уратып алган койманың теге ягына ымлап.— Мин барып бер-ике чалмалыны алып килим булмаса.

Әмма аның бу хәйләсе дә, атылмый калган мылтык сыман, файдасыз булып чыкты.

— Йөрмә, эчмим,— диде егет һәм гармунын күн букчасына салырга әзерләнде.

Шулчак кисәк кенә моңынчы сатулашудан читләшебрәк торган Нәҗип телгә килде.

— Тукта, ашыкма, брат. Бир әле, һич югы бер уйнап карыйм...

Тальянны кулына алгач, гадәтенчә, «Шахта»ны сузып җибәрәсе итте Нәҗип. Ярый әле, вакытында акылына килде. Урыс малаена синең «Шахта»ң ни. Үзләренчә бер көй уйнап күрсәтәсе иде менә. Бармакларын шоп-шома телләр өстендә йөгерткәләп, калынлы-нечкәле авазлар чыгаргалап бераз маташты да, өздереп Байкалны кичкән сукбай турындагы җырның көен сыздырып җибәрде.

Чит-ят көйне чын музыкантларча ук булмаса да, адәмчә яңгыратыйм дип, мавыга торгач, янында кешеләр барын да онытып җибәргән икән. Бервакыт бакса, урыс егетенең кабартма иренле авызы ачылган, күкчәчәкне хәтерләткән күзләре маңгаена менгән. Ул әле көйне тыңлап бетергәннән соң да, байтак кына исенә килә алмый торды. Аннан исә кисәк кенә Нәҗипнең җилкәсенә сугып алды:

— Ә син «Каким ты был»ны беләсеңме?—диде.

Белмәскә ни, ул елларда гади урыс арасында шуннан да тапталып беткән җыр юк та иде бугай. Кыстатмый-нитми генә уйнарга тотынды Нәҗип.

Көйнең ахырына җитәргә дә өлгермәде, егет сикереп диярлек аның муеныннан кочып алды һәм кош тоткандай шатланып кычкырды:

— Булды, җиндең, туган, ал син бу гармунны, ал!

— Ничек инде «ал»?

— Шулай, бушка бирәм мин сиңа тальянны. Ул синеке булырга тиеш! Ә миннән барыбер гармунчы чыкмады инде,—дип уфтанып бетерде ул сүзен.

— Юк, бушка ярамый.—Нәҗип гимнастеркасы кесәсенә тыгылды, аннан бер төргәк акча чыгарды һәм аны көчләп диярлек егетнең учына йомдырды.

Әле уйный башлагач ук сизгән иде Нәҗип: гармун, чыннан да, уйнарлык, тик шактый бушаган. «Бер-бер остага күрсәтәсе булыр»,—дип уйлады ул, үзе яши торган казармага кайткан чакта.

Икенче көнне ул әлеге күпне күргән гармунны парашют ефәге кисәгенә төрде дә, җаен чыгарып, шәһәргә китте. Спасск-Дальний ярыйсы ук зур шәһәр. Мәгәр монда гаскәриләрдән башкалар гел диярлек җирле халык булганлыктан, кайда нәрсә ятканын яхшы беләләр. Гармун төзәтү остасын тиз эзләп тапты егет.

Калининныкына охшаш сыек кәҗә сакаллы, калын пыялалы күзлек кигән карт оста гармунның эчен ачып җибәрде, аның ялтырап торган телләренә бик озак бакты, озын нәзек бармаклары белән аларга баскалап-баскалап карады да:

— Хә-хи-нә!—дип куйды.

— Нәрсә, әллә саф көмешме?—дип сабырсызланды Нәҗип.

— Көмеш?! Нәрсә ул көмеш? Аның ише чүп-чарың ерак торсын моңардан,—дип сөйләнде карт.

Нәҗипнең кызыксынуы чигенә җитте:

— Нәрсә соң? Нәрсә соң алайса?—дия-дия остаханәнең тишеге-тәрәзәсеннән эчкә кереп китә язды хәтта.

— Булат! Ишеткәнең бармы? Чын Шәрекъ булаты, егеткәем. Бу телләр инде, егеткәем, салкыннан карлыкмый, җылыдан гыжламый. Да-а, бу-лат!

Гармунны ошатты карт һәм озын-озакка сузмый карап-көйләп тә бирде. Шуннан бирле инде өченче ел менә шул тальянны суза Нәҗип. Рас, соңгы вакытта айдан артыграк тотмады тотуын. Аның каравы, бүген рәхәтләнеп суза менә. Тиздән, бик тиздән туган Кәминкәсенә кайтып төшәр, беренче кичне үк сугышта югалган Харис абыйсы урынына авыл урамнарын урар. Әнә ич, инде Новосибирскига да якынлашып киләләр.

Новосибирск вокзалы исә аларны халык диңгезе белән каршылады. Олы юллар чатындагы вокзалда халык беркайчан да бетеп тормый анысы. Күр инде, әйтерсең лә, кыямәт көне җиткән дә, бөтен әрвахлар каберләреннән кубарылган—кассалар янына якын килермен димә. «Зыян юк, хәрбиләр өчен махсус касса бар,—дип юатты үзен егет,—анда исә чират зур булмый. Алай да ашыгуың хәерле».

Үзара килешкәч, операциядән соң савыгып җитмәгән Мөстәкыйм әйберләр янында торып торырга булды. Нәҗип исә хәрбиләр кассасына йөгерде.

Ике сәгать чамасы чиратта торуның нәтиҗәсе булмады—якындагы ике көнгә урыннар юк иде. Аптырады-йөдәде дә Мөстәкыйм янына киңәшкә килде. Анысының исә, хәлнең шулайрак икәнен чамалап, үз ниятләрен ниятләп утыруы икән.

— Вокзал начальнигына керәм, вәт шул,—дип кайнап чыкты Мөстәкыйм.— Операциядән соң терелеп җитмәгән совет солдатын тоткарлар-

га не имеют права! Миңа покой кирәк! — Һәм ул, бөгелә төшеп, вак-вак адымнар белән каядыр китеп югалды.

Аннан шактый озак торып һәм ярсып диярлек кайтты Мөстәкыйм, полкташы янына җиткәнче үк кемнәрнедер тозлап-борычлап сүгә башлады:

— Санламаган була... сволочь... ил өчен гомерен бирә язган совет солдаты белән! Тукта, монда хәрби комендант та булырга тиеш,— дип, кабат китәргә талпынды ул.

— Син... ни... кызма, эшне бозып куюың бар, — дип озатып калды аны Нәҗип.

Тегесе исә кемгәдер яный-яный китеп барды. Җәрәхәтен дә онытты бугай, шактый кызу атлый.

Чирек сәгать тә үтмәгәндер, ул тагы килеп җитте һәм вокзалда гөр итеп торган тавышны да басарлык итеп кычкырына башлады:

— Карга күзен карга чукый димени?! Барысы да бер җырны җырлый: урын юк, имеш. Мине төшеп калганнардан, диләр бугай. Комендантның борын төбенә үк төрттем госпиталь кәгазьләрен... Не имеешь право, мин әйтәм...

— Син, якташ, кайнарланмый гына сөйләш алар белән. Эшне бөтенләй чуалтып ташлама, дим.

— Сез нәрсә, сүз берләшкән кебек... Комендант та әйтә әнә: әтәчләнмә, югыйсә кызык итәм мин сиңе, ди. Вокзалда кунарсың, диюдер инде үзенә калса. Тукта, монда бит әле партком да бардыр... Кереп тагы бер якасыннан алам да комендантның...

Мөстәкыйм баягыдан да тузынып китеп барды. Кайларда йөреп беткәндер, озак торып килде. Мәгәр йөзендә елмаю иде.

— Менә бит, сөйләшә белгәч...— дип масайды ул ерактан ук һәм кулындагы билетларын югары күтәреп күрсәтте. — Бүген кич үк китәбез!

Билетларны җентекләп карый-тикшерә башладылар. Аларга насыйп поезд тагы сәгать ярымнан киләсе икән. Вокзалны карап өлгермәсләр өлгерүен, алай да кайнар аш капкалап алырлык вакытлары бар. Шөкер, тәүлекләр буе вокзалда аунамаячаклар!

Тик шөкер итәргә ашыкканнар икән. Үзләре утырырга тиешле бишенче вагонда ниндидер сәер хәлләр барын башта ук чамалады Нәҗип. Ишекне ачуга, йөзенә мунча төтене булып тәмәке исе килеп сыланды. Үзенең һәм якташының чемоданнарын, капчыктагы гармунын текә баскычтан сөйрәп маташканда, кайдадыр якында гына бер марҗаның күкле-яшелле әче тавыш белән чинаганы ишетелде...

Өч ел армиядә, гел ир-ат арасында хезмәт итеп, мондый ук оятсыз такмазаны ишеткәне юк иде Нәҗипнең. Җитмәсә, хатын-кыз такмаклый бит әле. Ул, бите кызышканын тойган хәлдә, өскә күтәрелде, әйберләрен идәнгә куйды да Мөстәкыймгә вагонга менәргә булышты. Шул арада эчтән ниткәндер ят телдә кычкырышулары ишетелде. Әллә соң чит ил кешеләре арасына туры килделәрме? Юк икән, вагонда кайсысыдыр өч-дүрт катлы итеп сүгенде, кайсыларыдыр шөкәтсез хахылдады. Төшенде егет: үзебезнекеләр — болай әшәке итеп дөньяда тик урыс Иван гына сүгенә ала. Чемоданнарын һәм гармунын күтәреп, эчкә үтте. Туктап торгангамы, монда ярыйсы ук караңгы, эңгер-меңгер диярлек. Шул тонык яктылыкта да гаҗәп бер нәрсәне шәйләде Нәҗип: мондагы халык, игезәкләр сыман, барысы да бер төсле. Тукта, нидән бу? Ә, әһә, бөтенесенең дә өстендә сырма һәм сырган чалбар, ачык изүләреннән кешеләр эшләрендә генә кия торган киҗе-мамык пинҗәкләре күренеп тора. Аякларында зур-зур кирза итекләр. Өс-башлары болай чиста булса да, күренә ки, эш киемнәреннән болар! Бер-берен ничектер аңлап, үзара туктаусыз сөйләшәләр, бәхәсләшеп тә китәләр, ыржаеп көлешәләр. Араларында шактый гына кызып алганнары да байтак. Шунда гына башына барып җитте Нәҗипнең: тукта, болар бит зеклар — төрмә каргалары. Ә,

әйе, гәзитләрдән укыган иде шул: бөтен тоткыннарга да амнистия була дип. Димәк ки, шуның нәтиҗәсе болар. Менә кемнәргә бәйрәм, әй, менә кемнәргә шатлык даһи Сталинның үлеме. Мөстәкыймне кызык итәм дигәне шушы мәллә комендантның?! Тач шулай, билетларны юри шушы поездга көйләгән, каһәр.

Ул, әйберләре белән урта юлга якынрак утырган зекларның тез башларына бәрелә-сугыла, алга узды, Мөстәкыйм аның артыннан теркелдәде. Артларында берсеннән-берсе имәнгеч янау-сукранулар ишетелеп калды:

— Да ты осторожней, падлы!

— Син, сука, йодрык тансыклагансың бугай!

Җикеренүләргә игътибар итми генә, эңгер-меңгердә караштыра торгач, билетларында билгеләнгән урыннарны таптылар. Менә шушы бүлмтекнең ике ягындагы урта сәндерәләр аларныкы. Тик аларның сул яктагысына болай да чуен китеге кебек битен кап-кара сакал-мыек баскан такыр башлы берәү яткан, уң яктагысына шулай ук чәчсез кавын башлы әзмәвер туңкайган.

Чемоданнарын һәм гармунны идәнгә куеп, сулу алды Нәҗип, үзенә тиешле урында яткан бәндәнең китек ирененә, нурсыз-чорсыз күзләренә карап алды. Тегесе йокламый иде.

— Сәндерәне бушатырга туры килер, агай-эне!

Китек ирен, гүя, ишетмәде, өченче каттагы сәндерә астындагы оятсыз рәсемгә карап ятуында булды.

— Йә,— дип баштагы сүзләрен кабатлады Нәҗип, шинелен сала-сала. Шул арада борылып каршы якта ятучының иңенә кагылды.— Бу сүз сезгә дә кагыла, дускай, урынны бушатырга туры килер. Минем служак госпитальдән генә югыйсә — аңа тынгылык кирәк.

Әзмәвер, борыла төшеп, башын калкытты. Кыяфәте карап торуга ук ушыңны алырлык булса да, карышмады тагы, акрын кыймылдап, астагы катка төште.

— Бер кадерсез башка кайда да кадер юк инде ул,— дип мыгырданды үзе.

Мөстәкыймнең чемоданын сәндерәсенә күтәреп, полкташына өскә менәргә булышты Нәҗип, якташының шинелен башы астына салып, аны иләп яткырды. Бу кадәресе әйбәт килеп чыкты, әмма Китек ирен яткан җиреннән кузгалырга да уйламый иде.

— Ярар, назланма, агай-эне, күрәсең ич урын безнеке,— дип тегеңә билетын сузды Нәҗип. Ул исә аның билетын йонлач кулы белән этеп кенә җибәрде дә:

— Син, падлы, кем буласың соң әле ул кадәр? — диде.

— Күреп торасың ич, хәрбиләр без — дәүләт кешеләре. Ялга кайтып барышыбыз.

Китек ирен ничектер авыр гыжлап көлеп җибәрде, бастырыкка охшап калган кипкән гәүдәсе калтырап куйды.

— Без дә дәүләт кешеләре анысы. Сездән кадерлерәкләре дә. Синең сыман форма кигән йөзләрчә мельтләр саклап кына тордылар безне. Мужыт син әле үзең дә ынкывыдышниктыр.

— Син ир-ат, хәрби билгеләрне аерасың — авиаторлар без.

— Хезмәт дигәнен Колымада үттек без, иптәш янарал. Синең погоннарың, ялтыравык тәтиләрең бәдрәфкә барырга гына миңа. Ярый, төшәм мин, төшәм. Без үрәнгән халык. Тегендә гел аста, салкында йокларга туры килде миңа. Түбәндәге сәндерәдә дә үлмәбез, алмашлап булса да йоклarбыз. Идәндә черем итүе дә берни түгел безгә. Бушатам мин, бушатам урынны. Менә бу ялтыравыклы чемоданыңнан бер акбашны чыгар да...

— Акбаш юк, ярый, бәхәсләшмик.

Алар шулай тарткалашып торганда, Нәҗипнең колагы төбендә үк көр, яңгыравыклы тавыш ишетелде.

— А ну, бу ниткән тавыш монда, ә сугышучы юк. Ә, гаскәри?! Бергә кайтабыз алайса. Ә син, доходяга, тиз бул, урынны бушат. Аргандыр хәрби кеше, ял итсен, йокласын.

Нәҗип ялт кына борылып, яклаучысына карап алды һәм имәнеп китте. Башы ат башына, тешләре алашаныкына охшаган кып-кызыл битле, төп кебек таза бәндә, аксыл урман корты булып торган ике кашы өстеннән дә бурлат кызыл булып пычак эзе сузылган. Кызыл чырай аңа елмайгандай итте һәм сизелеп торган төчелек белән сөйләвендә булды:

— Хәрби кеше зекларны гына түгел, бөтен ил халкын дошманнардан саклый. Ул арган, аңа ял кирәк. Әй, Чалыш, аракы китер!

Әйтерсең, аның әмерен көтеп кенә торган, җилкәсе артында усал чырае гел сул якка каерылып торган кара мыеклы бер зат күренде, яртысына аракы салынган стакан сузды. Кызыл битле аны алды да, Нәҗипнең борын төбенә сонды:

— Имин отпускалар булсын, сержант.

Сасы ис укшытып җибәрде Нәҗипне. Күз алдына узган ел увольнениегә чыккач булып узган бер вакыйга килеп басты. Алар өч якташ өчесенә бер чәкүшкә аракы алып эчкәннәр иде ул көнне. Хәйран исерештеләр. Өстәвенә, сәгать буе укшып җәфаланды Нәҗип, бармагын авызына тыгып косканнан соң гына адәм рәтенә килгәндәй булды. Шуннан бирле исерткеч дигәнне авызына алганы юк.

— Гафу, мин эчмим,— диде ул тыныч кына.

— Ах, эчмисең?! — Кызыл чырай кискен селтәнеп, аракыны Нәҗипнең битенә чәпәде. Егет ярый әле күзләрен йомып өлгерде. Кесәсеннән кульяулыгын алып, битләрен сөрткәләде. Ә башы очында теге явызның дәһшәтле сүзләре ишетелде:— Биргәнне эчү генә түгел, киләсе тукталышта ук үзең алып менәрсең, падлы. Берне генә түгел, унны! Менә монда акчаң да мул күренә, паскуда.— Ул тимер кыскычтай кулы белән Нәҗипнең гимнастерка кесәсен умырып тотты.— Угу, Уфага кадәр типтерергә җитә монда. Буаз чемоданыңда закускаң да мулдан бугай.

Нәҗип кызмаска, тыныч булырга тырышты:

— Казылык белән ипи бар анысы. Тамагыгыз ач икән...

— Ач булмасак та ашыйбыз аны. Тегендә унөч ел ач яткан өчен ашыйбыз аны, сержант. Ә сиңа наказ шул: тагы сәгать ярымнан зур станца — бер дистә яртың менеп җиткән булсын.

Ул шулай гайрәт орган арада, арттарак тавыш купты. Тәмам исереп җиткән шадра битле бөкерс бәндә бүлемтек алдына бөялгән зекларны этә-этә эчкә ыргылды.

— Кем эчерә?! Кызыл түрәләрнең кызыл итләрен син сыйлыйсың мәллә, фиксатый? Аларны сыйларга түгел, корсакларын пычак белән айкарга да вагоннан томырырга кирәк!

Кыска гына булып алган тынлыкта Мөстәкыймнең тешен шыгырдатканы ишетелде. Нәҗип аның кулын учына алды, мәгънәле итеп кысты. Чыда, дәшмә, янәсе.

— Әтәчләнмә, Шадра! Мин түгел, алар үзләре сыйлаячак безне. Тимә! Бар, тереклек суыңны имеп бетер.

Бу кызыл чырай, чыннан да, вагондагыларның башлыклары бугай, Шадра тынды, ава-түнә вагонның түр ягына китеп барды. Кызык күрергә җыелышкан ачык авызлар кайсы кая таралышты. Шулчак кабат тешләр шыгырдавы ишетелгәч, Нәҗип Мөстәкыйм өстенә иелде:

— Түз, тыныңны чыгарма,— диде ул аңа шыпыртлап,— эшне катлауландырмаска кирәк безгә. Бу адәм имгәкләре үтереп ташларга да күп сорамаслар югыйсә. Түз. Чукынып китсен акчасы. Аракысын да алырбыз — баш кына исән булсын.

Нәҗипкә тиешле урын бушаган иде инде. Ул чемоданын һәм гармунын сәндерәгә күтәрде, шинелен дә шунда ыргытты да аптырап калды. Менә син, әй, очып-канатланып, шатланып-сөенеп кайтып барганда бит. Нишләргә соң әле? Талчыгу да җиткән, тик кая инде монда йокы кайгысы. Башларын

сакларга кирәк аларга, башларын. Тик ничек итеп? Мөстәкыйм чирле, ялгыз башың боларга каршы тору хакында уйлыйсы да юк. Тыныч юл, хәйлә белән хәл итәргә кирәк мәсьәләне. Аракы алып менәргәдер үзләренә. Ярый, алдың да ди. Булганы белән генә бугазлары тыгылырмы соң бу ачәрвахларның?! Тагы сораячаклар бит алар. Янә һәм янә алып та котылырмын димә, Уфага бит әле ике тәүлектән артыграк барасы. Нишләргә соң, нишләргә?

Ул, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына караналанды да тәрәзәгә иелде — поезд Новосибирск вокзалыннан кузгалып маташа иде. Корыч машина рельслар ботакланган чатларда лакыр-локыр килеп тизлеген һаман саен арттыра барды һәм даласы ала-колаланып яткан Себер киңлегенә килеп чыкты. Нәҗип җиңел сулап куйды, мәгәр бу әле аларның эшләре әйбәтләнүне аңлатмый иде. Вагон тулы сәрхуш төрмә ябалаклары арасында кайтулары, зиндан баландасы чөмерә-чөмерә вөҗданнарыннан ваз кичкән бу бәндәләрнең теләсә кайсы минутта килеп, теләсә нинди сәбәп табып бәйләнү мөмкинлекләре һич кенә дә башыннан чыкмады аның. Үзләре әйтмешли, әлеге шешурада һич кенә дә өмет юк: бар кадәр акчаңны каерып алырга да, якыннарыңа дигән бүләкләреңә ия булырга да тартынмас болар. Дөнья малыннан колак кагу белән генә чикләнсәң, бер хәл иде дә. Каршы сукмасаң да сылтау табып, пычак белән эчеңне айкарга, ул гына да түгел, үле гәүдәңне язгы юл өзеклегендә җәйрәп яткан далага ташлап калдырырга да күп сорамас бу адәм актыклары. Нишләргә, ничек котылып калырга бу афәттән?

Уйлап-уйлап та бернинди карарга килә алмагач, артка чикте, ятагына бакты. Әх, бераз черем итеп алсаң иде ул! Юк, ярамый. Әллә ни кыланулары, үзеннән битәр авыру хәлдәге Мөстәкыймне харап итеп ташлаулары бар. Ул кабат тәрәзәгә иелде һәм ай нурында коенып утырган аклы-каралы даланы күзәтә башлады. Әмма башындагы уй өермәсе кимемәде, тәртипкә килмәде — миен әлеге дә баягы үзләренең мөшкеллекләре бораулап тора иде. Әнә шул хәлендә ничә чакрым җир үтелгәндер дә, күпме уйлар ми иләге аша үтмәгәндер — анысын белмәде, тик үзенең эт булып арганын, бөтен тәненең авыртканын гына тойды. Тагы ятагы янына чигенде, урынына менеп аварга дип, ымсынып-ымсынып та куйды. Тик миенең әллә кайсы почмагында гына торган «сакчы» аны бу адымны ясаудан тыеп тора иде.

Ул инде сәгать-минутларны оныткан иде. Бүлемтек уртасында озак басып торганнан соң, үзенә-үзе хисап бирмәстән, сәндерәдәге арып капчыгына үрелде, күнегелгән хәрәкәтләр белән аны ансат кына чиште дә, тальянын алып, астагы катның тәрәзә буена чүмәште. Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, ник һәм нигә икәнен уйлап тормастан, «Шахта»ны сызып җибәрде.

Гармун тавышына янәшәсендә бөкшәнләп яткан Китек ирен торып утырды, чит галәмнән килгән җан иясен күргәндәй, беравык аптыраулы карап торды, аннан бөтен йөзенә елмаю чыкты — кара төк баскан бите нурланып китте хәтта.

— Бәй, туганым, татар икәнсең лә! — дип шәрран ярды бераздан. Аннан инде үзенең арттырып җибәргәнен сизде бугай, ярым шыпыртка күчте.— Ә син туктама, уйна. Уйна гына!

Китек ирендәге үзгәрешкә карап, Нәҗип абайламый калды. Кавын баш та калыккан икән. Ул соскы көрәк кадәр кулы белән егетнең иңбашына орынды:

— Әйтмисең дә, үзебезнең мөселман икәнсең бит, җанаш. Сыздыр әле, сыздыр үзебезнең моңнарны!.. Карале, син мужыт «Сарман»ны да беләсеңдер, ә?!

Нәҗип туктап тормый гына «Шахта»дан «Сарман»га күчте һәм шул мизгелдә ниндидер кысанлык тойгандай булды. Башын күтәреп караса, бөтен тирә-юне такыр башлы зеклар белән тулган, алар хәтта өске

каттагы сәндерәләргә дә менеп атланган, ул гынамы, гармун тартырга кыенлашкан иде.

— Сарман... Сарман...— дип чын артистларча сөйләнде каршысындагы Кавын баш һәм ыргакланып торган кара калын бармаклары белән күз төпләрен сөртеп алды.— Белсәгез, егетләр, һай, сагындырды Сарман! Ышанмасагыз, бер чиләк борчак өчен ун елга йомдырдылар бит, егетләр!— һәм ул, һич оялмыйча, кычкырып елап җибәрде.

— Бер чиләк! Син әле, туганкаем, барга утырасың икән ичмасам,— монысы хатын-кыз тавышы иде. Сүз иясе ике кулының да бармаклары белән генә икенче кат сәндерәгә тотынган да, кыска итеп кыркылган чәченә бер буй ак төшкән башын гармунчыга таба сузган. Күмер кара күзләрендә сагыш, ачы хәсрәт.— Мин соң, мин. Кырга сөт алып барган шешәмә тутырып кайткан бер уч арыш өчен биш ел издем Себер сазын. Үземә дә түгел, көннәр буе ач яткан ике сабыема дип эләктергән идем бит мин аны.— Хатын сулкылдап кырыендагы ирнең җилкәсенә капланды.

— Булды, булды, чәчби,— дип үзеннән этәрде аны зур авызлы, сыник тешле такыр баш,— чәрелдәмә. Ә синең, Кавын баш, ирлек медалең бар түгелме соң?! Аны таккансың икән, үкермә, чыда. Вупшем, гармунның ямен җибәрмәгез диюем. Яле, сержант, сыздыр әле бер безнең «Минзәлә»не!

Ул көй башлаганны да көтмәстән, ярыйсы ук иркен тавыш белән җыр суза башлады:

Барасызмы Минзәләгә...

Шуны гына көткәннәр диярсең, Нәҗип янына бөялгәннәрнең күбесе җырны күтәреп алды. Гармунчы аларның әле берсенә, әле икенчесенә бакты. Әле шушы көннәрдә генә дөньядан китеп, үлеме белән дә халыкны өнсез иткән дәһшәтле зат таләп-әмере буенча күп кышлар һәм күп җәйләр кыргый зоналарда газапланган бәхетсез җаннар, үзләре узган мәхшәр азапларын да онытып, Аллага сәҗдә иткәндәй бирелеп, туган як моңын сузалар иде. Нәҗипнең дә күңеле нечкәреп, йөрәге әллә нишләп китте, ул булдыра алган кадәр тырышып, көйне үзе генә белгән урыннарында боргалап уйнады да уйнады. Иске тальян сайрады, бәгырьнең әллә кай җирләренә үтеп, чәч төпләрен чымырдатты, кимсенгән күңелләрне өзгәләде, әлеге бәхетсез бәндәләрне сулкылдатты, үксетте. Түзмәделәр: «Шул Минзәлә дия-дия, үзәгем өзгәләнә»,— дигәндә, әле берсе, әле икенчесе буыла-шашына елаша башладылар.

Кинәт кайнар табага чиләге белән салкын су капланды, гүя — арттан әлеге Шадраның тупас сүзләре ишетелде:

— Ха, татарва, расплакалась! А-ну, разойдись! Үзегезгә генә дип белдегезме гармунны?! — Ул сытык чырайлы кешеләрне этә-еша алгарак чыкты.— Яле, филон, безнеңчә булдыра аласыңмы?!

Теленә күрә авызына сугасы гына иде дә, төрмәдә сакал агарткан бу кешеләр арасында абруйлы булып күренгән Шадраның күңелен тапмый булмый. Нәҗип «Минзәлә»не бүлеп, бармаклары белән ялтырап торган телләр өстеннән йөгереп үтте һәм әлеге дә баягы Байкал кичкән сукбай турындагы җырның көен чупли башлады. Шадра гәүдә-бәдәненә һич йогышмый торган йомшак-ягымлы тавыш белән җыр башлады:

По диким степьям Забайкалья...

Аңа кемнәрдер кушылды бугай, җыр көчәйде. Бераздан инде бөтен вагон, урысы-татары бер булып, ачынып-әсәрләнеп, сукбай язмышын моң итеп суза иде. Дистәләрчә ирләр һәм аларга ияргән хатыннар бугазыннан дәррәү ургыган җыр тәмам куәтләнеп, вагонга сыешмый башлады. Менә-менә ул түшәмне кубарып атар да, дала иркенә чыгып томырылыр сыман. Мәгәр кичәге тоткыннарның анда эшләре юк,

һәркайсы, өй почмагындагы Гайса сурәте алдында торгандай, онытылып, тәмам мөкиббән булып, үзенчә көйли дә көйли. Тавышы-моңы бармы-юкмы, колагына аю басканмы, анысы белән кызыксынучы юк — һәркайсы үзенчә үкерә, акыра, чиный. Әнә шул кыргый куәттән колагы тонып, байтак утырганнан соң гына искәрде Нәҗип: күрәле, күбесенең кайракланып беткән битләре буйлап гөрләвекләр ага, изүләре чыланып беткән ич боларның.

Тик әнә шул тәңрегә сыгынгандай изге, самими мизгелне юк итәрлек, тау-ташларны ишәрлек булып яңгыраган куәтле хор тавышын җиңәрлек тупаслык-җикеренү дә бар икән дөньяда. Җырны тәмамлап бетермәстән үк ишетелде ул Исрафил сурыннан чыккан аваз:

— Чего раскисли, суки?! А-ну, сөртегез күзләрегезне! Атаклы Себер зеклары түгел, елак барышнялар сез. Сержант, тарт әле «Барыня»ны!

Нәҗип аккорд алганчы ук, Кызыл чырай җиңел һәм килешле итеп тар аралыкта тыпырдый иде инде. Шөкәтсез хәрәкәтләр белән аңа Шадра кушылды, шул тирәдәге башкалары баскан урыннарында селкенгәләргә тотындылар. Бераздан инде бөтен вагон тыпырдый, дөберди, кыргый авазлар белән шашына иде.

Тәмам талчыгып, тальянын кысты Нәҗип — шашыну акрынлап басылды. Сулулары капкан бәндәләр мышнашып торган арада, алар өстендә стаканлы өч-дүрт кул берьюлы күренде:

— Яшә, браток! Мәле, синең исәнлек хөрмәтенә.

— Цыц! Сержант эчми,— дип җикерде аларга Кызыл чырай. Стаканнар юкка чыкты, ристаннар башлыгы исә Нәҗипкә «Ермак»ны уйнарга кушты.

Ул инде тәмам арыган, манма суга төшкән иде. Әмма берни эшләр хәлең юк, «Ермак»ны да уйнады, «Подгорная»сын да сызды, урысларның частушкаларын да сиптерде, «Әпипә»гә дә күчте. Ниһаять, бармаклары бөтенләй йөрмәс булды. Нәҗип тальянын шапылдатып япты да, аның күреге өстенә башын салды:

— Булды, егетләр, баста!

Башка бүлемтекнекеләр телләр-теләмәс кенә таралдылар. Китек ирен белән Кавын баш исә, итагатьле аталар сыман, Нәҗипне кайгырта башладылар:

— Син ят әле, якташ, йокла.

— Йоклыйсы иде дә...

— Бу адәм тәганәләреннән шикләнәсең мәллә? Ике дә уйлама, ят. Калганы безнең эш.

Аларның киңәшләрен тыңлап ятуын ятты Нәҗип, тик йоклап китә алмады. Менә тегеләрнең берәрсе килер дә, бер-бер кабахәтлек эшләп ташлар төсле тоелды аңа. Алай да йокы ястык сорамый шул — калгып киткән. Оеп-онытылып күпме яткандыр, сискәнеп күзләрен ачты — тоткынлыктан котылган якташлары, әмир төрбәсе янындагы каравыл сыман, янында уяу басып торалар иде. Ул тагы изрәп китте, янә күзләрен ачты. Тегеләр каккан казыктай һаман да аның сәндерәсе янында. Тәмам изелеп, иртәнге якта гына тирән йокыга чумган икән.

Иртән уянуына, башлап гимнастеркасы кесәсен капшады Нәҗип. Шөкер, акчасы урынында. Стена буендагы чемоданына да, башы очындагы гармунына да берни булмаган. Полкташы Мөстәкыйм исә тыныч кына пуфылдап ятуында.

Идәнгә төшеп басуына шаккатты Нәҗип: бүлемтекнең бәләкәй генә табыны төрледән-төрле нигъмәт белән тулы: сыр-казылык дисеңме, пешкән йомырка-май, кызыл балык-уылдык дисеңме — бар да бар, консервалары гына да дистәгә якын. Шулар арасында уч-уч сигарет, затлы папирослар да күргәч, егет ихтыярсыз елмаеп куйды. Бүлемтеккә әледәнәле зеклар кереп-чыгып тора, телләре исә башкала рестораннарындагы официантларныкыннан ким түгел:

— Юынып кына ал да, аша әле син, сержант, аша! Аннан инде безнең каткан күңелләрне йомшартып алырсың.

Урыс әйтә: гөмбә дип аталгансың икән, тырыска кер, ди. Ялындырмады, уйнады Нәҗип. Еллар буе салкын баракларда туңып, төрмәчеләрнең сүгенүләреннән йөрәкләренә таш каткан бәхетсез кешеләр тамаклары карлыкканчы җырладылар, йөрәкләре басылганчы биеделәр, күзләрендә яшьләре беткәнче еладылар. Көн яктысында гына абайлады Нәҗип: әлеге туң кешеләр башта күргәндәге сыман игезәкләр кебек түгелләр икән. Баксаң, аларның һәркайсы үзенчә сагышлана, үзенчә сагына, үзенчә сыкрый-сулкылдый, үзенчә елый белә икән.

Бу гадәттән тыш концерт Уфага кадәр дәвам итте. Монда инде Нәҗип белән Мөстәкыйм Казан поездына күчеп утырырга, ягъни көтеп алынмаган юлдашлары белән хушлашырга тиешләр. Ярый соң, хәерле булсын.

Вагоннан төшкәндә зеклар Нәҗипнең әйберләрен кулына да тидермәделәр, Мөстәкыймне исә вокзалга күтәреп кертеп куйдылар. Бу бәхетсезләр белән инде гомерлеккә аерылышабыз дигәндә, Нәҗип башына янә бәла төште — ирексездән юлдашларының һәркайсы аны кочаклый, кыса, изә башлады. Инде муеннары авыртып, буылып бетте, тизрәк качасы килде. Бакса, калганнары аның белән саубуллашу өчен чират торалар, имеш. Кыскасы, Нәҗипне тәмам исенгерәп беткәнче кыса-коча, аркасыннан чәбәкли-чәбәкли хушлаштылар алар. Авыр эштән тупасланып беткән куәтле кулларында сытылып-изелеп бетсә дә, бу хәлгә күңеле булды егетнең. Зекларның болай кылanулары аны яратканнан түгел түгелен. Алай да тальянга, моңга мөкиббәнлекләрен расладың ич алар!..

Әйе, ташны эретте тальян ул чакта, бичара тоткыннарның цемент тузаныннан каткан күңелләрен җебетте. Гармун шул ул, гармун!

ПУБЛИЦИСТИКА

## Ибраһим Салахов

# ХӘСРӘТ ТӨЕНЧЕКЛӘРЕ

**Язучы Ибраһим ага Салаховның бай архивы белән танышкан вакытта мин аның үз тормышына карата күп кенә истәлекләрен, язмаларын очраттым. Арада «Хәсрәт төенчекләре» дигәне аеруча кызыксыну уятты. Биредә, кешеләр тормышындагы фаҗигале хәлләр белән бергә, казакъ иленең кызыклы гореф-гадәтләре, йолалары турында кайбер мәгълүматлар да бирелә.**

**Татар әдипләренең күбесе, мәгълүм сүзләр белән әйтсәк, «тормыш төбеннән күтәрелгән» кешеләр. Тарихыбызның, язмышларның ачылыгы хәтта әдәбиятта исем яулаган язучылар биографиясендә дә үзенчә бер чагылыш таба. Толстой, Тургенев кебек урыс классиклары янәшәсендә Ибраһим ага Салаховның истәлекләрендә, бәлки, тормыш-көнкүреш вә абзар-түтәл тирәсендәге ваклыклар да җитәрлектер...**



*Танылган әдип Ибраһим Салахов (уртада — күзлекле һәм таяклы) үзенең якын дуслары белән. Уңнан сулга: Казагыстанның Алматы шәһәрендәге аксакаллар оешмасы рәистәше Ибраһим Хисаметдинов (җәлилче Рушад Хисаметдиновның бертуганы), Татарстан аксакаллар шурасы рәисе, Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе Рәфигулла Хәмидулла, күренекле мәгърифәтче-галим Габделгалләм Рәшидинең оныгы, мәгариф ветераны Арнольд Кәбиров (Казан, 1994, 8 июнь).*

Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотосы

**Ләкин, фаҗигале хәлләр кичереп тә, үзенең зурлыгын, күңел һәм каләм көчен югалтмаган әдип язмышына битараф калу мөмкин түгел. Бу язмалар, Ибраһим аганың тормыш юлына кагылышлы сәбәпле, аны укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдык.**

**Ләйлә ӘХМӘДИЕВА,**
педагогия университеты
укытучысы.

* * *

— Әби, әби! — дия-дия ишектән атылып-бәрелеп оныгыбыз Әхәт килеп керде. Үзе кызарган, мышнаган, күрәсең әллә кайдан йөгереп килгән,— әби, сөенче!

— Бәй, нәрсә таптың? — Мәһинур өйнең түр бүлмәсендәге диванда биш энә белән оекбаш бәйләп утыра иде. Оныгының болай ярсып кычкыруына гаҗәпләнеп башын күтәрде дә елмайды.— Алайса улҗаң уртак.

— Юк ла, бер әйбер дә тапмадым. Әнә, абыйлар Сөтлебикәне алып китәргә килгәннәр.

— Ә-ә?! — Мәһинурның оекбашы кулыннан төште китте. Итәгендәге ак йон йомгак идәнгә тәгәрәде.— Килделәр?!..

Мәһинурның йөзе кинәт ап-ак булып китте. Калтыранды. Аннары, нәрсәгәдер тотынырга теләгәндәй кулларын алга сузды да, авып китте. Корыч-ялтыр энәләр диванга кадалдылар...

* * *

Төрмәдән котылгач, ике елга якын эш таба алмыйча — дөресрәге, беркайда да эшкә алмаулары сәбәпле — аптырап йөрдем. Бу елларда мин Күкчәтауда эти белән бергә балта чабып өй дә салдык. Әмма тимер протез сынды. Аяктан кан саркыды, җәрәхәт һаман чиләнә барды.

1949 елның август аенда мине, ниһаять, Күкчәтау районы, Кызылъяр авыл сельпосы ашханәсендәге буфетка сатучы итеп алырга булдылар. (Анда да бер танышның булышлыгы белән.) Бу авыл Күкчәтау каласының төн ягында — күл артында. Ерак түгел, 7—8 чакырымда гына. Бала чакта, Сафа җизнинең уллары белән бу якка җәен еш килә идек. Башта җиләк-җимеш җыярга: карлыган, шомырт, җир җиләге, кура җиләге, ә аннан олылар белән печән чабарга. Ул елларда бу як дулкынланып торган көмеш дингез — билдән кылганлык иде. Чагалы елгасы ярлары шау чәчәктә. Әйтерсең лә, кар яуган. Хуш ис борынны кытыклый, рәхәт исертә. Кояшлы иртәләрдә елга өстендә чалт-чолт иткән тавышлар ишетелә. Бу — чуртаннар уены. Алар симезлектән ярсый-шаяралар, су эченнән сикереп биек күтәреләләр дә, ярты ай булып ялтырап, чулт итеп яңадан суга чумалар. Тургайлар, сыерчыклар, башка кошлар чут-чут сайрый. Кәккүкләр моңая... Бу күренешләр хәзер инде әкият.

Утызынчы елларда бу тирәдә колхоз утары корыла. Әйләнә-тирәне сөреп иген игәләр. Ул вакытта, Күкчәтау әле район үзәге була. Сугыштан соң, Күкчәтау өлкәсе оештырылгач, район үзәген монда — колхоз утарына күчерәләр. Шуннан соң бу тирәне чын-чынлап «үзләштерү» башлана. Колхоз елларында хәлле крестьяннарның бушап калган өйләрен, тирә-яктагы барлык авыллардан алып монда, яңа район үзәгенә күчереп салалар. Кайсылары — түрәләргә торак, кайсылары — мәхкәмә. Авылга Кызылъяр дип исем дә кушалар, гәрчә бу якын-тирәдә андый шөһрәт казанырлык тикә Кызыл ярлар күренмәсә дә.

Бу яңа район үзәгенең үзенә генә хас бер хасияте дә бар. Бу — комендатура. Сугыш елларында бу якларга немец, поляк, ингуш, чечен, калмык, кореялы куып китерелә һәм тирә-яктагы авылларга таратыла. Ләкин аларның качып китү

ихтималлары да бар бит әле, чөнки алар да аяклы җаннар. Менә шундый бәла-казадан саклану чарасы комендатурага тапшырыла — тулы взвод, коралланган НКВД хезмәткәрләренә!

1947 елдан соң бу комендатурага эш тагын өстәлә. Ун ел буе төрмә, лагерьларда газапланып та, ни сәбәптәндер үлмичә калып азат ителгән «халык дошманнарын» да монда җибәрә башлыйлар.

Ингуш-чеченнәр килеп чыкканчы мондагы җирле халыкның «саман» дип аталган, балчык-саламнан коелган дәү кирпечләрне ишеткәннәре дә юк иде. Менә шул тау халыклары далага килделәр дә, саман кирпечләр сугып, өй корып тора башладылар. Мондый аяк астындагы материалдан өй салу безнең ише гидайларга дә ошады. Чүлмәкчедән күрмәкче дип мондагылар да салам суга башладылар. Бу яңалыктан НКВД башлыклары да читтә калмады. «Җир ауганнар»дан[1] бушка саман суктырып, тиз арада үзләренә зур гына мәхкәмә (билгеле, КПЗ — изоляторны да онытмыйча) салдырдылар: озынга сузылган, ярыйсы ук биек, исәпсез күп бүлмә-кабинетлардан торган корылма. Һәр бүлмәдә чия кызыл төстәге гимнастерка, китель кигән, бик эшлекле кыяфәтле дәүләт иминлеген саклаучылар утыра. Эш монда хәттин ашкан, өлгер генә! Һәр иртә бу сарай алдына райондагы барлык «җир ауганнар» җыела. Алар әле үзләренең бу ирекле төрмәдән качып китмәүләрен һәм әле үләргә дә өлгермәүләрен исбатлап, комендатурадагы «Гамәл дәфтәре»енә «тамга» салырга тиешләр. Менә шундый хикмәтле җиргә, аллага тапшырып, (ялган паспорт, ялган хезмәт кенәгәсе белән) мин дә килеп чыктым.

Ничек әле мин бу бәхеткә ирештем соң! Хикмәт шунда ки, бу ашханәнең буфетындагы бер генә буфетчы да 5—6 айдан артык эшләми, растрата ясап, судланып төрмәгә китә икән. Шулай булгач, мондый хәтәр эшкә алынырга атлыгып торучылар күренми. Ә минем хәл «аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума» мисалындарак.

— Беткән баш беткән, алты ай булса да эштә булган булып калыйм,— дидем дә...

Ул вакытта Күкчәтаудан Кызылъярга хәзерге кебек автобуслар йөреп тормый иде. Тик анда-санда йөк машинасы гына күренә. Билет бәясе — 5 сум. Әмма миңа ул хәтле акча кайдан килсен, эшсез йөргәч?! Сафа җизниләрдән «уфалла» арбасын сорап алдык та, алты айлык Шамилне, урын-җирне шунда төяп, Мәһинур белән икәү парлашып тартып киттек. Яңа тормышка!

Әүвәле, ташландык бер өйгә барып кердек. Аннан соң, суыклар башлангач, (бездә утын-мазар юк), бер казакъка фатирга күчтек.

— Карале, Ибраһим,— диде җәмәгатем Мәһинур бер көнне, карлар эри башлагач.— Әйдә үзебезгә бер өй өеп керик. Кеше бусагасы туңдырды, без кемнән ким!

— Анысын шулаен шулай да, мин бит саман суга алмыйм сыңар аяк белән.

— И-и, исең киткән икән, казырсың, салам китерерсең. Мин авыл кызы, саманын күрмәсәм дә сабанын күргән!

Шулай итеп, бер дә уйламаганда, үзебезгә куыш төзү эшенә керештек. Әүвәле бисмилла: авыл Советыннан, ашханәгә якын бер буш урынны сорап алып, эштән кайткан араларда зур тагарак рәвешендә җир казыдым, кызыл балчыкка җиткәнче. Күрше казакъ салам бирде. Мәһинур Чагалыдан көянтәләп су ташыды да, ялан тәпи чокырга төште — саман басарга. Чеченнәрдән кинәш һәм калып алдык. Китте бит эш! Озакламый чокыр тирәсенә әрдәнә-әрдәнә саман кирпечләр өелде. Кояшта шыкырдап киптеләр.

— Инде безгә өмә җыярга вакыт,— диде дә Мәһинур, мич башына бер мичкә бал утыртты. (Ул елларны халык йорт-җирне шулай сый куеп, өмә җыеп, күмәкләп кора иде.) Мин ашханәдән ит-май юнәлттем. Ул арада мич башындагы бал да «егетләнеп» җырлый башлады.

Бер көнне тирә-күршене өмәгә чакырдык. Рәхмәт яугырлары — килделәр дә, өйделәр дә бер көн эчендә! Тәрәзә, ишек, башка агач эшләрен эти килеп башкарды. (Идән, түшәм — балчыктан гына. Такта кайдан аласың!) Менә шулай өйле булдык. Тамаша!

Бер көнне кичкырын буфеттан кайтсам, Мәһинур мине капка алдында көтеп тора. Куркып киттем, хәвеф-хәтәр бармы әллә, дип. Ләкин, йөзе якты. Туктадым — ни әйтер?

— Ибраһим, кара әле, мин бит сыер алдым.

— Нинди сыер! Саташасыңмы әллә!

---

[1] Җир ауган — үз җиреннән сөрелгән, хокуксыз халык. (Казакъ әйтеменнән.)

— Нинди саташу. Ышанмасаң күрсәтәм әйдә!
Капканы үтсәм — бозау күшәп тора.
— Бу бит тана бозау. Кыш чыкса, качып китә. Алдагы елда бозаулар да, алла язса.
— Анысы алай да... Ә менә бу бозауны сатып алырлык акча кайдан таптың?
— Башымдагы дебет шәлемне саттым. Сөт-катыксыз балага читен бит. Үзебезгә дә.

* * *

Әле мин төрмәдә вакытта ук Маһинур иреннән аерылган булган. (Сәбәбен әле дә белмим.) Ирендә өч улы калган: Өлфәт, Нигъмәт, Әхәт. Аларның әтиләре Күкчәтауның потребсоюз өлкә базасында склад мөдире булып эшли. Безнең өлкәгә килә торган барлык кызыл мал, азык-төлек аның кулыннан уза. Шулай булгач, аның тормышын һәм минем көнкүрешне чамалап була торгандыр дип уйлыйм.

Андый мул тормышны ташлап балалар миңа килмәсләр дип, тынычланып тора идем...

Шулай көзнең кар аралаш яңгыр яуган шыксыз бер кичендә катып-туңып (култык таякларында йөргәнгә, куллар туңса да кесәләргә яшереп булмый иде) эштән кайтсам — сәке өстендә 11—12 яшьлек малай утыра.

— Бу минем өлкән улым Өлфәт,— диде Маһинур уңайсызланып. Аннары улына эндәште: — Тор, абыеңа кулыңны бир. Исәнләш!

Малай сикереп торып кулын сузды, үзе түбән карый. Менә шулай Өлфәт белән таныштык. Әнисен сагынып кына килгәндер, ике-өч көн торыр да китәр, бал-майдан аерылып хәерче өйдә калмас, дип уйлаган идем — ялгышканмын икән.

Өлфәт икенче-өченче көннәрдә дә өйләренә кузгалмады, хәтта безнең мәктәпкә укырга да йөри башлады. Аның артыннан, озакламый кече малай Әхәт тә килеп җитте. Күрәсең, үги ананың бал-маеннан туган ананың каты-котысы тәмлерәк! Тик уртанчылары Нигъмәт кенә күчмәде, килеп-китеп кенә йөрде. Ул арада безнең өстәлдә дә сөт, катык, эремчек күренә башлады. Теге кызыл бозау сыер булган, сөбханалла, күз тимәсен! Менә бит, ыгы-зыгы белән бер ел гомер узып та киткән...

«Бәла-каза килсә, капкаңны каерып ач, ул ялгыз йөрми»,— ди урыс мәкале. Анда хакыйкать тә бар икән шул. Һич уйламаганда, аяз көнне яшен суккандай, безнең йортка да бер генә түгел, ике генә дә түгел, ә бер-бер артлы өч фаҗига атылып керде.

Өлфәт бик итагатьле, тырыш, зиһенле, укуга бик хирес малай булып үсте. Бигрәк тә рәсемгә, фотографиягә кабилият күрсәтте. Мәктәпнең стена газетасындагы рәсемнәрне, карикатураларны ул үзе ясый, фоторәсемнәр төшереп бирә. Бәйрәмнәр алдыннан төн йокламый плакатлар, лозунглар яза. (Дөрес, төн буенча өй эчендәге мунча-бүлмәдә кыштыр-кыштыр килеп йокларга комачаулый. Әмма мин ачуланмыйм, эшләсен, бәлкем ул киләчәктә данлы рәссам булып балкыр. Иншалла!)

Сигез еллык мәктәпне тәмамлагач, ул Күкчәтауга барып өч айлык киномеханиклар курсында укыды да, үзебезнең район клубы каршында эшли башлады. Кино күрсәтә — тирә-яктагы авылларга да чыгып йөри. Билгеле, ат белән. Шуның өчен бер китсә, атналар буе күренми.

Озакламый аңа армия хезмәтенә китәр вакыт җитте. Ул Мәскәүдә, Кремль гарнизонында хезмәт итте. Санаулы көн тиз уза, диләр, ике елга сузылган хәрби хезмәт срогы безгә сизелмичә дә калды шикелле. Бер көнне җыелышып иртәнге чәйне эчеп утырганда, кинәт ишек ачылып китте дә, өйгә озын буйлы, таза-атлет гәүдәле яшь солдат килеп керде, елмайды.

— Өл-фәт! — диде Маһинур, кулындагы чинаягын төшереп җибәреп,— улым!

Ул вакытта безнең өйдә Рәхимә исемле мөгаллимә кыз тора иде. Беренче сөенү шау-шуы тынгач, Маһинур аларны бер-берсе белән таныштырды:

— Бу, минем улым, Өлфәт. Ә бу кыз — мөгаллимә. Безнең мәктәптә укыта. Исеме — Рәхимә. Ул әле Шамилгә дәресләр әзерләргә дә булыша.

Алар бераз ятсынып-оялып кына кул бирештеләр.

Сөенеч! Бәйрәм! Тирә-күрше җыелды. Күкчәтаудан туган-тумача килде. Көтмәгәндә өйдә шау-гөр. Уен-көлке. Гармун моңнары.

Өлфәт тагын элекке эшенә — район культура йортына киномеханик булып урнашты. Элеккечә тирә-яктагы авылларга йөреп кино күрсәтә, атналар буе өйгә

кайтмый. Ә өйдә мин, Маһинур, Рәхимә, Шамил, әле генә дөньяга килгән Камил калабыз.

Рәхимә, чыннан да, һәр кичне, үзенең дә эшләре күп булуга карамастан, бик теләп Шамилгә булыша — яздыра, укыта, кайчакта әкиятләр дә сөйли. Ул арада өй эшләренә булышырга да өлгерә, җитез. Рәхимә якты чырайлы, йөзендә иман нуры бар, елмаеп кына сөйләшә. Урыс мәктәпләрен тәмамлап, урыс мәктәпләрендә укытуына карамастан, Рәхимә өйдә бары тик татар телендә генә сөйләшә. (Аның әтисе мулла, Күкчәтауда тора.) Менә шул сыйфатлары белән бу яшь мөгаллимә барыбызга да ошады, бигрәк тә Шамилгә. Улыбыз аңа бик тиз ияләште, «апа-апа» дип аның яныннан китми. Рәхимә дә аңа «улым» дип, иркәләп эндәшә. Шамил үзе дә инде зур үсте — икенче сыйныфта укый.

Командировкалардан кайткан араларда Өлфәт Рәхимәне кинога чакырды. Алар бергә клубка барып кино, спектакль карыйлар.

Менә әле былтыр ук, үземә язу-сызу өчен, аулаграк булыр дип, саман сугып, төп йортка тагын бер өчпочмак кушкан идем. Теге елны минем белән бергәләп кушылып (икәү булгач җиңелрәк) өй салган Исмәгыйль Байбулов, бик ашыгыч рәвештә авыру атасы янына Башкортстанга күчеп китәсе булды да, үз яртысын — бер бүлмәне — миңа сатты. Шулай итеп, минем йорт озынга сузылып, өч бүлмә рәвешен алды. Маһинур, мин, Камил, Шамил минем кабинетта, Рәхимә — урта бүлмәдә. Ул төн буе дәресләр карый. Әзерләнә. Өлфәт — алдагы аш бүлмәсендә. Ул клубтан бик соң кайта. Үзе шунда плитәдә чәй кайнатып, калган аш булса, җылытып ашый-эчә. Аннан таңга хәтле китап укый.

— Төн пәрие төсле утырасың, керосин әрәм итеп! — дип кайчакта Маһинур сукранып та ала.

— Әни, китап укымасам, йоклый алмыйм бит,— ди улы елмаеп. Маһинур кулын селти.

* * *

Әй гомер, әйтерсең агымсу — сизми дә каласың! Менә, Өлфәтнең армиядән кайтуына да икенче ел киткән. Шулай бер кичне бергәләп чәй эчеп утырганда Өлфәт нигәдер каушап, түбән карап кына сүз башлады.

— Әни... абый (ул миңа «абый» дип дәшә иде) без...— диде дә тотлыгып калды.— Кызарды. Маһинур авызына китереп җиткергән чинаяк тәлинкәсен кире өстәлгә куеп, улына аптырап карады:

— Нәрсә «без»... Сузма, әйтәсе сүзең булса әйт тә сал.

Өлфәт башын күтәрмичә генә сүзен ялгады:

— Без Рәхимә белән өйләнешергә булдык.

— Бәй! — Маһинур көлеп җибәрде.— Бик әйбәт, туй уйнарбыз, алла язса. Мин киленле булырмын. Әллә кайчан өметләнеп йөри идем. Үзебезнең кеше, марҗа түгел.

Менә, бер дә көтмәгәндә сөенеч! Туйга әзерләнә башладык. Әүвәле, ул елларның гореф-гәдәтенә муафыйк итеп, мич башына зур гына мичкә кунаклаттык — бал! Ул бит, айга якын утырып кына «егетләнә». Мин, бурычка кереп булса да, күрше казакъ Балтабайдан, бер «май койрык» куй сатып алдым. Туй булгач, берәгәйле булсын инде, безнең йортта беренче туй бит әле!

«Туйның булганыннан, була дигәне кызык»! — ди казакъ халкы. Без дә шул «була» шаукымы белән рәхәт исереп, арлы-бирле ташланабыз. Туйның нинди мәшәкать булуы барчабызга да мәгълүм. Аны шәрехләп торасы юктыр, шәт. Ул куаныч кеше гомерендә бер генә тапкыр була бит. Мәңгелек хатирә!

Шулай, сөенеп туйга хәзерләнеп йөргән көннәрнең берсендә, Өлфәт эштән бик күңелсез, кара көеп кайтты.

— Нәрсә, улым, әллә авырып киттеңме, төсең калмаган! — дип Маһинур сыер саварга чыгып барган җиреннән туктап, чиләген сәке өстенә куеп, куркып-аптырап карады:— Әллә эшеңдә бер-бер күңелсез хәл булдымы?

Өлфәт җавап бирмичә, өс-киемне дә салмыйча, сәкегә барып капланып ятты.

— Әйт инде, ни кырылды! Балтаң суга төшкәндәй кыланасың.

— Рәхимә отказ бирде!

— Ничек! — Маһинур кычкырып җибәрде. Мин дә ни әйтергә белмичә аптырап калдым. Өлфәт ышаныр-ышанмас кенә өстәп куйды:— Сиңа... чыкмыйм, ди.

— Менә мә! Мәсхәрә бит! — Чиләк шалтырап тәгәрәп китте. Маһинур улы янына барып, аны тарткалый башлады.— Йә, тор! Әйбәтләп сөйлә әле! Нәрсә, әллә туйны соңарта торыйк, диме? Без бит аңа инде әзерләнеп беттек,— тавышы

жыламсырый башлады.— И ходаем, кеше күзенә күренерлегебез калмады бит, раббым.

Әйтеп тә бетермәде, үксеп елый башлады.

Бер атна вакыт үтте, Рәхимә, чыннан да, күренми. Өлфәт күзгә карап шиңә. Агарынды. Ябыкты. Ашаудан, сөйләшүдән калды.

— ... И, исең киткән икән, Рәхимә булмаса Рәхилә булыр. Күкчәтауда кыз беткәнме! Бетермә үзеңне, юк өчен,— дип, Маһинур улын юатырга, уен таратырга да тырышып карый, ә егет кулын гына селти.

— Юк, әни! Мин аны гына яратам.

Ә Рәхимә юк та юк, теләсәң нишлә! Күргән кешеләр «мәктәпкә килеп, укытып йөри», диләр. Ә мәнә безнең өйгә нигәдер борылмый.

Мәнә сиңа аяк астыннан кысыр хәсрәт. Маһинур әйтмешли, урамга чыгар хәл юк, очраган берсе:

— Йә, агай, туй кайчан?— дип җәрәхәткә тоз сала.

Шулай бер кичне тавыш-тынсыз, күңелсез генә чәй эчеп утыра идек. Ишек ачылды. Мин башымны күтәрергә өлгермәдем, Шамил улым кычкырып җибәрде:

— А, апа!

Рәхимә кайткан!

— Инде калага бармыйм, сездә калам,— ди.

Тагын туйга әзерләнә башладык. Табак-савыт, өстәл, урындык, ашъяулык һ. б. кирәк-яракны күршеләрдән җыярга тотындык. Кичләрен җыелышып утырып — Маһинур, Өлфәт, Рәхимә, мин — туйга чакырыласы кунакларның исемлеген төзибез. Бу да бик четерекле эш — Рәхимәнең туган-тумачаларын, дусларын, үзебезнең як туганнарны, Өлфәтнең дусларын онытып калдырмаска кирәк. Өебез озын барак дисәк тә, ул да әле исәпсез кунакларны сыйдырырлык түгел. Сые да, хөрмәте дә булсын. Кунакны чакырып та утыртырга урының булмаса, оятыңнан җир тишегенә кереп китәрсең. Шулай булгач, исемлеккә дә бик илә кенә, иң-иң кирәкле кешеләрне генә язарга туры килә. Мәнә шуның өчен исемлекне кабат-кабат барлап, сызып-өстәп чыгабыз. Баш каткан, берәүне дә үпкәләтәсе килми.

Инде мич өстендәге мичкә дә җанланып чебер-чебер килә, гайрәт җыя. Туйны Рәхимәнең тәкъдиме белән, аның туган көненә — 10 февральгә билгеләдек. Атаанасына да сөенеч. Өлфәт тә хәстәрен күрә. Ул берара район газетасы типографиясендә печатник булып эшләгән иде, шундагы дуслары белән килешеп, туйга чакыру билетларын да бастырып алган. Әйбәт булсын: дус бар, дошман бар, дигәндәй.

Сафура бураннары белән февраль башланды. Туйга да инде барлы-юклы бер атна гына вакыт калып бара. Ашыгырга кирәк!

Ул фаҗигале кичне иртәдән үк күз ачкысыз буран күтәрелде. Ашханәдән — эштән кочкә кайтып егылдым. Җитмәсә, җил каршы яктан булды. Мин култык таякларын алга салыйм дисәм, җил артка атып бәрә. Кул-бит өши язды, мең газап.

Өйдә ниндидер авыр тынлык. Берәү дә сөйләшми. Маһинур оекбаш бәйләп утыра. Рәхимә белән Өлфәт кара-каршы, түбән карап утыралар, берсе караваты өстенә иелгән, икенчесе өстәл кырыендагы урындыкта. Эчем жу итеп китте. Өшеткән кулларымнан култык таякларын ташламас борын Маһинурга эндәштем. Шаяргандай булып, хәлне белер өчен:

— Нәрсә, туй алдыннан барыгызның дә сөмсерегез коелган?

— Туй сиңа! — Маһинур ачы тавыш белән кычкырып җибәрде дә, кулындагы бәйләп утырган оекбашын идәнгә атып бәрде. Энәләр төрлесе төрле якка чәчрәделәр.— Әнә, Рәхимә тагын чыгымлый, Өлфәткә чыкмыйм, ди.

Шып итеп сәкегә утырдым. Култык таякларым шалтырап идәнгә ауды. Ни әйтергә дә белмим. Башым зырылдап әйләнә башлады.

Мәнә шушы төнне, аш өендә Өлфәт улыбыз асылынып үлде...

* * *

Ак көннәр дә, кара көннәр дә туктамыйлар — берсе артыннан берсе агыла. Гомер уза.

Мәнә инде, аз булса да Өлфәтнең хәсрәтен суындырып, уртанчы улыбыз, Нигъмәт үсеп җитте — армиягә барып, Владивостокта хезмәт итеп кайтты һәм бик чибәр, укыган, җырчы Рәшидә исемле кызга өйләнде. Озакламый беренче сабый — уллары дөньяга килде.

— Өлфәтемнең исеме җирдә калып черемәсен, оныгымның исемен Өлфәт кушыгыз,— диде Маһинур күз яшьләрен йотып. Мин тәһарәтләнеп, азан әйтеп, сабыйга исем куштым.

— Исеме шәрифең Өлфәт булсын, аллаһ әкбәр!

Нигъмәт — шофер. Ул әтисе эшләгән товар базасында, Күкчәтау өлкәсенең барлык диярлек район кооперативларына товар ташый. Хезмәт хакы исә тонна-километрдан. Димәк, төягән йөк никадәр авыр, юл никадәр ераграк булса — түләү, эш хакы да күбрәк. Нигъмәт дөнья куарга хәвәс булып чыкты. Йокы, ял дигәнне белми — мал артыннан чаба. Өйләнүенең икенче елында ук шәһәр уртасыннан өй сатып алды, ике бүлмәле. Йорт — квартал почмагында, кояшка каршы. Җире — киң.

— Бу өйне җире өчен алдым. Киләсе елда моны бозып зур өй салам, 4—5 бүлмәле. Аннан мунча, гараж салам да, машина алам.

— Алла боерса диген, улым,— ди Маһинур. Куанып, улының аркасыннан кагып.— Утыр, чәй эч, хәзер коймак коям.

— Юк, әни, иртәрәк барып җитәргә кирәк. Кызылтауга барам. 500 километр бит. Сине күрергә генә кердем,— Нигъмәт чыга-барып бусагада туктый, әнисенә карап елмая.— Ә бит машинаны әни, алла бирми, әтидән алам, акчага.

— Кит чукынган, әльгаязи билләһи, диген.

Ә Нигъмәттән инде җилләр искән. Урамда, өй каршында мотор гөрелде. Кузгалды. Сигнал. Әнисе тәрәзәдән карап, эченнән белгән догаларын укый: «Йа хода, улымны бәла-казалардан сакла, илаһи амин!»

Менә шулай итеп, безнең Нигъмәт ару-талусыз дөнья куа. Өенә җиһазлар да алды. Инде үзе әйткәннәргә ирешә. Куанып туя алмыйбыз. Улы Өлфәт тә өченче яшь белән бара. Әтисе кебек бик тере, әйтерсең лә терекөмеш! Һичбер урында утыра алмый: йөгерә, сикерә, егыла. Еламый. Кирәк булса «Әтәч менгән киртәгә»не сөйли, теле телгә йокмый.

Ниһаять 1961 ел башланды. Барыбыз да дога-теләктә, бәла-казадан, авыру-сырхаудан аман буйлыйк. Төкле аягың белән, Яңа ел! Амин! Иншалла, шулай булыр.

Чатнап торган суык. Сигезенче гыйнвар иртәсе иде. Күкчәтаудан коточкыч хәбәр:

— Нигъмәтне өендә атып үтергәннәр!!!

Бу хәбәрне ишетүгә, Маһинур телсез калды.

Үтерүче — Рәшидәнең (хатынының) өлкән апасының улы, Нигъмәтнең кордашы, мәктәптә бергә укыган, базада бергә эшләүче туганы, шофер Равил икән. Шул шомлы төндә, иртәнге өчләр тирәсендә, Нигъмәтләр өе тирәсенә шакыйлар. Ул: «Рейска чакыра килгәннәрдер» — дип сикереп тора да, өйалды ишегенә чыга. Равил икәнен күргәч, ишекне ача да «Өйгә кер»,— ди. Шул мизгелдә Равил махсус алып килгән мылтыгыннан Нигъмәткә ата.

— Равил, нишлисең! — дип борылуга, тагын бер-бер артлы ату! Нигъмәт, канга батып, үз бусагасына егыла.

Килен йөкле булган. Бу фаҗигадән ярты ел үткәч, әле дөньяга килгәнче үк ятимә калган кыз бала туа.

— Әти, кызыма Индира дип исем кушыйк,— диде Рәшидә. Һәм бу тәкъдименең сәбәбен дә сөйләп бирде.

— Мин буйга узгач, бер кичне Нигъмәт белән киного барган идек. Анда фильм башланганчы хроника әйләндерә башладылар. Ул көннәрдә Советлар Союзына Һиндстанның Премьер-министры Неру үзенең кызы Индира белән кунакка килгән иде. Хроника шулар турында. Озын, кара толымлы, шомырт кара күзле, гүзәл кыз аңа бик ошады, шунда ул болай диде: «Рәшидә, карале, туасы сабыебыз кыз бала булса — исемен Индира куйыйк. Үзе дә чибәр, исеме дә гүзәл». Мин «ярый» дидем.

Мәрхүмнең соңгы теләген үтәү йөзеннән бу сабыйга Индира исеме бирдек.

* * *

Агыла болыт. Агыла еллар — кайгылар, хәсрәтләр, булыр-булмас сөенечләр белән. Инде менә улыбыз Камил дә мәктәпкә йөри башлады. Маһинурның бездә торып калган кече улы Әхәт тә мәктәбен тәмамлап, буй җитеп армиягә алынды. Ленинград гарнизонына. Ул хезмәт иткән частьтән берничә тапкыр безнең адреска рәхмәт хатлары да килде. Маһинурның түбәсе күккә тия. «Әни, Ленинградта татарлар да күп икән. Берничәсе белән таныштым. Үземне кунакка да чакырдылар»,— дигән хатлар да килә башлады Әхәттән.

«Кара, улың Ленинградтан бер татар кызы белән җитәкләшеп кайтмасын»,— дим Маһинурны үртәргә тырышып. Ул да бирешми — сөенә генә.

— Әйдә, алып кайтсын. Ак юл. Киленле булырмын. Ленинград кызлары да мөгезле түгелдер әле.

* * *

Яз башы иде. Мин ишек алдында су ерып-агызып йөри идем. Капкадан ике солдат килеп керде — «дерт» итеп киттем. Ун ел буенча сак астында йөрү, әле хәзер дә ялган документлар белән саклану күңелне өркеткән. Бигрәк тә шинель, гимнастерка якаларында кызыл петлицалар күренгәч.

— Әссәламәгаләйкүм, абый, әллә танымыйсыңмы?

Исем китте — алдымда үзебезнең Әхәт басып тора. Ә бит, аның хезмәт срогы тулырга әле ярты ел бар. Бәлкем, кунакка гына җибәргәннәрдер? Тазарып, буйга да үсеп киткән. Хәрби кием үзенә ятышып тора — «фырт» күренә. Сөбханалла, танырлык түгел, күз тимәсен!

Әхәт үзе янындагы шулай ук таза, озын, атлет гәүдәле, саргылт чәчле, мөлаем егет белән таныштыра башлады.

— Бу минем белән бергә хезмәт иткән иптәш. Николай, якташ, безнең Зирәнде районыннан.

Аннары инде Әхәтнең иптәше үземә генә болай сөйләде:

— Сез инде гафу итегез, әйтмичә булдыра алмыйм, командование тапшырды. Сезнең улыгыз безнең частьтә шофер иде. Яхшы йөрде. Күп кенә рәхмәтләр алды. Бер көнне ул йөк белән кайтып килгәндә, Ленинградның машина белән тулы, ыгы-зыгылы урамнарының берсендә каршы машинага сугыла. Әхәт айдан артык госпитальдә ятып, дәваланып чыкты. Баш мие селкенгән диләр врачлар. Анда-санда егылып кала — эпилепсия! Шуның өчен Әхәтне срогыннан алда армиядән бушаттылар һәм миңа озата барырга куштылар.

Менә сиңа тагын бер хәсрәт!

Бераз ял иткәннән соң Әхәт райпотребсоюзның автобазасына мөдир булып эшкә урнашты. Үзе рульгә утырып, чыгып йөрми. Ул бит үзе машинаның «телен» яхшы белә, машиналарга кирәкле запчастьларны да таба. Билгеле инде, сәүдә базасындагы әтисе аркылы. Кул астындагы шоферлар белән дә, түрәләре белән дә уртак тел таба ала. Шуның өчен тыңлыйлар, хөрмәт итәләр үзен. Әмма... авыру аннан калмаган. Ара-тирә, бер дә көтмәгәндә егылып аңын югалта. Мондый авыруның эшләве үзе өчен дә, башкалар өчен дә куркыныч булуы көн кебек ачык. Башта халыкка белдермәскә тырыштык. Ләкин... без капчыкта ятмый бит.

Әхәткә бу эшне ташларга туры килде. Мин аны Алма-Атага, нейрохирургия институтына алып барып, профессорлардан караттым. Диагноз куйдылар, шифаханәгә салдылар, өч айдан артык дәваладылар. Әмма шифасы күренмәде. Аннан операция өстәленә салдылар.

Операция озак һәм авыр барды, баш сөяген тишеп, ми өстенә җыелган шеш-үлекне алдылар. Тазарттылар, юдылар. Аннан тирене ябып, тегеп, яңадан шифаханәгә яткырдылар, айдан артыкка. Мин ул вакытта Әхәткә барып-килеп йөрер өчен Алма-Атада тордым.

Ниһаять, Кызылъярга кайттык. Аллага шөкер, авыру үзен сиздерми. Егылып калулар туктады. Әхәт тагын шул ук автобазага, механик булып эшкә урнашты. Бер елдан, инде үзен яхшы хис иткәч, Гөлнур исемле бер кызга өйләнде. Беренчеләре ир бала булды. Маһинурның теләге белән бу сабыйга, үзем азан әйтеп исем куштым.

— Улым, исеме шәрифең Нигъмәтулла булсын. Илаһи амин.

Операциядән соң биш ел вакыт узды. Әхәт әйбәт кенә эшләп йөри. Гөлнур да эшли. Нигъмәт тә күзгә күренә башлады — елмая, көлә. Сөенеч!

Аллага шөкер, авыру артта калды дип куанышып йөри идек... тагын егылулар башланды, элеккегедән дә ешрак һәм... 1967 елның гыйнвар башында бу, өченче улыбыз Әхәт тә үкенечле вафат булды. Абыйлары кебек бик яшьләй, өч дистә гомерне дә тутырып җиткерә алмыйча...

* * *

Менә шулай итеп, Маһинурның өч улы, өчесе дә армия сафларында хезмәт итеп кайтып, күзгә күренеп дөнья кора башлагач кына, бер-бер артлы фаҗигалы рәвештә һәлак булдылар. Ана йөрәгенә бер-бер артлы өч тапкыр үткен хәнҗәр кадалды. Гомер буена бетәшми, һаман кан саркып

торган ачык тирән яра. Ничек түзмәк кирәк! Хода үзе сабырлыклар гына бирә күрсен инде!

* * *

— Иаллам,— Маһинур тавышланып көрсенде. Каршы бүлмәдән аның бәгырьне телгән ачы авазы ишетелде, тетрәнде.— Ни хәлләр генә итим, күрше! Хәсрәтләрем бигрәк лә авыр бит. Бәгырьләрем өзгәләнә. Яна. Арыслан сынлы өч улыңны, үсеп буй җиткәч кенә, кара җир астына алып барып күм әле...

Минем дә күзләрне яшь томалый.

— Син инде, күрше, ничек тә сабыр итәргә тырыш. Болай җылый-җылый күзләреңнән аерылырсың. Әле, аллага шөкер, менә тагын да алмадай ике улың үсеп килә. Хода инде аларның кайгы-хәсрәтләрен күрсәтмәсен, диген, бәбкәм. Сабыр төбе — саф алтын, дигән борынгылар.

Бу — күрше Миңлегөл апа — хәл белергә кергән дә, серләшеп чәй эчеп утыралар. (Мин, аларга сөйләшергә комачаулыйм дип, ул өстәлгә чыкмадым.)

— Бәй, күрми дә торам ич. Касәң буш икән бит. Китер, ясыйм. Менә шулай, улларым исемә төшә дә күзләрем бәйләнә, зиһеннәрем тарала. Син инде гаепли күрмә, Миңлегөл апа. Менә карлыган вареньесы, үзебезнең бакча җимеше. Менә бусы, әле иртәнчек кенә атлаган атланмай. Үзебезнең кызыл сыерның сые. Менә каймагы да бүгенге, сипаратордан чыгаруым гына. Ал, ал, син керәсен белгәндәй, коймак та коя башлаган идем. Мактап йөрисең икән. Кайнар чагында ләззәтле була бит ул ризык, ал, ал, күрше!

— Рәхмәт, барысы да бик тәмле, Маһинур. Борынгылар белмичә әйтмәгәннәр бит. «Сыерлы көнең, сыйлы көнең» дип. Менә без сыердан аерылдык та, кибеткә калдык. Аларның каймак дигәннәре, менә синең чәйгә салган сөтеңнән сыек. Сөтләре, әстәгыйфирулла, ком күк, бар гына кылсын инде ходаем. Моннан да авыр заманнарны да күрдек. Инде мәүләм, ул хәлләрне балаларыбызга күрсәтмәсен.

— И-и, шулай булмыйча, үзем дә чиктем инде ул заман нужаларын, сыерсызлык җәфаларын!..

* * *

Нигъмәтнең улы Өлфәт әтисеннән өч яшьлек кенә булып калган иде, инде мәктәпкә йөри башлады. Бик уңайлы туры килде. Мәктәпләре өйләреннән урам аша гына, әнисенең күз алдында. Малай тырышып укый. Рәшидә үзе дә дәресләрен әзерләргә булыша. Ул бит укымышлы, бухгалтер. Якшәмбе, бәйрәм көннәрендә Өлфәт безгә, авылга килеп чана, елга өстендә тимертаякта шуа — карга чумып, арып-талып кайта. Әмма шат, авыз ерылган... Без үзебез дә аның килүен көтәбез, килми калса — ямансу.

Шулай бер якшәмбе көнне Өлфәт килде дә, ишектән керүгә үк тезеп китте:

— Әби, бабай, мин инде сездә торам. Калага кайтмыйм.

— Нәрсә, әллә әниең белән ачуланыштыңмы? — диде аптырап калган Маһинур. Мин дә, бу нинди әкәмәт дип, мыек астыннан гына көлемсерәп торам.

— Юк,— ди, малай күзләрен чекерәйтеп.— Калада торасым килми!

— Нигә?! — дим көлүдән тыелып, бу табышмакка аптырап.— Нәрсә кырылды?

— Сездә атлар бар. Мин җылкыга барып, җылкычылар белән ат менеп йөрим. Ә калада нәрсә!

— Җүләр, мәктәбең өегез каршында. Анаң дәресләреңне карарга булыша. Менә дигән шәһәр мәктәбен ташлап, авыл мәктәбенә күчмәкче буласыңмы? Бабаеңның синең белән утырырга вакыты юк!

— Әйттем бит инде, калада атлар юк дип,— кызарды, бүртенде. Тотлыга башлады.— Шуны да б-бе-белми-сез..., шундук елап җибәрде, тезеп китте.— Ярый, ярый, өегез җәл булса Уралбай агайның өенә барам. Җадныйлар!

Менә сиңа кирәк булса, әкәмәт!

Озын сүзнең кыскасы, бу «ультиматум»нан соң миңа райсоюздан ссуда алып, якындагы дәүләт ат заводыннан бер конан (кырыкмыш) сатып алып Өлфәткә бүләк итәргә туры килде. Малайның башы күккә тиде. Конан бик матур, курчак кебек җыйнак, чем кара иде.

— Айгырымны Алмаз дип атыйм,— диде яшь «хуҗа». Без каршы килә алмадык, чыннан да, ул инде хуҗа кеше бит. Алмазны Уралбай җылкысына

кушты. Якшәмбе генә түгел, башка көннәрдә дә килә башлады Өлфәт дусты янына.

Сигезьеллык мәктәпне дау-җәнҗалсыз Кукчәтауда тәмамлагач, үзлегеннән Воронеж шәһәренә барып, Союзда бердәнбер булган жокейлар әзерли торган ике еллык училищеда укып, алтын медаль алып Кукчәтауга кайтты, ат заводында жокей булып эшли башлады. Бара-тора Алмазны Күк биягә алыштырды, Айгыр ун елда да бирәү, бия исә ел да — икәү.

Өлфәт армиягә барып хезмәт итеп кайтканда безнең 4—5 җылкыбыз бар иде инде. Һәр көзне суела торган сугымнарны исәпләмәгәндә.

Өлфәт армиядә вакытта бу җылкы малы артыннан да Маһинур йөрде: күз-колак булды. Буаз бияләрне өердән алып кайтып курада, кулда колынлатты. Саулы, кымыз әзерләде. Менә дигән бал-шикәр кымыз. Бу кымызны татыган-эчкән казакълар үзләре хәйран калалар.

— Ой-бай, Маһинур җиңгәй, мынау ширбәт, гой теленңне йотарсың...

Тирә-як күрше, Кукчәтаудагы туган-тумача, таныш-белеш җәй булса безгә:

— Ага, без кымыз эчәргә, сор ашарга килдек! — дип, ишектән үк яр салып, көлешеп керәләр.

Кымызның ат сөтеннән, үзенә генә хас бер рецепт белән әзерләнә торган шифалы эчемлек икәнен һәркем беләдер дип уйлыйм.

Ә менә сор? Сор нәрсә соң?

Менә шул турыда бер искәрмә бирү артык булмас, иншалла.

Казагстанда казахлар гына түгел, монда торган башка халыклар да, көзен кар төшеп, көннәр суыта башлагач, сугым суя башлыйлар, кышлык сугымга күберәк җылкы малы суела. Чөнки аның кыш ашалмый калганын җәйгә дә саклап була: чожок, казы, картаны — һ. б. өлешләрне сор рәвешендә.

Гадәттә, елкы малы түлен — симезлек маен — корсак тирәсенә, кабыргалары өстенә җыя. Атны суеп тунагач, казакълар аның симезлеген билгелиләр — бармак калынлыгы белән. Әгәр кабырга өстендәге май бер бармак калынлыгында булса — бер илле дип әйтелә. Ике бармак калынлыгы — ике илле. Шулай, биш-бармак калынлыгына — биш иллегә хәтле җитә. Әмма, биш илле казыны — майлы кабырганы, гомер буе Казагыстанда торып, сугымга барып, бары бер генә тапкыр очраттым. Бер хөрмәтле мәрхүмнең елы — догасы иде. Менә шушы мәҗлескә, аның балалары озак симертеп ту (кысыр) бия суйганнар. Ике яшь егет икесе көчкә күтәреп килеп, кунаклар алдында зур ашлау тулы хуш ис аңкып торган корбан ите китереп куйдылар. Исем китте — ашлауда кабарып торган, кеше кулының биш бармагы калынлыгындагы эреп торган сап-сары май — казы.

Атны суйгач, тунагач, аның түшкәсен буыннан-буыннан бүләләр — балта белән чабу — гөнаһ!.. Бу мөшәләү дип атала. Һәр кабырга-казы шулай ук аерым-аерым. Эч мае да аерым алынып, зур табакка салына, җиңелчә тозлап бер тәүлек өйдә — җылыда тотыла.

Аннан, икенче-өченче көннәрдә чожок — өй казылыгы әзерләү башлана. Моның өчен яхшылап тазартылган, җылы суда юылган эчәгеләрне алып, теге табактагы вак-вак итеп туралган майны, шулай ук ваклап туралган кара калҗаларны алмаш-тилмәш май-ит, май-ит рәвешендә эчәгегә тутырып, очын бәйләп колгага элә баралар. Менә шушы инде чожок, елкы колбасасы була.

Яз башында, көннәр җылына башлагач, кыш ашаудан калган сугым итен җәйгә саклау өчен ыслау-каклау — төтенгә тоту эше башлана. Бу бик четерекле эш. Моны бары тик бу эштә тәҗрибәсе булган оста гына башкара ала. Чөнки төтен чожокка һәр яктан тигез «ятарга», корым утырмаска тиеш. Ыслау өчен тик кайрылы каен утыны гына ягыла. Нарат — ярамый, ул бик корымлы һәм ачы исе бар. Шуның өчен аны кулланмыйлар. Бу рәвешле какланган итне казакълар сор диләр. Аны төрле авыруларга дәва итеп, май кымызына салып ашыйлар, эчәләр, бик шифалы. Үзем дә шушы сор ашап, кымыз эчеп күп еллар интеккән ашказаны кызу авыруыннан арындым (врачлар биргән һичбер дәвалардан файда булмагач).

Мондый ит ничә ел сакланса да бозылмый. Гел шул элекке сыйфатларын саклый.

Мал үрчи, ел саен икешәр була. Кышкы бер конанны (2—3 яшьлек кырыкмышны) сугым итәбез. Акча кирәк булса, берәрсен сатабыз да. Әмма, аңа карап бездәге елкы малы кимеми, үрчем исәбенә арта гына.

Өлфәт өйләнде, өй салып чыкты. Машина сатып алды. Курасында бер көтү мал. Атлар, сыерлар, куйлар, кош-корт. Ул әтисенә тарткан — малкуар. Төн йокламый — эшли, дөнья куа. Җәл, әтисе Нигъмәт улының бу җәһәтлеген, байлыгын күрә алмыйча, үкенечтә китте...

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Марс Шабаев**

# САНДУГАЧ ЯЗМЫШЛЫ ШАГЫЙРЬ

*Табигать миңа сандугач*
*Язмышы бирсә әгәр,*
*Сайрамас идеммени соң*
*Сезнең өчен бу йөрәгем*
*Арыганчыга кадәр,*
*Ярылганчыга кадәр?!*




Шагыйрь Зөлфәт бу юлларны моннан чирек гасыр чамасы элек язган. «Табигать миңа сандугач язмышы бирсә...» дип, өметләнеп тә, әмма әле үзенең шагыйрьлек язмышына шикләнебрәк, ышанырышанмас йөргән бер мәлендәрәк күңеле түреннән ташып чыккан уй-хисләредер бу.

Сандугач язмышы...

Белгәнебезчә, сандугачлар җырчы кошларның иң затлыларыннан санала. Без аларны һәр яз саен сагынып, көтеп алабыз. Сайрый башласалар, һушларыбыз китеп тыңлыйбыз. Әмма, ни кызганыч, сандугачлар гел җырлап-сайрап кына тормый шул... Җәй башларына таба сандугач сайраулары өзелә. Нәүмизләнеп, күпме генә тыңлансак та, юк — сайрамый сандугач... Безгә яңадан киләсе язга кадәр көтәргә генә кала.

Карасана, табигать шагыйрь Зөлфәткә нәкъ үзе юраган «сандугач язмышын» биргән түгелме соң? Ул да бит һәрдаим «сайрап» тормый, ягъни, кайсыдыр урыс шагыйре әйткәнчә, «Ни дня без строчки» (шигырь юлысыз бер генә көн дә юк) дигән мәсләктән чыгып, шигырь арты шигырь кумый. Көттереп кенә «сайрый»: илһамы килсә — яза, килмәсә — көчәнми.

Шуңа күрә Зөлфәтнең шигъри иҗаты күләме-саны ягыннан әллә ни зурдан түгел. Китаплары да көттереп кенә дөнья күрә килде. Әле хәтердә: Зөлфәтнең ике дистәгә якын тәүге шигырьләре яшь шагыйрьләрнең «Беренче карлыгачлар» дигән күмәк җыентыгында (1968) басылып чыккач, Хәсән ага Туфан, сокланып: «Бак, бик өметле егетебез үсеп килә икән!» — дип, аны башкалардан аерыбрак куйган иде. Яшь шагыйрьнең «Язмышлар ярында» исемле беренче китабына (1971) кереш сүзне дә Хәсән ага Туфан язды. Шуннан тиз арада Зөлфәт шагыйрь буларак танылганнан таныла барды. Әмма икенче китабын чыгарырга ашыкмады.

Утыз елдан артык иҗат гомерендә Зөлфәт нибары дүрт-биш китап бастырды. Менә алар: «Язмышлар ярында» (1971), «Утлы бозлар» (1978), «Адашкан болыт» (1990) һәм урыс телендә ике китап: «Осенние костры» (1985, Казан), «Созвездие Сююмбеки» (1988, Мәскәү). Соңгысы — коллектив җыентык.

Ниһаять, менә кулыбызда Зөлфәтнең «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Ике урман арасы» исемле китабы (1995). Сайланмалары. Шигырь сөючеләргә янә дә көттереп, бик көттереп ирешкән китап.

Шагыйрь үзе китабына сүз башы урынына язылган «Чытырманда былбыл сайрый...» исемле уйлануларында»:... сезгә шигырьләр укытасым килә...» — ди. Шулай итеп, безгә «чытырманда сайраучы былбылның» тавышын иркенләп тыңлау мөмкинлеге туа.

Равил Фәйзуллиннар буыныннан соң шигъриятькә килгән шагыйрьләр арасында аерылып торганнары икәү булды: Мөдәррис Әгъләм белән Зөлфәт. Ике дус, ике романтик-бунтарь шагыйрь. Һәр икесе Хәсән Туфан фатихасын алган егетләр. Алар үз үрләрен тиз яуладылар. Бүген инде аларның берсе — Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, икенчесе — Республиканың М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты.

Бер шигырен Зөлфәт:

> Хәреф төртсәң, шигырь үсеп чыгар —
> Шундый чагы әле җанымның... —

дип башлый да, яза килеп, болай тәмамлый:

> Шигырь чәчеп, давыл урырмын күк —
> Шундый чагы әле җанымның!

«Шигырь чәчеп, давыл урыр»дай Зөлфәтне үз заманында Мөслим якларындагы Урәзмәт авылында бер ара укытып алган шагыйрь Рәдиф Гаташ «дөрләтеп-кабызып җибәргән», шигърият бакчасында «сайрар сандугач» булырдай икәнлегенә өметләндергән-канатландырган иде. Шуңа күрә дә Зөлфәт үзенең «Юл өзеге» (1991) исемле шигырен «Рәдиф Гаташка — шагыйрьгә, укытучыма» дип багышлый.

> Урәзмәтнең ак буранлы төне...
> Кем йокысыз йөри төнката:
> — Торыгыз! Тор! Йоклар чакмыни?! — дип,
> Шагыйрь безне кереп уята.
> Уята да... Мөслим түрендәге
> Адашкан бер төнге авылда
> Кар давылы дулый шигырь булып,
> Әверелә шигырь давылга.

Әнә кайлардан килә Зөлфәтнең «шигъри давылы»!

Үзенең китабына сүз башы рәвешендә язылган уйлануларын Зөлфәт, французча манер белән, эссе дип атаган. Бу «эссе» дигәне татарның «кайнар» мәгънәсендәге «эссе» сүзе белән буталганга күрә, мин аны шагыйрьнең иркәле уйланулары, шигырь турындагы шәхси карашларын ачып бирергә омтылышы дип кабул итәм. Асылда французча эссе шулайрак тәрҗемәләнә-шәрехләнә дә.

Зөлфәтнең әлеге уйланулары бик кызыклы. Бу сүз башы үзе шигъри әсәр кебек укыла: чөнки ул кайнар хис белән, чынлап та, «эссе» итеп язылган. Уйлануларның сөземтәсе болайрак булыр: «күңел тарихыннан мәхрүм шигърият» була алмый, «шигырь — тормыш юлы», «һәр шигырьнең асылы — ихласлык», «шигырь — күңел авазы» һ. б. һ. б. Шагыйрьнең шигырьгә биргән төп бәясе исә ассызыклап алынган.

«Шигырь ул, миңа калса, — дип яза Зөлфәт, — ургылып болганган җиһан өермәсеннән капшап табып алынып, камил тәртипкә салынган, һични какшатмас ритмга салынган, бердәнбер аһәңгә буйсындырылган мәҗүси, кайнар сүзләр яңгырашы.»

Купшырак әйтелсә дә, әйбәт әйтелгән!

Әмма Зөлфәтнең бу уйлануларында без һич тә килешә алмаган, алай гына да түгел, үз иҗаты белән дә каршылыкка керә торган бер фикере бар. Ул болай яза: «Мактана килдек: «Татар поэзиясе — солдат поэзиясе! Безнең поэзия — көрәшчеләр поэзиясе! Көрәшчеләр кирәк!»... Татар поэзиясе — каргышлы язмыш поэзиясе. Калганы — ялган... Көрәшкә чакыру — вәхшилек. Көрәш — талау, үтерү, көчләү, җимерү, мыскыллау, рәнҗетү. Көрәш — ыргыйлык гамәле. Аның максаты — җиңү. Җиңү — җирәнгеч тантана...»

Тукта әле, тукта, Зөлфәт! Бик кызып, бик эсселәп киттең түгелме соң? Үз иҗатыңа борылып кара әле: син бит романтик трибун! Синең лирик шигырьләрең публицистикадан, публицистик шигырьләрең лирикадан аерылгысыз, бергә үрелгән ич. Алар — бербөтен. Нәкъ менә шул сыйфатлар бөтенлеге Зөлфәтне шагыйрь Зөлфәт итә дә инде. Соң, син үзең дә, даһи Кол Гали язмышы турында уйланып, аның авызыннан мондый сүзләр әйттерәсең:

Таң сулкылдый ерак тамырларда.
Киенгәнем — көбәм.
Күгем — түбәм.
...Соңгы яу алдыннан кылыч кайрыйм
Һәм борынгы иреннәрне үбәм...

Аннары син: «Яшьлегемдә, Муса Җәлил хакында уйланып, болай дип язган идем:

...Сугыша белгән былбыл ул,
Һәм җырлый белгән бөркет...

Былбылны сугыш бөркете урынына яуга чыгарга мәҗбүр иткән илнең, халыкның гөнаһларын кем күтәрер?» — дигән бәхәсле сорау куясың. Ә иле, халкы мәҗбүр итмичә генә, «былбылың» үзе изге яуга чыгарга теләсә, ни әйтерсең? Азмы безнең тарихыбызда шундый мисаллар?

Юк, Зөлфәт, җәмгыятьтә яшәп җәмгыятьтән, көрәштән азат булып булмый. Син үзең үк: «... азат фикер кирәк»,— дисең. Азат фикер өчен көрәшергә дә кирәк! Һәм шагыйрь Зөлфәт, еш кына кануннарга-калыпларга сыймас Зөлфәт, үзенең иҗаты белән тоташ көрәштә. Көрәш кайнарлыгы белән ул аны үзе сизмәскә дә мөмкиндер, бәлки. Әмма ышан, укучыларыңа яхшырак күренә: синең поэмаларыңны, балладаларыңны, шигъри монологларыңны, күп кенә лирик-публицистик шигырьләреңне укыганда укучылар көрәш кайнарлыгын тоялар. Ул «талау, үтерү, көчләү, җимерү, мыскыллау, рәнҗетү» көрәше түгел. Ул — изге көрәш! Шагыйрьнең кылычларга тиң җыры-сүзе белән теле-дене өчен, иле-халкы өчен бәйсез дәүләте өчен изге көрәше. Җир-Ананы, бөек Табигать-Ананы афәтләрдән саклау өчен көрәше. Безнең уебызча, шагыйрь Зөлфәтнең бар иҗаты шул изге максатка юнәлдерелгән. Әнә ул әлеге уйлануларында хискә бирелеп, Зөлфәтчә бер «давыллап» алганнан соң, басылып: «Чын шигырь уен яки куен гына түгел. Шигырь — назлы бишек тә, яу атының сыртына салынганияр дә»,— дип фикерен төйнәп куя. «Яу атының сыртына салынган ияр...» Менә монысы белән без тулысынча килешәбез! Шагыйрь Зөлфәт иҗаты нәкъ шуны раслый да. Нәкъ шуны...

Ярар, бераз бәхәсләшеп алдык шикелле.

Зөлфәт, бик күп балладалар, сюжетлы әсәрләр иҗат итсә дә, ул — хис шагыйре. Аңардагы ургып-ташып торган лирик хис-тойгылар — бүлсәң — бер унлап уртакул шагыйрьгә җитәр иде, мөгаен. Ул кайбер шигырьләрендә, артык хискә бирелеп, дуамалланыбрак та киткәли кебек. Әмма эчке шигъри тоемы, шигъри зәвыгы аны тыеп тора, бик артык ычкындырып җибәрми, шигырьне түбән тәгәрәүдән саклап кала. Бу инде — талантлылык билгесе!

Шул ук вакытта Зөлфәтнең шигърияте исемле генә түгел, җисемле дә: аның күп әсәрләренең анык геройлары-образлары бар. Шуңа күрә дә ул сюжетлы-эчтәлекле әсәрләргә еш тартыла. Бу җәһәттән Зөлфәт Такташка, Туфанга таяна, алар үрнәгендә иҗади үсеш кичерә. Әле Туфан дигәннән, Зөлфәтнең «Балкыш хәбәре» (1978) шигырендә:

Балкыш яктысында ак болыт — ал,
Әйтерсең лә, эче тулы кан —
Танып алдым Туфан сагышларын
Урал аша аккан болыттан,—

дигән сагышлы юллар бар. Шагыйрь үз иҗатында Хәсән Туфан образына кабат-кабат кайта һәм ул «Чык төшкәндә Парнас тавына» (1986), «Халык дошманы» турында бер истәлек» (1992) кебек тирән эчтәлекле шигырьләр иҗат итте. Кайбер шигырьләре — «Сөйләшик бер, гомер, синең белән!» (1974), «Калыкты ай» (1993) — язылышлары белән дә Х. Туфанны хәтерләтәләр, аларда Туфанга «орынып алу» сизелә.

Иҗатының башлангыч чорындарак Зөлфәттә Есенинчылык та төсмерләнә иде. Аның «Тойгыларда алтын яфрак шавы» (1974) шигырендәге:

Эт шикелле, мин яларга әзер
Туган илнең һәрбер ярасын!—

кебек юллар әнә шундыйлардан. Ә бер шигыре исә «Бәгырь янында (С. Есенин туфрагына орынгач)» (1975) дип атала.

Зөлфәтнең тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләрен язылу елларына карап бер тәртипкә тезсәң, болайрак килеп чыга: «Бабичны юксыну» (1964), «Кандал карты» (1967) — Г. Кандалый турында риваять, «Каюм» (1973) — Каюм Насыйри, «Сөембикәнең хушлашу догасы» (1978), «Болдино көзләре» (1981) һәм «Мәлдерәмә» (1987) — А. С. Пушкин, «Марш» (1986) — С. Сәйдәшнең «Совет Армиясе маршы» турында баллада, «Итек» (1986) — И. Сталин турында кара баллада, «Соңгы төн (Александр Ульянов)» (1987), «Ялта тыкрыгында» (1987) — Г. Ибраһимов, «Сулыш (Ленин үлеме)» (1989).

Александр Сергеевич Пушкинга багышланган «Болдино көзләре» шигырендә шундый юллар бар:

Сулык-сулык тибә күкрәгендә аның
Туган илнең моңы, туган илнең җаны...

Ә туган ил — Империя. Анда «авыр, шыксыз кара төннәр... постлар, карантиннар — эпидемик дәүләт. Котылу юк аннан җаныңны да түләп!» Һәм шул ук вакытта «...Якты шампан чыжлый алтын подносларда... гөрли мазуркалы заллар...» Ә шагыйрьгә үлем әзерләнә...

Туктагыз, бу безнең көннәр турында түгелме? Бүген дә нәкъ шул — таркалып барса да, таркалмаска җан тартышкан Рәсәй империясе. Һәм хыянәт, үтереш, талау... Әнә бит, әле берничә ай элек кенә, Чечня-Ичкериядәге кан коешны туктатуны яклап кайнар чыгыш ясаганда, йөрәге ярылып, шагыйрь Юрий Левитанский вафат булды. Аның җеназасы өстендә шагыйрь Евгений Евтушенко «бүгенге Борис патша»ның йөзенә бәреп: «Юрий Левитанский да Чечня сугышы корбаны, сезнең корбаныгыз...» — диде.

Сүз уңаеннан, Зөлфәтнең иҗат алымнары: сюжетлылык, баллада-риваятьләр, кайнар публицистика, тарихилык — болар Евг. Евтушенко иҗатына да бик аваздаш.

Зөлфәтнең китабында үзе «баллада» дип жанрын билгеләгән әсәрләре күп түгел, бишәү генә икән: «Фатыйма» (1971), «Ике ат турында баллада» (1973), «Кара күбәләк» (1978), «Тау яшене» (1981), «Марш» (1986). Әмма, безнеңчә, шагыйрьнең балладалары болар белән генә чикләнми. Аның байтак кына башка әсәрләре дә сюжет-эчтәлекләре һәм язылышлары белән балладалар яки баллада булырлык әсәрләр. Шуларның кайберләрен «кара баллада» дип тә атарга мөмкин булыр иде.

«Сулыш (Ленин үлеме)» дип исемләнгән әсәр дә нәкъ менә шундый кара баллада.

Бу әсәр — Ленинның үлем алдыннан Тәңрегә, Ходайга булган тәүбә-монологы, ялваруы рәвешендә язылган.

Яңа Иман иңдердем мин җиргә,
Афәтнамә булып чыкты Иман.
Мин таң кабызырга тиеш илнең
Өсләрендә йөзә канлы томан...

Ә Ленинның үз өстенә «иелә дә Өер башы, елмайгандай итеп ыржая гел: «Йә, син канәгатьме, и Юлбашчы?!» Без бу тетрәндергеч юллардан кансыз-явыз Сталинның җан өшетерлек сурәтен дә, үлем түшәгендә ятучы Ленинның көчсезлектән гаҗиз гәүдәсен дә ачык күрәбез.

Без колларны азат итмәк идек —
Азатлыкка чыкты коллык үзе,—

дип әрни-өзгәләнә Ленин.

Ә инде аның «Өер башы» Сталинга биргән бәяләмәсеннән тагын бер кат тетрәнеп куясың, тәннәр чымырдап китә:

...Җирдә ерткыч, ач бүренең
Кайнар тынын мин калдырып китәм...

Әле безнең өчен дә, шагыйрь Зөлфәт өчен дә Ленин шәхесе үзенең иң яшерен серләре белән ачылып бетмәгән, әле укырга да куркыныч күп рәсми кәгазьләр, документлар халыкка килеп җитмәгән чорда язылган әсәр бу.

«Бөек юлбашчыларыбыз», «дөресрәге, «Өер башлары» турында Зөлфәт тагын бер әсәр иҗат итә. «Итек» дип атала ул әсәр. Монысы «Өер башы» Сталин образын янә бер кат күз алдына китереп бастыра. Бу әсәр дә, безнеңчә, кара баллада.

1945 ел. Кызыл Мәйданда Җиңү парады. Мавзолей трибунасында «Ленин мәете өстендә Сталин болгый кулын...» Нинди куаныч, нинди зур тантана! Әмма Зөлфәт безне бик тиз ачы хакыйкатькә кайтара: «Салют яктылары капшый төрмәле ил күген...» Без инде Җиңү парадын күрмибез. Безнең каршыдан, «Сталин каршысыннан атылган генераллар уза...»:

Уза кырылган халыклар,
Бертм-берәм уза.
Сталинның итекләре
Салкын ташта кыза.
— Яшә, даһи Сталин!
Синең
Даның — халык даны!
Итегеңдә —
Крестьянның
Мәңге кипмәс каны!

Ленин өстенә басып торган бу канлы итек хуҗасының әмере белән «Берлинга барасы юллар Колымадан үтте...» «Биеде бу йомшак итек! Илне томан басты...» Искиткеч контрастларда фикерен уйната шагыйрь.

Әсәрнең бетеме гаҗәеп тирән гомумиләштерелеп бирелгән, ул безне борчулы-шомлы уйларга сала:

...Уза батырлар тиранга
Исе китеп, карап —
Аны
    Җиңү бәйрәменә
Узар беркән парад!
...Ләкин,
    Мавзолейны таптап,
Кемнәр «Сәлам!» дияр?
Сталинның итекләрен
Иртәгә кем кияр?

Әйе, Сталинның шәхес культын «Җиңү бәйрәменә» парадлар ук узмаса да, без аны җиңгән шикелле булган идек. Ни кызганыч, вакытлар күрсәтте: ул «җиңү» тулы булмады, «шикелле» генә булып калды да шул. «Сталинның итекләрен» кияргә теләүчеләр тиз табылды бу «томан баскан Илдә». Сталиннан соңгы «Өер башлары» да, бүгенгеләре дә...

Менә шундый уйланырлык хәлләр...

Безне дә, үзен дә борчып торган әлеге уй-фикерләрен Зөлфәт әсәрдән-әсәргә үстерә бара. Аның «Соңгы төн (Александр Ульянов)» дигән әсәре дә үлем алдыннан соңгы монолог рәвешендә язылган. Александр энесе Володяга — булачак юлбашчы Ленинга — эндәшеп болай ди:

Императорларның исемнәре төрле,
Гасырлары төрле — хаталары уртак:
Конституциягә кертелми күз яше —
Һәм империяләр оча
Күз яшеннән шартлап!

Зөлфәтнең «шартлап очачак империяләр» белән көрәше иҗатының башлангыч чорында ук, гадәттә яшь шагыйрьләр мәхәббәт хисләреннән исереп йөри торган чорында язылган «Йодрык» (1970) исемле әсәрендә үк ачык чагыла иде. Җәяләр эчендә «Кабан күле бозындагы элеккеге йодрык сугышларыннан бер манзара» дип шәрехләнгән бу шигырь дә баллада булырлык әсәр.

Ике халык — гладиатор гүя —
Кан эчендә бүген укмаша!
Күзли шуны губерналар аша
Бу якларга үче зур патша.

Йодрык сугышында Батул бай ялчысы Гәрәйнең әтисен башына гер белән сугып үтерәләр. «Түбәтәйле кара малай» Гәрәй, үзен-үзе белештермичә, үтерүче урысның бугазына ташлана...

Үч кырында алар — кара дошман,
Язмыш каршысында — бертуган!

Кан эзләре...
    шушы эзләр буйлап,
Сиздермичә генә, империя,
Синең шыксыз байрак ертылган.

Шагыйрьнең «Нигез» (1972) дигән шигырендә исә инде юкка чыккан, «күптән үлгән авыл» язмышы сурәтләнә. Авыл нигезе булган ялан кырда басып торган шагыйрьнең моңсу хәтерендә ач хатыннар җанлана... Шул хатыннарның әрнеп сөйләшүләре аша «кыштыр-кыштыр алабута җыючы мәңгелек коллар»ның ачы язмышы үзәкләргә үтәрлек итеп тасвирлана. Сугышларны да Зөлфәт үзенчә атый: «Беренче бөтендөнья сугышы... Гражданнар сугышы... Бөек Ватан сугышы... Сугым еллары...»

«Игенче» (1974) шигырендә — сөргеннән качып авылына кайткан кулак язмышы. Бу әсәр дә Зөлфәтнең яраткан алымы белән — герой монологы рәвешендә язылган.

Бу каргалган илдә юлның
Конвойсызы юк сыман!
Көрт астында тын авыллар —
Биле сынган эт сыман...—

дип аһ ора Афзалетдин карт. Ул асылда бернинди дә кулак-фәлән түгел, ул — җирнең чын хуҗасы, игенче. Әмма ни хәл итсен, иген игәсе урында ул:

Сөрдек салкын тайгаларда
Мәңгелек салкын карны...
...Сагына җир минем назны...—

дип, җирсүенә түзә алмыйча, качып кайтса, ни күрә? Авыл халкы, крестьян җирдән бизеп бара түгелме соң?

Мыскылланган җир өстеннән
Тешемне кысып үтәм —
Күпме нур явасы калган
Авылкаема күктән?

Әйе, крестьянны җирдән биздергәннәр. Авыллар бетәргә йөз тоткан...

Зөлфәтнең бу әрнүле уй-хисләренең чиге юктыр сыман. Алар әледән-әле бәреп чыга гына торалар. «Ике ат турында баллада» (1973) булсынмы, «Ат йокысы» (1974) дигән шигырь булсынмы — алар шагыйрьнең тамырлары авылда икәнлегенә ачык дәлил булып калалар. Гомумән, ат образы Зөлфәт шигъриятендә үзәк образларның берсе. Аның тагын әле «Атлар су коена» (1975), «Ул карашлар истә» (1977), «Ат карагы» (1985), «Колыннар» (1985), «Сырынды» (1992) кебек шигырьләрендә дә шул ук атлар булыр. «Ат йокысы» шигыре гаҗәеп матур әсәр:

Ул дөньяга килде Тулпар булып,
Якты таңда, дала түрләрендә —
Елгыр ефәк канат иде сыртта
Һәм таң кошы иде күкрәгендә!

Күрәсез — янә дә баллада төсмерләре. Әмма шул канатлы Тулпарга да «җитте килеп камыт кияр көннәр». Һәм Тулпарның канатлары сына, ул да, башка атлар кебек үк, гади эш атына әйләнә. Шуннан соң инде:

...Аягүрә йоклый эш атлары.
Очып түгел, тартып үтелде шул
Гомеркәйнең юлы, сукмаклары.

Йа, ходай! Без дә шул, канатлары сынып, гомерлек камыт кигән «эш атлары» лабаса! Безнең сыртка да шул ук камчы төшә түгелме соң?

...Җил сызгыра абзар кыегында,
Дала түрләрендә яна утлар.
Колын төшен күреп карт ат йоклый —
Тере алаша һәм үлгән тулпар...

Безгә бик тә, бик тә моңсу булып китте, Зөлфәт...

Менә тагын бер шигъри риваять: «Тыным бетте» (1976). Шигырьнең башында мондый аңлатма бар: «Түбән Новгород Кремленең Көянтә манарасы нигезенә тере килеш бер кыз биклэп калдырылган. Манара каршында аның барельефы тора».

Абау! — Матурлыкның нәфис җаны биктә!
Абау! — Ул җан җансыз таш эчендә калган!
Абау! — Матурлыкны коткарырга кирәк!
Абау! — Матурлыкның тыны беткән!

Бу юллардан соң уй-фикеребез үзеннән-үзе Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» (1980) дигән лирик-публицистик поэмасына барып тоташа. Италия шагыйре, әкиятче Джанни Родари истәлегенә багышланган әлеге поэма турында сүз йөртер алдыннан, гомумән, Зөлфәт иҗатында поэма жанры турында берничә сүз әйтеп үтү кирәктер.

Шагыйрьнең яңа китабына өч поэма кертелгән. Беренчесен әйтеп үттек инде. Калган икесе — «Иске Казан карлыгачы» (1987) һәм «Җирдән кайтышлый» (1982) дип аталалар. Күп кенә сюжетлы шигырьләре поэма итеп, киңәйтебрәк язуны сорап торса да, Зөлфәтнең ашкынулы табигате классик калыптагы салмакозынлыкны кабул итеп бетерә алмый, күрәсең. Шагыйрь поэма жанрына сирәк кагыла.

«Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасы шулай ук Зөлфәткә хас баллада элементлары белән үрелеп иҗат ителгән әсәр. Бигрәк тә «Җәза», «Биеклек», «Циркта бунт» бүлекләре балладалар рухында язылганнар. Шагыйрь безнең алга бер сорау куя: «Әкияти хисең саумы, кешем, җанда?» Саташкан авыру заманның саташкан авыру кешеләренә (авырулары — комсызлык, байлык, рәхимсезлек, рухсызлык, хөсетлек һ. б.) бик вакытлы төбәлгән сорау бу. Әкиятне җую — кешелекне җуюга бәрабәр, ди шагыйрь.

Поэманы әдәби тәнкыйть тиз күреп алды, аның хакында матбугатта байтак төпле-нигезле фикерләр әйтелде.

Ау сезоны бара — әкиятнең
Аркасына пычак кем тери?
Тышау тотып, планета буйлап
Ак тулпарны аулап кем йөри?
...Канатлы ат чаба җир буйлатып —
Азат җан ул — Хыял һәм Өмет!
Йөрәгендә — үлмәс дастан — Бәхет!
Ул булырга тиеш мәңгелек...

Рәхмәт шагыйрьгә! «Ат йокысы» шигырен укыганнан соң күңелдә туган моңсу өметсезлекне юып ташлап, йолдызларга карарга мәҗбүр иткәне өчен, кешелек күңелендәге Хыял, Өмет, Бәхет төшенчәләрен үтермәгәне өчен рәхмәт!

«Эт тоту көне» (1978). Зөлфәт бу шигырен Себергә сәяхәтләре тәэсирендә язган. Беренче карашка, сүз хуҗасыз этләрне тоту-аулау турында гына бара кебек. «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасында да «ау сезоны» бара иде бит. Ә, юк! Шигырьдә сүз, «металл җигеп Яңа Замана» килеп кергәч, тайганың астынөскә китерә башлагач, тагын да төньяккарак күченеп киткән манси халыклары язмышы хакында икән. Әлегә тотылмый калган берләнбер эт — алардан калган ятим. Безнең байтак шагыйрьләребез «коммунистик яңа заман» дип җырлаган бер вакытта (онытмагыз, бу шигырь 1978 елда ук язылган!), Зөлфәт «Металлистик Яңа Заман»ны каһәрли. Эткә дә ул: «Бүре бул син, бүрек булганчы!» — дигән теләк тели.

...Күченүләр, аһ бу күченүләр!
Оя тузгытуның җилләре...—

бу юллар бүген бигрәк тә тирән мәгънә төсмере алып яңгырый башлыйлар. Әле анда — тайгада табигатьне актарып ташлау гына булса... Бүген империянең итәгенә ут капкан! Күченәләр... Ил качаклар белән тулды... Урта Азиядән булсын, Кавказ якларыннан булсын — күченәләр...

Соң, заманасы асты-өскә килеп буталганда, СССР дигән монстр җимерелеп, аның кыйпылчыклары арасында бәйсез яңа ил-дәүләтләр канга бата-бата ыңгырашып туып ятканда, Зөлфәт шагыйрь, Зөлфәт публицист битараф кала аламы?

Тупландылар кыргый өерләргә
Адәм балалары юлларда.
Шулай уңайлырак — ботарларга,
Шулай уңайлырак — уларга,—

«Ялгыз сандугач» (1992) исемле бу шигырь:

Үз нәҗесе белән уйный Ватан.
Барып җиттек —
Ватан тилерде,—

кебек кайнар юллар белән дәвам итә дә, аннары лирик Зөлфәт:

Һәм шуларны ярлыкауны сорап
Өзгәләнер ялгыз сандугач...—

дип, аны югары аһәңле чыңда тәмамлый.

Иҗатының беренче елларыннан ук Зөлфәтнең әсәрләрендә лирика белән публицистика аерылгысыз үрелеп барганын искәртеп үткән идек. Әле «Империя» (1973) исемле шигырендә үк ул:

Золым империясе диеп, илнең
Һәр тарафка чыкты яманаты,—

дигән фикерен үстереп:

Азат итеп маташабыз тагын
Үзебезнең түгел — Олы Җирнең
Бездән иреклерәк халыкларын!—

дигән ачы нәтиҗә ясаган иде.

Зөлфәтнең ил-халык язмышы өчен борчылып та, кайнарланып та язылган шигырьләре бигрәк тә соңгы елларда ишәеп китте. Аның «Адашкан болыт» (1985), «Серем» (1988), «Өн» (1989), «Көрсенү» (1989), «Буын» (1989), «Көз яңгыры» (1989), «Чор сурәте» (1989), «Безнең яшәешкә...» (1989), «Шик» (1989), «Сират күпере» (1989), «Тутык» (1989) дигән шигырьләренең исем мәгънәләренә игътибар итегез, исемнәре генә дә күп нәрсә турында сөйли бу әсәрләрнең. 1989 елда шагыйрь андый әсәрләрен аерата мулдан иҗат иткән икән. Бу безнең сүз иреге алып, күп нәрсәләргә күзләребез ачыла башлаган чор иде шул.

Тутык болынлыкта тимер бия
Шалтыр калай колын имезде,—

«Тутык» шигыреннән алынган, беренче карашка, абсурд мәгънәсезлек булып тоелган бу юллар шул ук «Металлистик Яңа Заман»ны тамгалау түгелмени?

Җир кучәренә ышкынып,
Рәхәт тапмак итәбез —
Йолдызларга карый белгән
Чучка түгел микән без?
*«Кем?» (1989)*

Имансыз калдың, и халкым,
Ни саклар күңелеңне?
Уйнаштан туган буынга
Калдыра күрмә илне!
*«Күңел сагы» (1989)*

Зөлфәт «Сырынды» (1992) дигән бер шигырендә үзе яраткан ат образына әйләнеп кайта да:

Атла, аткай, юл булырга тиеш...
Эзлә генә, эзлә юл катысын!—

дип, атын да, безне дә алга әйди. Әйе, безгә өшәнмәскә, ничек кенә булса да, алга атларга — «юл катысына» чыгарга кирәк. Әмма моның өчен, Зөлфәт шигыре белән әйтсәк:

Аксакал һәм егет була белгән
Чын ир җитми бугай бу илгә...
*«Юл өзеге» (1991)*

Менә шундый ул «Металлистик Яңа Заман», рәхим-шәфкатьсез заман...

«Мактыйсыз да мактыйсыз Зөлфәтне. Бер дә кимчелеге юкмыни соң?» — дип сораучылар табылыр, бәлки. Бар кимчелекләре Зөлфәтнең дә. Һәр шагыйрьнең, иҗади үрләре булган кебек, түбәнәйгән-сүлпәнәйгән чаклары да була. Монысы — котылгысыз. Уртакулрак, бушрак әйберләр дә языла. Андый әйберләрне укыгач, күңелдә язучы Марсель Гали бер дә яратмый торган сорау туа. Укыйсың да: «Йә, шуннан?» — дип куясың. Шигырьдә хис тә бар, күпмедер шигъри табыш та бар шикелле, әмма... андый шигырь безне ничектер ымсындырып кына калдыра, бераз «алдап» кына китә төсле... Уйланасың: «Ни өчен шундый бушлык соң әле?» Баксаң — андый язмаларга фикер җитми икән.

Ләкин Зөлфәтнең табигый таланты җиңел кулданрак язылган, үзе өчен уңышсыз саналган шигырьләрендә дә халтура дәрәҗәсендәге түбәнлеккә төшәргә бирми.

Мисаллар, дисезме? тезеп санап чыгу өчен генә мисаллар җыеп утырасыбыз килми. Алай да безнең карашка уңышсыз бер әсәргә — Зөлфәтнең «Җирдән кайтышлый» (1982) исемле поэмасына тукталып узу кирәктер. Шагыйрь ни өчендер бу әсәренең дөрес аһәңен таба алмаган шикелле. Ул аңа «Җалу тикшерү өчен Кояш системасына килеп киткән «Дезинфекция» исемле Очар Тәлинкә командирының гаризасы» дигән искәрмә биргән. Менә шушы искәрмә-«ачкыч» шагыйрьне бутаган да. «Ачмый» бу «ачкыч»! Әллә нинди бер җиңеллек, көлкәкәмитлек Зөлфәтне уңышсызлыкка дучар иткән. Башьйолдызга шикаять язган Җир шарының «инәң башы! тәре» дип сүгенүләре, Койрык Йолдызның «төсебите калмый мышнап төшү»ләре, аңа Җирдән шикаять китергәне өчен «медальфәлән ягын кайгыртыгыз» дип сораулар, «кеше-мәртәтне» юк итеп, «биопакетларга» тутырып алып кайтулар — болар һәммәсе дә әсәрне изә, харап итеп ташлый. Җиргә янаган фаҗиганы без, укучы буларак, тиешенчә җитдилек, акыл һәм йөрәк белән, бар тирәнлеге белән кабул итә алмыйбыз. Бу юлы Зөлфәтнең шигъри зәвыгы шагыйрьгә хыянәт иткән сыман тәэсир кала.

Зөлфәтнең туган төбәгенә — туган авылы Яңа Сәеткә, үзе укыган Урәзмәткә, Коргылды суларына, Ык торналарына бәйләнышлы сагыну-сагыш тулы байтак шигырьләре хакында сүз йөртергә булыр иде. Укучы аларны үзе эзләп табар, ләззәтләнеп укыр дип ышанабыз. Чөнки барыбыз да туган җир, туган туфрак балалары...

Мәхәббәт лирикасын читләп үтә аламы соң шагыйрьләр?! Юк, әлбәттә! Зөлфәттә дә шактый мулдан андый шигырьләр. Ә нәрсә соң ул мәхәббәт! Зөлфәт бу сорауга җавапны «Мәхәббәт» (1970) исемле балладасында эзли. Һәм бу әсәр Зөлфәтне шагыйрь итеп таныткан матур әсәрләреннән берсе дә. Шагыйрь үзе бу хакта болай яза: «Мәхәббәт» дигән әсәрем..., кем әйтмешли, яшьлегем таңында язылган иде. Нәрсә турында иде ул? Болай, тыштан карасаң, аюга каршы бермә-бер чыга алырлык, аны пычак белән егардай бер ирнең, җавапсыз мәхәббәттән тилмереп, чиксез газапларын хәтта аракы белән дә баса алмыйча, изалануы хакында иде ул баллада. Тукта! Шушы хакта гына микән?»

«Акбаш»ка һәм Такташка гашыйк» агай «кефир малае» — студентка йөрәген ачып сала:

Э-э-эх!
Тупас, кырыс диярсең син мине,
Ә син аңлый алыр идеңме
Аю сыман таза шушы ирне
Аягыннан еккан сөюне?
Ә?


Зөлфәт «Ике урман арасы» исемле бу сайланмаларына үзе язган сүз башында болай ди: «Шигырь язу өчен күңелнең мөлдерәп торуы, соңгы тамчының ташуы кирәк... Шигырь — язмыш».

Сандугач язмышлы шагыйрьнең күңеле ешрак мөлдерәп торуын, соңгы тамчының ешрак ташып, яңа шигырьләр булып түгелүен теләргә кала безгә.

Шигырьләрең язмышы якты булсын, Зөлфәт!

■ *Гыйнвар, 1996 ел.*

# ТАПЛАНМАС ИСЕМ



Фатих Кәрими

Шәрыкны өйрәнү институтының төрек теле укытучысы Ф. Г. Кәримевнең (Фатих Кәриминең) җинаять-тикшерү эшен 1937 елның сентябрь азагында ашыгыч рәвештә тәмамлыйлар. Ул шул ук елның 5 августында гына Мәскәү янындагы Черкизовода — яшәү урынында кулга алынган була. Аңа РСФСР Җинаятьләр кодексының яман 58 нче маддәсенең ату җәзасы бирелә торган өлешләре буенча гаеп ташлана. Ф. Кәрими шпионлык итүдә, партия юлбашчыларына, аерым алганда, иптәш Сталинга каршы террор әзерләүдә һәм яшерен контрреволюцион оешма төзүдә тотылган икән, ягъни, шул вакыттагыча әйтсәк, аның гаебе — «чәчәкләрнең тулы бәйләме», һәм шундый җинаятьләр кылучы һичшиксез атыла. Хәтта шул коточкыч заманда да мондый гаепләүләрнең мәгънәсезлеге һәм акылга сыймаслыгы ярылып ятуына без соңрак тукталырбыз әле.

СССР Югары Советы Хәрби коллегиясенең 1937 елның 27 сентябрендәге утырышында Фатих Кәрими үзенә ташланган гаепләрне раслаудан баш тарта, тикшерү барышында «җинаятьләр»не танырга, үзенә-үзе яла ягарга «физик көч куллану» нәтиҗәсендә мәҗбүр ителүен әйтә. Хәер, моның инде әһәмияте булмый, чөнки «хөкем карары» алдан ук чыгарылгандыр, күрәсең. Күренекле фикер иясе, Шәрык белгече, язучы, татар халкының бөек улларыннан берсе, мәдәнияттә һәм сәясәттә атаклы эшлеклеләр биргән гаиләнең бер вәкиле, кеше буларак сөйкемле зат шул ук көнне җәзалап үтерелә. Шулай итеп, Фатих Кәриминең төрле вакыйгаларга һәм батырлыкларга гаҗәеп бай гомере алтмыш сигезенче яшендә киселә.

Фатих 1870 елда Әлмәт төбәгендә туа. Аның әтисе Гыйлман Кәрими ахун руханилар арасында аң-белеме, мөстәкыйльлеге белән аерылып тора, бөек Мәрҗанинең яраткан шәкерте була. Аңа гаҗәеп мәрхәмәтле һәм игелекле рус кешесе, Казан шәһәре башлыгының хатыны Ольга Лебедева белән аралашу да зур йогынты ясый. Бу ханым исә Шәрык белгече булып таныла, Төркиядә аны «Гөлнар ханым» дип хөрмәтлиләр, төрек халкың рус әдәбияты белән таныштырудагы хезмәтләре өчен, империянең югары нишаны-ордены «Шәфакать» белән бүләкләнә. Гыйльман ахун, нәкъ менә Гөлнар ханым киңәше буенча, язмышын кискен үзгәртә, Оренбургка күчеп, нашир һәм журналист булып китә, шул ук вакытта дини эшчәнлеген дә бөтенләй ташламый. Ул яшен сугудан вафат була. Һәм бу хакта, дини хезмәттән читләшүе өчен Ходай биргән җәза, дигән сүз тарала башлый. Моны хатыны Мәгъсумәнең туганы, исламның күренекле эшлеклесе, галим Риза Фәхретдин, аның дуслары эшмәкәрләр һәм меценантлар бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр (соңгысы шагыйрь Дәрдмәнд буларак танылган шәхес) тиз туктаталар. Җомга намазы вакытында Риза казый, ислам кагыйдәләренең берсенә нигезләнеп, галим каләмендәге караның дине өчен газап чигүче

зат каны кебек үк ихтирам ителергә тиешлеген искәртә, Гыйлман ахунның яңа юнәлештәге эшчәнлеге Аллага кирәкле булуын әйтә.

Гыйлман ахун балаларының һәркайсы — аның өч улы һәм өч кызы була — татар халкының рухи тормышында сизелерлек үзгә эз калдыра. Мөхәммәтгариф, әйтик, 1917 елдан соң, большевизмга каршы көрәш лидерларының берсе, Гаяз Исхакыйның якын көрәштәше. Ул, рәсми юрама буенча, 1934 елда Варшавада тәрәзәдән «ташланып» үлә. Аның үлеменең төгәл сәбәпләре кайчан да булса ачыклануы шикле, шулай да кайбер хәбәрләр моны НКВД агентларына сылтый. Мөхәммәтгарифның иҗтимагый тормышта активлыгын һәм бу чакта Гаяз Исхакыйның Ерак Көнчыгышта булуын искә алсак, Европада «Идел-Урал»ның бөтен оештыру эшчәнлеге Мөхәммәтгариф кулында була, димәк, әлеге юрама да нигезсез түгелдер.

Мин Кәримевләр гаиләсе тарихын тулырак итеп аерым язарга ниятлим, хәзергә исә бу гаиләнең иң зур шәхесләреннән берсе Фатих Кәрими турында гына сөйләргә тиеш табам, өстәвенә язмабыз да аның 1937 елда һәлак булуын искәртүдән башланган иде.

Гыйлман ахун вафатыннан соң, аның нәширлык эшләрендә варисы булып бу вакытта инде төрле яктан әзерлекле, тирән белемле Фатих кала. Ф. Кәриминең мондый үсешенең кайбер баскычларын атап үтик. Истанбул университетында (1892—1896 еллар) ул Чистай мәдрәсәсендә әдәбият, тарих, филология һәм икътисад буенча алган белемнәрен эзлекле тирәнәйтә, татар һәм төрек телләренә өстәп, гарәпчә, фарсыча һәм французча иркен сөйләшергә һәм язарга өйрәнә. Ә рус теле аңа кечкенәдән үк таныш, бу телдә ул әйтелештә бөтенләй бозмыйча диярлек сөйләшә. Туксанынчы еллар азагында Кырым бераз вакытка мөселман модернизмының (XIX гасыр азагында һәм XX гасыр башында мәгариф һәм гамәли сәнгать өлкәсендәге юнәлеш) һәм Россия мөселманнарының Европа мәдәниятенә тартылуының төп үзәге булып тора. Бу хәл башкалардан аермалы шәхес, Россия уку йортларында төпле белем алган, ханнар башкаласы Бакчасарай шәһәре башлыгы Исмәгыйль Гаспринский исеме белән бәйле.

Фатих Кәрими И. Гаспринский ачкан яңа ысуллы милли мәктәпләрдә укыта. Тиздән ул 1898 елда Бакчасарайда ачылган укытучылар семинариясе директоры була. Алтын прискалары хуҗасы Шакир Рәмиев белән, иптәш һәм тәрҗемәче буларак, Европа буйлап бергәләп сәяхәт итү Кәримидә онытылмаслык тәэсир калдыра. Уңган эшкуарны беренче чиратта тау эше һәм алтын рудаларын эшкәртү өлкәсендә техник тәрәккыят яңалыклары кызыксындыра. Германиядә, Бельгиядә, Франциядә, Италиядә һәм Европаның кайбер башка илләрендә Рәмиев күренекле галимнәр, инженерлар, фирмалар хуҗалары белән очраша, машиналар һәм техник җайланмалар сатып ала. Әңгәмә-сөйләшүләрдә аңа Ф. Кәрими бәһа биреп бетергесез ярдәм итә. Сәяхәт ашыгыч һәм мәшәкатьле булмый, яшь Фатихның мәдәниятнең истәлекле һәйкәлләре, фән һәм мәгариф учаклары белән танышырга вакыты иркен кала, ә боларны күрү-белү турында ул студент чагыннан ук хыялланган була. Сәяхәттәге тәэсирләре һәм уйланулары соңыннан аның 1902 елда басылып чыккан «Аурупа сәяхәтнамәсе» дигән кызыклы китабы нигезен тәшкил итә. Шунысын да искәртик, китап татар бестселлеры булып китә, ягъни иң күп укыла торган китаплардан санала.

Егерменче гасырның беренче унъеллыгында ук Фатих Кәрими берничә газета-журналның (арада Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасы аеруча танылa) мөхәррире була, күренекле әдәбиятчылар исәбенә керә. Аның әсәрләре татар иҗтимагый аңындагы җитди каршылыкларны, кадимилек һәм җәдитлек арасындагы көрәшне чагылдыра. Тарихи әдәбиятта бу көрәш ясалма рәвештә гадиләштерелеп килде, анда күп кенә төрле төсмерләр булуга карамастан, еш кына буржуаз һәм эшчеләр идеологияләре көрәшенә кайтарып калдырылды. Җәдитчелек яклы буларак, Ф. Кәрими кайбер әсәрләрендә төрле юнәлеш вәкилләрен сурәтләргә омтыла, кадимчеләрне тасвирлауда сатирик буяуларны кызганмый. «Бер шәкерт илә бер студент», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» исемле хикәяләрендә, мәсәлән, җәдитлек дошманнары чиркангыч итеп сурәтләнгән. Мондый публицистик алым исә әсәрләренең укучылар арасында тиз танылуына да китерә.

Татар халкын да читтә калдырмаган иҗтимагый-сәяси күтәрелеш елларында язылган әсәрләрендә Ф. Кәрими татар интеллигенциясе вәкилләре арасындагы яңа тип кешеләрне шактый кискен һәм мыскыллап тасвирлый. Менә аларның кайберләре — вакытларын нәтиҗәсез гамәлдә уздыручы, сайлаучылар ихтыяҗын күптән оныткан депутатлар, түрәләргә тәлинкә тотучы оятсыз журналистлар... Ф. Кәриминең кайбер геройлары бик тә озын гомерле булып чыкты, аларга

охшашларны бүгенге тормышта да очратырга мөмкин. Кәриминең каләме Г. Исхакый, Ф. Туктаров кебек танылган эшлекләрне дә «чеметә».

Фатих Кәриминең ул чакта Россия әдәбиятында, хәер, Европа әдәбиятында да, тиңе-бердәйлеге булмаган китабы турында аерым әйтергә кирәк. Сүз 1913 елда басылган «Истанбул мәктүбләре» хакында бара. Бу мәктүбләрнең (хатларның) тарихына кыскача тукталыйк. 1912—1913 елларда Балканда берничә сугыш кузгала, бу сугышларда Төркия, Болгария, Греция, Италия катнаша. Әлеге сугышлар тиздән башланачак бөтендөнья сугышының үзенә күрә репетициясе төсен ала. Ф. Кәрими, хәзергечә әйткәндә, «кайнар нокта»да ел чамасы «Вакыт» газетасының хәбәрчесе вазифасын үти. Телләр белүе, университет буенча күп кешеләр белән элемтәләре аңа генераллар һәм солдатлар, галимнәр һәм язучылар, бизнесменнар һәм руханилар, мөгаллимнәр һәм һөнәрчеләр белән аралашырга ярдәм итә. Мондый очрашулар һәм күзәтүләр Ф. Кәриминең «Вакыт» газетасында кайчакта атнага берничә тапкыр басылган җитмешләп хәбәренең нигезен тәшкил итә.

Әлеге мәкаләләрдән 450 битле китап җыела, һәм ул, әйткәнебезчә, 1913 елда басылып та чыга. Китап бөтендөнья сугышы башлану алдыннан Төркия тормышының үзенә күрә энциклопедиясе булып тора. Бу илдә Ф. Кәриминең студентлык еллары уза, анда җәмгыятьнең төрле өлкәләрендә аның күпсанлы дуслары була, һәм язучы Төркия дәүләтенә хөрмәтен яшерми. Шулай да ул Төркиянең сугышта уңышсызлыкларга дучар булулары сәбәбе дошманнарының көчлелегендә түгеллеген, бәлки илнең үзенең куәтсезлегендә икәнлеген билгеләп үтә. Ф. Кәрими җиңү өчен пулеметлар һәм туплар гына җитмәве, ә сәясәттә, икътисадта һәм диндә карагруһчылыктан азат итү кирәклеге турында яза, ягъни Төркияне кризистан чыгарырга сәләтле лидерлар азатлык белән бергә генә килергә мөмкин. Һәм бу очракта аның фикере белән килешмичә булмый, хәтта һич тә ярамый.

Россия белән тотрыклы элемтәдә булу Төркияне чәчәк атуга китерүнең бер шарты икәнлеге китапта басым ясап әйтелә. Кәрими Россиядә мөселманнарга каршылык кылуларның ясалма күпертелүен дә җавапсыз калдырмый. Ул Россия яки Иран мөселманнарын Төркия канаты астында берләштерү идеясен күпчелек төрекләрнең саташу итеп санавын яза.



«Шура» журналының редколлегиясе. *Сулдан уңга:* Габдрахман Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Рәкыйб Рәкыйби, Риза Фәхретдинов, Госман Акчокраклы, Закир Рәмиев *(Дәрдмәнд)*, Ярулла Вәли, Борһан Шәрәф.

*Оренбург, 1909.*

Татарның рухи тормышын әйдәп баручылар Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан Ф. Кәрими иҗатының йомшак якларын еш кына искәртәләр, аның кайбер хикәяләре турында зәһәр чәнчүле кисәтүләр дә ясыйлар, ә «Истанбул мәктүбләре»н исә мактыйлар. Тукай бу китапны, уйлану өчен «рухи азык», дип атый. Күренекле рус галиме, шәркыятче В. Гордлевский, Кәрими китабын игътибар биреп укыгач, бу «читтән караш» төрек җәмгыятенә үз кимчелеген җитәрәк күрергә ярдәм итте, дип яза. Болгарларны һәм серләрны яклауда гаепләүләргә җавап итеп, Кәрими үз кимчелекләрен белгән халыкның боларны җиңелрәк бетерә алуын тагын бер тапкыр искәртә. Ләкин бу сүзләрнең дөреслеген аңлау өчен, Төркиягә, бөтендөнья сугышында катнашучы башка илләр белән бергә, канлы кырылышлар дәһшәтен татырга туры килә.

Ф. Кәриминең наширлык эшчәнлегенә киң колачлылык һәм эзлеклелек хас. Ул чыгарган күп кенә басмалар энциклопедик эчтәлекле, шул ук вакытта җәмгыятьнең иң киң катлауларына аталган бу китаплар яхшы аңлаешлы. Кәриминең мондый эшчәнлеге Россиядә әйбәт китапларны күпләп бастырып масса-күләм халәгә әверелдергән күренекле наширлар Сытин һәм Павленков хезмәтләрен хәтерләтә. Төрки телле мөселманнар өчен Ф. Кәрими дә нәкъ шундый ук эш башкара, ул чыгарган күп кенә китапларны Урта Азиядә дә, Кавказ артында да бирелеп укыйлар. Менә Кәрими тормышка ашырган киң колачлы проектларның берсе.

Күренекле тарихчы һәм географ поляк Фелициан Пуцекович дөньяның төрле халыклары турында әйбәт аңлаешлы уннарча брошюралар яза. Нигезле мәгълүматлардан файдаланып, тасвирлы итеп язылган бу китапчыклар бик күп илләрдә киң тарала. Кәрими 42 брошюраны татарчага тәрҗемә итеп чыгарырга исәпли. 1914 елга чаклы 26 брошюра укучыга барып ирешә. Нашир сериянең кайбер китапчыкларына кереш сүзендә татар җәмәгатьчелегенең көн үзәгендәге мәсьәләләренә тукталa. 1904 елның ахырында дөнья күргән, Япониягә багышланган беренче брошюрада Фатих Кәрими, инде берничә ай сугыш барса да, татарларның аның кузгалу сәбәпләрен аңламавын гына түгел, ә күпләрнең хәтта бу илнең кайдалыгын һәм анда кемнәр яшәвен белмәвен искәртә. Японнар хак мөселманнар икән дә, дип дәвам итә автор, алар кытайлыларны да үз диннәренә тартырга тырышалар икән, Россия исә моңа каршы төшкән дә шуңа күрә сугыш купкан, имеш...

Гарәпләргә багышланган китапчыкта Кәрими туган теленне һәм изге Коръән телен үзләштергәннән соң ук рус телен өйрәнергә кирәклеген әйтә. Европача киң карашлы, укымышлы Фатих Кәрими милли чикләнгәнлекнең килешмәүчән дошманы була. Заманының күп кенә фикер ияләренә хас булганча, ул шул вакытта модада саналган социалистик идеяләрне яклый, бу өлкәдәге кануннарга ахыргача ышанмаса да, төрле демократик юнәлештәге китаплар һәм брошюралар бастырып чыгаруда булыша. Мондый хәл властьларның ачуын куптара, мөхәррир һәм нашир Фатих Кәримине аерым очракларда хөкемгә һәм административ җаваплылыкка тарталар. Шулай да эш гадәттә штраф салу белән бетә, монда Кәриминең яклаучылары-химаячеләре бертуган Рәмиевләр булуы роль уйнавы шиксез. Рәмиевләр гаиләсе Фатихның күп кенә башлангычларына фатиха биргән Шакир 1912 елда поездга тапталып вафат булганнан соң да ярдәменнән ташламый.

Самодержавиене бәреп төшереп, империя хәрабәләрендә дәүләт һәм милли төзелешнең яңа формаларын җәһәтләнеп эзләгән чорда Фатих Кәрими мөселман хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе булып танылa. 1917 елның маенда ул, Россия мөселман дөньясының иң абруйлы унике эшлеклесе исәбендә, Бөтенроссия съезды президиумына сайлана. Ф. Кәрими яңа Россияне, аның халыкларына киң хокуклар биреп, федератив нигездә коруны тырышып яклый. Үзенең бер чыгышында ул читтәге халыкларга алга киткән төбәкләр дәрәҗәсенә ирешү өчен тарихи мөмкинлекне файдалануда ярдәм итәргә кирәклеген әйтә. Шәрыкның шартлары үзгә, ди ул, Тамбов губернасын Төркестан белән бутарга ярамый. Шул ук съездда Ф. Кәрими Россия мөселманнары шурасына бер тавыштан сайлана. Казанда уздырылган Икенче мөселман съездында да ул абруйлы лидерларның берсе булуы дәрәҗәсен саклый, аны, Садри Максуди, Һади Атласи, Ибнеәмин Әхтәмов кебек танылган эшлеклеләр белән бергә, «Идел-Урал» җөмһүрияте төзү планын тормышка ашырырга тиешле үзидарә комиссиясенә сайлыйлар.

Фатих Кәрими гражданнар сугышының иң кызган чагында да анда турыдантуры катнашмый. Шулай да ул большевиклар хәрәкәтенә һәм, гомумән, социалистик идеяләргә теләктәшлек күрсәтә. 1925 елга чаклы Кәрими Оренбургның төрле уку йортларында эшли, халык мәгарифенең яңа системасын булдыруда

булыша. Аерым алганда, «Хөсәения» мәдрәсәсен үзгәртеп кору — аның хезмәте. Бу үзгәртү киң танылган уку йортына совет укытучылары әзерләү үзәге сыйфатында үз статусын саклап калырга мөмкинлек бирә.

1925 елда Мәскәүгә күчкәч, Ф. Кәрими төрле нәшриятларда эшли, шул чакта Нариманов исемен йөрткән Шәрыкны өйрәнү институтында төрек телен әйбәт укытучы булып таныла. Мәскәүдә яши башлаган елында ук аның сайланма хезмәтләре һәм хикәяләре җыентыгы дөнья күрә. Әмма гаилә хәлләре, шулай ук иҗтимагый-сәяси чолганыш әдәби иҗат белән актив шөгыльләнергә мөмкинлек бирми. Вакытлы матбугатта аның кечкенә рецензияләре һәм мәкаләләре дә сирәк басыла.

Егерменче гасырның беренче чирегендә Фатих Кәрими башкарган эшләр төрки халыклар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихына керергә һичшиксез лаеклы. Соңгы елларда ул истәлекләр яза башлый, мөселман дөньясының күп кенә күренекле шәхесләре аларның үзәгендә тора. Ләкин аңа бу истәлекләрен язып тәмамлау насыйп булмый.

Солтангалиев эше белән бәйле рәвештә милли зыялыларны юк итүнең беренче өянәге Фатих Кәримигә читләтеп кенә кагылса, ягъни НКВДда аңардан берничә тапкыр сорау алу белән чикләнсәләр, 1937 ел аның өчен һәлакәтле булып әверелә. 1936 елда «Идел-Урал» эше әвәләнә, аның баш өлешендә үк татарлар һәм башкортлар арасында көнбатыштан да, көнчыгыштан да дошман агентурасы ятьмә салуы әйтелә. Электәге «Шахта эше» яки «Промпартия эше» процессларыннан үзгә буларак, хәзер органнар гаеп ташлауларның хәтта якынча гына булса да чынлыкка охшавына игътибар да итеп тормыйлар. Мәсәлән, Мәскәүнең өлкән яшьтәге мулласы Абдулла Шәмсетдинов (Фатих Кәриминең дусты), гестапо кушуы буенча, Мәскәүдә ...өч заводны, дүрт күперне һәм берничә тимер юл вокзалын шартлатырга җыенган икән. Хәтта дәһшәтле сугыш елларында да немецларның махсус хезмәтләре һәм авиациясе Мәскәүдә мулла «вәгъдә иткән» җимерү эшләренең уннан берен дә кыла алмадылар. Бу яман заманнарда тикшерүчеләр әнә шундый «романнар» иҗат итәләр.

Фатих Кәрими һәлакәткә алдан ук дучар ителгән була, күрәсең. Өстәвенә тормыш юлы да чираттагы «фаш итү» эше оештырырга ымсындырып тора. Аның биографиясен белгән тикшерүчегә Ф. Кәрими өстенә нинди гаепләр өяргә кирәклеге турында озак уйланырга туры килмәгәндер. Төркиядә укыганмы? Укыган! Димәк, бу ил жандармериясе аны инде 1894 елда ук яллаган. Аңа төрек разведкасы «шефы» итеп танылган педагог, Истанбулда укучы татар яшьләре оешмасы җитәкчесе Гобәйдулла Бубиины «билгелиләр». Ә Кәриминең «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы хәбәрчесе сыйфатында Балкан сугышында булуы — шпионлык бурычларын үтәвенә кире кагылмаслык дәлил, имеш. Кем кушкан бурычны үтәгән соң ул? Тикшерү эшендә монысын күрсәтергә «онытканнар».

Шпионлык итүдә һәм диверсия әзерләүдә күренекле эшлеклеләр — Ильяс Алкин, Шамил Усманов, Кави Нәҗми һәм бу вакытка инде атып үтерелгән Абдулла Шәмсетдинов Ф. Кәриминең «агентлар»ы булганнар, имеш. Хәтта чит ил «резидентлар»ы да атала — Кәрими Шакир-паша, Й. Акчура һәм Г. Идриси боерыкларын үтәгән икән. «Шпионлык итүче һәм диверсия әзерләүче» төркемнең болай ук чуарлыгына гаҗәпләнергә кирәкми — бу кешеләр, нигездә, Мәскәүгә нәшрият эшләре ветераны янына әдәби иҗат мәсьәләләре буенча килүчеләр яки аның революциягә чаклы ук танышлары була. Мондый хәлләр кешеләрне фаҗигале язмышка китермәсәләр, көлке генә булып тоелырлар иде, әлбәттә. Һәм әлеге фаҗига иң зыялылар гомерен кисә, ә андый бөекләр һәр ун ел саен туып тормыйлар бит.

Дөрес, күзәтүчеләрнең Ф. Кәриминең шпионлык мәгълүматларын чит ил кешеләренә бирүен күргәннәре булмый. Әмма бу мәсьәләнең дә ансат чишелеше табыла! Тикшерүчеләр юрамасы буенча, Фатих Кәрими 1936 елда саклану заводлары һәм Кызыл Армиянең коралланы турындагы яшерен мәгълүматларны ...Мәскәүгә килгән төрек футбол командасы тренеры Кәрим-бәйгә «төрткән», имеш!

Гаебен танытуда һәм төрле мәгълүматлар алуда нинди ысуллар кулланылуы турында сөйләүнең кирәге юктыр, мөгаен. Әйе, Фатих Кәримине «чишелергә» мәҗбүр итәләр...

Бу язманы Югары Советның Хәрби коллегиясе хөкеме карарыннан башлаган идек. Коллегиянең шул көнге утырышында тагын берничә татар кешесенең эше карала. Хөкем ителүчеләр арасында Татарстанның элекке премьеры, соңыннан Мәскәү дәүләт университетының Шәрык халыклары кафедрасы мөдире Хаҗи

Габидуллин һәм дивизия командиры, Зәки Вәлидинең көрәштәше, соңрак кыю кызыл кавалериячe, гаскәре белән деникинчыларны һәм полякларны куркуга төшерүче башкорт Муса Мортазин да була. Һәм аларны да шул ук көнне аталар...

Ә аннары яшәеш юклыгыннан кайтуның зур көенечле юлы башлана. Илленче елларда Фатих Кәримине аклыйлар, аның тапсыз, яхшы аты кире кайтарыла игъни. Бу хәбәр Фатихның уллары Ибраһимга һәм Фәриткә ирешә. Шулай да бер нәрсәдә, шул чактагы инструкция буенча, ялган «җибәрелә» — Фатих Кәрими 1945 елда үлгән булып күрсәтелә, аның гомерен сигез елга «озайталар» игъни. Җитмешенче елларда исә татар рухи дөньясына зур өлеш керткән, әмма инде онытылган һәм яла ягылган бик күп шәхесләрнең яхшатларын халыкка кайтаруда олы хезмәтләр башкарган тынгысыз-тырыш Мөхәммәт ага Гайнуллин китабында Фатих Кәриминең 1937 елда үтерелүе төгәл әйтелә. Әйе, Фатих Гыйлман улы Кәриминең тапланмас исеме әнә шундый коточкыч явызлыклар кылу белән тамгаланган яман 1937 елдан тарихка әйләнә.

**Булат СОЛТАНБӘК.**

◆


## БЕРГӘ БУЛЫЙК!


Без әле кайчан гына укучыларыбызга «Ватаным Татарстан» газетасына язылуның чираттагы нәтиҗәләрен хәбәр иткән идек. Матди кыенлыкларга, хезмәт хакларының һаман да тоткарлануына карамастан, 1996 елның беренче яртыеллыгында безнең сафлар ай саен йөзәрләп тә, меңәрләп тә арта торды. Бүгенге көндә тиражыбыз — 58 712 данә.

Инде менә заман күпләребез алдында янадан шул ук сорауны куя: 1996 елның икенче яртысында да бергә була алырбызмы? Бу сорауга укучыларыбыз үзләре җавап бирәчәк. Һәрхәлдә, аларның алга таба да безнең белән дус булып калачакларына ышанабыз. Безнең даими авторларыбыз — күпсанлы хәбәрчеләр, тәҗрибәле журналистлар, күренекле галимнәр һәм әдипләр. Газетаның һәрчак: «Әссәламегаләйкем, кардәшләр-милләттәшләр!» — дип сәламләп торуын теләсәгез, үз вакытында «Ватаным Татарстан»га язылып куярга онытмагыз.

1996 елның икенче яртысына язылу бәясе — 32 400 сум.
Индекс — 54123.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасы редакциясе.

# ФУАД ТУКТАРОВ



Егерменче гасыр башларында татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, язучы Гаяз Исхакыйның дусты һәм көрәштәше булган Фуад Фәсах улы Туктаровның кем икәнлеген белмәгән, аның турында ишетмәгән бер генә укымышлы татар да булмагандыр, мөгаен.

Гаҗәеп күпкырлы талантка ия бу шәхеснең тормышы һәм эшчәнлеге ничәмә-ничә дистә еллар буена тарихи хезмәтләрдә булсын, әдәбиятта булсын, һаман да кара тамга белән тамгаланып килде: аны 1918 елда Мулланур Вахитовны атып үтерергә фәрман бирүдә гаепләделәр. Соңрак, инде Фуад Туктаров чит илгә чыгып киткәч, аңа шпион мөһере сугылды. Заманы шундый булган: эмигрант икәнсең, димәк, син — шпион... Гаяз Исхакый белән Фуад Туктаров совет чоры әдәбиятында, бигрәк тә шигырьләрдә, һәрвакыт сүгелеп, һәрвакыт каһәрләнеп килделәр. Мәсәлән, 1930 елда Мәҗит Гафури «Агулы хыяллар» исемле шигырендә аларны Пилсудский ялчылары дип тирги, хуҗасына ярарга тырышып, Советларга каршы өргән ике эт дип атый. Мондый «шигъри бәяләмәләр» шул чор совет матбугатында даими басыла килгән ялган, уйдырма мәкаләләр тәэсирендә «иҗат ителгәннәр», әлбәттә.

Инде хәзер Фуад Туктаровның берниндә дә чит ил шпионы булмавын, Мулланур Вахитовны сатып, аны үлемгә хөкем итүче дә түгеллеген исбатлап торырга кирәкмидер. Әлеге уйдырмаларны раслый торган бертөрле дә рәсми белешмә-документлар юк һәм булмаган да.

Дөрес, милли азатлык хәрәкәтенең күренекле бу ике эшлеклесе — Мулланур Вахитов белән Фуад Туктаров, төрле сәбәпләр, төрле шартлар аркасында, икесе ике юлдан китә. Мәкалә-чыгышларында да алар бер-берсен аяп тормыйлар.

Төрле мәсләктәге сәясәтчеләрнең үзара шулай тиргәшүләре февраль инкыйлабыннан соңгы Рәсәйдәге сәяси бәхәсләр өчен гадәти күренеш була. М. Вахитов Ф. Туктаров адресына «шамакай», «уртакул нотыкчы», «сәяси базардагы әрсез маклер» кебек сүзләр ыргыта икән — болар инде «иркле Рәсәй сәясәтчеләре»нең «джентльменнарча әдәпле» сүзлегендәге иң усал гыйбарәләрдер дип уйламагыз. Аннан тозлыраклары да күп булган. Ф. Туктаров та үзенә каршы чыгучыларны аяп тормаган, шулай ук тозлап-борычлап җавап бирә белгән. Юкка гына үзен «Усал» псевдонимы белән йөртмәгән инде ул! Ул чордагы сәяси уен, сәяси бәхәсләрнең әдәп кагыйдәләре шундый булган. Хәер, бүгенге Рәсәй сәясәтчеләре дә шул кагыйдәләргә таянып «уйныйлар» түгелме соң?

Ләкин Комуч сәясәтчеләре (Комуч — Учредительное Собрание әгъзалары Комитеты. 1918 елның июнендә Самарада төзелгән.) арасында кечәге сәяси

«дошманнарын» физик үтерү юлына баскан бер генә татар кешесе дә булмый. Ф. Туктаров фикердәшләре дә, М. Вахитов көрәштәшләре дә әле кайчан гына патша самодержавиесенә каршы кулга-кул тотынып, иңгә-иң торып көрәшкән социалистлар була. Хәзер алар мәсләкләрендә капма-каршы фикердә булсалар да, үзләренең «уртак бишек»ләрен онытмыйлар. Ф. Туктаров та шул «бишектән» тәпи басып киткән сәясәтче була. Сөйләгәннәргә мисал итеп бер факт китерәбез: элекке Хәрби Шура әгъзасы, хәзер исә Комуч рәисе урынбасары И. Алкиннар йортында М. Вахитовның абзасы, танылган большевик Исхак Казаков аклардан качып ята.

...Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостендагы Күлбай Мораса авылында яшәүче танылган дин әһеле Фәсах хаҗи мулла Туктаровның унбиш яшьлек хатыны Мәфтуха 1880 елның 5 февралендә дөньяга бер ир бала китерә. Балага Мәхмүд-Фуад дип исем кушалар.

Фуад зиһенле бала булып үсә. 1901 елны ул Чистай мәдрәсәсеннән шактый төпле белем алып чыга. Әмма аның белән генә канәгатьләнми, үзенең укуын Казандагы татар укытучылар мәктәбендә дәвам итәргә карар кыла, шул ниятен тормышка ашыру теләге белән Казанга килә.

Татарлар арасыннан урыс сыйныфларында укытучылар әзерләү максатыннан 1876 елда ачылган Казан татар укытучылар мәктәбе чын мәгънәсендә татар зыялыларының милли үзаңын тәрбияләүче үзәккә әверелә: бу мәктәптә татар халкы тарихында күренекле урын тоткан бик күп шәхесләр — М. Солтангалиев, С. Максуди, Г. Исхакый, Х. Ямашев, Ш. Мөхәммәдьяров, Терегуловлар, Акчуриннар һ. б. укып чыга.

Мәктәптә укыган елларында Ф. Туктаров үзенең якташы Г. Исхакый белән дуслашып китә. Милли азатлык көрәшендә бер мәсләктә булган бу ике дус алга таба озак еллар буена кулга-кул тотынып эшлиләр. Егетләрнең язмышларында охшашлыклар да байтак: һәр икесенең әтиләре муллалар һәм балаларын да мөселман гореф-гадәтләре, мөселман мәдәнияте рухында тәрбияләгәннәр, һәр икесе Чистай мәдрәсәсендә белем алган, яшьләре белән дә бер чама — Гаяз Исхакый Фуад Туктаровтан ике яшькә генә өлкәнрәк. Мәктәптә укыганда ук аларның фикерләүләре һәм дөньяга карашлары тәңгәл килә. Провокатор Тәхфәтулла Мәмлиев (ул да шул мәктәптә укыган) әле 1895—1900 еллар арасында ук мәктәптә яңа татар әдәбиятын өйрәнү түгәрәге оештырылган иде, дип искә ала. Әлеге түгәрәкнең сәяси йөзе тонык кына шәйләнсә дә, киләчәктә танылган татар сәясәтчеләре булып китәчәк Садри һәм Һади Максудилар, Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Гомәр Терегулов, Фуад Туктаровлар иң актив түгәрәк әгъзалары булалар. Г. Исхакый истәлекләренә караганда, 1901 елда (Фуадның мәктәпкә килгән елы була бу) укучы яшьләрнең «Шәкертлек» җәмгыяте оештырыла. Аның яшерен гәзите «Тәрәккый» чыгарыла башлый. Г. Исхакый мәктәпне тәмамлап чыкканнан соң, «Шәкертлек»нең фактик җитәкчесе булып Ф. Туктаров кала.

1905 елгы инкыйлаб шәкертләрнең аңына да зур йогынты ясый. Алар арасында урыс сәяси партияләренә, шул партияләр күтәреп чыккан лозунг-шигарьләргә теләктәшлек белдерүчеләр барлыкка килә. Мәктәп түгәрәгендә чыныгу алган бер төркем яшьләр — Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Х. Ямашев, Ш. Мөхәммәдьяров һ. б.— 1905 елда Казанда «Таң» исемле гәзит чыгара башлыйлар. Мөселман яшьләре арасында кискен-каттый фикерләре белән аерылып, сәяси карашлары Рәсәй эсерларына (социалист-революционерлар) якын торган бу төркем озакламый «Таңчылар» дип йөртелә башлый. Шул ук елны «Таңчылар» Түбән Новгородта (мишәрчәләп әйткәндә, Нижгарда) үткәрелгән Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда катнашалар. Корылтайда Мөселманнар берлеге «Иттифак»ка нигез салына. «Таңчылар»ның бу корылтайны оештыруда алдан ук актив катнашулары билгеле: 1905 елның май ахырларында, Чистайда Камаловлар йортында булган туй мәҗлесеннән файдаланып, алар үзләренең киңәшмәләрен үткәрәләр, шунда корылтай мәсьәләсе дә карала. Аны Мәкәрҗә ярминкәсенә туры китереп үткәрергә карар кылына. 10 августта Мәкәрҗәгә мөселманнарның бик күп сәясәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре җыела. Губернатор корылтайны Мәкәрҗәдә үткәрергә рөхсәт бирми. Шул сәбәпле, 150 ләп кеше җыелып, аны Ука (Ока) елгасы өстендә — «Густав Струве» пароходында оештыралар. Шунысы кызык: корылтайны оештыручылар анда «сул» радикаллар — «Таңчылар»ның катнашуын бик үк теләмәгәннәр, күрәсең — пароход билгеләнгән вакыттан ярты сәгать алдан кузгалып китә, яшь татар эсерларына аны баркаста куып җитәргә туры килә.

Эсерлар партиясенең Идел буе комитетына автоном башлангычта, ягъни үзидарә хокукы белән кушылган, татар шәкертләре арасында «Берек» түгәрәге оештырып, активлык җәелдереп җибәргән «Таңчылар» төркеменең эшчәнлегє хөкүмәт вәкилләрен дә борчый башлый. «Таңчылар» өстеннән даими күзәтчелек алып барыла. Казан губерна жандарм идарәсе Фуад Туктаровның да һәр адымын күзәтеп тора. 1905 елның 21 июнендә аның фатирында тентү үткәрелә, егет беренче тапкыр кулга алына.

Аннан соңгы берничә елда Фуад Туктаров, милли карашларын эсерлык карашлары белән бергә үреп, милли хәрәкәттә дә, эсерлар партиясе эшчәнлегендә дә актив катнаша.

Икенче Дәүләт Думасына сайлауларда шактый урын (37 депутат) яулаган эсерлар 1907 елның февралендә Таммерфорста үзләренең Икенче ашыгыч корылтайларын үткәрәләр. Анда аларның Думада тотачак сәяси тактикалары хакында фикер алышу була. Фуад Туктаров ул корылтайда эсерлар партиясенең Идел буе комитеты каршындагы татар үзәге вәкиле сыйфатында катнаша. Рәсәй эсерлары Думада мөстәкыйль фракция оештырырга карар кылгач, мөселман депутатлары да үзләренең группаларын оештыралар. Петербургка «Таңчылар»ның җирле бүлеген төзү өчен Фуад Туктаров җибәрелә. Ул анда мөселман депутатларының Думадагы группасына бик тырышып ярдәм итеп йөри. Әмма, мәгълүм булганча, Икенче Дәүләт Думасы озак эшли алмый — 3 июньдә патша хөкүмәте тарафыннан куып таратыла.

Ул елларда Фуад Туктаров татар матбугатында талантлы публицист-журналист буларак таныла. Аның яшьлегендә татар укытучылар мәктәбендә яшерен чыгарылып килгән «Тәрәккый» газите битләрендә сыналган каләме хәзер Уральскидагы «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр») журналы, Казандагы «Таң йолдызы» газитләрендә чарлана-үткенләнә. «Таң йолдызы» — «Таңчылар» төркеме органы булган «Таң» газитенең дәвамчысы, ә Фуад Туктаров аның мөхәррирләреннән берсе була. Татар публицистикасы тарихында Фуад Туктаров ачы үткен телле журналист буларак билгеле. Соңрак ул Беренче, Икенче, Өченче Дәүләт Думаларындагы мөселман депутатларның эшчәнлеге турында, һәр депутатның сурәтрәсеме һәм биографияләрен урнаштырып, ачы тәнкыйтьле китабын «Усал» псевдонимы белән бастырып чыгара.

Фуад Туктаров 1911 елда, үзлегеннән әзерләнеп, Казандагы Икенче гимназиядә өлгергәнлек аттестатына имтихан тота һәм Казан университетының юридик факультетына укырга керә. Инде җитди сәясәтче һәм публицист булып җитлеккән 31 яшьлек Фуад ни өчен соң әле яңадан дәресләргә тотына, ни өчен парта арасына утыра? Мулла әтисе бала чагыннан ук белемгә мәхәббәт тәрбияләгәнлектән генәме? Әллә һәр заманда да дәрәҗәле саналган юрист һөнәрен аласы килгәнлектәнме? Юктыр, алай гына булмас. Юристлык һөнәре, гамәлдәге законнарны биш бармагың кебек белергә омтылу ул елларда сәяси көрәш юлына баскан күп яшьләрне кызыктыра. Казанда гына түгел, Петербургта да үзенең көрәштәшләре белән төрле бәхәсләрдә еш аралашкан Фуад Туктаров тирән белем кирәк булачагын да аңлагандыр. Һәм ул, әйбәт кенә укып, университеттан 1915 елның язында юрист дипломы алып чыга.

Алай да студентлык еллары Фуад өчен авыр чор була. Ул вакытта әтисе инде үлгән, Фуадка әнисе һәм өч сеңелесе турында кайгыртырга кирәк. Ул әнисенә авылда йорт салдырта, ара-тирә генә эшләп тапканыннан шул йорт өчен әҗәтен түли, кайчакларда университетта укыганына үз вакытында түли дә алмый кала. Фуад үзенә матди ярдәм күрсәтүләрен — пособие билгеләүләрен сорап мөрәҗәгать итсә дә, Казан укыту округы попечителе «христиан булмаган инородец»ның үтенечен кире кага. Бирегә егетнең сәяси яктан бик үк ышанычлы булмавы да үзен сиздергәндер: әле 1911 елның августында ук Казан губерна жандарм идарәсе университет студенты Газиз Гобәйдуллинның (киләчәктә танылган татар тарихчысы) татар шәкертләре арасында «Казан мөселманнары түгәрәге» оештыруы хакында хәбәрдар була. Бу түгәрәк эшендә Ф. Туктаров та катнаша.

Матди кыенлыклары янына Фуадның мәхәббәт газаплары да килеп өстәлә: университетта укыганда ул бер марҗа кызына гашыйк була. Аның газаплы мәхәббәт кичерешләре турында, күп еллар үткәч, күренекле башкорт сәясәтчесе Зәки Вәлиди искә ала. 1913 елның җәендә ул Фуад Туктаровны Көньяк Уралга — үзләренең туган авылына ялга — кымызга чакыра. Моңа кадәр тәмәкене авызына да алып карамаган Фуад авылда үткәргән ике ай эчендә тәмәке тарта башлый, сөйгән кызыннан килгән хатларны «көнгә берничә тапкыр кат-кат укый». Бер дустының кабере янында үсеп елаган Зәки Вәлидине йомшаклыкта гаепләгән, хисләрен тышка чыгармыйча, эчендә саклый белә торган егет үзе дә бер мәлгә җебеп төшә.

Әмма шуны әйтергә кирәк, студентлык елларында да Фуад Туктаров сәяси һәм журналистлык эшчәнлеген туктатмый. Аның университетта укыган чорына караган кызыклы гына рәсми кәгазьләр сакланып калган. Мәсәлән, 1914 елның 6 маенда Казан укыту округы попечителе, Казан губернаторы мәгълүматларына таянып, университет ректорына Ф. Туктаров турында болай дип хәбәр итә: «...ул Казанда булгалап кына китә, нигездә башка шәһәрләрдә, күбесенчә Санкт-Петербургта рөхсәтсез-нисез генә яши; аерым алганда, 1913 елның азагында һәм 1914 елның башында ул Петербургта тора, Казанга февраль урталарында кайта, ә февраль ахырларында яңадан Петербургка китә; шул ук вакытта ул университет канцеляриясеннән торырга рөхсәт кәгазенең икенчесен алганда, беренчесен тапшырырга тиеш булса да, аны тапшырмый калдыра, шулай итеп, законсыз рәвештә ике рөхсәт кәгазе белән файдалана». Күрәсез, ничек уяу күзәтәләр! Бу, әлбәттә, җитди гаепләү була. Студент Фуад Туктаров өстендә болытлар куера башлый. 1914 елның 28 маенда ректор исеменә язган аңлатмасында Фуад рөхсәт кәгазенең берсе тапшырылмый калуны гади аңлашылмаучылык дип күрсәтә, ә үзенең Петербургка еш барып йөрүләрен матди хәленең авырлыгы, «мәктәптә үк бергә укыган сабакташы» аны каникул көннәрендә бер конторада эшләп алырга чакыру белән бәйләп аңлата. Университет проректоры профессор А. А. Овчинниковның үзенә карата булган яхшы мөгамәләсе Фуадны артык зур күңелсезлекләрдән саклап кала. Проректор эшне дисциплинар судка кадәр үк җиткерми, «үрнәк булырлык әйбәт студент»ның үз гаепләрен чын күңелдән тануын искә алып, аның аңлатма язуына «каты шелтә белдерү белән чикләнергә» дигән резолюция сала. Шулай да, Фуад Туктаровның аңлатмасы бөтенләй үк чын күңелдән булмагандыр дип уйларга нигез бар, Петербургка аны «бераз акча эшләп алу өмете» генә тартмагандыр, әлбәттә.

1905 елгы һәм 1917 елгы ике инкыйлаб арасындагы чор татар журналистикасының гөрләп үскән чоры була: Рәсәйдә мөселман төркиләре телендә чыгарыла башлаган 166 газитнең 62 се Казан татарлары телендә басыла. Шуларның 22 се Казанның үзендә чыгып килә. Казандагы күп кенә газит-журналларга даими язып торучы журна'лист һәм сәясәтче Ф. Туктаров үзенең дусты Гаяз Исхакый белән берлектә Петербургтагы «Ил» газитендә мөхәррирлек итә («мәктәптә үк бергә укыган сабакташы» бер конторада тәкъдим иткән эш шул булмадымы икән?). Фуад бу газиттә 1913 елның сентябреннән башлап мәкаләләрен бастырып килә. 1914 елда газит Мәскәүгә күчерелә, Г. Исхакый анда кайбер бай татар сәүдәгәрләренең матди ярдәме белән типография ачып җибәрә.

Нәкъ менә шул чорда — беренче бөтендөнья сугышы алдыннан «Таңчылар»ның сәяси карашларында кискен борылыш ясала. «Ил» газитендә басылып чыккан материалларда, шул исәптән, Ф. Туктаров мәкаләләрендә дә, сыйнфый көрәш идеяләренә капма-каршы буларак, милләтнең бердәмлегенә, милли мөстәкыйльлеккә чакыру авазлары торган саен ешрак яңгырый башлый. Мәсәлән, Ф. Туктаровның «Ил» газитендә 1914 елның 29 мартында басылып чыккан «Милләтчелек вә сәясәт» исемле мәкаләсендә милләт мәнфәгатьләренең беренче урында торырга, Дүртенче Дәүләт Думасындагы мөселман депутатларының эш-хәрәкәтләре дә шуңа юнәлдерелгән булырга тиешлеге хакында языла. Думадагы мөселман фракциясенең үз тактикасы булырга тиеш. Әмма нинди тактика? Алты кешелек кечкенә төркем, үз каланчасыннан торып, бүген «прогрессистлар»ны, ә иртәгә «уң»нарны үзенә каршы куйса, нәрсә булыр? Мондый сәяси сукырлыктан сакланырга кирәк. Вакытлыча булса да, көчлерәкләр артына ышыклану зарур. «Уң»нар да, «октябристлар» да түгел, көчлеләр бары тик «прогрессистлар» гына булыр. Ф. Туктаровның бу фикерләре аның инде сыйнфый көрәш идеяләреннән ваз кичеп, милли көрәш идеяләренә бирелгән акыллы һәм хәйләкәр сәясәтче булып үсеп җиткәнлеген күрсәтә.

1917 елның февраль инкыйлабына кадәр Ф. Туктаров Казанда яши, адвокатлык итә, сәяси һәм журналистлык эшчәнлеген дә онытмый.

1917 елның мартында Казанда мөселманнарның гомуми җыелышы була. Анда Мөселман Комитеты төзелә, соңрак ул Милли Шура итеп үзгәртелә. Комитетның рәисе итеп Фуад Туктаров сайлана. Комитет игълан иткән программада азчылыкта булган халыкларның милли хокукларын тәэмин итү зарурилыгы, Рәсәйнең дәүләт төзелеше федератив формада булырга тиешлеге күрсәтелә. Эшчеләр мәсьәләсе буенча меньшевик социал-демократлар таләбе, җир мәсьәләсендә эсерларныкы кабул ителә; милләт мәнфәгатьләрен яклау өчен аерым хәрби мөселман частьләре төзү күздә тотыла; агымдагы бурычлар итеп һәркайда мөселман комитетлары оештыру, сугышны тизрәк бетерү, Учредительное Собраниены чакырту, Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнары корылтаен үткәрү мәсьәләләре билгеләнә.

Мөселман Комитеты белән җитәкчелек иткәнә халдә, Фуад Туктаров тиздән Казан шәһәр управасының мөселман фракциясе рәисе дә булып ала, ә 1917 елның 2 июленнән Милли Шура органы булган «Корылтай» газитен оештыра һәм аңа мөхәррирлек итә. 1917 елның маенда ул — Мәскәүдә үткән Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтае делегаты, аннары июль аенда Казанда үткәрелгән Мөселман хәрби корылтае делегаты була. Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда аны Бөтенроссия Мөселман Советы (Милли Шура) әгъзалыгына кандидат итеп сайлыйлар, ә корылтайдан соң ул Петроград Милли Шурасы рәисе итеп сайлана. Казанда үткәрелгән Мөселман хәрби корылтаенда исә Президиум рәисе була.

Мәскәүдәге корылтайда Рәсәйнең дәүләт төзелеше буенча кайнар бәхәсләр куера, фикерләр төрлелеге күренә: берәүләр милли-мәдәни автономия фикерен яклый, икенчеләре — федератив дәүләт булуны, өченчеләре исә унитар парламент республикасы ягында торалар. Татар вәкилләренең күпчелеге унитарлык нигезендә милли-мәдәни автономия фикерен куәтлиләр, ләкин милли хәрәкәтнең бик абруйлы кайбер җитәкчеләре, шул исәптән, Ф. Туктаров та федерализм идеясен алга сөрәләр. Тырыша торгач, күпчелек тавыш белән Рәсәй дәүләте территориаль автономияләргә нигезләнгән федератив дәүләт булырга тиеш, дигән тәкъдим кабул ителә.

Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары арасындагы иң кыен ярты ел дәвамында Фуад Туктаров Казанда Милли Шура рәисе булып эшли. Революциянең сыйнфый көрәш характеры ала барып үсүе аны бик нык борчый. Ул бу хакта «Корылтай» газитендә әледән әле язып чыга. 1917 елның июлендә язылган бер мәкаләсендә ул татар милли сәясәтчеләренең һаман да таркала-бүгәләнә баруын күрсәтә. Кемнәрнеңдер социал-демократ, кемнәрнеңдер социалист-революционер, кемнәрнеңдер милләтче булып киткәнен, ә кемнәрнеңдер милләтләрне бөтенләй танырга теләмәгәнлекләрен ачынып күзәтә. Халык бүгәләнеп-болганып бетте, болай да көчебез чамалы иде, хәзер инде анысы да калмады, дип борчыла ул. «Байлар, ярлылар! Кайда сез? Барыбыз да бер өстәл тирәсенә утырышыйк!» — дигән өндәү белән чыга.

Октябрь инкыйлабы алдыннан Милли Шура шактый кыенлыкларга тара, аның эшчәнлеген Казаннан өязләргә күчерергә кирәк, дигән фикерләр әйтелә башлый. Ф. Туктаров эштән китәргә мәҗбүр була.

Октябрь переворотыннан соң ук, 1917 елның 28 октябрендә Казанда Беренче мөселман хәрби округ корылтае җыелып, Вакытлы Революцион Комитет төзелә. Аның составына Хәрби Округ Шурасыннан И. Алкин, Милли Шурадан Ф. Туктаров, социалистлардан М. Вахитов кертелә. Казан хәрби округының вакытлы командующие итеп большевик Н. Ершовны сайлыйлар. Әмма бу килешенү, большевикларның башка сәяси көчләр белән исәпләшүе озакка бармаячагы көн кебек ачык була...

1917 елның ноябрендә Учредительное Собраниегә сайлаулар вакытында Ф. Туктаров кандидатурасы берничә округтагы берничә исемлектә күрсәтелә. Казан губернасында да аның фамилиясе ике исемлектә була. Учредительное Собраниегә исә ул Самара сайлау округыннан 13 нче исемлек буенча «Мөселман Шурасы» вәкиле буларак сайлана.

1918 елның 2 гыйнварында Казан Учредительное Собраниегә китәсе татар делегациясен тантаналы төстә озатып кала. Делегация пайтәхеткә Собрание эше башланганчы, иртәрәк килеп төшә. Ф. Туктаров килә-килешкә үк мөселман фракциясе оештыру эшенә керешә. Учредительное Собраниенең беренче һәм соңгысы булган бердәнбер утырышында да ул шуны кайгырта. Учредительное Собрание большевиклар тарафыннан куып таратыла. Мөселман фракциясенең шуннан соңгы киңәшмәсендә Ф. Туктаров, А. Цаликов, Ш. Мөхәммәдьяровлар законлы сайланган Учредительное Собраниены яклап чыгалар, большевиклар хакимиятенә каршы көрәш юлына басалар.

Петроградтан куылып кайтарылган Ф. Туктаров 1918 елның берничә аен Г. Исхакый белән берлектә туган якларында — Чистай өязендәге бер авылда үткәрә. Үзләрен кулга алырга тиешле кешеләрдән берсенең әтисе аларны вакытында кисәтеп өлгерә һәм көрәштәш дуслар качып котылалар.

1918 елның июнендә Самарада Учредительное Собрание әгъзалары Комитеты (КОМУЧ) оештырыла. Ф. Туктаров та аларга барып кушыла. Июль аенда ул инде Самарада чыга торган «Безнең фикер» газите мөхәррире була.

1918 елның сентябрендә Ф. Туктаров эсерлар демократиясеннән Колчак диктатурасына күчүнең соңгы этабы булган Дәүләт Киңәшмәсендә катнаша. Ул киңәшмә Өфедә үткәрелә. Учредительное Собрание әгъзасы буларак, Ф. Тук-

таровның имзасы «Бөтенроссия Югары хакимиятен оештыру турындагы акт»та башка мөселман эшлеклеләре — Г. Терегулов, В. Таначев, Ф. Төхфәтуллин, М. Әхмеров, Г. Исхакый, И. Әхтәмовларның имзалары белән янәшә тора. Әмма Рәсәй халыкларына киң хокуклар бирерлек күп партияле демократик Бөтенроссия хакимияте урнаштыру өмете бу юлы да җимерелә: 1918 елдагы Колчак фетнәсе юкка чыгара ул өметне. Адмирал Колчак нинди дә автономияләр, халыкларның хокуклары турында сөйләнүләрне ишетергә дә теләми, ул аларны бер дә өнәми. Колчакчылар Учредительное Собрание һәм аның әгъзалары белән дә артык исәпләшеп тормыйлар. Ноябрь ахырларында Екатеринбургта КОМУЧ корылтае рәисе В. Вольский, аның урынбасары И. Алкин, сәркатибе Н. Святицкий, әгъза В. Чернов һәм башкалар кулга алына, колчакчылар аларны чак кына атып үтерми калалар.

Ләкин Ф. Туктаров гражданнар сугышы тәмамланганчы тагын ике ел чамасы Рәсәйдә яшәп кала: 1919 елның декабрендә ул әле Петропавловскийда Милли Шураның рәсми органы булган «Маяк» газитенә мөхәррирлек итә.

Гражданнар сугышы большевикларның җиңүе белән тәмамлангач, Ф. Туктаров Маньчжурия аша Япониягә чыгып китә, аннары озак та үтми Көнбатыш Европага күчә. Европада, башка эмигрантларныкы шикелле үк, татар эмигрантларының да эшләре кайнап тора. Ф. Туктаров рәисе Г. Исхакый булган «Идел-Урал бәйсезлеге Комитеты»ның эшчәнлегендә катнаша. «Прометей» исемле журналга язышып тора, Г. Исхакый һәм М. Рәсүлзадә белән берлектә Берлинда чыгарыла торган татарча «Азат Шәрекъ» журналында мөхәррирлек вазифаларын башкара.

Парижда эмиграциядә булган Учредительное Собрание әгъзалары 1921 елның 8 гыйнварында янә бер киңәшмә җыялар. Чит илләргә чыгып качкан 59 әгъзаның 33е катнаша ул киңәшмәдә. Күпчелеге — 22 кеше — эсерлар була. Шуларның өчесе Рәсәйнең мөселман халкы вәкилләрен тәшкил итә. Болар Садри Максуди, Гаяз Исхакый һәм Фуад Туктаровлар булалар. Кадетлардан берсе — тарихчы П. Милюков, автономияләр турындагы һәр төрле хыялларны вакытлыча калдырып торырга кирәк, дип чыгыш ясый. Мөселман фракциясе исеменнән җавабында Фуад Туктаров аңа кискен каршы төшә: «Большевиклар мөстәкыйль Татарстан Җөмһүрияте игълан иткән Идел буена кайтып, үз халкыма мин, мәсәлән, болайрак дисәм: «Әфәнделәр, бу большевистик җөмһүриятегездән ваз кичегез! Мин сезгә Учредительное Собрание әгъзалары киңәшмәсенең резолюциясен китердем. Анда сезгә татарча сөйләшергә вә тәүлегенә 24 сәгать эшләргә ирек куела». Шуннан соң милләттәшләрем миңа нәрсә әйтерләр икән?»

Кызганычка каршы, Ф. Туктаровка Идел буйларына яңадан әйләнеп кайтырга насыйп булмый шул...

Ф. Туктаров бераздан Төркиягә күчеп килә. Анда да мөгаллимлек итә. Утызынчы еллар уртасында ул күпмедер вакыт татар бае Мостафинның туку фабрикасында директор вазифаларын үти. Сәүдә эшләре белән берничә мәртәбә Кытайга — Синьцзянга да барып кайта.

Төркиядә яшәгән елларында Ф. Туктаров СССРдагы туганнары белән элемтәгә керергә тырышып карый, берничә мәртәбә хатлар яза. Ләкин бу эшкә тиз чик куела: аның туганнарын контрреволюционер белән элемтәдә булуда гаепләүләр. Туганнарының язмышлары фаҗигале тәмамлана. Мәскәүдәге Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда хатын-кызларның хокуклары мәсьәләсе тикшерелгәндә чыгыш ясап, 1917 елның апрелендә Казанда булып үткән Мөслимәләр корылтае карарлары турында сөйләгән сеңелесе Илһамия Туктарова 1937 елда 10 елга хөкем ителә. Туганнан туган сеңелләре, Хәсәен Ямашевның тол калган хатыны Хәдичә Таначеваны (кыз фамилиясе Бадамшина) шулай ук 10 елга төрмәгә ябалар. Илһамиянең ире, литва татары Якуб Богданович Казанда медицина институты укытучысы була. 1918 елда Кырымда Милли Фирка әгъзасы булып торуда гаепләп, аны да кулга алалар һәм атып үтерәләр.

Хәзер Казанда Фуад Туктаровка туган тиешле Үзбәк Якуб улы Богданович яши. Ул Бөтенсоюз травматология һәм ортопедия Фәнни-тикшеренү институтының Казан филиалы директоры булып эшләде. Танылган галимтабиб.

Татар милли азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, оста сәясәтче, талантлы публицист-журналист Фуад Туктаровның тормыш юлы һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге, кыскача гына җыеп сөйләгәндә, әнә шундый булган.

Светлана МАЛЫШЕВА,
тарих фәннәре кандидаты.

## ФАТИХ УРМАНЧЕГА 60 ЯШЬ



**Фатих Ибраһим улы Урманче 1936 елның 28 маенда Омск өлкәсенең Азов районы Кызыл Маяк авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында ана телендә ала, аннары күршедәге Тарбак казакъ җидееллык мәктәбен тәмамлый. Омск шәһәренең Казакъ педагогия училищесендә һәм Педагогия институтының тарих-филология факультетында белем алганнан соң, туган районындагы урыс урта мәктәбендә урыс теле һәм әдәбияты, тарих укыта.**

1962 елда Фатих Казанга күчеп килә. Монда ул Татар тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантура уза һәм 1968 елда татар халык иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Моннан соң аңа гыйльми эзләнүләрен югары уку йортларында укыту белән бергә дәвам итәргә туры килә — ул Казан, Алабуга, Эгер (Мажарстан) педагогия институтларында урыс әдәбияты укыта, ун ел чамасы Алабуга пединститутының проректоры вазифасын да үти.

Татар, казакъ, урыс, мажар телләрен, әдәбиятларын тирән өйрәнү Фатихның гыйльми тикшеренүләре колачын киңәйтә, туган халкы авыз иҗатын барлау, анализлау һәм бәяләүдә төплелек һәм кыюлык бирә. 1989 елда ул татар бәетләре буенча Ташкентта докторлык диссертациясе яклый, тиздән профессор итеп тә сайлана. Галим 1992 елдан бирле Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺТИдә халык иҗаты бүлеге мөдире булып эшли.

Ф. Урманче хәзер алты монография, 150дән артык фәнни хезмәт авторы, ул бүген дә гыйльми эзләнүләрен уңышлы дәвам итә. Шуның белән бергә ул ТӘҺТИнең фольклор бүлеген үстерүгә, андагы белгечләрнең санын арттыруга һәм фәнни әзерлекләрен күтәрүгә зур игътибар бирә.

«Казан утлары» редакциясе галимне гомер бәйрәме белән котлап, аңа киләчәктә дә иҗади уңышларга ирешүне тели һәм аның яңа бер мәкаләсен укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итә.

**Фатих Урманче**

# ЧЫҢГЫЗ ХАН ҺӘМ АНЫҢ ЭПИК БИОГРАФИЯСЕ

Алтын Урданың нигез ташларын салучыларның берсе булган Чыңгыз ханның эпик биографиясе турында сүз чыккач, барыннан да элек термин-төшенчәнең мәгънәсен ачыклап үтәргә кирәк. Бу очракта сүз билгеле бер тарихи шәхеснең халык эпосы әсәрләрендә беркадәр үзгәртелеп, еш кына идеаллаштырып күрсәтелгән тормыш юлы хакында бара. Тик шунысын да өстик: халык эпосында гәүдәләнү дәрәҗәсенә күтәрелгән тарихи шәхесләрнең гомуми саны әллә ни түгел.

Төрки халыклар иҗатында киң гәүдәләнеш тапкан Идегәй турында монда сөйләп тору кирәкмәс. Моннан кала нугай, үзбәк, кыргыз халыкларында Алтын Урда чоры тарихи шәхесләре хакында төрле дастаннар бар. Әмма мондый дастаннарның иң зур күпчелеге казакъ халык эпосында сакланган булса кирәк. Сүз казакъ халкының кырык нугай батыры эпик циклы хакында бара. Аларның барысында да диярлек Идегәйнең ата-бабалары һәм аның ул-оныклары образлары гәүдәләнә. Тик бу персонажлар кайвакыт Алтын Урда тарихына гына «сыеп бетмиләр».

Төрки халыклар эпосында Идегәйдән соң икенче урында Чыңгыз хан образы тора дип әйтеп була. Ул — төрки-монгол эпосының иң популяр һәм «иң карт», чын мәгънәсендә тарихи образларыннан берсе. Тик монда тагы бер искәрмә кирәк: Чыңгыз хан образы бу шәхеснең әле исән чагында төрки-монгол халыкларында барлыкка килгән риваять, легенда, җырларда, аннан соң инде монгол язма әдәбиятында чагылыш таба.

Чыңгыз ханның дәүләт эшлеклесе буларак кылган эшләре, күпсанлы халыклар тормышында, аларның тарихи язмышларында калдырган эзләре берничә гасыр буена дөнья тарихында гаять тә зур роль уйнап килделәр. Моны Чыңгыз хан образын ничек тә булса чагылдырган әсәрләрнең «этник тамырлары» һәм таралу географиясе дә ачыктан-ачык раслап торалар. Чыннан да, Чыңгыз хан образын гәүдәләндергән яки бу тарихи шәхеснең нинди дә булса сыйфатларын чалымлап үткән әсәрләрнең ерак саха-якут урман-кырларыннан башлап Дунай буйларына, Урта Идел тирәсеннән Һиндстан, Иран, Гыйрак илләренә кадәр таралган булуын истә тотарга кирәк. Бу яктан Чыңгыз ханның халык иҗатында гәүдәләнеш тапкан образын борынгы тарихтан Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский), төрки халыкларның данлыклы юлбашчысы Атилла образлары белән чагыштырырга мөмкин.

Тарихи шәхес буларак Чыңгыз ханның дөньяви биографиясе, тормыш юлы, яу башчысы буларак таланты хәтта бездә дә беркадәр өйрәнелгән. Дөрес, нигездә тискәре яктан. Ни кыласың, Рәсәй идеологиясе гомер-гомергә прогрессив дөнья юлларының кырыеннан гына барды. Моны без бигрәк тә бүгенге көннәрдә яхшы беләбез. Тик минем максат — идеологик билгеләмәләр бирү яки ярлыклар тагу түгел. Бу очракта тик конкрет фактлар гына ниндидер әһәмияткә ия. Ә инде аларны ничек аңлау һәм аңлату — менә бу чыннан да җитди бурыч.

Чыңгыз ханның эпик биографиясе турында сүз кузгатуның төп сәбәбе — ул Алтын Урда халыклары һәм аларның соңгылары иҗатында барыннан да элек чын мәгънәсендә эпик герой буларак гәүдәләнә. Аерым әсәрләрдә яки аларның теге яки бу мотив-сюжетларында аның тарихи шәхес булуы да истә тотыла кебек. Ләкин шулай да халык иҗаты әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан Чыңгыз хан конкрет тарихтан, хәтта үз биографиясеннән дә ярыйсы ук ерак тора.

Икенчедән, Чыңгыз хан образын гәүдәләндергәндә, төрки-монголларның шигъри әсәрләре барыннан да элек аларга кадәрге төрки фольклор традици-

яләренә нигезләнәләр. Хәтта болай дип тә әйтергә мөмкин: Чыңгыз хан образын гәүдәләндерүдә төрки халыклар иҗаты традицияләре монгол әдәбияты тәҗрибәсенә караганда җитдирәк роль уйныйлар. Ә кайбер очракларда хәтта борынгы Шәрекъ фольклоры йогынтысы өстенлек ала. Әнә шул күзлектән кайбер конкрет мисалларга тукталып карыйк.

* * *

Билгеле булганча, халык эпосы әсәрләрендә геройның исеме, ул исемнең мәгънәсе искиткеч зур роль уйный. Бу күренеш барыннан да элек конкрет тормыш белән бәйләнгән. Әйтик, төрки һәм башка халыклар иҗатында тотемистик исемнәр зур урын алып торалар: Арыслан, Алып Арыслан, Бүре, Байбүре, Бүребәк, Бүрехан, Коблан һ. б. Мәсьәләгә бу яктан килгәндә, Чыңгыз хан исеме дә фольклор әсәрләрендә төрлечә аңлатыла. Шундыйларның иң соңгы чорларга караганы, гади һәм аңлаешлы эчтәлеккә ия булганы казакъ халкының тарихи риваятендә китерелә. Анда сүз ханның гөнаһсыз, тәүфикълы кыздан һәм кояш нурларыннан яратылуы турында сөйләнә. Ханның исеме дә әнә шул факт белән бәйләнгән, имеш. Риваятьтә сөйләнүенчә, кыз кояш нурларыннан балага уза һәм, вакыты җиткәч, Чын-кыз хан (Шын-кыз хан), ягъни, чыннан да кыз кешедән туган бала китерә. Соңыннан бу бала хан дәрәҗәсенә күтәрелә.

Академик А. Н. Веселовский әлеге риваятьнең тагы бер версиясен китерә: Алтын-бил исемле хан үзенең кызын җир астында ясалган бер мәгарәдә яшереп асрый. Чөнки аны беркем дә күрмәскә тиеш. Бервакыт кыз үзен карап торучы апайдан: «Кайларга соң син вакыт-вакыт юкка чыгып торасың?» — дип сорый. Әлеге апай: «Мин бөек дөньяга чыгам»,— дип җавап бирә. Кыз бала бик ялына торгач, хатын аны җир астыннан үзе белән бергә якты дөньяга алып чыга. Мәгарәдән чыгып, гомерендә беренче тапкыр кояш нурларын күргәч, кызның башы әйләнә башлый. Нәкъ әнә шул мизгелдә нindидер илаһи бер көчләрнең үз нурлары кызга төшә. Кыз балага уза. Соңыннан бу инсафлы кыздан Чыңгыз хан туа, имеш.

Бу риваять-легендаларның сюжетына яңашәлекләр башка бик күп, шул исәптән, төрки халыклар иҗатында да киң таралган. Әйтик, кыргыз халкының атаклы дастаны «Манас»та әйтелүенчә, баш геройның ярдәмчесе-нөгәре Алмамбет изге нурдан яралган. Казакъ халкының «Кобланды батыр»ында баш геройга карата «асыл нурдан җаралган» диелә. Татар халкының кыска җырлары арасында мондый бер мисал да очрый: «Йөзләреңә, йөзләреңә йөз карадым, туймадым; Мин сине «нурдан яралган гүзәл бу» дип уйладым».

Мин монда башка яңашәлекләргә тукталып тормыйм. Тик өстәп шуны гына әйтим: эпик геройның яки соңыннан дастани батыр булып киткән хан, хакан, падиша, фиргавеннәрнең кояш нурларыннан яратылуы турындагы легендалар дөнья әдәбияты вә фольклорында гаять тә киң таралган. Бу сюжетның башы, күрәсең, борынгы Шәрекъ, бигрәк тә борынгы Мисыр, Шумер-Аккад, Ассирия, Бабил әдәбиятлары белән бәйләнгән. Классик легендаларның урта гасырларда Чыңгыз хан исеменә килеп кушылуы заманында киң таралган Чыңгыз хан культы белән бәйләнгән булса кирәк. Ханны изгеләштерү, хәтта аллалаштыру заманында Монголиядә, Үзәк һәм Урта Азиядә киң таралган була. Сүз уңаеннан, беркадәр идеологик иркенлек туган безнең көннәрдә Чыңгыз хан культы төрки һәм монгол халыкларында яңадан калкып чыкты һәм төрле халыклар арасында киң таралды. Дөресен әйткәндә, бу ханны изгеләштерү, аллалаштыру монгол вә төрки халыклар арасында беркайчан да бөтенләй юкка чыкмады. Тик ул туктаусыз идеологик изү нәтиҗәсендә вакытлыча гына беркадәр сүрелебрәк торган иде.

Безнең заманда монгол әдәби һәм тарихи традицияләрендә Чыңгыз хан исеме Тэмучин формасында да кулланыла. Тик бу исемнең чак кына башкачарак формасы да бар: Тэмуҗин. Аның да килеп чыгышы билгеле бер легенда ярдәмендә аңлатыла. Имеш, Чыңгыз хан туган көнне аның атасы Тэмуҗин исемле бер татар хакимен кулга төшерә һәм шул уңайдан әле генә туган улына алып әсир исемен куша. Бу традиция дә реаль тормышта булган хәлләрнең халык иҗатында чагылышы белән бәйләнгән. Һәрхәлдә, яңа туган балага беренче очраган кеше исемен кушу традициясе башка кайбер әсәрләрдә дә чагыла.

Ханның бу исеме турында башка төрле мәгълүматлар да бар. Әйтик, «Татар-монголларның тулы тасвирламасы»нда түбәндәгечәрәк язылa: Тэмоҗин татар

хакименең балалык исеме. Башта татарларда фамилияләр булмаган. (Җөмләдән, татарларда фамилияләр хәзер дә юк — Ф. У.). Шулай ук тыелган исемнәр дә булмаган (гадәттә үлгән кешенең исеме тыела). Соңгы елларда татар хакимнәре үз иленнән качып киткән чжурчжэнь түрәләрен дә файдаланалар. Качкын түрәнең титулын кытайчага тәрҗемә иткәч, Чэн-цзи-сы хуан-ди сүзе килеп чыга. Башка кайберәүләрнең сүзләренә караганда, Чэн-цзи-сы кытайлардан алынган тянь цы сүзләренең тәрҗемәсе генә. Бу версия буенча, Чыңгыз хан исеме качкын түрә сүзләреннән алынган булып чыга.

XIII гасыр җитди чыганагыннан алынган бу өзек аерым шәрехләүгә мохтаҗ. Селенга бурятларында безнең көннәргә кадәр шундый бер легенда яши. Анда Чика елгасы буенда як-як кырыйлары кылыч белән киселгәндәй тигез, пирамидага охшаган бер кыя бар. Аның түбәсе тимерче таганыдай тигез. Заманында Чыңгыз хан әнә шул кыяда тимер суга торган булган, имеш. Ул гадәттә бер аягы белән елганың бер ягында, икенчесе белән икенче ягында басып тора торган булган... Күрүебезчә, монда барысы да тик әкияти-эпик традицияләр белән генә бәйләнгән. Шундый ук сюжет-мотивларны башка халыклар иҗатында да табарга мөмкин. Ягъни, ханның исемен мәгънәви яктан аңлата башласаң, Тэмуджин — Тимерче сүзе килеп чыга. Шул рәвешчә, бөек ханның исеме беркадәр гадиләштерелә. Җөмләдән, килеп чыгышы ягыннан тимерче булган эпик геройлар башка халыклар иҗатында да билгеле. Мәсәлән, көньяк немецларының «Нибелунглар турында җыру» дастанының төп геройларыннан берсе Зигфрид та килеп чыгышы белән легендар тимерче булган дигән мәгълүматлар да бар. Ә инде эпик геройны тимерче осталыгы белән бәйләү бик борынгыдан килгән карашларга барып тоташа: күп кенә халыкларда борынгы заманнарда ук тимерче осталыгы аллалаштырылган, һич югы изгеләштерелгән. Тимер кадәр тимерне дә үзенә буйсындыра алган оста изге бер зат дип саналган.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Чыңгыз ханның балалык исеме Тэмуджин, аның сеңелесе Темулун, Ханның сугыш хәрби башлыкларының берсе тургаут Темудерның һәм башка кайбер тарихи шәхесләрнең исемнәре дә тимер — тимур сүзе белән бәйләнгән булуы мөмкин. Ә инде безгә мәгълүм чыганакларга караганда, төрки-монголлар арасында, бигрәк тә өстен даирәләрдә хан, сугышчы — яу башы һ. б. исеменә тимер сүзен кушу гадәти бер күренеш булган. Кайбер легендаларга караганда, Чыңгыз ханның да тимерче булуын истә тотсак, әлеге фаразның нигезе тагы да ныгый.



Чыңгыз ханның XIV гасырда билгесез рәссам тарафыннан эшләнгән беренче сурәте.

Әйтелгәнчә, хан исеменең икенче төре турында да төрле легендалар яши. Аларның иң гадиенә, соңгырак чорларда иҗат ителгән монгол чыганагы — Саган чичәннең «Эрдени-йин тобчи» — да теркәлгәненә тукталырга мөмкин. Анда әйтелгәнчә, 1189 елда, Тэмуҗинны хан итеп сайлаганда, тирмә алдында дүрт почмаклы таш өстендә утырган биш төстәге нииндидер тургайга охшаган кош «чингис», «чингис» дип сайрый. Чыңгыз ханның исеме әнә шуннан алынган, имеш. Ягъни, ханны сайлагач, аңа яңа — хөкемдар исеме кушу кирәк була. Әлеге кошның сайрап утыруын Алла кодрәте дип таныган кешеләр ханга Чингис — Чыңгыз исемен кушалар да.

Икенче бер чыганаклар Чыңгыз исемен төрки-монголларда киң таралган диңгез сүзеннән алынган дип исәплиләр. Тик бу фаразлау да нинди дә булса җитди фәнни нигезләү таба алмады.

Мәсьәләнең бу өлешен йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин: Чыңгыз хан тарихи аренага чыкканчы күп еллар элек кайбер төрки халыкларда, мәсәлән, якутларда шул ук Чыңгыз исемендәге Алла булуын да күрсәтеп үтик. Бәлки бу мәҗүси Алла исеме соңыннан данлыклы хан — хөкемдар исеменә әверелеп киткәндер...

* * *

Китерелгән легендаларның кайберсеннән күренүенчә, Чыңгыз ханның исеме генә түгел, аның дөньяга килүе белән бәйле легендалар да киң эпик традицияләргә нигезләнә. Монголларның 1240 елгы тарихи хроникасы «Илаhи дастан»да («Сокровенное сказание») әйтелгәнчә, Чыңгыз ханның атасы — Югары Күк кодрәте белән дөньяга килгән Борте-Чино. Аның хатынының исеме Гоа-Марал була. Борте-Чино монгол телендә с о р ы  б ү р е дигәнне аңлата. Гоа-Марал — г ү з ә л  б о л а н («баласы»?).

Бу легендаларның төрле һәм күләмле версияләре төрки халыклар иҗатында бик күптәннән һәм ярыйсы ук киң таралган була. Сүз бередә хөкемдарның бүредән тууы турында бара. Кытай чыганакларында теркәлеп калган легендаларның берсе тасвирлаганча, V гасырның 40-нчы елларында тугюлар Көньяк Алтайда яшиләр. Алар жуань-жуаньнар өчен тимер казыйлар. Тугюлар с о кабиләсеннән килеп чыкканнар. Башта алар 70 агай-эне булалар. Аларның иң олысы Нишиду ана бүредән туган була. Ул үз кодрәте белән җил вә яңгыр башлап җибәрә ала торган була. Аның хатыннары: берсе — җәй кызы, икенчесе — кыш кызы була.

Н. Я. Бичуринның мәгълүм китабында әлеге легенданың тагы бер матур версиясе китерелә. Анда инде сүз хуннуларның (гуннарның) ата-бабалары турында бара. Легендада сөйләнгәнчә, бер шаньюйның искиткеч матур ике кызы була. Аксөякләр аларны а л и һ ә л ә р дип йөртәләр. Шулай булгач, шаньюй алдында мондый сорау калкып чыга: бу кадәр гүзәл кызларны гади адәм баласына кияүгә бирергә ярыймы икән? Уйлана торгач шаньюй: мин аларны Күккә багышларга тиешмен,— дигән фикергә килә. Ул төньякта, беркем дә булмаган бер җирдә манара салдыра. Кызларының икесен дә әнә шул манара башында салынган өйдә калдыра: ялварам Күктән, алсын ул аларны,— дип. Өч ел узгач кызларның аналары аларны өйләренә алып кайтмакчы була. Тик шаньюй каршы чыга: ярамый, әле вакыты җитмәде,— ди. Моннан соң тагы бер ел вакыт уза. Бер карт бүре әлеге манара янына килеп, үзенә өн казый һәм шунда яши башлый. Кызларның кечесе олысына әйтә: безнең әтиебез безне бередә Күккә багышлап калдырган иде. Ә хәзер менә бүре килде: бәлки аның килүе — бәхет билгесеңдер. Кече кыз шунда ук аның янына төшмәкче була. Апасы бик курыккан хәлдә, болай ди: ул хайван бит. Ата-ананы хур итмә. Кече сеңлесе аны тыңламый. Бүре янына төшә, аңа кияүгә чыга һәм ир бала китерә. Аларның балалары үрчеп, тулы бер дәүләт төзиләр.

Бу әсәр Чыңгыз ханның тууы турындагы легендага бик якын. Тик Чыңгыз хан турындагысында сүз аллалаштырылган бүре хакында барса, бередә ул юк. Бүренең аллалаштырылуын тик легенданың эчтәлегеннән генә аңларга мөмкин. Легенда буенча, шаньюй үзенең кызларын олы Күккә багышлаган иде бит. Бередә Күк урынын гади бүре алыштыра. Тик бу очракта да сүз аллалаштырылган бүре турында бара булса кирәк. Һәрхәлдә Күк белән Җирне ирләр (инь) һәм кыз-хатыннар (янь) җенесе белән бәйләү патша-ханнарны Күк һәм патша хатыны-ханбикәне Җир белән бәйләүгә тәңгәл булса кирәк.

Бу фикерне раслап торган һәм Чыңгыз ханның дөньяга килүе белән турыдан-туры бәйләнгән тагы бер легендага тукталып үтәргә кирәк. Ул төрки халыклар иҗатында XIII—XIV йөзләрдә таралган «Чыңгызнамә» дастанында китерелә. Легендада әйтелүенчә, Алангова иреннән тыш балага уза. Моны ул болай аңлата: миңа кояш нуры төшә, әмма минем яннан бүре чыгып китә. Шулай булгач, тикшереп карарга булалар. Өч ир Аланговaның тирмәсе янында күзәтеп торалар. Таң алдыннан алар күрәләр: күктән ап-ак якты нур төшә... Бераз вакыттан ул ак яллы соры бүре булып әверелә.

Алдарак китерелгән легендаларда сүз шаньюй кызыннан һәм бүредән туган бала һәм аның балалары турында барса, шул ук легенданың башка кайбер версияләрендә сүз аерым төрки кабиләләрнең а н а  б ү р е д ә н үрчеп китүләре турында сөйләнә: «Тукюларның аерым бер аймак булып яшәгән төркеме (Өе — Дом) көнбатыш диңгезеннән көнбатыштарак җирләрдә гомер итә. Бу — хуннарның Ашина исеме белән билгеле булган аерым бер төркеме. Соңыннан бу ыру күрше бер ыру тарафыннан җимерелә һәм гомумән юкка чыгарыла. Тик бер ун яшьлек малай гына исән кала. Гаскәрләр, аның яшьлеген күреп, үтереп ташларга кызганалар: малайның аяк-кулларын кисеп, бер үләнле күл буенда калдырып китәләр. Ана бүре аңа ит биреп тора. Хөкемдар, малайның исәнлеген ишетеп, аны үтерү өчен тагы бер тапкыр үзенең кешеләрен җибәрә. Малайны ана бүре янында күреп, гаскәрләр аны үтермәкче булалар. Кытай

чыганакларына караганда, нәкъ әнә шул вакытта көнбатыш якның көнчыгышында, Гаочан тауларының төньяк-көнбатыш ягында ана бүре пәйда була. Тау арасындагы мәгарә эчендә куе үлән белән капланган тигез җир була. Мәгарәнең дүрт ягында да таулар. Ана бүре әнә шул мәгарәдә яшеренә һәм ун бала китерә. Алар барысы да зураеп үсәләр, өйләнәләр һәм һәркайсының да үз балалары була. Соңыннан аларның һәркайсы аерым ыру булып оеша. Шулар арасында искиткеч зур сәләтләргә ия Ашина да була һәм ул соңыннан падишa — хөкемдар дип таныла.

Бу легендаларның төрле версияләре башка халыкларда да бар. Безнең өчен бу очракта иң әһәмиятлесе — әле генә китерелгән әсәрләрнең асылда Чыңгыз ханның тууы белән бәйләнгән легендаларның, һичшиксез, нигезе булып торуында. Ягъни, Чыңгыз ханның тылсымлы тууын тасвирлаучы риваять-легендалар төрки халыклар эпосында монголларның һәм Чыңгыз ханның тарихи аренага күтәрелеп, киң мәгънә алуыннан күп гасырлар элек барлыкка килгән әсәрләргә нигезләнүендә. Бәлки шуңа күрәдер әлеге легендаларның монголларда таралган версияләренең кайберсе Чыңгыз ханның гына түгел, хәтта монгол кабиләләренең барлыкка килүен дә бүре образы белән бәйлиләр. Бу хакта, әйтик, XVII йөз елъязмасы «Алтын дастан»да сөйләнә: «Бортэ Чино-а Тегис-далай аркылы үтеп, төньякка таба китә һәм Дзад җиренә килә (Дзад — төркичә чит, йат дигәнне аңлата булса кирәк). Гоа Марал исемле әле кияүдә булмаган кызны үзенә хатынлыкка ала һәм әнә шул Дзад җирендә яшәргә туктала. Монгол ыруы әнә шулай барлыкка килә. Күрүебезчә, легенданың бу версиясендә төп геройлар — бүре белән болан баласы түгел, ә кешеләр. Тик аларның исемнәрендә генә тотемистик карашлар да чагылып китә. Ягъни алар, халык иҗаты традицияләре нигезендә, ерткыч хайван исемнәре белән аталалар («звериные имена»). Әмма шуңа карамастан, бу легенданың дәвамы да Чыңгыз ханның эпик биографиясенә килеп тоташа һәм ханның Бортэ Чино белән Гоа Маралдан тууы хакында сөйли.

* * *

Чыңгыз ханның дөньяга килүен тасвирлаган легендаларның кайберсендә аерым өстәмә, шул ук вакыт искиткеч тирән мәгънәгә ия булган күренешләр бирелә: «Аңа туарга вакыт җиткәч, ул уң учында бәкәй сөяге кадәр каткан кан төере тотып туа». Шул ук күренеш монголларның «Илаһи дастан»ында да чагыла. Әле генә туган баланың анасы бу күренешне улының киләчәктәге ерткычлыклары, күп кан кою мөмкинлеге билгесе дип кабул итә.

1662 елда Саган-сэцэн тарафыннан язылган «Кыйммәтле төймәләр» («Драгоценные застежки») һәм 1765 елда Мэргэн-гэгэн иҗат иткән «Алтын дастан» («Алтан тобчи») кебек әсәрләрдә Чыңгызхан белән бәйле кайбер күренешләр аның энесе Хасарга күчерелә. Күрәсең, бу авторлар халык дастаннарында киң таралган эпик геройны идеаллаштыру юлына басалар һәм әлеге кан төерен дә Хасар кулына «күчерәләр». Икенче бер төркем чыганакларда әлеге кан төере башка бер зат — бу очракта булачак ханга луслар — илаһи бер көчкә ия булган мифик затлар ханы тарафыннан бүләк ителгән тамгага әвереләләр.

Чыңгыз ханның тылсымлы тууы белән бәйле легендаларның бу гаять тә үзенчәлекле детале халык иҗатының бик борынгы заманнардан килгән һәм дөнья фольклорында киң таралган әкияти-мифологик һәм эпик традицияләренә нигезләнәләр. Мәсәлән, борынгы грек мифологиясе һәм эпосының төп персонажларыннан берсе, Ахилл, Геракл, Одиссей һәм аның хатыны Пенелопа, аларның улы Телемахның ярдәмчесе, яклаучысы һәм саклаучысы Афина Паллада исемле алиһә яшен алласы Зевсның башыннан тулы сугыш савытларына киенгән һәм кулына сөңге тоткан килеш чыга. Борынгы һинд мифологиясендә, «Сугыш алласы Сканданың тууы» дип аталган әсәрдә сөйләнгәнчә, Сканданың улы Вишанха атасының бөереннән алтыннан ясалган сугыш киемнәрендә һәм шулай ук кулына сөңге тотып чыга.

Аңлашыладыр, борынгы грек һәм һинд мифологиясендә һәм эпосында сүз алла һәм алиһәнең могҗизалы тууы хакында бара. Борынгы мифология һәм эпос өчен бу гадәти һәм киң таралган күренеш. Беркадәр соңгырак, Чыңгыз хан заманнарына якынрак чорларга караган әсәрләргә мөрәҗәгать итсәк, тагы да җитдирәк, китерелгән сюжетка «якынрак» янәшәлекләр булуы ачыклана. Әйтик, англо-саксоннар эпосы «Өлкән» Эдда»да. Аның «Хлед турында җыру» дип аталган бүлегендә мондый сүзләр бар: «Хлед гуннар җирендә, изге бер урманда, кулына пычак һәм үткен итеп кайралган хәнҗәр тотып, башына шлем кигән килеш, озын тимер савытта һәм йөгерек ат белән туа». Бу тасвирлама — тулысы-

нча әкияти-мифологик характерда. Тик аның тормышчан нигезе дә бар. Ул «Хервер турында сага»да чагыла: «Ул заманнарда шундый бер мәкаль таралган була: «сугышчы үзенең коралы һәм аты белән туа». (Татар халкында да «Ир-егетнең эчендә иярләгән ат ятыр» дигән мәкаль бар). Ул заманнарда ир-егет туганда махсус корал сугып куялар икән. Ир-егет белән бер үк вакытта туган атны да, әзер коралны да аңа бүләк итә торган булганнар».



Чыңгыз ханның сурәтләре тарихта бик күп сакланып калган. Рәсемдә шуларның берсе.

Төрки-монгол эпик традицияләрендә дә дастани батырның аты аның үзе белән бер үк вакытта туа. Күрәсең, бу сюжет гуннарның шигъри иҗатында да яхшы таныш булган. Бәлки Европа эпосына да ул гуннар иҗатыннан күчкәндер. «Өлкән Эдда»да ул нәкъ әнә шул «гуннар җирендә туган» Хледка карата китерелә бит. Бу фаразны дәлилләп торган тагы бер җитди фактор бар: англо-саксоннарның «Беовульф» һәм көньяк немецларның «Нибелунглар турында җыру» кебек әсәрләрендә — Көнбатыш Европаның бу классик дастаннарында төп геройлардан берсе — гуннарның мәшһүр юлбашчысы Атилла (Аттли, Этцель).

Чыңгыз ханның тылсымлы тууын күрсәткән детальләргә якынрак килсәк, аларга тагы да җитдирәк янәшәлекләр табарга мөмкин: әрмән халык дастаны «Давид Сасунский»ның геройларыннан берсе Мгэр шулай ук кулында кан төере тоткан килеш туа. Шул ук мотив кыргыз халкының «Манас»ында да бар: Манасның нөгәре Алмамбет та учында кан төере тотып туа. Генеалогик яктан соңрак барлыкка килгән «Семетей» дастанында әйтелгәнчә, Семетейнең нөгәрләре Көлчоро кулында чәчәк, Канчоро кан төере тотып туалар.

Шушы ук мотив беркадәр үзгәртелгән килеш алтайлыларның героик эпосы «Маадай-Кара»да да чагыла. Аның баш герое Көгүдәй-Мәргән туганда аның кулларында соры һәм кара ташлар була. Шул ташлар ярдәмендә ул һаваның торышын үзгәртә, дошманнарны җиңә, кирәк булганда хәтта һәлак булган сугышчыларын да терелтә ала. Бу кара һәм соры таш Көгүдәй-Мәргәнгә аның куркыныч дошманы булган Кара-Коланы җиңәргә ярдәм итә.

Көгүдәй-Мәргәннең кара һәм соры ташы — барыннан да элек шаман атрибутлары. Моның шулай булуын Африка халыклары эпосыннан күрергә мөмкин. Анда әйтелгәнчә, эпик герой — Кояш улы туганда аның муенында бөти, кулларында саңгеләр, магия һәм сихер кораллары була: арбау өчен кулланыла торган ташлардан тезелгән муенса, тылсымлы кыңгырау, могҗизалы тәгамнар салынган янчык, пычак, мөгез, тылсымлы бау һ. б.

Борынгы карашларның үзгәрүе һәм халык эпосының алга таба үсү процессында бу ташлар да төрле үзгәрешләр кичерәләр. Каракалпакларның «Кырык кыз» героик дастанында әйтелгәнчә, аның төп геройларыннан берсе Арысланның хәрәземлеләр аңа бүләк иткән тылсымлы кыйммәтле ташы — гәүһәре була. Бу ташны югалткач, Арыслан үзенең дошманнарыннан җиңелә. Борынгы эпик дастан герое гадәттә тылсымлы әйберне беркайчан да югалтмый. Арысланның гәүһәр ташын югалтуы соңгы чор мажаралы сюжетлары белән аңлатыла.

Башка кайбер әсәрләрдә шул ук тылсымлы әйберләр бөтенләй башка төрле вазыйфада кулланылалар. Әйтик, Тибетта иҗат ителгән «Зиһенлелек һәм ахмаклык турында сутра»да шундый бер сюжет китерелә: кечкенә бала учларында нәрсәдер кыскан килеш туа. Малайның ата-анасы моңа нык гаҗәпләнәләр. Баланың кулларын ачып карасалар, аның ике учында да алтын тәңкә икән. Иң җитдие — бу тәңкәләр беркайчан да бетми икән, имеш.

Китерелгән һәм беркадәр күзәтелгән легендаларның, шул исәптән, аларның Чыңгыз хан исеме белән бәйләнгәннәренең дә барлыкка килүе һәм киң таралуы борынгы индоарийлар мифологиясе һәм эпосы белән бәйләнгән. «Кришна турында дастан» героеның дөньяга килүен тасвирлаган күренешләрдә әле генә

күзәтелгән версияләрнең барысы да диярлек бер җиргә, бер әсәр эченә тупланганнар кебек. Анда әйтелгәнчә, Деваки белән Васудева үзләренең әле генә туган сигезенче улларын күргәч, нык куркып калалар, аның алдында сәҗдәгә китәләр һәм аңа котлары алынып карап торалар. Чөнки сабый чыннан да искиткеч була. Аның күзләре лотос чәчәгенә охшаган; куллары икәү генә түгел, хәтта дүртәү; бер кулында кабырчык, икенчесендә — сугыш чукмары, өченчесендә нык кайралган диск, дүртенчесендә — лотос чәчәге. Ул үзе баштан аякларына кадәр алтыннан яратылып, әле генә күтәрелеп килгән кояш нурларына чумган болыт кебек икән.

Китерелгән материаллардан аңлашыладыр: Чыңгыз ханның могҗизалы тууын сурәтләгән легендада чагылыш тапкан мотивларның барысы да диярлек халык иҗатының киң таралган һәм күптән, хәтта бик борынгы заманнардан ук билгеле булган традицияләргә нигезләнәләр. Төрки фольклордан алынган һәм бүре образы белән бәйле детальләр күрсәтүенчә, әлеге легендаларның барысы да, аларда чагылыш тапкан аерым мотивлар Монгол империясеннән һәм Чыңгыз ханнан күп элегрәк төрки халыклар иҗатында барлыкка киләләр. Монголларның «Илаһи дастан»ына алар безгә билгеле булмаган борынгы төрки язма чыганаклардан яисә төрки халыкларның авыз шигъри иҗатыннан алынып кертелгәннәр.

Чыңгыз ханның дөньяга килүе белән бәйләнгән легендалар турындагы кыскача күзәтүләрне әлегә шушының белән чикләп, каһарманның эпик биографиясендә чагылыш тапкан тагы бер җитди һәм гаять тә үзенчәлекле күренешкә тукталып карыйк.

* * *

Тарихтан билгеле булганча, Чыңгыз ханның бөтен гомере, аның эшчәнлеге нигездә төрле һәм уңышлы сугышлар белән бәйләнгән. Бу тарихи шәхес дөнья тарихында яулап алучы һәм ул заманнарның ярты дөньясыннан да киңрәк җирләргә җәелгән Монгол империясен төзүче буларак танылган. Мәсьәләнең бу ягын ачыклауны бурыч итеп куймастан, мин тик биредә халык иҗатында киң таралган тагы бер легендага, бу очракта Чыңгыз ханның чыннан да сугышлары белән бәйләнгән күренешкә тукталып үтәргә кирәк дип саныйм.

Югарыда без Ашинаның зур сәләтләргә ия зат булуы һәм аның хөкемдар итеп сайлануы турында әйтеп үткән идек инде. Монда бу фактка тагы бер тапкыр игътибар итеп, шуны өстик: үзенең бүредән килүен ассызыклап үтү өчен, Ашина үзе яши торган илнең капкасы башына бүре башы сурәте төшерелгән байрак элеп куя. Соңыннан төрки-тугю кабиләләренең хәрби байраклары алтыннан бүре башы рәвешендә ясала башлый. Бу, күрәсең, халык иҗатында бик сирәк очрый торган һәм эпик геройның кайдан килеп чыгуын, кемнән тууын турыдан-туры күрсәтеп торган деталь. Килеп чыгышы ягыннан бу йола һәм аны чагылдырган легенда барыннан да элек төрки халыклар иҗаты белән бәйләнгән. Соңыннан ул төрки кабиләләрнең тотемы булган ата бүре һәм ана бүре хакындагы легендалар белән бергә монголлар тарафыннан үзләштерелә һәм шулай ук киң тарала. Легенда буенча, Чыңгыз хан да соры бүредән туган булгач, ул да үзенең «атасына ихтирам йөзеннән үзенең байрагын алтын бүре башы белән бизи». Бу гадәт төрки халыклар арасында шулкадәр киң таралган булган, күрәсең, монголлар аны бернинди үзгәрешсез үзләштерәләр һәм үзләренеке дип игълан итәләр. Бу адым билгеле бер сәяси мәгънәгә дә ия була. Чөнки монгол кабиләләренең төрки халыклар белән тугандаш булуларын ассызыклап тора. Өстәвенә, төрки халыклар Монгол империясендә төп урынны алып торалар.

Күрсәтелгән мотивның борынгылыгы турында башка кайбер мәгълүматлар да бар. Үзәк Алтайның безнең эрага кадәрге VII—VI йөзләргә караган Башадар курганнарында С. И. Руденко археологик эзләнүләр алып бара. Анда табылган һәм бик матур итеп эшләнгән камчы сабына уелып ясалган һәм алтын белән бизәлгән бүре башы сурәтләре төшерелгән. Сурәттәге өч бүре башы да алга таба карап торалар. С. И. Руденко сүзләренә караганда, бу — безгә күптән таныш, үткен тешле һәм азулы, борыннары беркадәр күтәрелгән, күзләре ачык, колаклары очлы ерткыч хайваннар.

Билгеле булганча, хәрби камчы — сугышчы һәм ауч коралы. Бәлки ул хәрби бәрелешләр вакытында да кулланыла торган булгандыр. Камчы күчмә малчылар һәм сугышчылар тормышында гомумән зур урын алып торган. Л. В. Гребнев сүзләренә караганда, тува халыкларында хәрби җайдакның төп коралларыннан берсе хәрби камчы була. Нәкъ әнә шуңа күрә аны сурәтләүгә халык эпосы әсәрләрендә зур урын бирелә. Димәк, кайчандыр алтын бүре башы хәрби корал-

ларны бизәү өчен кулланыла торган булган. Камчы сабында урын алган бүре башларын С. И. Руденко «безгә күптән таныш» дип атый һәм аларның «сугыш-чан :ыяфәтен» ассызыклап яза. Күрәсең, биредә дә сүз шул ук безгә чыннан да яхшы таныш алтын бүре башлары турында бара. Соңыннан ул А ш и н а һәм Ч ы ң г ы з х а н байракларына күчерелә.

Халык иҗаты, бигрәк тә халык эпосы әсәрләре күрсәтүенчә, бүрене, бигрәк тә а к яки с о р ы б ү р е н е аллалаштыру башка, шул исәптән, татар халык иҗатында да киң таралган. Хәрби байракка яки бүтән хәрби әйберләргә алтын бүре башы сурәтен төшерү дә зур популярлык казана. Үз вакытында профессор Кирәй Мәргән язганча, бүрене изгеләштерү, аңа тирән ихтирам белән карау Башкортостанда да ярыйсы ук таралган күренеш була. Кабилә башлыклары, соңыннан хәтта волость старшиналары да, үз хакимиятләренең бик борынгыдан килүен күрсәтү өчен һәм аерым символ итеп бүре башы төшерелгән тамга йөртә торган булганнар.

Төрки-монгол халыкларының бу йолалары шулай да соңгы чорларда туган карашлар белән бәйләнгән. Бу йоланың чын тарихи-этнографик нигезе, күрәсең, тирәндәрәк яшеренгән һәм аның үзенә генә хас аерым серле-сихерле йола мәгънәсе дә бар. Гомумән, төрле җәнлекләрнең, хайваннарның символын хәрби атрибутларга беркетү бик борынгыдан килә торган гадәт булса кирәк. «Татар-монголларның тулы тасвирламасы» китабында күрсәтелгәнчә, монголларда гадәттә югары социаль баскычта торган түрәләр үзләре белән алтын тактачык йөртә торган булганнар. Анда бер-берсенә карап торган ике юлбарыс сурәте төшерелгән була. Бу билгене «юлбарыслар сугышы» дип атыйлар (пайцза). Башкортларның «Урал-батыр» дастанында падиша байрагына төшерелгән к а р а  к а р г а сурәте турында сөйләнә. Бу байрак кешеләрне корбанга чалу йоласын үтәгәндә күтәрелә икән. Ә инде кара карга бик күп халыкларда һәрвакыт диярлек үлем символы булып килә. Моның да бик күп конкрет мисалларын китереп булыр иде.

Төрки-монгол легендаларында бүре башы төшерелгән байракларны сугышка барганда дошманнарны куркыту өчен куллану хакында бер сүз дә юк. Хәер, бу үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк. Шулай да төрки-монгол риваять-легендаларыннан «төшеп калган» күренешне Корнелий Тацит хезмәтләрендә китерелгән һәм герман кабиләләренә караган детальләр белән тулыландырырга мөмкин. Тацит сүзләренә караганда, бу кабиләләр кыргый хайваннар сурәтләрен төрле изге урманнарда саклыйлар һәм сугышка барганда үзләренең алларында күтәреп баралар. Сугыш башланыр алдыннан гаскәрләр алдында төрле кыргый хайваннар сурәте төшерелгән байракларны яки штандартларны йөртү йоласы турында башка кайбер мәгълүматлар да бар һәм алар бу йоланың бик борынгы заманнардан ук билгеле булуы турында сөйлиләр. Безнең эрага кадәрге VIII йөз Ассирия патшасы Саргон II-нең хәрби язмасында шундый сүзләр бар: «Минем алдан баручы билгеләр». Академик И. Дьяконов бу сүзләргә мондый аңлатма бирә: «Борынгы заманнарда сугышчылар алдында байрак урынына төрле символик сурәтләр төшерелгән һәм металлдан ясалган тамгалар йөртә торган булганнар; бу тамгаларда төрле аллалар яки аларның символлары сурәтләре ясала торган булган».

Мондый гореф-гадәтләр һәм йолалар халык иҗаты, бигрәк тә халык эпосы әсәрләрендә дә чагылыш табалар. «Шаһнамә»дә күрсәтелүенчә, Тусның байрагында фил, Гудерзанықында — арысланның зәңгәр сурәте, Гиз байрагында — алтын бүре символы төшерелгән була. Башка кайбер батырларның байракларында кыр дуңгызы — кабан, көмеш ай, аждаһа һәм алтын башлы арыслан сурәте бирелә.

Шулай да төрле символик сурәтләрнең безнең өчен иң отышлы чагылышы борынгы һинд эпосында — «Бхарат оныкларының бөек сугышы турында дастан»да чагыла. Анда сөйләнүенчә, Кауравлар сугышка әзерләнәләр. Шул вакыт Шантану патшасы белән Гангның улы, ак чәчле Бхишма пәйда була. Ул — көмеш белән ялтыратылган арбада, алтын пальма сурәте төшерелгән ак байрак белән ак болытлар арасыннан ялтырап күренгән ай кебек килеп чыга. Сугышчы байрагын бизәп торучы пальма яфрагы берничек тә сугышчанлык турында сөйләми, билгеле. Чөнки пальма бик борынгыдан бирле һәрвакыт тик тынычлык һәм дуслык символы ролен үти. Б е р е н ч е л е к  п а л ь м а с ы дигән мәгълүм тәгъбир дә шул хакта сөйли. Борынгы Грециядә төрле спорт ярышларында беренчелекне алган кешегә пальма яфракларыннан ясалган бәйләм бүләк итә торган булганнар.

Шул ук әсәрдә бөек сугышчы, Кунти белән Кояш алласы Сурьяның улы — Карна байрагындагы символ турында да сөйләнә. Карна җитәкчелегендәге сугышны тасвирлаганда, дастан түбәндәгечәрәк сүзләргә мөрәҗәгать итә: менә Карна үзенең кояш кебек ялтырап торган арбасында сугышчылар алдында пәйда булды. Аның кулында алтын белән бизәлгән ук, байрагында — сугышчан фил сурәте. Биредә күрсәтелгән фил геройның сугышчанлыгы хакында сөйли, билгеле.

Гаять тә сугышчан, көчле һәм илаһи бер куәткә ия булган Арҗунаны сурәтләгәндә дастан әлеге мотивның чын мәгънәсенә тагы да якынрак килә. Ул сугыш алып барганда, аның байрагын бизәп торучы маймыл сурәте коточкыч бер тавыш белән улап җибәрә һәм Арҗуна дошманнарының котын ала. Бу сурәт-символның борынгы төрки символларга якынлыгы бәхәс уятмый кебек. Тагы да җитдирәге: байракта күрсәтелгән символ бу очракта эпик батырның үзен алыштыра кебек. Гадәттә халык эпосы әсәрләрендә батырның коточкыч көчкә ия булган тавышы дошман гаскәрләрен чиксез куркуга сала. Мисал рәвешендә якутларның архаик эпосы «Ашкынулы Нюргун Боотур» дастанында китерелгән күренешне алырга мөмкин: «Нюргун Боотур аңлады — ерткыч аны сугышка чакыра; батыр үзе котырган үгез кебек улап җибәрде». Халык эпосында киң таралган бу күренешнең тамырлары шумер-аккад эпосыннан башлана. Гильгамеш турындагы «Барысын да күргән» дастанында шундый сүзләр бар: «Хумбаба — аның тавышы гарасат кебек». Хумбаба — явыз зат. Әлеге дастанның баш герое Гильгамеш әнә шул зат белән сугыш алып барырга тиеш.

Шул рәвешчә без, төрле тарихи-типологик чагыштырулар ярдәмендә борынгы төрки-монголлар, бу очракта Ашина белән Чыңгыз хан байракларында урын алган алтын бүре башы символының төп мәгънәсен аңлау дәрәҗәсенә якынайдык кебек. Иң элек әле генә күрсәтелгән Арҗуна байрагындагы маймыл — символның сугыш вакытындагы хәрәкәтләренә игътибар итик. Ул тере һәм көчле, куркыныч җан иясе кебек хәрәкәт итә: сугыш дәвамында аның авызыннан коточкыч тавыш чыга һәм дошманнарның котын ала. Ягъни, символ үзе конкрет сугышта конкрет эшләре белән катнаша. Бу, күрәсең, бик борынгыдан калган күренеш. Төрки-монголларның алтын бүре башы да шулай ук хәрәкәт итә дигән мәгълүматлар фольклорда сакланмаган. Әмма бу чыннан да шулай булырга тиеш дигән фикер әллә ни бәхәс уятмый. Арҗуна байрагындагы маймылның үз-үзен тотышында әлеге символның иң борынгы һәм беренчел мәгънәсе сакланып калган булырга тиеш. Димәк, мондый символлар һәрвакыт эпик геройның дошманнарын куркуга салу сәләтенә ия. Аны хәрби байракка шуның өчен төшерәләр дә. Гомумән, бу символ хәрби дошманнарның гына түгел, тирә-яктагы һәрбер затның котын алырга тиеш. Димәк, бу символ тик ерткыч хайван — арслан, юлбарыс, сугышчан фил, соры яки ак бүре ролен генә үти дип уйлау мәсьәләнең асылын ачыклап бетерми. Ул тагы да ниндидер җитдирәк, куркынычрак мәгънәгә ия булырга тиеш. Борынгы төрки-монгол легендаларында сүз ата-бабаның алтын башы символы турында бара. Шулай булгач, аның төп мәгънәсе дә ата — бабалар культы белән бәйләнгән булып чыга. Ә инде ата-бабалар культы бик борынгы заманнарда кешеләрнең көндәлек тормышында искиткеч зур роль уйнаган. Ата-бабалар культы — бу барыннан да элек үләләр культы. Билгеле булганча, үләләр культы мәгълүм диннәргә кадәр барлыкка килгән иң борынгы ышанулардан тора. Соңыннан барлыкка килгән диннәр әнә шул үләләр культына нечкә бер пәрдә булып кына торалар. Шуңа күрә борынгы төрки-монголларның байрагында урын алган символ — ак яки соры бүре башы әлеге кабиләләрнең дошманнарын зур куркуга салырга, аларның котын алырга тиеш. Шуңа күрә бу символ борынгы төркиләрдән монголларга күчә һәм Алтын Урдада яшәгән башка халыкларның шигъри иҗатында киң тарала.

Идел буе татарлары иҗатында һәм аларның көндәлек тормышында әлеге гореф-гадәтләр һәм йолалар сакланмаган кебек. Аның каруы — безнең халык иҗатында бүрене, бигрәк тә бүреләр яки урман патшасы Ак бүрене олылау, ихтирам итү, аллалаштыру турында искиткеч матур һәм зур күләмле әсәр — «Ак бүре» әкияте сакланып калган. Җөмләдән, Ак бүрегә багышланган күләмле гүзәл бер әсәр тик безнең халыкта гына билгеле.

Биредә мин төрки-монгол халыклары иҗатында Чыңгыз хан образы белән бәйле иҗат ителгән әсәрләрнең барысына да тукталуны бурыч итеп куймадым. Мондый эшне бер мәкаләдә генә хәл итү мөмкин дә түгел. Моның өчен махсус һәм күләмле монография язарга кирәк. Бу мавыктыргыч бурычны киләчәккә калдырып, шуны әйтим: Мин тик Чыңгыз хан белән бәйле әсәрләрнең өч кенә мотивына кыскача тукталып үттем: халык иҗаты әсәрләрендә эпик герой буларак гәүдәләнгән Чыңгыз ханның исеме; ханның тылсымлы туы; аның төп

эшләре белән бәйләнгән, гаять тә тирән мәгънәгә ия булган алтын бүре башы символының иң борынгы һәм беренчел мәгънәсе. Кыскача күзәтүләр нигезендә түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин: Чыңгыз хан образы гадәттә халык иҗатының тирән мәгънәле традицияләре нигезендә барлыкка килгән әсәрләрдә гәүдәләнә. Монгол әдәбиятында һәм фольклорында бу образ нигездә язма чыганакларда сурәтләнсә, төрки халыкларда ул барыннан да элек авыз иҗаты, фольклор әсәрләрендә гәүдәләнә. Тик монгол язма әдәбиятында да Чыңгыз хан образын сурәтләгәндә чыганаклар барыннан да элек төрки халыклар шигъри иҗатына нигезләнәләр. Югарыда беркадәр күзәтелгән сюжетлар һәм мотивларның барысы да борынгы төрки фольклордан алынганнар. Моның төп сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: монгол кабиләләре һәм Чыңгыз хан тарих дөньясына күтәрелгәнчә һәм күп гасырлар элек шул ук җирләрдә, шул ук далаларда төрки халыкларның берничә катлаулы һәм зур цивилизацияләре булып уза: Атилла җитәкчелегендә иксез-чиксез Евроазия далаларына җәелгән гуннар державасы; аннан соң 350 ел буена шул ук далаларда барлыкка килгән һәм Ашина нәселеннән килгән хөкемдарлар кул астында яшәгән төрки дәүләтләр (VI—VIII йөзләр); Хәзәр каганаты; Кубратның Бөек Болгарстаны; Урта Идел буе Бөек Болгар дәүләте.

Чыңгыз хан образын сурәтләгән әсәрләрнең нигездә төрки фольклор традицияләренә нигезләнүенең икенче төп сәбәбе — бу төр әсәрләр Чыңгыз хан үзе нигез салган Монгол империясенә караганда, Алтын Урда халыклары арасында киңрәк таралалар. Бу төр әсәрләр тик Монгол империясендә генә яшәсәләр, алар әлеге империя юкка чыгу белән бергә онытылган булырлар иде. Әмма бу традицияне шул ук җирләрдә барлыкка килгән Алтын Урда халыклары иҗаты күтәреп ала һәм киң таратып, күп кенә очракларда, Чыңгыз хан культы белән бергә, безнең көннәргә кадәр саклап кала.

# Тәлгат Нәҗмиев

**Тәлгат Самат улы Нәҗмиев 1950 елда Кукмара районының Байлангар авылында туган. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Менә унбиш ел инде «Саба таңнары» район газетасында мөхәррир булып эшли. Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, республикабыз журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты.**

**Кечкенәдән сәнгатькә гашыйк булуы аны Шәмәрдән һәм Саба мәдәният йортларында эшләгән чагында ук сәхнәгә алып килә. Тәлгат — концертларны алып баручы, шуңа да ул әллә ничаклы шигырьләрне һәм мәзәкләрне яттан белә, аларны тамашачы күңеленә хуш килерлек итеп сөйли. Мәзәкләргә, җор-тапкыр сүзгә хиреслеге әнә шул еллардан ук килә, билгеле.**

**Әйдәгез, Тәлгат Нәҗмиев туплаган мәзәкләр хәзинәсеннән «авыз итеп» карыйк булмаса...**

## Нәрсә төшкән?..

Язучы Мөхәммәт Мәһдиев вафатыннан соң көндәлек матбугатта бер-бер артлы истәлекләр басыла. Әдипнең якын туганы, хәбәрчебез Сәҗидә апа Ракова, аның мәзәкләр яратуын искә төшереп, болай сөйләде:

— Бервакыт шулай мәктәптә укыта башлаган елы иде аның. Укытучылар киңәшмәсеннән соң элеккеге Чүриле районы үзәгендә башланып киткән концертны алып барды ул. Сәхнәгә чыкты да җитди кыяфәт белән сөйләп китте: «Бүген сельмагка кергән идем. Шуннан чыкканда башыма бернәрсә килеп төште. Күтәрелеп карасам, «Сельмаг» дигән язуның мягкий знагы төшкән икән. Ничек твердый знак төшмәгән әле, бетәр идем»,— ди бу. Тамашачылар рәхәтләнеп көлештеләр.

## Ишек төбе саклау

Сабадагы бер дәрәҗәле генә кеше Яңа елны танышларында алданрак «каршылаган». Уянып китсә, таң беленеп килә икән. Киенгән дә өенә чапкан. Менә икенче катка күтәрелә бу. Ишек шакый. Ачучы юк. Көтә. Шул арада хатыны шыпырт кына килә дә «глазок»тан карый һәм келәне ачып китә. Махмырлы баш белән дустыбыз моны сизми. Яман ачуы чыга тегенең, ирлеген күрсәтәсе килә. Шуннан соң ул... барлык көчен җыеп, бөтен гәүдәсе белән ишеккә китереп бәрә! Ишек ачылып китә, ир дигәнең исә коридор идәненә очып барып төшә. Хәле авыр була, әлбәттә. Шулай да телен көчкә әйләндереп: «Күпме ишек төбендә тотып була ирне, мин сиңа Габдулла Тукаймы әллә...» — дип әйтеп куя.

## Мин чыгып торырмын

Казанның Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында академик якташыбыз — Әбрар ага Кәримуллинның 70 еллыгына багышланган тантана башланырга санаулы минутлар калып бара. Шунда әлеге институтның директор урынбасары Шәрифҗан Асылгәрәев, чыгыш ясаучыларның исемлеген барлап, болай ди:

— Әбрар абый, ни бит... Фәлән Фәләнеч урысча сөйләячәк инде.
Шунда милләт җанлы якташыбыз бер дә аптырап тормады:
— Сөйләсен, сөйләсен! Ул сөйләгәндә мин чыгып торырмын,— диде.

## Без — хәерчеләрмени?

Инде Сабада Әбрар абыйның олы юбилеена багышланган кичә бара. Шул ук Шәрифҗан Асылгәрәев, газетабызның исемен ялгыш бутап, «Саба таңнары» диясе урынга «Саба байлары» дип ычкындырды.
Шуннан юбилейга килгән «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире Хәлим Гайнуллин тавыш куптарды:
— Нишләп сез генә Саба байлары әле! Без, нәрсә, Казан хәерчеләремени?

## Дуслыкны ныгыту чарасы

Венгриядә мин «Ватаным Татарстан» газетасының ул вакытта бүлек мөдире Миргалим Харисов белән бер бүлмәгә туры килдем. Ул шактый җор кеше булып чыкты.
Исән-сау кайтып, Казан аэропортында саубуллашканда болай ди бу:
— Ярар, Тәлгат туган, тату яшәдек, дуслаштык. Әгәр дә син яз көне бакчага бер машина тирес төятеп җибәрә алсаң, безнең дуслык тагын да тирәнәер иде...

## Аңлата белмәсәң...

Безнең белән Венгриягә чыккан группада колхоз рәисләре дә бар иде. Һәр кешегә үзең белән икешәр шешә аракы алырга рөхсәт иттеләр. Таможнядан үткән вакытта 2 метрлы, әзмәвердәй бер рәиснең 10 яртысын күрсәләр дә, гәүдәсенә һәм табак кадәр йөзенә карагач, аны-моны әйтмәделәр. Тегендә дә бик «блатной» йөрде инде бу. Юморга бай. Гармунда да уйный, җырлый да. Үзен күрсәтәсе дә килә. Шулай беркөнне кичке аш вакытында официантны чакырып китерде дә болай диде:
— Карале, сеңлем, бик ошадың бит әле син. Аякларың да матур, юан икән, җитмәсә, кап-кара йонлы. Өйдә, ужиннан соң бер күрешеп алыйк әле...
Теге туташ мадьярча нәрсәдер әйтте, ризалык биргән шикелле итеп елмайды да кухняга кереп китте.
Берзаман ни күрәбез: официантка аш тәлинкәсенә богыл чаклы бәрәңге боламыгы өйгән, өстенә ит кисәкләре тутырган. Шуларны өстәлгә китереп куйды һәм тагын бер кат матур итеп елмайды.
Соңыннан аңлашылды: официант тегенең гәүдәсе зур булгач, ашарга җитмәүдән зарлана дип аңлаган икән...

## Рәттән чәчәләр

Подряд ысулының «чәчәк аткан» вакыты иде. Муса Җәлил исемендәге колхозның район буенча өч көнлек ярышта җинеп чыккан механизаторына күчмә вымпел тапшырырга бардым. Ул вакыттагы колхоз рәисе Чыңгыз Хәлилов белән басуда йөрибез. Бер заман сорап куйдым:
— Чыңгыз Гыйззатуллович, подряд белән чәчәсезме?
— Әйе, подряд чәчәбез. Бу басу беткәч, аның янәшәсенә керәбез,— диде ул.

## Вакланмаска кирәк

Чыңгыз Хәлилов җор күңелле рәис иде. Бервакыт аңа ызандаш Ленин исемендәге тәҗрибә хуҗалыгы директоры Габделхак ага Галиев болай дигән:
— Карале, Чыңгыз! Сезнең шоферларыгыз безнең басуның теләсә кайсы төшеннән юл салып үзәккә үтәләр бит.

— И-и Габделхак Галиеч, вак та кеше икән инде сез. Язын сезгә килгән самолетлар борылган вакытта безнең басуга кереп, ашлама сибеп чыгып киткәндә минем бер дә зарланганым булмады бит...

## Үзем язмаган идем

Калинин исемендәге колхоз рәисе Габделнур ага Җәлиловка күпчелек чыгышларны партия оешмасы секретаре Мәхмүт Шакиров яза иде. Ул аның язуына шулкадәр күнеккән иде ки, хәтта күчереп тә тормады, алдан карап чыгарга да өлгерми иде.

Бер олы җыелышта «Сельхозтехника» район берләшмәсенең тетмәсен тетеп ташлады бу. Тәнәфестә моның янына ул вакыттагы управляющий Бернард Мөбарәкович килеп:

— Габделнур, дус кеше, нишләдең син? — дип сораган.

— Укып бетергәч, үзем дә аптырап киттем. Партоешма Мәхмүт язган, Мәхмүт! — дигән Габделнур ага.

## Аптыраулы хәлнең чишелеше

Нилэр генә уйлап тапмый бу галимнәр! Башта «интенсив технология» диделәр. Аннан шул ысул белән игелә торган арышның өске яфрагын «флаг» дип атадылар. Ул вакыттагы КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов районга килгәч, кайсы басуга керсә дә, шул флагны таптырып аптыратты бит, малай.

Ә менә Карл Маркс исемендәге колхоз рәисе Фәтхрахман Рафыйков югалып калмады. Башта «ха-ха-ха» дип шаркылдап көлде ул, имтихан алучыны шаккаттырып. Аннан авыл Советы түбәсенә кулы белән ишарәләп, җайлап кына әйтеп куйды: «Арышта флаг буламыни? Әнә урыны кайда аның...»

## «Равил кушты»

«Беренче Май» колхозы рәисе Равил Сөнгатуллинны озак еллар Миңнәхмәт исемле шофер йөртте. Аның кая барса да — бухгалтериягәме, складкамы, кибеткәме, ашханәгәме — «Равил кушты» дип әйтә торган ике сүзе бар иде.

Шулай бервакыт Елыш куаклыгында колхозга кирәкле кунакларны сыйлау бара. Шул форсаттан файдаланып, Миңнәхмәт дус та хәйран йомшаган һәм бер куаклык төбенә аягүрә барып баскан... Моны күреп алган партком секретаре Гасыйм ага ачу белән аннан сорый:

— Нишлисең син, егет?

— Равил кушты,— дигән Миңнәхмәт, гадәттәгечә.

## Соравына күрә җавабы

Сайлау алды җыелышында сүз экология мәсьәләсенә барып тоташа. Депутатлыкка кандидатларның берсенә — баш табиб Фәнис Алиевка сорау бирәләр. «Сез табигать турында сөйлисез. Урта Саба авылы турындагы пычрак инешне аркылы чыкканыгыз бармы?».

— Бар,— ди ул һәм сорауга канәгатьләнерлек җавап биргән кыяфәт белән урынына барып утыра.

## Бертавыштан

Киров исемендәге колхозның партком секретаре Миңнезакир ага Нурмөхәммәтов отчет-сайлау җыелышларында күзлеген кия дә, сорау билгесе кебек бөгелгән хәлдә, язган кәгазен укый башлый иде.

— Кем дә кем колхоз председателе итеп Фәрит Шәйхетдиновны сайлыйбыз ди, тавыш бирүегезне сорыйм. Каршылар? Тоткарланып калучылар? Юк. Бертавыштан!!!

— Закир абый, нишләп бер дә залга күз салмыйсың? — дип сорап куя аннан берәү.
— Карамыйм. Анда карасаң, буталып бетәсең, черту. Берсе кулны күтәрә, икенчесе төшерә...

## Аэропортта очрашырбыз

Беркөнне Саба урамында таныш ханымны очраттым. Хәлләрен сорашам.
— Әйбәт түгел,— диде бу,— ирем Шәфәгать әллә нишләде. Беркөнне йокымсырап ятам. Төн уртасы. Шәфәгать гырлый-гырлый йоклаган җиреннән уянып, бит уртасыннан «чүт» итеп үпте һәм колакка: «Аэропортта очрашырбыз»,— диде.
— Шуннан,— дим.
— Шуннанмы? Сабада аэропорт бөтенләй юк бит. Таптырам әле мин аңа Сабаның аэропортын!

## Соңарып йөрүче

Эчүчелекне бетерү турында каты чаралар күрелә башлаган 1985 ел иде. Чаллыда яшәүче язучы Газиз Кашаповларның көмеш туена җыйналдык. Табын күптәннән әзер. Күзебез өстәлгә төшкәләп ала, чөнки ак башлы, үзләре колаклы шешәләр ялтырап утыра. Ә мәҗлес һаман башланмый. Бөтен кеше түземсезлек белән берәүне — бик кирәкле түрәне көтә. Шулай итмичә булмый, дөнья бит...
Чакырылган вакыттан соң, нәкъ сәгать ярым үткәч, хатынын култыклап ишектән килеп тә керде көткән кеше һәм кычкырып та җибәрде:
— Җәмәгать, кичерегез, давайте миңа штрафны!

## Мач килмәү

Ул замандагы ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Земфирә Вәлиева рәислегендә бюро утырышы бара. Нырсы ягыннан килгән яшьләрне комсомолга кабул итәбез. Укучылар беткәч, 25 яшьләр чамасындагы олы гәүдәле керәшен егетенең гаризасын карыйбыз.
— Ник моңарчы комсомолга кермәдең? — дибез.
Ул югалып калмады:
— Мач килмәде,— диде.

## Нәрсә аңларга?

Сабада колакка ныграк Габдерахман исемле бер кеше бар, болай үзе «төшерергә» дә ярата. Бервакыт моны колхоз һәм авыл советы рәисләре бер сәгать алмаш-тилмәш сүккәннән соң: «Аңладыңмы инде»,— дип сораганнар.
Теге, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән, дөм чукракка сабышып:
— Нәрсә аңларга? Сезнең үзара талашып бетергәнегезне түзеп көтеп утырам бит әле,— дигән.

# БЕР ЯЗМА УҢАЕННАН — ИКЕ ХАТ

Исәнмесез, хөрмәтле милләттәшләр! «Казан утлары»ның узган елгы 11 нче санын укыгач та сезнең журналны даими алдырып, укып баруыма сөенеп туя алмадым. Югыйсә кайдан белер идем савыктыручы-табип Рәфыйкъ феномены турында?

Укыйм, укыйм да, бугазга төер утыра, күзләрдән яшь бәреп чыга. Менә бит нинди кешеләр дә бар икән ич дөньяда! Мин укытучы кеше, дәрескә кергәч тә гел аның турында сөйләдем. Коллегаларымда да зур кызыксыну уяттым, ахрысы: күбесе укырга омтылдылар. Уйларым гел шул тирәдә чуала. Рәфыйкъ әфәнде һәм аның булышчылары турында уйлыйм. Ник безнең Себердә дә андый кешеләр юк икән? Мин дә табипнең бер булышчысы булыр идем. Урыс арасында, алар мохитендә яшәгән татарлар, әхлакый яктан, һәрхәлдә, тизрәк бозыла бит.

Әгәр табиплек көченә ия булсам, мин дә иң элек эчүчелекне бетерү өчен (ә Рәфыйкъ әфәнде үз мисалында, гамәлендә һәм дәвалау сеансларында нәкъ шуның өчен көрәшә) тырышыр идем. Мескен балаларга карап, җаным көя-әрни. Анасы да эчә, атасы да сәрхүш. Ә без балалардан белем, тәрбия таләп итәбез. Ул бахырларның исә күбесе юньләп ашамаган да булыр. 20 елдан артык иптәшләр суды рәисе, район судының халык утырышчысы булу дәверендә миңа күп кенә кайгы-хәсрәтле хәлләрне күрергә туры килде. Барысы да — шул эчүчелек аркасында. Моннан утыз еллар чамасы элек мин Тукыз авылына килен булып төшкәндә ике-өч хатын гына эчкәлиләр иде. Алар инде гүр иясе, авыр туфраклары җиңел булсын. Ә хәзер, әйтергә дә оят, киресенчә: нибары дүрт-биш кенә хатын-кыз хәмердән ерак йөри.

Менә шуңа да: һай, тылсымлы көчкә ия булсам, гаиләләрне бәхетле итәр идем, балаларны шатландырыр идем, дип хыялланам-уфтанам.

Хөрмәтле мөхәррир әфәнде, Сездән сорыйбыз: Миңнекәев әфәндене адресын әйтсәгез иде. Без, берничә укытучы, Казанга ничек тә барып кайтыр идек.

Хәреф хаталарым булса, гафу итәрсез. Чөнки мин татарчага үзлегемнән өйрәнгән кеше. Укыганнарым — «Казан утлары», «Сөембикә» журналлары һәм үзебезнең «Яңарыш» газетасы. Әмма үзебезнең себер телендә әшкәрә шәп кәпләшәм.

Барыгызга да исәнлек-саулык, иҗади уңышлар телим.

**Зәйтүнә ӘБҮСӘГЫЙТОВА,**
Россия Федерациясенең атказанган укытучысы.
Түмән өлкәсе, Вагай районы.

* * *

Хөрмәтле редакция!

Мин үзем Башкортстанның Морак авылында яшәүче 73 яшьлек бер пенсионермын. Шунысын әйтергә кирәк, «Казан утлары» журналын күптәннән алдыручы, яратучы, ихтирам итүче һәм дә ышанучы бер укучыгызмын. Чөнки ул күп кенә журналлар арасында зур, югары торучы, дәреслекле, нәфис бер журнал! Соңгы елларда аның әдәби-нәфис сыйфаты һәм эчтәлеге нык яхшырды. Моны берничек тә кире кагып булмый. Бу уңышларда журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның роле дә зур дип исәплим. Журналга, шунда эшләүче коллективыгызга да рәхмәт!

Шулар белән бергә, журнал битләрендә әдәби-нәфис яктан бәхәсле һәм кайтыш язмалар да булгалый. Моны мин М. Муллануровның «Тылсымлы кеше»

дигән басмасын күздә тотып әйтәм. Шундый хөрмәтле журналда, мондый әкиятне дип әйтимме, ничек бастырырга уйладыгыз икән? Хәлбуки, анда язылганнарга ышанучылар бардыр, әмма мин үзем ышана алмадым. Теләгем: фантазия дөньясыннан аерылып, үзебезнең реаль тормышка, чынбарлыкка кайтырсыз, бәлки?

Саулык-яхшылыклар теләп,
**Т. ХӘКИМОВ.**

## АЕРЫЛЫРГА ТЕЛӘМИБЕЗ

Гәрчә үзебез ерак Кыргызстанда яшәсәк тә, Туган җиребез белән матбугат аша бердәнбер кавыштыручы булган, безнең өчен кадерле-газиз саналган «Казан утлары» журналын озак еллардан бирле бик теләп алдырабыз. Чөнки аннан татар дөньясы сулышы бөркелеп тора — җанга җылылык, йөрәккә дәрт-дәрман өсти ул. Соңарып килсә, нык борчылабыз. Чөнки кайбер газета-журналларга «көн бетте» бит. Шәт, 74 еллык бай тарихы булган «Казан утлары»на андый куркыныч янамас, ул чит җирләрдәге кан-кардәшләребезне, милләттәшләребезне дә сөендереп, көннән-көн көчлерәк балкыр, үз тирәсенә җылылыкка, яктылыкка мохтаҗ булган күп меңнәрчә кешеләрне туплар, дигән олы ышанычта калабыз.

«Казан утлары» журналында данлы-гыйбрәтле үткәнебезгә багышланган, бүгенге чынбарлыкны бөтен тулылыгы белән чагылдырырга омтылган кызыклы әсәрләр еш басылып тора. Бер уңайдан, без яшәгән төбәктәге татарлар тормышыннан да язмалар бирсәгез иде. Без — биредә күбәү бит! Соңгы вакытта игълан ителгән мәгълүматлардан күренгәнчә, 1990 елда «Казан утлары»н Кыргызстанда 367 кеше алдырган. Хәзер дә әлеге яраткан журналыбызга язылучылар байтак. Икътисади кыенлыклар «билбауны кыса төшәргә» мәҗбүр итсә дә, без үзебез теләгән рухи азыктан һич тә аерылырга теләмибез. Сез дә, журнал хезмәткәрләре, безнең сүзләргә колак салып, «Казан утлары»н һәрчак үз вакытында чыгарып, меңләгән күңелләрне даими сөендерсәгез иде!..

Сезгә игелекле, бик тә кирәкле хезмәтегездә бетмәс-төкәнмәс уңышлар теләп:

**Рәис МОСТАФИН,**
пенсионер.
Ош шәһәре.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

Татар әдәби хәрәкәтенең үзәк бер мәйданы буларак, редакциябезгә еш кына кунаклар килеп тора. Алар арасында төрле профессия ияләре дә була. Андый очрашуларда, гадәттә, ил язмышы, милләтнең киләчәге, әдәбият мәсьәләләре хакында сөйләшәбез.

Укучыларыбыз игътибарына төрле еллардан алынган ике фотосурәт тәкъдим итәбез.



*Рәсемдә: Башкортстанның халык шагыйре Нәҗәр ага Нәҗми белән очрашудан соң. Утырганнар (уңнан сулга) — журналыбызның ул чактагы баш мөхәррире Ренат Харис, Нәҗәр Нәҗми, Кояш Тимбикова, Рәдиф Гаташ, Рашат Низами, Мәхмүт Хәсәнов, Мәхмүт Хөсәен, Мансур Вәлиев, Рәшит Әхмәтҗанов. Басканнар — Җәүдәт Миңнуллин, Тәүфикъ Әйди, Флүс Латыйфи. 1987 ел, август.*



*Ә монысы «Планетаны яңарту» мәдәни-сәламәтлек үзәк президенты, табиб-экстрасенс **Рәфыйкъ Миңнекәев** белән очрашудан соң төшкән рәсем. 1996, 16 январь.*

Д. Бунтуков фотосы.

***РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР***

### ПРЕЗИДЕНТ АНТ БИРӘ

2 апрельдә Казанда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының пленар сессиясе булды. Ул Татарстан Президенты итеп икенче срокка сайланган Минтимер Шәрип улы Шәймиевның Ант итүенә багышланган иде.

Тантанада Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе В. Черномырдин, Казагыстан Президенты Н. Назарбаев, Башкортостан Президенты М. Рәхимов, Мәскәү шәһәре мэры Ю. Лужков, Казан шәһәре башлыгы К. Исхаков, Украина Хөкүмәтенең беренче вице-премьеры П. Лазаренко, Кыргызстан Хөкүмәтенең беренче вице-премьеры Г. Тогаев, Кабарда-Балкар Республикасы Президенты, РФ Федераль җыелышының Федерация Советы Рәисе урынбасары В. Коков, Свердловск өлкәсе губернаторы Э. Россель, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев һәм күп кенә башка республикалардан, өлкәләрдән, чит илләрдән килгән кунаклар катнашты һәм чыгыш ясадылар.

### ХӨКҮМӘТЕБЕЗНЕҢ ЯҢА СОСТАВЫ

25 апрельдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы пленар сессиясе булды. Анда, нигездә, ТР хөкүмәтенең яңа составы турында эшлекле сөйләшү барды.

Татарстан Республикасының Премьер-министры итеп яңадан Фәрит Мөхәммәтшин, аның урынбасарлары итеп Равил Моратов (беренче урынбасар), Илгиз Хәйруллин, Владимир Швецов, Алла Габетдинова сайланды. ТР Министрлар Кабинеты аппараты җитәкчесе итеп Нәҗип Бакиров, Мәдәният министры итеп Марсель Таишев, Мәгълүмат һәм матбугат министры итеп Ислам Әхмәтҗанов, Мәгариф министры итеп Васыйл Гайфуллин расланды, башка министрлыкларның да җитәкчеләре билгеләнде.

Сессиядә Татарстан хөкүмәтенең яңа составын төзү мәсьәләләре буенча йомгаклау сүзе белән ТР Президенты Минтимер Шәймиев чыгыш ясады.

Депутатлар һәм кунаклар чечен сугышында һәлак булганнарны бер минутлык тынлык белән искә алдылар.

***ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ***

М. Җәлилнең 90 еллыгы уңаеннан, шушы елның февраль ахырында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, академик И. Таһиров, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Р. Фәйзуллин, Казан шәһәре хакимиятенең мәдәният башлыгы Р. Тәхфәтуллин, өлкән журналист-фотограф М. Шакирҗанов Оренбур өлкәсендә булып кайттылар. М. Җәлилгә Оренбур шәһәре үзәгендә салыначак һәйкәлнең нигезенә таш кую тантанасында катнаштылар.

Татарстан делегациясе вәкилләре шулай ук каһарман шагыйрьнең туган төбәге — Шарлык районының Мостафа авылында үткәрелгән бәйрәм очрашуларында катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

### МӘСКӘҮДӘ — «ТАТАР КИТАБЫ КӨННӘРЕ»

10—13 апрель көннәрендә Мәскәүдә, Россия һәм Татарстан Мәдәният министрлыклары тарафыннан, яшьләр өчен махсус рәвештә «Татар китабы көннәре» үткәрелде. Анда Казаннан бер төркем язучылар һәм шагыйрьләр — Р. Харис, Р. Мостафин, Р. Миннуллин, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, артистлар И. Биктаһиров, Л. Шакирҗан, Л. Әхмәтова һ. б. катнашты.

Очрашулар Мәскәү үзәгендәге Россия яшүсмерләр китапханәсендә, ике меңләп татар яшәгән Зеленоград каласында үткәрелде. «Татар китабы: кичә, бүген, иртәгә...» дигән темага эшлекле сөйләшү, «Тарих сәхифәләре буйлап» дигән күргәзмә, Татарстанда нәшер ителгән китаплар, газета-журналлар белән танышу, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең чыгышларын тыңлау күпләгән яшь күңелләрдә зур кызыксыну уятты.

«Татар китабы көннәре» халкыбызны дөньяга танытган каһарман шагыйребез М. Җәлилнең тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

### ЧӘЧӘК КИТЕРӘЛӘР ТУКАЙГА...

Халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тууына 110 ел тулуга багышланган искә алу кичәләре республикабыз башкаласында һәм районнарда зур оешканлык һәм жан-

лылык белән узды. Елдагыча, 26 апрельдә — шагыйрьнең туган көнендә — аның һәйкәле итәгендә Шигърият бәйрәме үткәрелде. Анда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә быел лаек булган яңа лауреатлардан күренекле әдип Г. Бәширов (Казан) белән мәшһүр җырчы Ф. Кудашеваны (Уфа) кайнар котладылар.

28 апрельдә исә Мәскәүнең Россия Язучылары йортында Тукайга багышланган юбилей кичәсе уздырылды.

Май аенда да олуг әдибебезгә багышланган чаралар дәвам итәчәк. 22 майда, мәсәлән, Казанда, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Г. Тукай иҗаты буенча халыкара фәнни конференция үтәчәк. Ул 23 майда тантаналы кичә һәм Татарстан сәнгать осталарының зур концерты белән тәгәлләнәчәк.

24 майда исә юбилейда катнашучыларны һәм ерак-ераклардан килгән мөхтәрәм кунакларны шагыйрьнең туган төбәге — Арча көтә...

## ИБРАҺИМ САЛАХОВ — КАЗАНДА

Ерак Казагыстанның Күкчәтау өлкәсендәге Кызыл Яр авылында гомер кичерүче татар әдибе — Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим ага Салахов быел март — апрель айларында Казанга дәваланырга килгән иде. Шул форсаттан файдаланып, ул әдәбият сөючеләр белән күп кенә очрашулар үткәрде.

Инде мәгълүм булганча, Казандагы Татар яшьләре театры коллективы аның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») дигән роман-хроникасын сәхнәләштергән иде. Аны тамашачы хөкеменә тәгъдим иткән премьерада 85 яшьлек өлкән әдип үзе дә катнашты һәм чыгыш ясады. Аннары ул, шушы әсәре буенча әдәби-документаль фильм төшергән режиссер Фәрит Хәбибуллин белән берлектә, республикабызның Балтач, Арча районнарында булып, укучылар белән очрашты.

23 апрельдә И. Салахов заманында үзе белем алган уку йорты — Казан дәүләт педагогия университеты студентлары һәм укытучылары каршында чыгыш ясады. 26 апрельдә исә ул мәркәзебездә үткән Шигърият бәйрәмендә катнашты.

## ТРОИЦКИДА — ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

Чиләбе өлкәсенең үзәк татар-башкорт китапханәсендә һәм Троицк мәдәният сараенда шагыйрь Басыйр ага Рәфыйковның 75 яшьлек юбилеен билгеләп үттеләр. Тумышы белән Татарстанның Мамадыш шәһәреннән булган әлеге әдип, мөгаллим 50 ел буена диярлек Троицк шәһәрендә балалар укыткан, җиде шигъри җыентыгын чыгарган... Күптән түгел генә Б. Рәфыйков туган ягы Мамадыш районында булып китте һәм район үзәгендәге «Туган як тарихы музее»на яңа чыккан китапларын бүләк итте.

## КАЛӘМДӘШЕБЕЗ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Г. Исхакый исемендәге бүләк лауреаты, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка багышлап, туган ягында — Баулы районында музей ачылды. Казанның Мәүлетов урамында урнашкан 13 нче китапханәдә дә шагыйрьнең туган көне әдәби-музыкаль кичә рәвешендә билгеләп үтелде.

24 апрельдә шундый ук кичә мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда үткәрелде. Анда «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Р. Низамиев һәм бүлек мөхәррире М. Вәлиев катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## «ШИГЪРИЯТ ОСТАХАНӘСЕ»НЕҢ КҮЧМӘ УТЫРЫШЫ

2 апрельдә Татарстан Фәннәр академиясенең һәм Казан дәүләт университетының уртак «Шәкли Фәһем» фәнни-эзләнү лабораториясендә «Шигърият остаханәсе»нең чираттагы күчмә утырышы үткәрелде. Анда компьютерларны татарча сөйләштерә белүче галим һәм шагыйрь Җәүдәт Сөләйманның яңа шигъри җыентыгы тикшерелде. Фикер алышуларда Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев, К. Латыйп, Р. Гаташ, Р. Юныс, Ф. Латыйфи, Р. Якуш, Г. Садә, Р. Зәйдулла, Л. Лерон, Л. Зөлкәрнәй һ. б. катнаштылар.

Һәр ике җыентыкка да, нигездә, уңай бәя бирелде һәм Җ. Сөләйман Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәгъдим ителде.

* * *

Җыр сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен, Чаллы язучылар оешмасының «Карурман» әдәби-музыкаль берләшмәсе солисткасы **Саҗидә Әхмәтсафа кызы Мостафина-Әхмәтгалиева** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Казан. XVI гасыр уртасы.» — рәссам Равил Заһидуллин картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь Шамил Маннапов.

# ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕ ДУСЛАРЫБЫЗ!

Инде Сезгә мәгълүмдер: ошбу елның 1 апреленнән 1996 елның икенче яртыеллыгына (июль — декабрь айлары өчен) «Казан утлары» журналына язылу башланды.

Бу чара Татарстаннан читтәге әбүнәчеләребез өчен — 1 июньгәчә, Җөмһүриятебездә яшәүчеләр өчен 15 июньгәчә дәвам итәчәк.

«Казан утлары»н алдырырга теләүчеләр өчен әзер әбүнә кәгазен тәкъдим итәбез. Аны журнал битеннән пөхтә генә итеп кисеп алырга һәм тәртип белән генә кирәкле графа-бүлемтәләрен тутырырга, аннары элемтә (почта) бүлекчәсенә тапшырырга кирәк.

Журналыбызның әбүнәчеләр өчен ярты еллык бәһасе — 13 мең 200 сум, ягъни 192 битлек һәр китабы (бер саны) 2 мең 200 сум тора.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
"Союзпечать"

**АБОНЕМЕНТ на** газету / журнал — 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания) — Количество комплектов:

на 1996 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

---

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на газету / журнал — 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Кол-во комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на 1996 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

Республикабызда чыга торган башка басмалар белән чагыштырганда, шактый арзан бәя бу. Әгәр инде «Казан утлары»на язылasыгыз икән, без Сезне 1996 елның икенче яртыеллыгында берсеннән-берсе мавыктыргыч роман-повестьлар, хикәя-новеллалар, шигырь-поэмалар, халкыбыз тарихына һәм мәдәниятенә караган кызыклы язмалар белән сөендербез, иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздагы яңалыклар, яңа китаплар белән таныштырырбыз!

**Журналыбызның индексы — 73210.**

Ул Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән, Татарстан һәм Россия күләмендә чыгарылган каталогларга кертелгән.

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

---

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки "ПВ-МЕСТО" производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Татарское отделение "Росбланкиздат". 1/24/112/. 02.95 г. т. 350000 Асбест. тип. З. 641.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. **Татар шәҗәрәләре** (беренче китап). Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995 ел. 128 бит. Тиражы — 5000 данә.




Шәҗәрә нәрсә дигән сүз? Бүгенге татар әдәби телендә бу сүзнең төп мәгънәсе — нәсел-ыру тарихы дигән тәгъбиргә туры килә.

Мөселман-ислам дөньясы борын-борыннан үзенең мәдәни-рухи системасына шәҗәрәләр белүне керткән. Һәр мөселман үзенең әти-әнисе ягыннан бабалары исемнәрен җиде буынга кадәр белеп, алар рухына дога укырга тиеш була.

Китапка беренче мәртәбә зур гыйльми һәм этнографик әһәмияткә ия булган татар шәҗәрәләре тупланган. Мәсәлән, Идегәй, Чабынчы, Таҗетдин бине Ялчыгол, Шәех Дирбеш, Акчурин, Яуш, Мәмәт, Надир Уразмәт һ. б. шәҗәрәләре. Аларга әтрафлы тарихи һәм гыйльми аңлатмалар бирелгән.

Флера БАЯЗИТОВА. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995, 160 бит. Тиражы — 10 000 данә.

Борынгылардан килгән йолаларыбыз инде онытыла, юкка чыга баралар дип әйткәләсәк тә, әле халкыбызның хәтерендә, бигрәк тә өлкән буын кешеләренең күңелендә бик күп истәлекләр, тел һәм рухи байлыгыбыз саклана. Ерак араларга, күз төбәп җитмәслек җирләргә сибелеп утырган татар халкының төрле төбәкләреннән җыелган мәгълүматлар тупланган бу хезмәткә. Китапта бирелгән бүлек исемнәренә генә игътибар итик: сабан боткасы, яңгыр намазы, өмет корбаны, нәзер-ният, яфрак бәйрәме, аулак өйләрутырмалар, каз өмәсе һ. б.

Бу хикмәтле китапка кергән бөтен язмалар халкыбыз йолаларын яхшы белгән осталар авызыннан язып алынган булулары белән кызыклы һәм әһәмиятле.



Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)